ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2000



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



Tatarstan yazuçılar berlege rəise **Foat Ğalimullin** Tərkiədə.
*İstanbul, may, 2000 yıl.*



Yazuçı **Rafael' Mostafin** kongress baqçasında, V'etnamda həlak bulğan soldatlarğa quyılgan həykəl yanında. *AQŞ, Vaşington.*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2000*

# 7

**(933)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Тулгак. *Повесть* ..... 5
Әхмәт ГАДЕЛ. Күтәрелә безнең күңелдән ай. *Шигырьләр* ..... 72
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Шул көннәрдән тәсбих тезәмен. *Шигырьләр* ..... 82
Луиза ЯНСУАР. Яфрак ярам, кошка әвереләм... *Шигырьләр* ..... 87

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

НУРЗИЛӘ. Хикәяләр ..... 75

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Гариф ГАЛИЕВ. Каракош сыртында ..... 89

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Факил САФИН. Җаек буе—яу җире ..... 94

**ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ**

Әдхәт СИНУГЫЛ. Адам Мицкевичның «Кырым сонетлары» ..... 119
Адам МИЦКЕВИЧ. Кырым сонетлары ..... 122

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рифат СВЕРИГИН. Үткән ел прозасына бер караш ..... 131
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. «Безне кемнәр аңлар?» *(Рецензияләр конкурсына)* ..... 139

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

Мирза МӘХМҮТОВ. Коръәнне тәрҗемәсез укып буламы? ..... 145

**ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Марс ШАБАЕВ. Анын кулы җылы иде... ..... 157

**СӘНГАТЬ**

Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Талант һәм тыйнаклык ..... 171

**КИТАП КУЗӘТҮ**

Шамил МАННАПОВ. Монга әверелгән гомер ..... 175

**ХӘТЕР**

Шамил ӘХТӘМОВ. Дәһшәтле көннәрдә ..... 179

**ФӘН**

Рөстәм НӘБИЕВ. Монгол яуларына тагын бер караш ..... 182

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Г. ГАЛИЕВОЙ «Схватки»; стихи А. АДИЛЯ, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Л. ЯНСУАР.
«Новые имена»: НУРЗИЛЯ. Рассказы.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: Г. ГАЛИЕВ «На хребте орла».
«Публицистика»: историко-публицистическая статья Ф. САФИНА «Край Яицкий - поле брани».
«Образцы мировой литературы»: «Крымские сонеты» А. МИЦКЕВИЧА.
«Литературная критика»: Р. СВЕРИГИН. «Взгляд на прозу прошлого года».
«На конкурс рецензий»: Р. ШАРАФИЕВ рецензирует книгу И. Юзеева.
«Жизнь и религия»: М. МАХМУТОВ. «Можно ли читать Коран без перевода?»
«К 100 - летию Хасана Туфана»: М. ШАБАЕВ. «Аксакал татарской поэзии».
«Искусство»: статья К. МИННИБАЕВА «Талант и скромность».
«Книжное обозрение»: Ш. МАННАПОВ рецензирует книгу Р. Фаттахова «Рашит Вагапов».
«Память»: Ш. АХТЯМОВ. «В грозные дни».
«Наука»: Р. НАБИЕВ. «Еще один взгляд на монгольское нашествие».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Лето— фотоэтюд, писатель Л. Лерон.

## IN OUR ISSUE:

"Prose and poetry": G. GALIEVA'S novel «The labour»; verses of A.ADIL, F. GIZZATULLINA, L. YANSUAR.
"New names": NURZILA'S stories.
"From treasure of Tatar stories": G. Galiev «On eagle's bask».
"Journalism": Saphin's article «Yaisk land - the field of battle».
"World literature": A. Miskevich «Crimea sonatas».
"Literary criticism": R. SVERIGIN «The view of last year prose».
"Review competition": R. SHARAFIEV'S review of I. Useev's book.
"Life and religion": M. MAKHMUTOV «Can we read Koran without translation?».
"Commemorating the 100 th anniversary of Hasan Tufan": M. SHABAEV «Connoisseur of Tatar poetry».
"Art": K. MINNIBAEV'S article «The talent and modesty».
"Book review": Sh. MANNAPOV'S review of R. Fattahov's book «Rashit Vahapov».
"Our calendar".
The diary of social and cultural life.
In our covers: Summer -photosketch, writer L. Leron.

*The magazin edits monthly*

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 15.06.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-253
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс басмаханәсе».
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.



**Гөлчәчәк Галиева**

# ТУЛГАК

ПОВЕСТЬ

*Бик тә кыска вакыт бирелгән бит,*
*Җирдә һәрбер адәм баласына.*
*Гөлләр генә түшәп китсәк иде,*
*Яшәү белән үлем арасына.*

Фәнис Яруллин.

Район үзәгендәге хастаханә янына яңа тарантаска җигелгән кара айгыр килеп туктады. Тарантастан горур кыяфәтле мәһабәт ир сикереп төште һәм йомшак печән түшәлгән тарантаста ярым ятып торучы ханымны иплəп күтәреп җиргә бастырды. Хатынның чыраена авырту, газаплану билгеләре чыкса да, аның йөзеннән һәм дә киеменнән зыялы зат икәнлеге сизелеп тора. Ул иргә яратып карады да болай дип пышылдады: «Җибәр, Самат, үзем керәм, үзем...»

Самат исә хатынын хастаханәнең бала тудыру бүлегенә култыклап алып барды. Ирнең һәр хәрәкәте кадерле кешесенә мөмкин булганның барысын да эшләргә әзер торуын күрсәтә иде.

Бала тудыру бүлегендә төне буе ут сүнмәде. Ире Самат караватка кертеп салуга ук Саимәне тулгак тота башлады. Саимә әле тулгакның ни-нәмәрсә икәнен белми иде, шуна күрә ул, авырту китереп кысуга, үләм ахры, дип уйлады, сабырсызланды, бәргәләнде, «Самат, Самат!» дип кычкырды. Хәтта бер мәлне күз аллары караңгыланып, түшәм чайкалып киткәндәй булды. Бераздан аның газаплары саташуга әверелде. Гүяки якты кояш әкрен-әкрен сүнде дә тау түбәсенә төшеп утырды. Аннары, олы ташка әйләнеп, түбәнгә тәгәрәде. Ул Саимәгә якыная барды. Саимә читкә тайпылырга теләде—аяклары тыңламады, кычкырмак-

---

ГАЛИЕВА Гөлчәчәк Кәрим кызы — *Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлагач башкалабыз мәктәпләрендә тарих укытучысы һәм мәктәп директоры булып эшли. Тәрбия темасына кагылышлы мәкаләләре белән вакытлы матбугатта даими катнашып килә. Казанда яши.*

чы иде—тавышы чыкмады. Ниһаять, түбәнгәрәк тәгәрәгән саен тизлеген арттыра баручы таш Саимәнең күкрәгенә төшеп кунды. Саимәнең тын алуы авырайды, йөрәк тибеше ешайды. Табиб һәм шәфкать туташлары аның янында мәш килде, ләкин Саимә аларның хәтта берсен дә күрмәде.

Күзләрен ачып җибәргәч иң беренче Саимәнең күзенә чалынган нәрсә—палата түшәмендәге ярык булды. Аннары гына карашы караваты янындагы табибка һәм шәфкать туташларына төште.

—Куркыттың бит,—диде бер ак шәүлә. Саимә, гаепле баладай, елмайгандай итте. Һәммәсе җинел сулап куйды. Авырту кинәт басылгач, Саимәгә палатадагы ярык түшәм дә, янындагы ак халатлы кешеләр дә, буяуларын кояш ашаган тәрәзә рамнары да матур булып күренде. Әйтерсең, янгырдан соң яктырып кояш чыгып, офыкта салават күперен калкытты. Шушы күпер буйлап ул татлы хыял дөньясына кереп чумды.

Менә ул—нәни кыз офыкка таба йөгерә. Офыклар читенә барып җитеп югарыга үрмәләргә ниятли. Әмма офык, ул алга барган саен ерагая. Күк йөзен әллә кара болыт каплый, әллә яшен кылычлары телгәли. Болытлар таралган арада балачакның гүзәл мизгелләре чагылып үтсә, башы өстендә төннең кара кошы канатларын җәйгәндә исә тормышта тотка таба алмыйча бәргәләнүләре, сугыш чорында бер сынык икмәккә тилмерүе исенә төшә.

Саимәнең хәтере балачакның тирән упкыннарын сикереп үтәргә тырыша. Аның иң матур хыяллары Самат белән бәйләнгән. Самат аның үткәннәрдән килгән күңел төбендәге бушлыгын тутырып торучы да, киләчәккә илтүче якты өмет тә бит. Менә ул Саматка тупырдап торган малай алып кайтып бирер. Бу малайны алар өч ел буе көттеләр. Бу өч ел Саимәгә бөтен бер гомердән дә озынрак булып тоела башлаган иде инде. Хәзер, Ходайга шөкер, өметсезлеккә төшеп бәргәләнүләр, балалы хатыннарга көнләшеп караулар, ә иң җанына тигәне—Фәридәнең төрле сүз ишеттерүләре—һәммәсе артта калачак. Самат та «хатының кысырмы әллә?» дигән мыскыллы сораулардан котылачак.

Ә бит Саимәне сөйгәне Саматка илтүче юллар шактый катлаулы да, бормалы да иде.

Аңа олы мәхәббәтне язмыш дигәнең җан газапларына төреп бирде.

Каенлы авылы урта мәктәбенә химия укытырга килгәч, Саимә мәктәпкә, авыл кешеләренә тиз иялънде, аның үзен дә ихластан үз иттеләр. Фатир хуҗасы—тол хатын Хәдичә дә бу ягымлы кызны үз туганыдай якын күрде.

Беркөнне мәктәп директоры Мансур ага:

—Шимбә, якшәмбе көннәрендә колхозга бәрәңге алышырга чыгабыз. Һәр сыйныф житәкчесе үз укучылары белән булырга тиеш,—диде.

Алтын көзнең юмарт кояш нурларына төренгән бик матур көне иде бу. Саимә иртүк торып тиз-тиз генә чәй эчте дә ашыгып урамга чыкты. Чиләк күтәргән укучылары аны шунда көтәләр иде инде.

—Саимә апа, сез дә чиләк алыгыз, бездә эшкә һәркем үз коралы белән бара,—диде берсе.

Саимә ишегалдына кереп, рәшәткә башыннан чиләк алды.

Шау-гөр килеп бәрәңге чүпләп йөргәндә, болар янына бер ир егет килеп туктады. Барына да ачык кына сәлам бирде. Шунда бер чая кыз:

—Самат абый, әйдәгез, безнең янда гына калыгыз. Сезнең ярдәм белән үзебезгә бирелгән өлешне тизрәк бетерер идек. Сез, Саимә апа белән бер чиләккә чүпләсәгез дә ярый,—диде дә пырхылдап көлеп җибәрде, бу көлүгә башкалар да кушылды. Самат та шаярып:

—Сезнең янда калырга була. Кызлар янында бәрәңге чүпләү—болында чәчәк җыю белән бер,—дип җавап бирде.

Аның сүзләреннән тагын көлешеп алдылар. Ә Самат исә сиздермичә генә Саимәгә карады. Чибәр туташ икән бит ул! Ничек моңарчы күрмәгән соң Самат аны?! Күзләре серле, бик тә серле. Керфек араларыннан саркып чыккан сихри нурлар кызның йөзен яктыртып җанны ымсындыра.

Якыннанрак танышасы иде бит чибәркәй белән. Ләкин ничек? Саимә башкалардан арттарак калган мизгелне тотып Самат:

—Иртәгә клубта кино булачак, килерсезме? Бик тә фаҗигале мәхәббәт турында, диләр, килегез яме. Мин сезне көтәрмен,—диде дә, кызның күзләренә туп-туры карап, серле генә елмайды.

Һич тә көтелмәгән бу хәлдән Саимә каушап калды. Ике битен рәхәт ялкын кыздырып алды: кызарды, кинәт кенә каш-ирен өсләренә тир бәреп чыкты. Бу каушаудан кызның тагын да чибәрләнеп китүен Самат та сизде. Ул кызлар белән мөгамәләдә инде шактый тәҗрибәле, утызы үтеп бара торган, таза гәүдәле, чибәр, өстәвенә, җырчы һәм гармунчы булуы белән күп кызларны үзенә гашыйк итәрдәй егет иде.

Саимә дә керфек арасыннан гына карап егетне күзәткән икән. Саматның гап-гади сүзләр белән киногa чакыруы аны әллә нишләтте. Гаҗәп, кыска гына шушы мәлдә үзенә якын, кадерле булып өлгергән егеткә озаклап-озаклап карыйсы килде аның. Ләкин дистәләгән күзләрнең үзенә сынаулы карашларын тоеп, айнып киткәндәй булды. Саматның кем, нинди кеше булуы турында бик сорашырга теләсә дә тыелып калды. Чөнки балалар күнеленең сизгер икәнен бик төпченсәң иртәгесен үк мәктәптә төрле сүзләр таралачагын яхшы аңлый иде. Аның уйлары гел Самат тирәсендә әйләнде. Бирсә дә бирер икән Ходай: куе зәңгәр күзләр, сөрмәле озын керфекләр дисеңме, маңгаенның уң як почмагына дулкынланып төшкән коңгырт чәчләре дисеңме, елмаеп җибәргәндә бит урталарының бераз гына батып китүе дисеңме! Ә тешләре тезелеп киткән эрерәк энҗеләр шикелле җем-җем итеп тора. Гәүдәсе баһадирларныкына охшаган, адымнары нык лы... Кыз үзе дә тәскә-биткә чибәр, буйга зифа булса да, бу минутларда Саматны үзеннән өстен санап көнләшеп куйды: «Ходаем ла, ниләргә генә дип ир кешегә матурлыкны шулай үлчәмичә бирден?»—дип аптырады ул. Әмма егетне күңеленнән куып җибәрә алмады.

Мондый халәтнең булганын хәтерләмәгән Саимә: «Хәерлегә генә булсын инде! Бер күрүдә үлеп гашыйк булу дигәннәре шушымы әллә? Алай дисәң, мин бит яшь җилбәзәк түгел, егерме алты яшемдә ләбаса. Бөтен дөньямны онытып гашыйк булу чоры, офтансаң-офтанмасаң да, узып киттеләр»,—дип уйлады.

Институт елларында авыру әнисен караудан калган вакытын, укуына зарар китермим, дип, китапларга ябышып үткәрде. Күңел ачуларга, төрле кичәләргә йөрергә вакыты җитмәде. Курсташ егетләр аның артыннан йөреп карыйлар иде дә, кызның өй мәшәкатьләреннән арына алмавын күреп, мәхәббәтләрен башка кызларга күчерәләр иде. Яшьлекнең иң матур көннәрендә аның йөрәгендәге ярсулыкны әнә шулай сабырлык алыштырды.

Беренче елларда эшләгән авылындагы мәктәптә укытучылар барысы да диярлек хатын-кызлар булып, ирләрдән фәкать мәктәп директоры, бер аягын сугышта югалткан, алты бала атасы Хөсәен абый, пенсия яшенә якынаеп килүче, юморга бай татар теле укытучысы Гомәр абый гына иде. Тәскә-биткә чибәр, зифа буйлы, шәһәрчә киенгән Саимәне беренче тапкыр күргәч Гомәр абый:

—Сөбханалла! Син безнең мәктәптә бик озакламассыңдыр. Моннан тизрәк очып китү ягын карарсың. Аккош белән йорт казы парлаша алмый, авылыбызда сиңа яр булырлык егет табылырмы икән, ай-һай?!—дигән иде.

Чыннан да ул авылда дүрт ел эшләү дәверендә аңа гаилә кору бәхете насыйп булмады. Дөрес, кичләрен клубтан озата кайтучылар, мәхәббәтләрен белдерүчеләр табылып торды. Әмма кыз әлеге егетләрне тиң күрмәдеме, мәхәббәт ялкынына уралып китә алмады. Ул елларда укучылар саны ел саен кими бару сәбәпле химия-биология сәгатьләре азайды. Бу фәннәрне укытучы ике кешенең берсенә мәктәпне калдырырга кирәк булды. Көчле укытучы саналса да, кыскартылу афәтенә Саимә эләкте. Ләкин ул моңа борчылмады, мәктәп һәм авыл белән җиңел генә

саубуллашып китте дә барды. Яңа уку елы башланыр алдыннан гына аны мәгариф министрлыгы әлеге Каенлы урта мәктәбенә җибәрде.

Саимә кич җитүен түземсезлек белән көтеп алды. Тизрәк кайтып, Хәдичә ападан Самат турында бәйнә-бәйнә сорашасы килә иде аның. Кайтышлый киногa чакыручы чибәр егет очрамасмы дигән өмет җанын җилкетте. Әмма ишегалдына керүгә Хәдичә апа:

—Кызым, казанга бәрәңге салганыем, учакны гына ягып җибәр әле. Мин көтү каршылыйм,—дип эш кушты.

Кая инде Самат турында сорашу... Ул арада көтү дә кайтып житте.

Хәдичә малларын абзарга ябып, сыерын савып өйгә керде. Ул иң элек пешкән бәрәңгенең тәмле исен тоеп:

—Алланың биргәненә шөкер! Уңган кыз икәнсең, эшләрем бетте, хәзер тәмләп кенә бәрәңге ашарбыз, чәен дә эчәрбез,—дип аш бүлмәсенә үтте. Әмма, бәрәңге казанда гөбер-гөбер кайнап, таралып беткән, ә Саимә күренми иде.

—Һай Алла! Балакай, син кайда? Сиңа ышанып мин өйгә кереп тормадым, бәрәңге изелеп беткән, самавыр да куймагансың, әллә басудан чирләп кайттыңмы?—дип сөйләнә-сөйләнә олы якка чыкты.

Бу тавыштан Саимә сискәнеп китте, уңайсызланып:

—Хәдичә апа, җаным! Онытып җибәргәнмен бит, кичә юган керләрне үтүкләп алыйм дигән идем, вакытның узганын да сизмәгәнмен,—дигән булды.

Чынында исә, иртәгесен киногa барганда ничегрәк киенергә икән, дип киемнәрен барлаганда, янадан Самат турында уйлана башлап, бөтен дөньясын оныткан иде. Күңеленнән: «Ни булды соң миңа? Ул бит мине бары киногa гына чакырды. Рәтләп карамады да. Хәер, карады. Ничек кенә карады әле! Аның карашы кайнар су белән коендыргандай итте. Әле дә бөтен тәнем кызыша. Йә, Ходай, беркайчан да мондый хәлгә төшкәнем юк иде бит, хәерлегә була күрсен»,—дип уйлап аш бүлмәсенә ашыкты. Хәдичә апа бәрәңгене сөзеп алды, Саимә самавыр куйды.

Инде ашарга утырабыз, менә шунда иркенләп сөйләшербез, дип торганда, күрше Хәбирә керде, кыстауны да көтмичә өстәл янына килеп тә утырды. Бәрәңге каба-кабышына:

—Абау жаным, кайсыгыз пешерде моны, бигрәк тә тозлы булган ич, житмәсә изелеп беткән. Әллә икәүләшеп гашыйк булдыгызмы?..—дип әйтеп куйды. Саимә комач кебек кызарды. Менә шуннан соң Самат турында сорашу мөмкин түгел иде инде.

Бәрәңгене сөт белән кушып ашагач, тозлылыгы әлләни сизелмәде тагын. Тик Саимә генә ашар-ашамас утырды. Хәбирә чәй эчәргә калып тормады, өйдә балалар үзләре генә, дип амин тотып, рәхмәтен укый-укый чыгып та китте. Инде Самат турында сорашырга дип Саимәнең авызын ачуы булды, тагын кемдер ишек шакыды. Йә, Хода! Нинди тынгысыз кич булды бу. Һич кенә сөйләшергә форсат юк, дип күнелсезләнде Саимә. Шөкер, ишек шакучы сүзен кыска тотты, Хәдичә апасына иртәгә көтү чиратына чыгарга кирәклекне әйтергә кергән малай икән ул.

Менә тын бүлмәдә икәү генә калдылар, Саимә үзен тыныч тотарга тырышып:

—Хәдичә апа, сезнең авылда Самат дигән кеше кем ул?—дип сорады.

Сүзләренә битарафлык бирергә тырышса да, Саимәнең тавышы барыбер калтыранды, тамырлары буйлап аккан кайнар дулкынны йөгәнләрлек көче юк иде аның.

—Беләм, балакаем, ник белмәскә. Ә сиңа нигә кирәк булды әле ул? Басуда күрдеңме әллә? Аптыраган идем аны, нәрсә булган безнен Саимәгә, дип. Ни эшеннен, ни ашавынның рәте булмады. Тәгаен генә күңелен төшкәндер әле шул мут егеткә. Безнең агроном ул. Тау ягыннан икән үзе, институт бетергәч, безгә җибәргәннәр. Аңа бер күрүдә гашыйк булган кызларның чуты юк. Әле ул, үзәкләрне өзәрлек итеп гармун уйный башласа, гармунына кушылып җырлап та җибәрсә, егыл да кит

менә. Кызларның гына түгел, кайбер ирле хатыннарның да төн йокыларын алды булса кирәк ул шайтан. Болай үзе азып-тузып йөргәнгә охшамаган. Инде менә бер елдан артык хисапчы Фәридә белән чуала икән, дип сөйлиләр. Янында кунгалап та чыга икән, дигән сүзләр дә бар. Белмәссең яшьләрнекен, тик нишләптер өйләнергә исәбе барга ошамаган. Инде яше дә утыз тирәсендә булса кирәк,—дип тезеп китте Хәдичә апа.

Тик Фәриданен кемлеге турында берни әйтмәде. Саимәнең исә төпченергә кыюлыгы житмәде. Әмма бер сорау жанына тынгылык бирмәде. Яратамы икән ул Фәридәне? Яратадыр. Яратмаса, ел буена аның белән йөрмәс иде, ә яратса, нигә алайса мине кинога чакырды? Ул мине бөтенләй белми бит...

Саматның басуда әйткән сүзләре Саимәнең төн йокысын да алды. Әйләнде-тулганды, тәрәзә челтәре аркылы кергән ай нурларыннан качып та карады, барыбер күзенә йокы кермәде. Таң нурлары аның керфекләренә килеп сарылгач кына күзләренә йокы рәшәсе тулды һәм, ниһаять, изрәп йоклап китте. Әмма тиздән сәер төшеннән сискәнеп уянды.

Менә ул кояш жылысыннан иркәләнеп ян тәрәзә янында утыра икән. Кинәт кенә көчле жил чыкты да зур капканы шыгырдатып ачып жибәрде. Озын яллы акбүз ат ишегалдына кешнәп чабып керде дә Саимә каршына килеп туктады. Һәм ат, телгә килеп, кызга эндәште:

—Атлан мина, ялыма ныклап ябыш, төшеп кала күрмә—бөтен көченә тотын. Безнең юлыбыз хәтәр: алда текә борылышлар, үрләр, упкыннар, карурманнар һәм елга-дингезләр бар.

—Минем атка атланганым юк бит... Шәһәр кызы ич мин.

—Язмышын авылга язылса, атка атланырга өйрәнерсен!

—Юк, юк, мин куркам!

—Курыкма, ялларыма тотын,—диде ат һәм кыз алдында башын иде, тик Саимә атның ефәк сыман ялларына ябышыйм, дигәндә, кинәт уянып китте.

Иртәнге чәйне эчкәндә Хәдичә апасына күргән төшен сөйләде кыз.

—И, балакаем, төштә ат күрсәң, ул ир-атны белдерә. Кияүгә үк чыгарсың, дип әйтә алмыйм, шулай да бу синең өчен бик матур төш,—дип аңлатты Хәдичә апасы.

Сабырсызланып көткән кич житте. Саимә, тыйнак һәм килешле киенеп, ашыкмыйча гына клубка китте. Клуб тирәсендә бала-чаганың гөж килүен һәм бер читтәрәк егетләрнең гәпләшеп торуларын күргәч, күңеленә ашкыну дулкыны бәреп кергәндәй булды. «Самат та шулар арасындадыр»,—дип уйлады. Шунда икән шул, ул Саимәне күрүгә үк төркемнән аерылып, аның каршына атлады.

—Инде килмисең икән дип курыккан идем, тагын биш минуттан килеп житмәсәң, өегезгә барып алырга иде исәп,—дип дулкынлануын яшермәде егет.

—Алайса юкка ашыкканмын. Акбүз атым үзе яныма киләсе булган икән...

Самат кызның тел төбенә төшенеп житмәсә дә, моны ачыклап торасы итмәде.

Алар клубка кергәндә, буш урыннар инде калмаган иде. Көтмәгәндә зал уртасыннан:

—Самат, мин монда, сиңа урын алдым,—дигән тавыш ишетелде.

Саимә егетне чакыручының Фәридә икәнлеген бөтен күңеле белән тойды. Ләкин күңелендәге кайнарлыкны сиздермәскә тырышты. Шулай да Саматка сынаулы караш ташлады. Нәкъ шул чакта кырыйда утыручы ике яшүсмер урыннарыннан торды:

—Саимә апа, Самат абый, менә монда утырыгыз,—диде берсе. Саимә аларның тугызынчы сыйныф укучылары булуын шәйләп алды.

Ут сүнде, фильм башланып китте. Бик мавыктыргыч бер урында, ягъни егетнең түземсезлек белән кызны кочаклап алган вакытында, Самат

та Саимәнең кулына үзенең кулын салды. Саимәнең йөрәге уч төбенә төшкәндәй леп-леп типте. Йөрәге тибеше Саматка да ишетеләдер һәм жаны тирбәлеше егетнең тамырларына күчәдер кебек тоелды. Ул бөтен тәненең кызышуын сизде. Нишләргә? Үзенне ничек тотарга? Кулын сак кына алып куяргамы? Нинди дер сәер, моңарчы кичерелмәгән халәт кызның күңелен күкләргә күтәрде. Шулай да Саимә үзендә көч табып:

—Укучылар күрер, яхшы түгел,—дип Саматның кулын йомшак кына этеп куйды.

Кызның бу хәрәкәтенә егет ризасызлык күрсәтмичә буйсынды, теләсә дә, бу хәрәкәтен кабатламады. Тик кино бетәр алдыннан кызның колагына:

—Кинодан соң төрле уеннар була, калырбыз, яме,—дип пышылдады. Кино бетүгә егетләр эскәмияләрне тиз генә жыеп алдылар. Гармунчы бию көе уйный башлауга уртага бер кыз чыгып бөтерелеп биеп китте. Матур, бик матур бии, каһәр! Саимә анын кем икәнлеген шунда ук сизде. Бераз биегәч, кыз Самат каршына килеп басып, ана кулларын сузды. Егет ялындырып тормады. Фәридәнең кулыннан жайлы гына тотып биергә чыкты. Бик матур итеп, парлап озак биеделәр. Әллә Саимәгә генә шулай озак тоелдымы? Бу минутларда анын клубтан чыгып йөгерәсе килде. Ләкин нинди дер көч аны идәнгә кадаклап куйгандай, бер урында тотты. Самат, биеп туктагач, Саимә янына килсә дә, никтер аны биергә чакырмады. Биюче парлар күп булды, әмма Самат белән Фәридә кебек жинел һәм килешле бию башка кабатланмады. Биюләрдән соң бер житез кыз:

—Әйдәгез, жыр багышлаулы уйныйбыз,—дип уртага бер пар сайлап чыгарды, калган яшьләрне түгәрәккә жыйнады.

Аннары тагын бер пар сайлап алды һәм аларга уртадагы парга багышлап жыр жырларга кушты. Жырны башлап жибәрүгә яшьләр аны күтәреп алды:

Быел-быел дигәнең,
Быелгы ел көйгәнең;
Янмас идең, көймәс идең,
Уртак диләр сөйгәнең.

Саимә күршесеннән:

—Нигә мондый жыр жырладылар?—дип сорады.

—Кызның тагын икенче егете бар...

Саимә бу уенны белми иде. Уртага янә бер парны чыгардылар. Боларына нинди жыр булыр икән...

Сөям дә дисең икән,
Сөймим дә дисең икән.
Ә шулай да быел көзгә
Өйләнәм дисең икән.

Мондый жырны да Саимәнең ишеткәне юк иде. Бәлки, һәр авылның үз жырлары, үз уеннары бардыр. Ә, бәлки, бу жырлар шушындый уеннар вакытында туадыр. Бөек Тукай юкка гына: «Халык әдип ул, шагыйрь ул,—димәгәндер. Ә халыкның төп тамыры авылда бит.

Саимә күңеленнән шундый уйлар үтте. Берничә пардан соң уртага Фәридә белән Саматны чакырдылар. Уенны алып баручы кыз аларга багышлап жырлау өчен, юри булса кирәк, Саимә белән Рашат дигән егетне сайлады. Рашат Саимәнең колагына:

И икегез, икегез,
Икегезнең битегез;
Икегез дә пар килгәнсез,
Парлар булып, ярлар булып
Тигез гомер итегез—дип, жырлыйк,—

дип пышылдады.

Саимә Самат белән Фәридәгә мондый җыр багышларга теләми иде. Ул күпмедер вакытка югалып калды. Ләкин аңа каушап калырга ярамый. Аны сынийлар. Самат та анарга өметле караш ташлап ала.

Ниһаять, Саимә киеренке халәттән чыгу юлын тапты. Ул гармунчыга борылып:

—«Гөлҗамал» көен уйный беләсезме?—диде.

—Башлап җибәрсәгез, артыгыздан иярермен.

Саимә искиткеч моңлы тавышы белән акрын гына җыр башлады:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энҗе-мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Бу тавыш, бу моң әле генә дәртләнеп уйнаган яшьләрнең күңелләренә сагышлы яктылык булып үтеп керде һәм йомшак, рәхәт дулкында тирбәтә башлады. Клубтагылар тынсыз калды. Хәтта бер читтә шап-шоп домино, шашка уйнаучылар да җырны онытылып, ләззәтләнеп тыңладылар. Саимә шул бер куплет белән туктап калмакчы иде, кая ул! «Тагын, тагын җырла!»—дип кычкырдылар.

Кайсы гына егеткә барырбыз дип, Гөлҗамал,
Колактан-колакларга кызлар сөйлиләр...

Җыр тукталгач яшьләр күпмедер вакыт бу җанга якын тавышның рәхәтлегенә бирелеп, аңга килә алмый тордылар. Бераздан гына шаулатып кул чабарга тотындылар. «Менә ичмаса җырчы! Булса да булыр икән моң! Нигә җырчы гына булып китмәгән бу?»—диештеләр. Самат утырган җиреннән торып Саимә янына килде һәм бик хисләнеп аның кулын кысты.

—Җырың белән җанны айкадың, Саимә. Рәхмәт!—диде.

Әлеге минутларда Фәридәнең ни хәлдә булуын берәү дә күрмәде, барысының да карашы Саимә белән Саматта иде.

Күңел ярларына сыеша алмыйча агылган җырдан соң яңадан дәртле уенга күчү мөмкин түгел иде инде, чөнки Саимәнең тавышы әле һаман, күзгә күренмәс дулкыннар аша күңелдән күңелгә күчеп, йөрәк кылларын тирбәтә иде. Саимә, эчке бер сизенү белән, үзенең җиңү ялавын аңлады. Саматның һаман кулларыннан тотып торуы, өметләндергеч карашы, йөзенә бәреп чыккан соклануы Саимә өчен һәр нәрсәдән кадерле бүләк иде.

Ләкин мондый халәттә озак калырга ярамый. Беренчедән, һәммәсенең карашы Самат белән Саимәгә текәлгән, икенчедән, берәр көтелмәгән хәл килеп чыгып, тылсымлы тәэсир көченең югалуы мөмкин. Шуңа күрә Саимә үз уңышыннан тизрәк аерылырга тырышып:

—Миңа кайтырга вакыт, иртәгә тагын басуга чыгасы бар,—дип урыныннан кузгалды.

Үзенә сиздермичә генә Саматка карады: егет монда калырмы, ана ияреме? Әле бит клубта уеннар бетмәгән. Каяндыр читтән Фәридә дә Саматны күзәтә кебек, Саимәгә шулай тоелды.

—Әйдә, озатып куям. Йә безнең авыл егетләре урлап китәрләр үзеңне, Хәдичә апа кулына тапшырмасам, үзем дә тыныч булмам,—дигән булып, Самат аны култыклап алгач, кыз җиңел сулап куйды. Алар клубтан чыгып киткәндә Фәридәнең күзләрен тутырып карап калуын күреп, Саимә бераз уңайсызланды. Башка берәүне бәхетсез итү бәрабәренә җиңү ялавы җанын чеметкәндәй булды. Фәридә үзенең халәтен кешеләрдән яшереп маташмады. Ялкын кабынган йөзен яулыгы белән җилләтә-җилләтә клубтан чыгып китте. Чыгуга, көчкә генә тыеп торган күз яшьләренә чикләнмәгән ирек бирде һәм сабыйларча үксеп елап җибәрде. Өенә кайтып җиткәч тә озак кына кермичә торды. Әнисен борчырга теләмәде. Үзенә-үзе никадәр кызганыч булса да, Саматны гаепли алмады. Саматка артык җиңел табыш булу хатасының җәзасын кичерә иде ул. Их, Самат,

Самат! Йөрәк җәрәхәте булып каян гына килдең син?

Ә Саимә юл буе, мөмкин кадәр әкренрәк атларга тырышып, фильм һәм андагы бәхетсез мәхәббәт турында ачынып-ачынып сөйләп кайтты. Анын бу сөйләве тышка бәреп чыккан кичерешләрен тыю өчен иде. Ә күнелендә Самат капка төбендә үзен ничегрәк тотар, анын тотышына ничек җавап бирермен икән, дигән уйлар кайнады. Шул унайдан иптәш кызы белән булган хәлне исенә төшерде.

Бервакыт ул дус кызын акыллы гына егет белән таныштырган иде. Бер-икеме тапкыр очрашканнан соң егет:

—Юк, Саимә, миңа ул кыз ошамый, ул бит нәкъ булыжник,— дигән иде.

—Нигә алай дисең, бу нәрсә дигән сүзең инде?—дигәч:—Күләгәдәге таш нинди салкын булса, синең Кадриян дә шундый,—диде.

Саимәнең, әлбәттә, Саматтан үзенә карата мондый сүз ишетәсе килми иде. Аптырап калсаң, мүкләнгән таш, дияр, кыюланып китсәң, җилбәзәк, дип уйлар. Уф, кыен икән билгесезлек дигән нәрсәкәй!

—Ярый, сау бул, Самат, мин керим инде. Хәдичә апа йокламыйча көтеп утырадыр,—дип Саимә капка келәсенә үрелде. Ә Самат яшен тизлеге белән келәгә үрелгән кулны тотып алып, үзенең йөрәге турысына куйды.

—Саимә! Бүген бу йөрәктә ниләр барын тоясынмы син? Әгәр аз гына булса да хәлемне аңласаң, Хәдичә апа янына болай ашыкмас идең. Әллә нишләттең син мине...

Саматның үзенә бик якын, хәтта бераз гына орынып торуыннан, көчле кулларының кайнарлыгыннан, аның җылы сулышы битенә үк бөркелүдән Саимәнең башы әйләнеп киткәндәй булды. Сүзсез генә күзләрен йомды һәм шунда ук егетнең кайнар кочагында әсир калуын тойды. Әйтерсең, яшен белән яшен кушылды. Яшен тамырлары иреннәр аша бер йөрәктән икенче йөрәккә күчте. Бу ут, бу ялкын икесен берьюлы чолгап алды да ниндидер сусау барлыкка китерде. Иреннәр ешрак очрашкан саен сусау арта барды. Бу хәл күпме дәвам итәр иде, билгесез. Җаннарның бер-берсенә иң якынайган мизгелендә өйалды ишеге ачылганы ишетелде һәм Хәдичәнең:

—Саимә, иртәгә иртүк торасың бар,—дигән тавышы икесен дә айнытып җибәрде.

Саимә тиз генә Саматның кочагыннан ычкынып, ана сүз әйтергә ирек бирмичә, йөгереп кереп китте. Хәтта капканы ябарга да борылмады.

Иртәгесен Саимәгә бөтен дөнья ниндидер бер сихри нурга күмелгәндәй тоелды. Бәрәңге басуындагы һәр күренеш: балаларның чыр-чу килүләре дә, буш чиләк тоткаларының шыгырдаулары да, чиләк төпләренә шапылдап төшкән бәрәңге тавышлары да бары бергә кушылып, Саимәнең колагына матур бер музыка булып ишетелде. Анын җаны шул музыкага кушылып, тантана итә иде. Күнеле шулай тәэсирләнгән чакта кинәт кенә:

—Саимә, бер генә минутка килеп кит әле!—дигән тавыш ишеткәч кенә күктән җиргә төшкәндәй булды. Артына борылып караса, юл чатында басып торган физкультура укытучысы Камил эндәшә икән.

—Кичә ни кыланганыңа отчет бирәсеңме син? Фәридәне нинди хәлдә калдырдың, йә? Алар бит инде ел буе бер-берсенә гашыйклар. Самат сине, яна килгән кеше итеп, сынап кына карагандыр, ә син тәмам мөкиббән китеп жебеп төштең. Авыл яшьләренә ошамады бу, миңа бигрәк тә,—дип тезеп китте Камил.

Саимә башта ни әйтергә белмәде. Бераздан гына:

—Син кем әле, нигә миңа акыл өйрәтәсең? Мин бала-чагамы әллә?—дип ярсып китте.

—Мин, укытучы буларак, сине ялгыш адымнан сакларга телим. Үзен егетләр белән җинел тоткан укытучы мәктәпкә тап төшерә. Без бит балалар тәрбиялибез. Башкалар мәхәббәте арасына керү берәүгә дә бизәми.

Саимәнең бу вәгазьне тынлап бетерергә түземлеге җитмәде. Кырт кына борылды да, горур китеп барды. Кешеләргә сиздермәскә тырышса

да, ул инде әле генә очынып йөргән Саимә түгел иде, йөзе уйчан, аяклары авыр атлый. Мондый үзгәрешне балалар да сизде, арада буйга иң кечкенә Сания:

—Апа, бер-бер күнелсез хәл бармы әллә?—диде.

—Юк, юк, Сания. Барысы да әйбәт,—дигән булды Саимә.

Әммә Камилнен: «Бәлки, ул сине сынап кына карагандыр»,—дигән сүзе, алмага төшкән корт шикелле, Саимәнең йөрәген кимерергә тотынды. Чынлап та, нишләп әле ул бу чибәр егетнең һәр сүзенә бик тиз ышанды? Ярый әле Хәдичә апа вакытында чакырып алды. Юкса, Алла сакласын, башынны югалтуың да ихтимал иде. Әнә бит, шашынып үбә башлаган Саматны этеп җибәрәсе урында, анын ярсуына үзе үк кушылып китте. Әй, бу тыелган җимеш! Ни өчен шулай татлы, нигә бик тә ымсындыргыч икән? Хәер, нигә әле мәхәббәт тыелган җимеш булырга тиеш? Саимә укытучы булгангамы? Укытучынын да йөрәге шундый ук ашкынучан, ярсучан, яраланучан түгелмени? Бәхет җимешенә буем җитте, дигәндә генә нигә гел кулга сугалар икән? Камилне шундый мәкерле дип уйламый иде Саимә.

* * *

...Хәтер сукмаклары Камил белән беренче очраштырган борылышка китереп чыгаргач, Саимәне янадан тулгак тота башлады.

—Уф, үләм бит, үләм! Нигә ярдәм итмисез?—дип бәргәләнде ул.

Бер читтә сабыр гына ниндидер кәгазьләр белән мәш килеп утырган акушерка Саимә янына ашыкты.

—Нигә ул кадәр сабырсызланасың? Үзең малай табарга җыенасың. Кеше кадәр кешенең дөньяга килүе дә, китүе дә җиңел генә булмый ул, җаныем.

Акушерка кызнын юату сүзләре Саимәгә әллә ни тәэсир итмәде. Ул ыңгырашты, кычкырды, бәргәләнде, ярдәм сорап ялварды.

—Ничек ярдәм итим соң, синен өчен үзем тудыра алмыйм бит инде мин,—диде акушерка.—Кая, карыйм әле, эшләрен кай тирәдә икән?—дип Саимәнең кан басымын тикшерде, йөрәк тибешен санады. Тагын ниләрдер ачыклады һәм йомшак кына: болай үк каударланма, акыллым. Әле хәленә караганда түзәрлеген бар, бала табу өстәленә салырга да иртәрәк. Көченне әнә шул вакытка сакла. Беренче балада берәүнең дә капкасы тиз генә ачылып китми. Бик авыртканда ике яктан да менә шушы җирләргә баш бармагын белән нык кына итеп басып тор. Алар авыртуны җиңеләйтә торган нокталар,—дип таз сөягенең алгы ягындагы ике урынны күрсәтте акушерка.

Баланы сау-сәламәт кабул итү дә, ананың үзен саклап калу да җиңел булмаячагын белә иде ул. Утыз яшендә беренче генә баласын таба бит Саимә. Нервылары да какшаганга охшый.

Саимә үзен кулга алырга тырышты. Авыртуы кимегәндәй булды. Ул арада ишектән:

—Кабул итегез, тагын бер әни!—дигән тавыш ишетелде.

Саимә янәшәдәге буш караватка күз төшерде. Шунда ук ишектән җиденче баласын табарга җыенучы ат караучы Шакир хатыны Зәйтүнә пәйда булды.

Кендегеннән аз гына төшеп торган ак күлмәктән, аякларының икесендә ике төрле чуәктән иде Зәйтүнә апасы... Әммә Саимәгә ул бик сөйкемле булып күренде. Саматы хаклы икән,—авырлы хатыннардан да гүзәл җан иясе була алмый... Саимә үзенең ботларына, аякларына күз ташлады. Аллага шөкер, ак мәрмәрдәй тыгыз, шома, төз иде аяклары. Шушы кыяфәтендә дә үзенең зифалыгын тою аңа рәхәт иде. «Их, Саматым да янымда булса иде»,—дип уйлап алды ул. Әйе, хатын-кызның авырлы вакыттагы үзенә генә хас чибәрлеге, сөйкемлелеге аны изге җан иясенә

әйләндерә. Элек эчкә яшеренеп яткан яктылык, күңел нурлары аларның йөзләренә бәреп чыгадыр күрәсең.

Зәйтүнә елмаеп кына исәнләште дә караватына килеп утырды.

—Саимәбезнең үзенә генә күңелсездер дидем дә синең янга ашыктым. Әле берничә көн йөрерлегем бар иде бугай. Сезнең малай киткәнне бөтен авыл белә. Ә безнеке кыз булырында шигебез гүпчи дә юк. Синең малай артыннан ашыга бугай, чеметкәли инде. Ә син әле һаман «бөтен» көе ятасың икән. Малаең минем кызны котәдер инде, рәхмәт төшкере,—дип сөйләнде Зәйтүнә.

Саимә җавап бирергә өлгермәде, янә тулгагы китереп тотты. Зур корсагы өскә калкып чыкты, маңгаен тир бөртекләре каплады, учлары йомарланды. Аның күз алдыннан Самат үтеп киткәндәй булды. Самат аңа: «Курыкма, мин синең белән!»—дип әйтә башлауга каяндыр Фәридәләр, Камилләр килеп чыкты да аяк астындагы пычракны учлап-учлап Саматка атарга тотындылар. Саимә ирен якларга теләп арага кергән иде, пычрак үзенә тиде. Тыны кысылды, сулыш авырайды, үпкә-бавыры бугазына менгәндәй булды. Гомер җебе зыңгылдап тартылды.

* * *

Камил шушы авыл егете. Армиядән кайткач физкультура укыта башлады. Янәшә-тирәдә милли көрәш буенча батырлыкны ике ел рәттән инде үз кулында тота. Урта буйлы, киң җилкәле, җирән чәчле. Тәкәббер, аерата хатын-кыз алдында борынын чөя. Әмма егерме биш яшьлек бу егетнең Саимә каршында тәкәбберлеге какшады, әй. Җае туры килсә-килмәсә дә кыз артыннан тагылырга тырышты.

—Химия туташ тирәсендәрәк булыйм әле, әйбәт кенә берәр химик реакция килеп чыкмасмы, дим. Берни чыкмаса, лаборатор опытлар ярдәм итәр бәлки,—дип мәгънәсез генә шаярткалап та алгалады. Тик Саимә битараф. Камилнең бу кыланышлары аның саруын гына кайната. Һәрчак дымлы, шактый тупас, кайтарылып торган иреннәре, тар маңгаена төшеп торган җирән чәчләре һәм бернигә исе китмәгәнне чагылдырган төссез күзләре Саимәне үзенә тарта алмады. Бары тик ихластан көлгәндә генә аның йөзенә ягымлылыкның саран билгеләре чыга. Көлгәндә ул йөзе белән генә түгел, бөтен гәүдәсе белән көлә. Ә гәүдәсе—чын мәһабәт ирләр гәүдәсе. Аңардан ниндидер кыргый көч бөркелә һәм шушы көче—тазалыгы белән масая иде ул. Саимәнең үзеннән бер яшькә олы икәнен белгәч, тыелыбрак йөргән иде. Ә кичә клубта Саимә аны яңадан җилкендереп җибәрде. Яшь аермасын оныттырды. «Шәп җырлый икән, чукынчык. Уен вакытында үзен тотышлары, тыйнак кына елмаеп куюлары барысы да үзенә килешеп тора, шайтан алгыры. Бу кызны кулдан ычкындырырга ярамас»,—дип уйлады ул. Ә Саматның Фәридәне калдырып, клубтан Саимә белән бергә чыгып китүләре, билгеле инде, Камилгә ошамады. «Шалиш, брат, ничу монда сиңа кызлар котыртып йөрергә, без дә төшеп калганнардан түгел! Көрәшче Камил, диләр безне!»—дип күкрәгенә сугып куйды ул.

Икенче көнне кичен Камил туп-туры Хәдичәләргә китте. Юлында Фәридәне очратты.

—Нишләп үзең генә барасың әле? Саматың кая?—дигән булды егет.

—Ул районда, агрономнар җыелышына киткәние.

—Җыелышта, пычагым, Саимә янындадыр әле. Авызыңны ачып йөрсәң, Саматыңны шәһәр кызлары тиз каптырыр. Күрдеңме, кичә ничек җырлады, Саматың эреп төште. Клубтан Саимәнең итәгенә тотынып чыгып китте.

Камил кызның йөрәгенә ут салып үз юлыннан атлады. Билгеле, Фәридәнең бу вакытта авылның үзәк урамында йөрүе тикмәгә түгел иде. Районнан кайтучылар фәкать шушы юлдан үтәләр. Ничек кенә булса да

Саматны очратып сөйләшәсе, кичәге үпкәләвен житкерәсе килә иде анын. Өмет дигән сихри тойгы әле бөтенләй өзелеп бетмәгән. Бәлки, мине сынар өчен генә шулай кылангандыр, дип үзен юатырга тырышты. Нишләп соң һаман кайтып житми? Ни аты, ни үзе. Ат караучы Шакир абый да аптырашта.

Фәридә янынннан киткәч, Камил адымнарын кызулата төште. Саматнын Саимә янында булуына шиге үсә барды. Районнан безгә күп дигәндә ат белән бер сәгатьлек юл, ә хәзер сәгать сигез тулып килә.

Ишек каккан тавышка Саимә дерт итеп китте. Самат ничек тә килми калмас, дип көткәндә ишек шакылдавы анын өметен канатландырып жибәрде. «Менә бит, килде, килде! Камил тәре, күнелемнән бөтен ямен алган иде шул, жүнсез»,—дип уйлап тиз генә өйалдына атылды, һәм үзен тыныч тотарга тырышып, пышылдап кына:

—Самат, синме?—дип каушавыннан тыны кысылып ишекне ачып жибәрде.

—Юк шул, Саимә, бу мин әле—Камил. Саматынны юлда күрдем. Фәридә белән житәкләшеп каядыр баралар иде. Авызлары—авызда, мин сина әйтим. Самат бик кызык нәрсә сөйли иде, ахрысы. Фәридәсе шырык-шырык көлә. Кичә синен шаян уен барганда, үзенне күрсәтергә теләп, озын жыр жырлавыннан көлгәннәрдер, бәлки,—дип сөйләнә-сөйләнә эчкә узды Камил.

Сүзләрнен Саимә йөрәгенә агулы ук булып кадалуын кызнын каранрыланып калган йөзеннән үк күрде ул. Беренчедән, Саматнын монда юклыгы шатландырса, икенчедән, горур, тәкәббер кызнын мин-минлегенә сугарга жай таба алуы куандырды аны.

Камил хәйлә-мәкергә шактый оста иде. Шуна күрә ул башта Саимә янына түгел, ә Хәдичә апа янына килгән булып кыланды. Хәдичә апага төрле мәзәкләр сөйләп көлдерде. Әлбәттә, анын мәзәкләре, Хәдичә апага кушылып, көлүләре бик ясалма чыкты. Сизгер күнелле Хәдичә апа егетнен йомышы үзендә түгеллеген тиз төшенде һәм сәбәп тапкан булып, зур якка чыгып китте.

Икәүдән-икәү генә калгач, бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Камил әрле-бирле йөренде. Саимәнен бу сөйкемсез сөякне тизрәк чыгарып жибәрәсе, ялгыз калып күз яшьләренә ирек бирәсе килде. Ә Камил үз алдына сөйләгәндәй:—Самат белән Фәридәнен аралары шактый ук якын бугай,—диде.—Икесен тоташтыручы яна жан туа калса, партия аларны өйләндереп куярга да күп сорамас. Андый башбаштаклыкка партия беркайчан да түзеп тормады һәм түзмәс тә.

Саимәнен битараф кыяфәттә утыруын күргәч, Камил кызга бүтән яктан һөжүмгә күчте: «Их Саимә, яратам бит мин сине. Беренче күрүемнән бирле яратам. Үземне жинәргә дә тырышып карадым, әмма онытырга теләгән саен ныграк ярата барам. Ышан мина, Саимә, ялгышмассын».

—Нәрсә, яна кеше дип син дә мине сынап карамакчымы? Берегез дә кирәкми! Мәхәббәт турындагы әкиятләрегезне бүтәннәргә сөйләгез. Әнә ишек, әнә тотка—минем эшләрем бар. Әкият тынларга вакытым юк!

Саимә ишекне барып ачты.

—Эх, Саимә! Тәки анламадын,—диде Камил, адымнары авыр иде.

* * *

Фәридә, яшьләр төркеменнән аерылгач, кеше күзенә чалынмас өчен авыл башындагы ялгыз каенга таба юнәлде.

Тулы айлы көзге төн. Тын гына назлы жил исә. Карт каеннан берән-сәрән коелган сары яфраклар, анын иннәренә кагылып, түбәнгә таба тирбәлә-тирбәлә очалар. Жирдәге ишләре янына төшкәч, берсенен-берсе хәлен белгәндәй кыштырдап куялар. Каеннын үзенен дә шаулавы жәйдәгечә горур түгел. Ничектер монсу гына ялгызлыгыннан зарланып

уфылдаган кебек ишетелә. Нигә бу бичара каен ялгыз икән? Каенны һәм үзен кызганудан Фәриданең күнеле тулды, каенны назлап сыпыра башлады. Йә Хода, җәрәхәтләнеп беткән каен кәүсәсендәге балта һәм кадак эзләре бичараның озын гомере буена кешеләрдән күргән газаплары турында сөйли түгелме соң? Әгәр шушы минутларда ул телгә килә алса, йөрәге тулы хәсрәтле кызга ниләр сөйләр, нинди кинәшләр бирер иде икән? «Түзә алсаң, түз инде, балакаем, сабыр ит, мин гомерем буе ялгыз булдым, бирешмәдем»,—дияр идеме? Әллә: «Ялгыз кала күрмә, миннән гыйбрәт ал»,—дип кисәтер идеме? «Кайда соң син, Самат бәгърем? Әгәр син, мина якынаю юлында булсаң, каршыңа төннәр буе йөгерергә риза бит мин. Җитәр, җитәр, җуләрләнмә кызый, сәгать уникенче китте. Кайтып ятыйм, әни борчыла торгандыр»,—дип уйлап кузгалуы булды, ерактан-ерактан тонык кына җыр тавышы ишетелде. Фәридә баскан урынында катып калды. Самат җырлый түгелме соң? Әйе-әйе, ул җырлый, димәк, кайтып килә. Фәридә шул якка томырылып йөгерде, тыны кысылды. Каршысына йөгерүче кызны күргәч, Самат җырын өзеп, атын чыбыркылап куа башлады. Килеп житүгә:

—Фәридә! Ни булды? Бу вакытта берүзең кая барасын?—дип аптырады.

Фәридә сүз әйтерлек хәлдә түгел иде. Саматның күкрәгенә капланып үксеп җылап җибәрде. Самат аны тынычландырырга тырышты.

Күшегеп беткәнсең бит, кызыкай, бөтен гәүдән дерелди. Шушы вакытка кадәр курыкмыйча басуда йөрденме? И җуләркәй-җуләркәй...

—Самат, бәгърем, ни булды сина? Кичә нигә мине ташлап киттең? Әллә арага дошман сүзе кердеме? Үзең беләсең, мин сиңа бөтен гомеремне багышлаганыем. Җанымны да җәлләмәс идем, тик анысы Ходай Тәгалә кулында. Инде нишлим? Кулымнан эш, тамагымнан аш төште. Якты көнем кара төнгә әйләнде. Ә син нигә болай сонга калдың? Җыелышыгыз биштә үк бетте бит, телефоннан чылтыратып белештем.

—Фәридә, тыңла әле. Мин үземне аңламый башладым. Аны күргәннән бирле әллә нишләдем. Күңелем гел аңа тартыла. Син ярсыма, Фәридә. Мине аңларга тырыш һәм беразга гына булса да үз иркемдә калдыр. Бер-беребезне сынап карыйк. Бәлки, бу халәтем үтеп китәр. Хәзергә мин сиңа берни әйтә алмыйм. Йә бу минем бәхетемнең, йә бәхетсезлегемнең башы. Бүгенге соңга калуымның сәбәбе дә шул. Институтта бергә укыган иптәшемне очраттым. Аның белән бик озак ресторанда утырдык, хәлемне аңа сөйләдем. Аңардан киңәш соравым идеме, белмим. Ул исә «үзенә кара» дан узмады.

Сөйләшеп кайта торгач Фәридәләрнең өе турысына килеп җиттеләр. Фәридә теләр-теләмәс кенә тарантастан төште дә сүзсез генә капкага таба юнәлде.

* * *

Иртәгесен көтү каршылаган чакта Хәдичә Саматны очратты.

—Хәдичә апа, бүген сезгә кич утырырга җыенам, әгәр сез каршы булмасагыз,—диде Самат.

—Ник каршы булыйк. Кил, тик Фәридәң нәрсә әйтер бит. Син, егеткәем, ике кибән арасында кайсын ашарга белмичә ачтан үлгән ишәк хәлендә кала күрмә.

Самат бу сүзләргә үпкәләмәде. Чөнки аңың халәтен Хәдичә дөрес бәяли иде.

Саимә Саматны салкын каршылады. Әмма егетнең ачык чырае, йомшак сүзләре, юк-юк та, Хәдичәгә сиздермәскә тырышып, бер күзен кысып Саимәгә серле итеп карап куюлары кичәге үпкәләүне бераз таратты.

—Җәмәгать, әллә чәй куеп җибәрәсезме? Бераз күчтәнәчләрем дә бар иде,—дип Самат тартмалы конфетны һәм такта чәйне өстәлгә куйды.

—И-и-и, рәхмәтләр яугыры. Районнан апкайткансыңдыр инде

боларны,—дип Хәдичә кучтәнәчләрне алды.

Саимә самавыр куйды. Чәй эчкәндә сүз үзеннән-үзе ялганып торды. Саимә дулкынлануын сиздермәскә тырышып:

—Кичә әллә бик соң кайттыңмы?—дип сорап куйды.

Саматның йөрәге дерт итеп куйды. Әллә кичә Фәридәне тарантаска утыртып кайтуымны Саимәгә берәрсе житкергәнме, дигән шик күңеленнән йөгереп узды. Ләкин Саимәнең күзләрендә ачу түгел, бары тик сорау гына күргәч, тынычлана төшеп, дусты белән ресторанда утыруы хакында сөйләп бирде.

—Мине сагынып көтүче юк ич,—дип шаяртты ул.

—Бар, дип уйларга кирәк иде.

—Моннан соң уйлармын, жаныем.

Саматның «жаныем» дигән сүзе кызның күңелендәге ташны алып атты. Димәк, кичә Камил алдаган, Фәридә белән Саматның авызлары авызда иде, дип Саимәнең йөрәгенә юри яра салырга теләгән.

Саимәнең уйланып калуын күреп, Самат:

—Әллә вакытсызрак килдем инде,—диде.

Шунда гына Саимә уйларыннан айнып киткәндәй булды.

—Юк, юк, Самат, бик вакытлы килдең, рәхмәт,—дип ягымлы карашы белән егетне иркәләп алды.

Алар бу кичне бер-берләренә тагын да якыная төштеләр. Кызның матур итеп артка өеп куйган чәчләре, савыт-саба тирәсендә кайнашканда йөгерек куллары, каймалы чуәк кигән төз һәм тулы балтырлы аяклары, юка жәйге күлмәк эченнән калкып торган күкрәкләре, сыгылмалы зифа гәүдәсе Саматка әкияттәге чибәркәйне хәтерләтте. Хәдичә апа бу ике яшь йөрәк арасында мәхәббәт жепләренең торган саен ныграк үрелә баруын күреп-тоеп утырды. Һәм күңеленнән: «Хәерлегә булсын!»—дип нәтижә чыгарды.

—Самат, Габделхәй абыеңнан калган тальян бар бездә, «Галиябану» көен уйнап жырлагыз әле. Сугышка китәр алдыннан Габделхәем гел шул көйне уйный иде. Бик матур уйный иде жанашым. Үзе сугышта югалды, гармуны белән мин ятим калдым,—дип чыланган күзләрен алъяпкычы белән сөртә-сөртә түр сандыктан гармунны алып бирде. Самат гармунны бераз тарткалап-кычкырткалап алды һәм әкрен генә «Галиябану»ны уйный башлады. Гармун моңына көчкә генә түзеп утырган Хәдичә алъяпкычын битенә каплап үксеп жибәрде. Яшьләр уңайсызланып калдылар.

—Хәдичә апа, ирегездән соң бу гармунны бер кешенең дә уйнаганы булмадымы әллә? Сезгә авыр булса, мин уйнаудан туктыйм.

—Юк, юк, зинһар уйна, жырын да жырлагыз. Хәтергә әллә ниләр килде, сөйлим әле үзегезгә.

Хәдичә күзләрен сөртте, инде суынып өлгергән чәен бер йотып куйды да күңеленә якын хатирәләргә кереп китте.

... Сугыш алдыннан безнең авылга әртисләр килеп «Галиябану» театрын күрсәткәннәрие. Минем Габделхәемнең әртис Галиябануга күзе төште ләбаса. Шул көйне уйный да жырлый, уйный да жырлый. Икенче көнне бездән дүрт чакрымдагы әртисләр туктаган Алмагачлыга киткән бу. Ә без аны эштә дип көне буе көттек. Төнге уникедә генә кайтып керде. Кайда йөргәнен әйтү юк, ашарга утыру юк—гармунын алды да шомырт төбенә утырып уйнады да уйнады. Уйнап кына утырса бер хәл иде, Галиябану сүзләрен жырлады да әле.

Кече яшьтән бирле сөешеп,
Күзебез күзләрдән китмәде,
Ходай насыйп итмәде.

Әкрен генә янына чыктым. Шактый салмыш икән, әй. Күршеләрдән уңайсызлансам да, аны-моны әйтмәдем. Уйнап-жырлап туйгач үзе кереп ятар әле, дидем. Төне буе утырды бу гармуны белән юанып. Таң беленгәч кенә туктады.

—Хәдичә, син рәнжемә инде,—дип мине кочаклап алды үзе.—Мине әллә нишләтте бу Галиябану. Жыры бигрәк үзәкне өзде...

Хәдичә көрсенеп куйды һәм:

—И-и-и Аллам! Хәзер барысы да сагынып сөйләргә генә калды шул,—дип сүзен йомгаклады.

Самат гармунда уйнап әкрен генә жыр сузды.

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән.
Тәрәзә ачып карап калды
Галиябану, сылуым иркәм,
Әллә ярата микән.

Саимә дә түзмәде, аңа каршы жыр белән жавап бирде.

Сине сөйми кемне сөйим,
Син бит егет солтаны.

Хәдичә исе китеп:

—Сөбханалла!!! Сез әртисләрне дә уздырасыз икән. Әйдәгез, клубта «Галиябану»ны куегыз әле. Авыл халкынын исе китсен. Абау жаным, бигрәкләр дә пар килгәнсез икән. Әллә инде бер-берегезне күтәп йөргәнсез шунда...

—Хәдичә апа, сезнең бу сүзләрегездән соң минем монда гына каласы килә башлады.

—Юк инде, Самат, бу йорт басымчак ителә торганнардан түгел. Иртәгә яңадан килерсен, Алла боерса. Кичкә кыстыбый пешерербез, син «Галиябану»ны уйнарсың. Габделхәем кайткан күк булды. Ул да синең рәвешлерәк таза буйлы иде, гармунда да өздереп уйный иде. Бүген түшемә керсә ярарые. Саимә, кунакны үзең озатырсын, мин кереп ятыйм инде,—дип Хәдичә апа икенче якка кереп китте.

* * *

Кыр эшләре тәмам. Бәрәңге дә алынып бетте. Колхоз идарәсе уңыш бәйрәмендә юмарт кыланды. Клубны өрьяңадан бизәделәр. Мәктәп ашханәсендә бәйрәм ашын мулдан хәзерләделәр. Күңел ачу уеннары һәм концерт программасын Самат төзеде, Саимәсе аңа теләп ярдәм итте. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигәндәй, тырышулары бушка китмәде. Бәйрәм күңелле узды, халык канәгать булды. Тик Фәриданең генә күңеле төшенке иде, Самат белән Саиманең парлап жырлыйсын ишеткән иде, шуңа күрә концертка калмады. «Тапты егетнең йомшак ягын,—дип уйлады ул.—Жыр аракы белән бер. Егетләрне исертә. Ләкин шуны исеңнән чыгарма, Саимә, моңлы кеше бәхетсез була!»

Авыл халкы концертны аеруча ошатты. Парлы жырдан соң Саиманең үзен генә дә кабат-кабат жырлаттылар.

* * *

Саиманең тулгагы туктап торган арада палатада жанлы гына әңгәмә башланды. Зәйтүнә төрле мәзәкләр сөйләп көлдерде. Саимә Зәйтүнә белән якыннанрак танышмавына көрсенеп тә куйды. Ә бит Зәйтүнә апаларнын балалары Саимәдә укый. Хәлләренә керергә мөмкинлек бар иде. Алты балалы гаиләнең тормышы жинелдән түгелдер. Ире—Шакир абзый колхозда ат караучы.

Саиманең авыл халкына торып-торып исе китә. Монда кешеләр бер-берләренә ярдәмчел. Саимә шәһәрдә үсеп, мондый хәлне күрмәгәнлектән, яхшылык иткән кешеләргә кайвакыт шикләнеп тә карый. Әмма

соныннан үзенең ялгышканын күреп, тирән оялу кичерә. Менә бүген дә ул Зәйтүнә апага:

—Сине палатабызга салгач җинелрәк булып китте әле, Зәйтүнә апа—диде.—Мин бу газапларга чыдый алмыйча үләрмен ахры, дип уйлый башлаган идем.

—Үлмисен! Бала табучы ананың үләргә хакы юк. Без иребез өчен дә, балабыз өчен дә асубый кирәк бит.

—Анисы шулай,—дип килеште Саимә.—Саматым бик малай көтә инде. Тизрәк алып кайтып бирәсе иде үзенә.

—Кайтырсың, Алла боерса, барысы да әйбәт булыр. Беренче баланы тапканда борчылына инде ул,—диде Зәйтүнә һәм елмаеп:—Һич онытасым юк, мин Фәритемне Казанга ит сатарга баргач таптым,—дип дәвам итте.—Шулай, Казан бульнисында ятам. Күрше караватта яшь кенә бер марҗа тулгаклый. Бар сүзе: «Ой, мама, больше не дам, ой маминка, больше не дам!» Икенче янымдагы татар хатыныннан: «Әнисенә нәрсә бирмим ди соң ул?»—дип сорагач, тегә хатын көлде һәм: «Әнисенә түгел инде, иренә»,—диде. Шулай, Саимә җаным, ул марҗа гына түгел, без һәммәбез шундый. Авыр чакта ирләребезгә борылып та карамаслык булабыз, хәлебез бераз җиңеләйдеме—алар кирәк.

Зәйтүнәнең сүзләреннән Саимәнең күңеле күтәрелеп китте. Ә яхшы кәеф белән Самат һәрвакыт янәшә. Саматның беренче мәртәбә аны киногa чакыруы, өйләнешергә тәкъдим ясавы исенә төште.

... Сихри тыныч кич иде. Күктә йолдызлар атыла да, егет белән кызның хисләр елгасы агымын көчәйтә. Шунда Самат хисләр ташкынына тагы да куәтле ашкыну өстәп:

—Саимә, икебезнең дә яшьләребез бара. Бер-беребезгә карап туя алмыйча тилмереп йөрибез. Өйләнешеп куйсак, Аллага тапшырып, гел бергә булырбыз. Әйдә, Яна елга туй ясыйк!—диде.

—И-и җанкисәк, кем әйтмешли, минем кулымны соравың булдымы инде бу?

Икесе дә шаркылдап көлеп җибәрделәр. Саимә бу тәкъдимне күптән көтә иде. Шатлыгы эченә сыя алмыйча йөзенә чыкты, ике бите кызарып пешкән алма төсенә керде. Күзләреннән сирпелгән наз тулы караш егетне әллә нишләтеп җибәрде. Ул түземсезлек белән Саимәне кочаклап күкрәгенә кысты да:

—Саимәм, сайрар сандугачым минем! Без бик бәхетле булырбыз дип пышылдады.—Әгәр үпкәләмәсән, бер шартым бар иде...

—Шартынны әйтеп кара, үтәрлек булса үтәрбез.

Саматка моны әйтү авыр, ләкин әйтмичә дә ярамый иде.

—Ни, Саимә, шарт дигәч тә, бәлки шарт та түгелдер инде ул. Тик син мине дөрес аңла. Мин саф кызга гына өйләнергә сүз биргән идем...

Саимә башта Саматның сүзләренә төшенә алмыйча торды, ә мәгънәсе аңына барып җиткәч, башына күсәк белән тондырылган кешедәй, мингерәүләнеп калды. Бераздан гына:

—Ни дигән сүз бу, Самат? Мине мыскыл итүеңме? Мине урам кызына санавыңмы?—дип кызып китте.

Кинәт кенә йолдызлар сүнде, төн дөм караңгыланды. Саимәнең бу минутта авылны да, Саматны да ташлап качасы килде. Әле генә йөрәгендә талпынган бәхет кошының сайравы тынды.

—Саимә, мин сине рәнҗетергә теләмәдем. Әгәр сүзләрем урынсыз булган икән—гафу ит. Ләкин, минемчә мәхәббәт илаһи көч булса да, яраткан кешеләр арасында алдан аңлашу кирәк. Яраткан кешене гомерлеккә сайлыйсың. Ә минем бу сүзләремне авызы бер мәртәбә пешкән кешенең салкынны да өреп кабарга теләве итеп аңла.

Саматның сүзләрендә хаклык барын акылы белән аңласа да, Саимәнең йөрәге: «Ул миңа ышанмый, ышанмый!»—дип типте. Акыл да бирешергә теләмәде: «Нигә мондый сүзләргә ул кадәр рәнҗергә соң? Әйе, авыл кешеләре шәһәр кызларын җилбәзәккә санаучан. Хәер, авылның

да, шәһәрнең дә язылмаган кануннары бар: йөргәндә егетләргә жинелрәк холыклы кызлар ошый, ә өйләнгәндә саф кызлар кирәк. Берәү булса, әдәп саклап эчендәге шикләрен яшерер иде. Самат һәркем уенда туарга мөмкин булган сорауны кычкырып әйтте. Бары шул гына. Саф кыз үзенең сафлыгын кычкырып әйтергә оялырга тиеш түгел.

Акыл белән хисләр арасында әнә шундыйрак бәхәс барды. Моңарга Саматның кайнар пышылдаулары өстәлде. Ахыр чиктә акыл бизмәне баса төште. Саимәнең кызуы сүрелде. Самат:

—Ахмак соравым белән рәнжетүем өчен гафу ит, Саимә,—дип кызның калтыраган кулларын учларына алды.

—Мондый сүзне йөзгә бәреп әйтеп буладыр дип уйламый идем. Бәлки, син хаклыдыр. Чөнки без бер-беребезне бик аз беләбез бит әле. Ә күңелендәге шигеңне куып тарата аласың, Самат. Мин...

—Ышанам, ышанам, Саимә! Һич икеләнмим шулай да әйтүне тиеш санадым. Бергә булыйк, Саимә. Мәңгегә бергә!

—Бер-беребезне бик аз беләбез бит...

—Яши-яши белербез. Ризалыгыңны бир, Саимә. Бер атнадан туй итәрбез. Сине башта әниләр белән таныштырырмын. Аннары сезнекеләргә китәрбез.

Саматның соңгы сүзләреннән Саимә кинәт коелып төште. Керфек араларыннан яшь бөртекләре бәреп чыкты. Әнисенең соңгы минутлары, хушлашу сүзләре йөрәген телгәләп үтте. Саимәгә бу чакта унтугыз яшь тулмаган иде әле. Әтисе сугышта һәлак булды. Әнисе ягыннан туганнары Чиләбедә яшиләр. Сирәк кенә хат алышудан башка элемтәләре юк.

—Самат, мине сорап барырдай бер генә якын кешем дә юк шул... дип Саимә егетнең күкрәгенә капланды.

—Борчылма, тынычлан. Зату минем яктан туганнар ишле. Без алты ир, ике кыз туганнар үстек. Әни кече энем белән яши. Төпчек булса да миннән алда өйләнде, инде малай үстерәләр. Танышкач барысын да күрерсең-белерсең әле. Алар сине һичшиксез ошатачаклар.

Вәгъдәләшеп сүзләр беркетешкәч һәр икесе тынычланып калды. Туйга әзерләнү башланды.

Туйлар матур гына үтте. Яшьләр Хәдичә өендә яшәүне кулай күрделәр. Хәдичә үзе дә Саимәнең башка жиргә күчеп китүен теләмәде. Бик ошады ул аңа. Инде әкрен генә жырлап та жибәрсә, бөтен эшен ташлап, онытылып тыңлар булды. Кайчак:—Бәхетләрең генә булсын иде, балакай...—дип куя иде.

Туйдан соң ике атна буе Хәдичә, яшьләрнең үзләрен генә аулакта калдырып, кунарга күршесе Гайшәгә йөрде. Кияү белән килен мунчасын да, таңнан торып бик хасиятләп үзе якты. Яшьләр кергәнче берәр дошманы-фәләне мунча ташына тавык тизәге салып чыкмагае дип, үзе үк саклады да. Бу көнне ике күрше хатынның сөйләшер сүзләре күп булды. Сәгать тугызларда Хәдичә әкрен генә яшьләрнең ишеген какты. Ишекне Саимә ачты. Күз төпләре сизелер-сизелмәс кенә зәңгәрләнеп, йөзе сулыгып киткәнрәк күренсә дә, кәләш бик шат иде. Бәхете тышкы якка чыккан. Үзе ояла, Хәдичә апасының күзләренә туры карый алмый. Кызның йөзен күргәч Хәдичә үзенең Габделхәй белән булган беренче төннәрен күз алдыннан үткәрде. Ул арада күршесе дә кереп житте.

—Әле кайчан гына без дә шулай бәхетле идек бит, Гайшәкәем. Бәхетләре ахыр көннәренә кадәр барсын. Без күргәннәрне Ходаем аларга күрсәтмәсен. Газизләребездән аерылып, яшьтән тол калып, ир белән йоклау рәхәтләреннән мәхрүм булуларыбыз да бик житкән.

—Син әле Габделхәең белән алты ел чүкердәшеп яшәп калдың. Ә миңа ир рәхәте алты көн дә тәтемәде. Кавышуыбызның нәкъ алтынчы көнендә, Алланың каһәре төшкере, сугыш Сабирымны кайнар куеныман суырып алды да ут эченә илтеп салды. Ярар, Хәдичә, сүздән коймак пешмәс, мунчадан чыгышларына кияү коймагыбыз майда йөзсен.

Ике күрше чүкердәшеп мич тирәсендә кайнаша башлады. Берсе

чүпрәсен салып коймакка камыр туглады, икенчесе мичкә ут тергезеп җибәрде. Читтән карап торганда алар үз балаларын өйләндерүче аналарга ошаган. Тормыш авырлыгы аларның күңеленнән башкалар бәхете өчен шатлана алу сыйфатын юып төшерә алмаган иде.

Мунчадан соң Саимә Хәдичә апасына рәхмәтләрен әйтергә Гайшәләргә сугылды. Бөтен өйгә хуш исләрен тараткан, парлары чыгып торган кайнар мич коймагын күргәч, әйтәсе сүзләрен онытып җибәрә язды. Бик тә ашыйсы килгәнен аңлады.

—Коймакларны ала чык, балакаем. Беренче мунчадан соң чәйне икегез генә кияү коймагы ашый-ашый рәхәтләнеп эчегез. Кичкә, Аллаһы боерса, кияү пилмәне пешерергә торабыз, анысына монда керерсез. Гайшә апаң пилмәнне бик тәмле пешерә ул. Бу көннәрне үзегез генә булыгыз әле. Сөешеп туя алмый торган чагыгыз. Сәвит биргән өч күнлек ялыгызның, урыслар мидәвәй мисәс диләр бугай, рәхәтен күрегез. Без ашарыгызга хәзерләп кертеп торырбыз. Ходайга шөкер, кәтү куасыгыз, эшкә барасыгыз юк әле.

—Сез безгә әнием хөрмәтен күрсәтәсез—Саимәнең күзләре дымланды. Яхшылыгыгызны мәңге онытмам... Саимә тәлинкәгә өелгән кайнар коймакны күтәреп Саматы янына ашыкты.

Хәдичә белән Гайшә яшьләрдән соң мунчага кергәч исләре китте. Бөтен җирдә тәртип, алгы якның сәкесенә өр яна җәймә җәелгән. Саимә җәймәсен оныткандыр, алып куйыйк дисәләр, җәймә астындагы утызлык акчаны күреп, икесе берьюлы шаркылдап көлеп җибәрделәр.

—Сөбханалла! Борынгы йолаларны да беләләр икән. Мунча ягучыга кияү бүләге монысы. Егет юмарт икән, рәхмәт төшкере! Димәк, кәләштән бик канәгать дигән сүз инде бу,—дип әхириләр мәгънәле генә елмаештылар.

... Өйләнүенә өч ай тулганда Саматны колхозга рәис итеп сайладылар. Элеккеге рәис Сәгъди абзый пенсиягә китәр алдыннан:

—Энем, безнең авылда төпләнергә туры килер сиңа. Үз урыныма тәкъдим итәм сине. Белемең, тырышлыгың бар, үҗәтлегең дә җитәрлек. Авыл халкы үз итеп өлгерде үзеңне. Райкомда ризалар, тәвәккәллә, энем,—дигән иде.

«Сәгъди абзый алдан кайгыртканн икән. Әйтәм аны, былтыр партиягә керергә димләгән иде. Партия дигәннәре менә нәрсә өчен кирәк булган икән»,—дип уйлады Самат һәм каршы килеп тормады. Шулай да:

—Ышанычыгыз өчен рәхмәт, Сәгъди абзый. Тик булдыра алырмынмы...—дип икеләнде.

—Булдырырсың!—дип кырт кисте өлкән агай. Әмма хисапчың белән бергә эшли алмассыз, пожалуй. Дөрес, Фәридә акыллы кыз түгел, эшен дә белә. Ләкин, үзең чамалыйсыңдыр, кызлар гыйшкын кире какканны гафу итмиләр,—диде Сәгъди абзый һәм Фәридә белән үзе сөйләшергә булды.

Фәридә монарчы буш торган мәктәп завхозы урынын белешкән икән инде. Колхозга район финанс бүлегендә эшләүче егет бухгалтер булып кайтты.

Яшь рәиснең язгы чәчүне тиз һәм сыйфатлы уздыруы район җитәкчеләренең Саматка ышанычын ныгытты. Партия райкомының беренче секретаре Әхмәдиев, колхозга бер килгәч, Саматка:—Тамырны тирән җибәреп яшәгез, егетем.—диде.—Гел өйдәшләр булып яшәмәссез бит, үзегезгә өй салу хәстәрен күрегез. Булышырбыз...

* * *

Фәридә белән бер мәктәптә эшләү Саимә өчен җиңел булмады. Йорт салу мәшәкатьләре дә күп вакытны алды. Самат ике көннең берсендә дигәндәй әле район үзәгенә, әле Казанга чаба: колхозга тегә кирәк, бу кирәк, аларны булдыру өчен кемнәрнедер җайларга кирәк.

Рәхмәт инде Сәгъди абзыйга, четерекле мәсьәләләрдә акыллы киңәшләре белән Саматка ярдәм итәргә тырышты.

Саимә түземсезлек белән балага узуын көтте. Кайвакыт үзендә үзгәрешләр сизеп дулкынлану кичерде. Өмете акланса, Саматка әйтеп шатландырырмын, дип очынып йөрде. Әмма, менә уздым, менә уздым, дип йөрүләре организмның чираттагы ялгышуы булып чыга да Саимәнең кәефе бозыла иде. Мондый көннәрдә ул кырыслана, көйсезләнә, Саматка карангы чырай күрсәтергә дә күп сорап тормый.

Ел ярым тирәсе вакыт йорт салу, өйне җиһазлау-бизәү эшләре белән үтте. Шулай да ул бәбәйгә узу өметен күңеленнән чыгармады. Эшләре саега төшкәч бу уй аның бөтен барлыгын биләп алды, сабыр канатларын сындырды. Ул бер көнне, Казанда күп кенә баласыз хатыннарны балалы иткән, бик дәрәҗәле хатын-кыз профессор булуын ишеткәч, күренеп кайтыйм әле, дип тәвәкәлләде. Профессорның эш урынын тиз тапса да, чираттагы кешеләрнең күплегенә гаҗәпкә калды. Чират көтеп утырганданиләр генә уйлап бетермәде. Әгәр... әгәр, син беркайчан да балага уза алмаячаксың, дисә нишләрмен? Фәриденең кеше аркылы ишеттергән сүзләре исенә төште. «Саматка әйттем әле, нәрсә, хатының кысыр булдымы әллә, дидем. Мин бит сине беләм: кысыр хатын белән барыбер тормаячаксың. Синең бөтен хыялың—тизрәк кулларында бала чөеп уйнату. Ә мин сиңа әллә ничә тупырдап торган малай табып бирәчәкмен. Үзең дә ишетәсеңдер, Камилнең минем арттан ничек йөргәнен, бусагабыздан яучылары өзелеп тормый. Минем синнән башка беркемгә карамаганымны белеп яшә,—дип әйттем әле...»—дигән көндәше. Чыннан да, соңгы вакытта Самат үзгәрә төште бугай. Күтәренке күңеллелеге, йомшак иркә сүзләр белән эндәшүләре азая бара кебек. «Саимә, нигә син балага уза алмыйсың икән?»—дигән соравы ешайды. Берничә мәртәбә салгалап кайтты. Кызмача чакларында сорауларның тагын да авырракларын ычкындырды Самат. «Әгәр безнең балабыз булмаса нишләрбез икән? Синең бу турыда уйлаганың бармы? Минем балаларны бик тә яратканымны беләсеңме син? Яшәүнең мәгънәсе, минемчә, үзеннең дәвамыңны калдырудыр». Моның шулай икәнен Саимә белмимени? Ул бит инде яшертен генә күрше авылдагы бер карчыкка да барып карады. Карчык аңа өшкереп ниндидер дарулар биргән иде, файдасы гына тимәде. Менә хәзер бирегә килде. Чират җитте. Озын буйлы, бик сөйкемле йөзле бу ханым Саимәне зур игътибар белән карады. Аның аналарча йомшак итеп саф татарча сорашулары, кирәкле урыннарны артык авырттырмыйча гына баскалаулары Саимәнең күңелен йомшартып ук җибәрде. Күзеннән яшьләре түгелеп киткәнен сизмичә дә калды.

—Зинһар, ярдәм итә күрегез. Балам булмаса ирем минем белән тормас, дип, борчылам, бер-беребезне бик яратышып өйләнешкән идек...

—Борчылмагыз әле, элгәре анализлар алыйк...

Саимә, анализларның нәтиҗәсен көтеп торганда, әллә ниләр уйлап бетерде, күз алдыннан берсеннән-берсе күңелсез вакыйгалар йөрәкне тырнап узды. Саматсыз калу—айсыз, кояшсыз калу белән бер булып тоелды. Бәхетенә, анализлары әйбәт икән. Бу турыда белгәч, Саимәнең шатлыгы эченә генә сыеп бетә алмады, тышка бәреп чыкты. Үз гомерендә беренче күргән профессор ханымны, рәхмәтен әйтә-әйтә, кочаклап ук алды.

—Ярый, тынычланыгыз, әле сезнең белән генә эш бетми, акыллым. Ирегезне дә тикшерергә кирәк, бәлки, гаеп аңардадыр. Әгәр ирегез ягыннан бары да яхшы булса, миңа тагын бер килерсез әле.

Сөенеченнән Саимә авылга ничек кайтып җиткәнен дә сизмәде. Саматка барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Аңа да кичекмәстән тикшеренеп кайтырга кирәклекне аңлатты. Самат хатынының сүзләренә рәнҗеде.

—Безнең нәселебездә юк ул кысырлык! Әгәр мин тикшеренеп йөрсәм, бөтен авыл миннән кычкырып көләчәк. Син шуны телисеңме?—дип ярсуын тыя алмады.

—Юк, жаныем,—дип иренә сырпаланды Саимә,—без бу хакта беркемгә әйтмәбез. Самат, минем дә бит балалар сөясем килә.

Саимәнең йомшаклыгы Саматның кирелеген җиңде. Ул:

—Ярар, мин иртәгә барыбер Казанга барам, җай чыкса, тикшеренеп тә кайтырмын,—диде.

Икесе дә тынычланды. Саимә Казаннан алып кайткан тәм-томнар белән бәйрәмчә өстәл әзерләргә кереште. Самат баянын алып өздереп уйнап җибәрде. Ул кичне нинди генә көйләр уйналмады да, нинди генә җырлар җырланмады. Күптәннән болай ял иткәннәре юк иде. Төннәре дә яңа кавышкан, берсен-берсе күреп, сөеп туя алмаган парлардай иркәләшеп үтте. Соныннан икесе дә, бу төнгә зур өметләр баглап, изрәп йоклап киттеләр.

Самат Казанга барган көнне үк бөтен эшен бетерә алмады. Тикшеренү нәтиҗәләрен алырга соңга калды. Ирен дүрт күз белән көткән Саимәнең «соңга калдым» дигән сүзләргә ышанасы килмәде. Күңелен, әллә гаеп үзендә булып, мина дөресен әйтергә уңайсызлана микән, дигән уйлар биләде. Өстәвенә Самат шактый исереп кайткан иде. Аның үпкә катыш гарьләнеп әйткән сүзләрен тыңлап тору Саимәгә җиңел булмады.

—Больше, валлаһи, дип әйтәм, ул тикшеренү дигәннәренә ике аягымның берсен дә атлыйсым юк! Аның уңайсызлыкларын, читенлекләрен телгә дә аласым килми. Бу хәлне дустыңа түгел, дошманыңа күрсәтмәсен. Ярый ла ул сезгә җиңел, җәелеп тик ятасыз. Сине яратуым хакына гына түздем ул хурлыкка. Анализ дигәннәрен күрмәсәм дә, мин үземне кысыр ирдермен дип һич кенә дә уйламыйм. Әгәр, гөнаһ шомлыгына каршы, Аллаһының каһәре төшеп, кысыр була калсам да, башка мине борчыма. Асрамага бер бала алырбыз әле...

Нәкъ бер атнадан Самат тикшеренү нәтиҗәләрен белеште. Аны кабул иткән табиб җор телле икән, ул:

—Котлыйм, сез сирәк очрый торган ирләрнең берсе икәнсез. Орлыкларыгызның ник берсе буш булсын. Хатыныгызның да туфрагы уңдырышлы булса, бала-чагаларыгызны кая гына куеп бетерерсез икән— дип шаяртып алды.

Самат бу сүзләрне шулай тиешле дип кабул итте. Чөнки аның үзенә карата һичнинди шиге юк иде. Әмма кәгазь кисәген Саимәсе кулына салганда, ир горурлыгын яшермәде. Табиб әйткәннәрнең бер генә сүзен дә төшереп калдырмыйча кабатлады. Тик ярым шаярып:

—Менә шулай, җанкисәк! Син дә бик шәп, мин дә бик шәп, ә бала юк... Әллә тырышуыбыз җитеп бетмиме икән?—дип өстәде.

Һәр ай саен яңа өметләр белән балага узуны көтә-көтә тагын бер ел узды. Ай, бу елның авырлыгын, озынлыгын ничек иннәр күтәргән дә, ничек йөрәк түзгән?! Бу ике йөрәкне тоташтырган кылларның, менә өзеләм, менә өзеләм, дигән көннәре санап бетергесез иде. Өстәвенә Фәридә сүз арты сүз ирештерә торды. Имеш, Самат, аз гына салып алса аның белән очрашу җаен эзли. Һич оныта алмый икән. Саимәгә өйләнүенә бик үкенә икән. Имеш, тагын бераз көт инде, дип Фәридәгә ялына икән.

Саимә бу сүзләргә ышанып бетми бетүен. Әмма иренең салгалап кайтулары ешая башлагач, чыннан да шулай микән әллә, дигән шикләре, чүпрәдән унган камыр шикелле, тышка бәреп чыккалый. Андый чакта өйдә буран кузгала.

—Син тыярга уйлыйсыңмы ул Фәридәнне? Мин тәмам гарык аның ишеттергән сүзләреннән! Теләсәң нишлә—йә ул, йә мин!

—Җитәр, Саимә, тукта! Кайчаннан бирле Фәридә минеке әле ул? Син ни әйткәненне чамала. Җыен гайбәткә ышанганыңа шаккатам. Ярый, Фәридә белән үзем сөйләшермен. Аның белән талашып йөрмә тагын. Кеше көлдереп. Алла хакы өчен тынычлан, мине дә юкка борчыма,—диде дә элеккечә иркәләп-юатып тормыйча, ишекне каты гына ябып чыгып китте.

Иртәгесен, икесе дә риза булып, асрамага бала алу хәстәрен күрә

башларга кирәк дип килештеләр. Әмма «иртәгә» дигәннәре гел күчә барды.

Ай чамасы узгач, Саимә үзендә үзгәрешләр сизә башлады. Тик моны Саматка әйтергә ашыкмады. Беркөнне, бер кемгә дә сиздермичә генә, таныш профессоры янына барып кайтты. Авырлы икәненә тәмам ышангач кына шатлыгын иренә әйтергә булды. Саматы кайтышка яңа күлмәген киде, бәйрәмчә өстәл көйләде. Ире капкадан керә-керешкә үк, очар коштай булып:

—Сөенче, сөенче! Сөенчегә нәрсә бирәсен?!—дип аның кочагына атылды.

—Сайрар кошым ни сораса, шуны!

—Алайса син миңа бик күп итеп кильки алып кайт!

—Кильки?..

Бу сүзләр баштарак Саматның аңына барып җитмәде. Ә инде эшнең нәрсәдә икәненә төшенгәч:

—Ура! Безнең урамда да бәйрәм!—дип Саимәсен күтәреп алды.

Мондый назны Саимәнең соңгы вакытларда күргәне юк иде. Ул Саматның кайнар итеп үбүләреннән, иркә сүзләреннән, кулында сабый баладай күтәреп йөрүеннән тәмам эреде. Аннары пышылдап:

—Мин шундый бәхетле, Самат,—диде дә,—бәхетемнән хәтта үләсем килә,—дип пырхылдап көлеп җибәрде.

—Ни өчен бәхеттән үләргә?

—Бәхетле мизгелдә мәңге калу өчен...

—Без болай да мәңге бәхетле булачакбыз. Бәхет агачыбызның чәчәк бөресе бар. Хәзер шул орлыктан бәхет җимешен үстерә башлыйбыз.

* * *

Иртәнге дүртләрдә Саимәне тудыру өстәленә салдылар. Зәйтүнә аның артыннан:

—Эшенне озакка сузма, җәһәт бул. Синең артыңнан ук мин дә килеп җитәрмен,—дип хәер-фатихасын биреп калды.

Саимә Зәйтүнәнең сүзләрен әллә ишетте, әллә ишетмәде. Чөнки аның хәле авырайганнан авырая барды. Кан басымы күтәрелде. Берничә укол кадаганнан соң бөтенләй хәрәкәтсез калды. Акушерка хәлне бик тиз төшенде.

—Без сине монда йокларга алып килдекмени? Йокынны караватта туйдырырга иде. Әйдә, уян, тиз уян, үз эшенне үзең башкар, безгә генә салынып ятма. Балаң юлда бит инде. Болай тик ятсаң, ярты юлда буылып үләчәк,—дип ул Саимәнең ике битен дә шактый сизелерлек итеп чәбәкләп алды. Авырайган күз кабакларын көч-хәл белән күтәреп, Саимә күзләрен ачты.

—Нишлим соң? Хәлем юк ич... ярдәм... ярдәм итегез! Үзем үлсәм үләрмен, улымны Саматым өчен исән калдыра күрегез...

—Кара син аны, үлсәм үләрмен, имеш... Җинел генә үлеп котылмакчы. Баланы табу гына түгел, аны кеше итәсе дә бар әле. Барсын да Саматына ансат кына калдырып китмәкче... Ярар, ял иттең, хәзер бөтен көченә көчән. Менә шулай, менә шулай... Булдырасың бит, булдырасың...

Акушерка әле назлап, әле ачуланып Саимәгә көч бирергә тырышты. Шәфкать туташын да яныннан җибәрмәде. Алар шулай шактый озак азапландылар. Инде баланы кулга алабыз, дип торганда, бүлмә ишеге шыгырдап ачылды. Борылып карасалар—Зәйтүнә!

—Мине бөтенләй оныттыгыз... Көтеп-көтеп сабырлыгыбыз беткәч, кызым белән, Аллага тапшырып, үзебез юлга ашыктык. Әле ярый, баламны ике арада төшереп калдырмадым. Тизрәк... башка тотып торыр хәлем юк...—дип икенче өстәлгә барып ятты.

Табибларның игътибары берара Зәйтүнәгә юнәлде. Ә Саимәнен эчендә нәрсәдер өзелгәндәй булды. Ул, суга батып баручы кеше кебек,

куллары белән каядыр тотынырга теләде. Бала елаган тавыш ишетелде. Табиблар җинел сулап җибәрде.

—Аллага шөкер!!! Бала да, ана да исән! Менә нинди матур кызын бар, ә син, малай да малай, дисен. Беренче баланы кыз итеп без бик бәхетле аналарга гына бирәбез...

Саимә табибларның ни әйткәннәрен анлап бетермәде бугай, газаплы хәрәкәтсез ята бирде. Ләкин табибларның Саимә янында озак кайнашырга мөмкинчелеге юк, икенче өстәлдәге кем әйтмешли Зәйтүнәнен, күәс чиләге тулып, камыры түгелергә җиткән иде. Зәйтүнә бәбиен җинелләп тапты.

—Тагын бер кыз!

—Каяле, кая, кызымны карыйм әле,—дип Зәйтүнә кулын сузган гына иде, беренче өстәлдә ятучы Саимә әллә саташып, әллә авыртуы басыла төшеп урыныннан кузгала башлады. Табиблар аны уратып алдылар. Күпмедер вакыт ыгы-зыгы булып алды. Балалар кулдан кулга күчте.

Бәбиләрнең икесен бергә алып чыгып киттеләр.

Егерменче гасырның илленче елы иде бу.

... Саимә, кызын беренче мәртәбә кулына тоткач, үзен дөньядагы иң бәхетле кеше итеп сизде. Баласы башта имиен капмыйчарак маташкан иде, соныннан дөньяга килгәч, ашарга кирәктер, дигәндәй, имине суырырга тотынды.

Зәйтүнәгә дә кызын китерделәр. Кызын күргәч:

—Әйтәм аны бик җинел таптым, бер йомарлак май кадәр генә икәнсен, кызыкаем...—дип сөйләнде ул.

Ә Саимә баласыннан килгән татлы искә оеп күзләрен йомган, кызынын җылы, дымсу бите анын күкрәгендә ята. Шушы рәхәт җылылык, баласынын йомшак сулышы, сизелер-сизелмәс кенә йөрәк тибеше Саимәне күкнен җиденче катына күтәргән. Әгәр шушы минутта анын баласын тартып ала калсалар бала белән бергә йөрәге дә йолкынып чыгар иде.

Зәйтүнә күрше караватка еш-еш күз төшергәләде. Ә инде Саимә күзен ачкач:

—Саматың, дим, ничек очып килеп җитми сон, әйтеп өлгермәгәннәрдер, бахыр,—диде.

—Әйе, Саматым сөенер инде. Кызыбыз нинди матур! Шулаймы, Зәйтүнә апа?

—Шулай, Саимә. Бик авыр тапкан иден, олырак булган икән шул бәбәен. Ничә кило диделәр?

—Әй, анысы нигә кирәк анын... Балам, кызым туды!

—Шулай, сау-сәламәт булсыннар да Ходай бәхетләрен бирсен...

* * *

Саимә белән Зәйтүнә хастәханәдән бер көнне чыктылар. Аларны алырга Самат, Шакир белән сөйләшеп, икесенә ике ат куып йөргәнче, дип үзе генә алып кайтырга булды. Өйдә тәмле ризыклар пешереп, мунча ягып торырга Хәдичә апасына әйтте. Бик тырышты Хәдичә, аягы җиргә тимәде, кулы-кулга йокмады. Кар базыннан иртән сауган куе сөтен алып мeнде. Мичкә казнын баш, аяк, канат һәм эчке әгъзаларыннан, ана бераз бозау ите дә кушып, зур гына шулпалы бәлеш ясап тыкты. Вак итеп токмач кисте. Аш салып җибәрде. Бәби мунчасын да өлгертергә тырышты. Ярый әле булышырга Гайшә ахирәте вакытында керде. Саимәсез торган бер атнада өйдә шактый тәртипсезлек барлыкка килгән. Гайшә тегендә-монда аунап яткан әйберләрне киеи шкафларына, кайберләрен өйдәге чөйләргә элде. Аннары, бик әйбәтләп, өй белән мунча идәнен бар көченә ышкып юды. Изге эшкә катнашуына сөенеп йөрде ул.

Менә кайтып та җиттеләр. Самат, төшереп җибәрә күрмәгәем дип,

баласын сак кына тотып, авызын колагына кадәр ерып өйгә керде.

—Хәдичә апа! Менә безнең дүрт күз белән көткән багалмабыз! Ал кулына, ач битен, бик тә күрәсем килә. Юлда ачып карарга Саимә рөхсәт итмәде,—диде дә баланы Хәдичәгә сузды. Алар артыннан чиксез бәхетле йөзен балкытып Саимә килеп керде.

—Самат җаным, бар, Зәйтүнә апаларны илтеп куй. Аннары туйганчы-туйганчы карарсың. Кызыбызның имчәк суырганын күрсәң, исләрең китәр! Күзләремә карап шундый тәмле итеп суыра, мин сиңа әйтим.

—Ярар, сандугачым, кайткач мин сиңа бер кызык хәл турында сөйләрмен әле, ә хәзергә очтым,—диде дә Самат, шактый биек баскычтан ике генә сикерде.

Зәйтүнәләрнең дә капкалары төбенә кадәр ачылган. Ике яшьлек кызыннан башка балалары урам якка ук чыгып тезелешкәннәр. Әниләрен көтү шактый ялыктырган, ахыры, битләре кызарган, туңганнар. Атны күргәч дүрт яшьлек Әхмәткә кадәр, борын астындагы куе юешлекне теле белән ялап алды да:

—Әни тайта, бәбәй алып тайта!—дип кычкырып җибәрде. Балалар гөж килде. Бу тавышка ишегалдында йөргән этиләре дә, кызу-кызу атлап, Зәйтүнәсе янына ашыкты. Баланы кулына алып:

—Менә нинди икән минем кечкенә кызым!—дип сөенде.

—Самат, рәхмәт сиңа! Әйдә, өйгә кер, бәби тәпиен дим... Зәйтүнә тотын миңа, балалар, әниегезгә булышыгыз,—дип өйгә ашыкты. Кая инде ул Саматка анда кереп тору. Аның күңеле күптән баласы белән Саимә янында ич! Ул атын җайлап кына борды да элдертте генә.

—Әйдә, малкай!..

Саимә Саматы кайтып керүгә тизрәк баланы күрсәтергә ашыкты. Әти кеше баланы кулына алуга:

—Минем дә балам бар, мин дә—әти кеше!—дип ярып салды. Чибәрнең чибәре безнең кызыбыз! Кыз димәктән бая әйткән кызык хәлне сөйлим әле. Больницага килеп керүемә сестра чыкты да, «кызыгыз бар, котлыйм», ди. Мин аны, янымда басып торган кешегә әйтә, дип торам. Миңа әйтәдер дип башыма да китермим. Каян килеп минем кызым булсын ди, бөтен авыл белән малай көткәндә. Сестра, «сезгә әйтәм, сезнең кызыгыз бар»—дип кабатлагач кына айнып киттем. «Ни өчен кыз?» дип әйткәнемне сизмичә дә калдым. Без—ир-атлар, ни өчендер, беренче балабызның малай булуын телибез бит. Бу, нindидер, ялган горурлыктыр, күрәсең. Минем күңелемнән дә мизгел эчендә кимсенүгә охшаш уйлар үтте. Хәтта атна буена, нишләп кыз булган?—дип уйлап йөрдем бит. Фәкать баланы кулыма алгач кына, үз баламны кочагымда тойгач кына, аның кем булса да барыбер олы бәхет икәнен аңладым. Бу минутларда җаным сөйләп, аңлатып бетергесез чиксез рәхәтлек кичерде. Рәхмәт сиңа, Саимәм!

Бәхетле көннәр тиз үтә. Самат эштән кайтып керүгә авызын ерып баласы янына килә. Нишләтергә дә белми сабыен: йокламаган чагы булса кызы белән сакаулап сөйләшә, иреннәрен төрле кыяфәткә кертеп, әллә нинди авазлар чыгара. Бу көннәрдә Самат белән Саимәнең йөрәге бер булып типте. Авылда алардан да бәхетлерәк кеше юк иделер. Юк иде.

* * *

Баланы алып кайткан көннән Шакир үзен сәер тота башлады. Бәбәйне бишеккә салгач, юрган почмагы белән ябылган йөзен ачып карады да: «Мунчаны томалап кайтыйм әле, ә сез, балалар, әниегезгә булышыгыз, мин хәзер керәм»,—дип чыгып китте.

Арада әниләрен иң сагынганы Әхмәт булды, чишенеп тә тормастан, әнисенә килеп сарылды. Әллә бәбидән дә көнләшеп куйдымы, еламсырап такмаклый башлады:

—Әни, безгә бәби киләкми. Бил син аны теге апайга,—дип күршеләре Гафифәгә күрсәтте. Мин аны ялатмыйм, кәкәй ул...—Өйдәге ыгы-зыгыга караватында йоклап яткан ике яшьлек Фәния елап уянды. Ана, Әхмәтен житәкләп килеп, кечкенәсен кулына алды.

—Мин сезгә тәти бәби алып кайттым. Анын сезгә тәмле мәмиләре бар. Хәзер мин аларны сезгә өләшәм—дип үзенә китерелеп тә ашамыйча саклаган конфет-печениеләрне Әхмәт белән Фәниягә бүлеп бирде.

Ул арада:

—Мин зур үстем, бер дә жыламыйм,—дип торган алты яшьлек Наил күчтәнәчкә кулын сузды. Ана да өлеш тиде. Бер конфеты белән печениесен ашаганнан сон, калганнарын хәсиятләп кесәсенә салып куйды. Өлкәнрәкләре бәби тирәсендә этешә-төртешә, һәркайсы якынрак килергә тырышып, мәш килде. Ә бәбинең бернидә гаме юк, меш-меш килеп йоклавын белә иде. Йокы аралаш көлгәндәй итә инде әллә...

—Әни, әни, бәби көлә! Әни дим, без аңа исем таптык инде. Ания ул, Ания!

—Мин риза, балакайларым, бик матур исем тапкансыз, әтиегез нәрсә дип әйтер бит.

—Бу юлы исем кушарга безнең чират. Син малай бәби алып кайтканда әти үзе куша ич.

—Бу исемне мин дә бик ошаттым: Фәния, Ания—килешеп тора,—дип бу сүзгә күрше Гафифә апалары да кушылды.

Шулчак Шакир кереп житте. Җәһәт кенә чишенде һәм бәби янында тукталып бераз карап торганнан сон, берни әйтмичә өстәл янына килеп утырды. Бу хәл Зәйтүнәгә борчу салды, шулай да ул:

—Кызыбызга шатланмадыңмы әллә, атасы. Әллә авырып торасыңмы? Аллага шөкер, бәбиебез сау-сәламәт. Монысы, бәлки, төпчегебездер, башкаларыннан ябыграк, кечкенәрәк булып туды. Төзү материаллары алдагыларга мулдан киткән, ахры. Шуна күрә монысына мая әзрәк калгандыр... Башкалар шикелле ашамсак та түгел, бик аз имә,—дип Шакирны көлдерергә тырышты.

Әти кеше чәй янында да ачылып китмәде. Башка вакытларда каймакны мактый-мактый ашарга ярата иде. Бу юлы аңа да исе китмәде. Баланың исеме турында сүз чыккач та кушылмады.

—Ничек телисез, шулай кушыгыз,—дип өстәл яныннан торып ук китте.

Зәйтүнә ни уйларга да белмәде. Баланы табуга каршы түгел иде бит үзе. Әллә хәзер фикере үзгәрдеме икән? Еллар ярлы, жиде баланың тамагын туйдырып, өс-башын карап тору жинел түгел. Колхоз эшләгәнгә берни бирми диярлек.

Зәйтүнә шулай уйланды. Шакирның кыланышлары өчен күршесе алдында уңайсызланды. Шакир, тәмәке тартып кергәч, тагын бәби каршына килеп басты. Әллә бик текәлеп караганга, әллә вакыты житепме, бала кычкырып елап уянды.

—Ни булды, балакаем? Болай әче итеп елаганың югые,—дип ана аны кулына алды, имезергә теләде.

Юк, сабый имчәкне алмады, өзгәләнеп елавын дәвам итте. Астындагы чүпрәген алыштырып, урынын жайлап карады Зәйтүнә, әмма бәби елаудан барыбер туктамады. Бу хәл исә Әхмәткә житә калды:

—Әйттем бит, кәкәй бәби, дип. Әнә, акыла да акыла. Мә, кәнфитең дә киләкми, үзең аса,—дип кесәсендәге конфетны бәбигә таба ыргытты.

Кечкенә Фәния тәмам аптырап, үзе дә елап жибәрергә житешеп, бәби яныннан читтәрәк торган әтисенә елышты. Нишләргә белмәгән Зәйтүнә:

—Шакир, син аңа озаклап, бик текәлеп карап тордың. Әллә күзең тидеме икән?—дип борчылды.—Мә, кулыңа алып, куеныңда тотып кара әле. Бисмилланы әйтеп, өф-өф иткәләсәң тынычланыр сыман...

—Нишләп минем күзем тисен аңа? Мин бит сокланып карамадым.

Артык сокланып карасаң гына күз тия. Вакыты житкәч, туктар әле. Мин бер әйләнеп кайтам,—дип киенергә керешге.

Баласына болай битарафлыгы өчен Зәйтүнә Шакирны күнеленнән генә битәрләде. Үзе бит бала табу йортына ничек ашкынып илткән иде. Юлда Зәйтүнәгә:

—И әнкәсе, маладис син. Төшертеп котылу ягын карамыйсың, барысын да табып барасың,—дигән иде.

Ә хәзер Шакирны, әйтерсең, алыштырганнар. Төсе качкан. Әллә чыннан да чирли микән?

Шакир чыгып китүгә, ни гажәп, бала елаудан туктады. Бераз киреләнгәннән соң имчәкне дә алды. Имә торгач, йоклап ук китте.

Ире соң гына кайтты. Исерек иде. Кайры тунын салып идәнгә атты да шунын өстенә ятып гырлап йоклап китте. Зәйтүнә анын бераз салгаларга яратуын белсә дә, бүгенге кыланышын һич анлый алмыйча гажизләнде. Ни булган? Нигә балага бүрегә карагандай карый. Борынгылар, «баланы ата күнеленә якын итсен, атасына охшасын»,—дип белеп әйткәннәр шул. Алты бала табып мондый хәлне күрмәгән ана нишләргә дә белмәде, күнеленә шом йөгерде. Төнге уникеләрдә бала имезергә торгач, идәндә кадерсез яткан ирен, җәлләп, үз янына чакырды. Менә шулчак, айнып бетмәгән Шакирның теле ачылды.

—Зәйтүнә, бала минеке түгел. Әйт дөресен, кем баласын алып кайттың син?

—Син нәрсә, тиле бәрән орлыгы ашадың мәллә? Кырык яшемә житкәндә мине кем дип белдең? Нигә мыскыл итәсең? Ямьле көнемнен ямен аласың. Балалар ишетсә, ни уйлар? Йорттан бәрәкәт качар. Рәнжетмә мине, бала имезгән ана рәнжеше буш калмый, Алла сакласын!

Зәйтүнә гарьләнеп елап жибәрде. Шакир аны юатмады да, ачуланмады да, ул нәрсәнедер анлап бетерә алмый иде булса кирәк. Гомер кыланмаганны әллә ничә тапкыр тәмәкесен сөрсетте. Бу төн икесе өчен дә авыр, үтә дә озын булды.

Иртәгесен Шакир, маллар карагач, чәй эчәргә дә кермичә, эшенә ашыкты. Атларының пошкырып каршы алуларыннан, борынга бәреп кергән җылы тирес исеннән анын күнеле хушланып, жинеләеп киткәндәй булды. Кечкенә тәрәзәләрдән юл-юл булып төшкән кояш нурлары абзар эчендә үзенә бер хозурлык тудырган. «Кашка»ның ялларын бармаклары белән тарады, ә тегесе йомшак иреннәре белән хуҗасының янакларына, кулларына кагылды.

—Сөбханалла! Син дә түгәрәкләнеп киләсең, тиздән безгә нәни кашкаңны бүләк итәрсең,—дип атның тулып торган корсагын сыйпады. Бала имезеп утырган Зәйтүнәсе күз алдына килде. Бугазына төер утырды. Хәтта «Кашка»ның муеныннан кочаклап елап жибәрә язды.

... Нишләдем соң мин, Зәйтүнәне нахакка рәнжеттем түгелме? Кая инде ул аңа жүнсезләнеп йөрү: өй тулы бала-чага, абзар тулы мал-туар. Өстәвенә салгалап борчып торам. Юк... Зәйтүнәнең, пожалый, гаебе юктыр. Бусы башка балаларыбызга охшамаган икән, нишлисең инде—аттан ала да туа, кола да туа, диләр түгелме соң? Насыйбы шулдыр, әйеме, «Кашкакаем?»

Шакир атыннан киңәш сорагандай аны муеныннан кочты. Үзен сүзсез тыңлап торучы «Кашка»га рәхмәтле иде ул. Тиз-тиз эшен бетереп, махмырдан башы чатнаса да, кибеткә тукталмыйча, өенә ашыкты.

Яланаяктан гына баскыч башыннан песен чәптереп торган Әхмәт әтисен күрүгә сөенеп:

—Әти, әти, кала әле, тамсылар тама. Тамсы турында бел жыл беләм мин.

«Там-там тамсы там,
Тамуыңны ялатам.
Әз эшләлгә, күп йоклалга,
Тәмле асалга ялатам»,—

дип такмаклап җибәрде. Әтисе аны күтәреп алды да кәлә-кәлә: «Юк, улым, син дөрес җырламыйсың. Ул күп эшләргә, аз йокларга яратам, дип җырлана»,—дип төзәтмәкче иде, малае исә һаман үзе белгәнчә такмаклавын дәвам итте.

Өйдә тынлык. Өлкән балалар мәктәпкә киткән. Фәния ишеклетүрле йөреп, куеныңдагы курчагын йоклата. Зәйтүнә күренми. Бишек җәймә белән капланган, димәк, бала йоклый. Әхмәт кенә әтисе тирәсендә бөтерелә, һич тынгы бирми.

—Әти, әти, дим, әни сина күлсе апайдан далу алып сыкты. Синең басын авылта ди, далу киләк ди. Мин аның кайда икәнен беләм, әнә, скафның ин басына куйды.

—Әниең кайда соң, улым?

—Ул монсада, әнә теге кәкәй бәбинең сүпләкләлен юа.

Шакир әкрен генә бишек янына килде. Җәймәне күтәрде. Гөнаһсыз нарасый тирән-тәмле йокыда. Күкрәк баласының үзенә генә хас баш әйләндергеч татлы исе күп хатирәләрне күз алдыннан уздырды. Әмма баланың йөзе Шакирның күнелен үзенә тарта алмады. Бу юлы озаклап карап торасы итмәде. Бишек каплавычын сак кына ябып, Фәниясен күтәрде дә уйга калды: «Нишләп бу бала мина ят? Әллә булниста алыштырганнармы? Алай дисән, Самат хатыны белән икәве генә яттылар бугай. Ничек кенә ачыкларга соң моны?.. Юк, бүген бу турыда сүз куертырга ярамас. Башым чатный, хатынны да өсте-өстенә борчу җүнлелеккә илтмәс...»

Шулай уйланып утырганда, чиләк тулы кер күтәреп, Зәйтүнә керде һәм бер ни булмагандай:

—Чәй дә эчми киткәнсең. Кичәге тамашаннан башың тубалдыр. Шкафтан ал да үз чаманны үзен кара. Мич алдында аш бар. Балалар кайтышка бәрәнге пешерергә кирәк.

—Бик ачуланма инде, карчык. Ир кеше ни уйламас та, ни әйтмәс. Бәби тәпие юабыз дип кичә артыграк киткән...

Килештеләр кебек. Көн артыннан көн үтте. Әмма Шакир күнелендәге шигеннән арына алмады, киресенчә, ул һаман тирәнәя барды. Кайвакыт атналар буе эчте. Үзе өйдәгеләрнең берсенә дә каты бәрелмәде. Кечкенәләргә кесәсендә берәр генә булса да конфеты табылып торды. Тик бишек ягына кырын күзен дә салмады, хатынына җаны эремәде.

Зәйтүнәнең артык түзәр чамасы калмады. Ире галәттәгечә исереп кайткан кичтә ишектән керә-керешенә акаеп карады да:

—Оятсыз, җир бит!—дип битәрләргә тотынды.—Һәркөн дунгыз булганчы эчәргә күпме акча кирәк?! Әйт дөресен, нинди акчага эчәсен? Балаларыннан оял әзрәк. Урамга чыгарлыгыбызны калдырмадың бит инде...

—Эчсәм, синекен эчмим. Кибетче Сәлимә куены... Вакыты житкәч туктармын.

—Менә хикмәт нәрсәдә икән... Әйтәм, җирле, мина синнән кабер салкынлыгы... Сәлимәсен әйтер идем, җиде бала атасыннан башка ир беткәнме ана. Иртәгә үк кибеткә төшеп, давыл кубармасам, Шакир хатыны дигән исемне күтәреп тә йөрмим. Кара аны, икегезне берьюлы адәм мәсхәрәсе итәчәкмен.

—И-и-и, җүләр, җүләр, шуны анларлык та баш юкмыни? Сәлимәнең куен кенәгәсен әйтәм мин. Эчкән саен ул шул кенәгәсенә кешеләрнең бурычын язып бара. Бурычка эчәм мин, беләсенме, бу-рыч-ка!.. Тинтәк баш, тинтәк булмасаң, баланны алыштырганнарын сизәр иең. Хайваннар да үз балаларын таный. Бездә бит Саматлар кызы. Беркөнне, кәнсәгә кереп, Саматка бик озак карап утырдым. Бездә тучно Самат кызы, ә безнең кыз алардадыр... Ул көнне мин ана берни әйтә алмадым, кыюлыгым җитмәде. Ә менә иртәгә үк өйләренә барам да кызларын карыйм. Безнеке булса, алам да кайтам! Саимәсен әйтер идем, ярый, синең надан башың уйлап житкермәгән ди. Ул бит укыган кеше, укытучы, адәм мәсхәрәсе. Бәлки, аның кызы үзенекедер. Әллә өченче бала табучы булдымы?—дип күнелендәгесен ачты да салды салмыш Шакир.

—Алла хакы өчен туктат җүләр сатуыңны,—дип күз яшьләрен түкте Зәйтүнә.—Бүлнистә Саимә белән икәү генә яттык. Мин аңышмасам ул чамаларые. Имезгән чакларында баласыннан күзен алмыйдырые. Ялгышып кына да минем кызны тотып карамады. Ә мин гомерем буе рәтле йокы күрмәгән нәрсә, бала табу газапларыннан котылуга бу юлы да изрәп йоклап киткәнмен. Ике елга бер генә, бала тапканда гына туйганчы йокы эләгә бит миңа. Бала имезгәндә черем иткәлим аннары. Калган чакларда аяклар йөгерүдән туктамый, куллар эштән бушамый. Өй тулы мәшәкать тә мәшәкать. Аңгыра булмасаң да аңгыраерсың. Ничәмә еллар авыру әнкәйне карадым. Авырыксынмадым, үзең беләсең. Төннәр буе син йокы күрсәтмәдең. Бер туймас җан булдың. Шуңа күрә бала ташыйм да бала ташыйм. Ярый ла син һәр көнне көндез гырлап йоклап аласың. Сәлимә юкка гына куен кенәгәсеннән эчермидер әле. Ирләрне бик ярата, диләр аны. Тагын менә нәрсәне исеңдә тот, әгәр Саматларга барып тавыш чыгарып йөрсәң, риза-бәхил түгел! Саимәсе—безнең Нуриянең класс җитәкчесе, тегесе—колхоз хуҗасы. Йомышыбыз гел аңа төшә. Әгәр инде син уйлаганча булса, безгә алар беренче булып килеп җитәрие!..

* * *

Самат сонлады бүген, бераз салып та алган.

—Саимә, кил әле, киңәшең кирәк. Кызмача кайтканыма ачуланма. Камил сыйлады. Каршы төшмәдем. Бер атнадан Камил белән Фәридәнең туе икән. Безне дә чакырдылар. Нишлибез? Синең белән сөйләшмичә мин ризалык бирмәдем.

Саимә уйга калды. Нишләргә? Саматка бармыйча ярамас, ачу тота, диярләр. Аны ялгызын җибәрергәме? Тукта әле, нигә сер биреп торырга. Баланы карап торырга Хәдичә апа бар ич, калып торыр. Сөтемне савып калдырырмын... Һәм Саимә:

—Зурлап чакыргач барырга кирәк. Барырбыз, баяныңны да алырсың. Туй җырын җырлап тәбрик итәрбез. Күптәннән дөньяга чыкканым юк,—дип ризалыгын белгертте.

Саимәнең болай фикерләве Саматка ошады.

Камилләрнең туе алдыннан Самат сәер хәбәр күтәреп кайтты.

—Авылда, Саимә белән Зәйтүнәнең кызларын больницада ялгыш алыштырганнар икән, дигән сүзләр таралган. Шакир абый эчкән баштан шулай сөйләнгән. Миңа үз кызым кирәк, ди икән. Бу хәбәргә нокта куярга барыбер кирәк булыр бит,—диде дә, йоклап яткан кызы янына килеп, озак кына карап торды, Саимә иренең карашы гадәти булмавын сизде.

—Ни чыкса—шул исерек кешедән чыгар инде. Әллә син дә шикләнәсеңме? Иртәгә үк Зәйтүнә апа янына барып сөйләшеп кайтырмын. Аның бит инде беренче тапкыр гына бала табуы түгел. Үз баласын исеннән үк сизәдер. Ярый, мин тәҗрибәсез. Юк, юк, гайбәт кенәдер бу. Мин баланың үзебезнеке икәненә ышанам. Әнә ич, ничек итеп «мәммәм»гә үрелергә тора. Чит кеше баласы булса ул шулай миңа тартылыр идемени? Җанның да, канның да тартылуы бит бу...

Саимә баласын алып имезә башлады. Иртәгесен Саимәнең Зәйтүнәләргә барырга вакыты булмады. Нишләптер бу турыда Зәйтүнә белән сөйләшеп утырасы да килмәде. Ә Самат, киресенчә, иртүк ат абзарына юл тотты. Шакир белән сөйләшергә ниятләде. Тик атлар янында каравылчыдан башка беркем юк иде.

—Шакир абый кайда?

—И-и Самат энем, ул бу атнада тоташтан эчә бит, җитмәсә, әллә ниләр сөйләнә, ычкынып барамы шунда. Үзен бер кәнсәгә чакыртып сөйләшеп карасаң, файдасы тияр иде. Минем белән сөйләшкәнне үзенә әйтә күрмә, гомере буе көн күрсәтмәс.

Самат күп уйлап тормады, Шакирларның өйләренә китте. Ачуыннан ишек шакып, рөхсәт сорап та маташмады. Тик Зәйтүнәнең бала йоклатып утырганын күргәч, үзенең тупаслыгыннан:

—Зәйтүнә апа, гафу итегез,—дип уңайсызланды.—Шакир абый кирәк иде. Эшенә бардым, эшендә юк, инде менә үзегезгә килергә мәҗбүр булдым. Кайда соң ул, нишләп йөри?

—И-и-и Самат, кайда булсын, иртә таңнан эчү артыннан йөри. Әйтсәм-әйтим инде, башка түзәр хәлем калмады. Һаман кибет тирәсендә чуала. Эчеп кайттымы, өйдә тавыш, балалар ишетә дип тә тормый: «Бар, үз балабызны алып кайт, миңа Саматныкы кирәк түгел»,—ди. Кичә кызыбызның кырыгы тулды, ә аның баланы бер мәртәбә дә кулына алганы юк әле. Өстәвенә, сезгә барып кызларны алмаштырып кайтам, дип теңкәмә тия. Сезгә килеп керә калса арт сабагын укыт үзенең. Кибетче Сәлимәсен дә авыл советына чакыртып алып пешерсеннәр ие. Әле кичә кибеттә Шакир белән икәүләшеп эчкәннәрен күргәннәр. Җирбит, хатын-кыз башы белән эш вакытында эчеп утырсын әле! Эшләре болай барса, бер афәт китереп чыгара инде болар. Самат, актыгын әйтәм, зинһар гаеп итә күрмә. Бүлнистән кайтканнан бирле яныма килеп караганы юк. Элек бит ул һәр төнне, ач эт сөяккә ташлангандай, балалар йоклап беткәнне дә көтми, миңа ташлана иде. Ә хәзер, йокла, сиңа йокы гына төс, ди. Баланы алыштырганнар, дигәне бәйләнү өчен генә түгел микән, дим. Шул азгын Сәлимә генә башын әйләндерә бугай. Мондый хурлыкны күрермен дип уйламаган идем...

Тәмам түземлеге бетеп Зәйтүнә елап җибәрде.

—Еламагыз, Зәйтүнә апа. Сезгә борчылырга ярамый. Мин икесе белән дә җайлап сөйләшермен. Балагызны саклагыз, зинһар. Ничек соң, бик еламыймы? Рөхсәт итсәгез, Ания бит әле, үзен бер карыймчы.

—Кара, кара, Самат. Син бит инде үз кеше. Балаларны бер вакытта тапканнандыр инде, Саимә дә, син дә якын кешеләргә әйләндегез. Сезне бәбиегез белән кунакка чакырып аласым килә. Тормышыбыз, Аллага шөкер, түзәрлек. Итебез, аз булса да икмәгебез дә бар. Шакир абыегыз үзе булган кеше бит ул. Тик менә, әллә нәрсә, җүләрләнеп йөри башлады. Мин бүлнистә чакта балаларны да әйбәт караган, күршекүлән исе китеп сөйли.

—Зәйтүнә апа, Шакир абый кызыгызны нигә минеке дип саный? Сезнең үзегездә андый шик юкмы? Балаларны буташтыру очраклары булгалый диләр бит.

—И Самат, без бит икебез бер палатада, бер үк вакытта тудырдык. Саимәнең хәле авыр үк иде, ә мин бит үземне белештермичә ятмадым.

Шулчак бишек селкенеп куйгандай булды. Зәйтүнә сак кына япманы ачты.

—И-и-и Аниябез уянып килә икән ич... Кунак абый барында йоклап ятып булмас, диденме, кызым? Менә, Самат абыйсы, күр инде, без әкрен генә булса да калкып киләбез...

Самат балага кыяр-кыймас кына күз төшерде. Чыннан да бала уянган, куе зәңгәр күзләре, ирен кырыйлары елмайган рәвешне чыгарып ята. Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер, дигәндәй, сабыйның йөзен күргәч Самат әллә нишләп китте. Кызның кара-кучкыл төсе, башлыгыннан чыккан коңгырт чәчләре Саматка бик якын булып тоелды. Баланы кулына алып сөяргә теләде. Нәкъ шул вакытта Самат йөрәгенең кысылып китүен тойды, гүя аңа киң күкрәк читлегендә урын тарайды сыман. Ярый әле тиз үтте бу хәл. Әмма аның күзләре һаман балада иде.

—Сөбханалла! Берүк күзем тимәсен! Бик сөйкемле кыз, тфү-тфү,—дип бишек япмасын ябарга ашыкты Самат. Бала, ризасызлыгын белдергәндәй, елап җибәрде. Аның елау тавышы да якын-үз иде. Самат, шул тавыштан сихерләнеп урынында катып калды. Аннары тиз генә борылды да бишекнең япмасын тагын ачты. Гаҗәп, сабый шунда ук елаудан туктады. Биләве эчендә хәрәкәтләнмәкче булды. Кымшана торгач, тәки

бер кулын биләүдән чыгарып, нәрсәгәдер үрелгәндәй итте. Тагын елмайгандай булды. Нәкъ шул мизгелдә, Самат кызның ике бит уртасының беленер-беленмәс кенә батып китүен күреп алды.

—Йә болай озак карап торудан күзем тияр. Алай-болай мин киткәч, елый башласа, менә шушы чәч бөртекләрен бала каршында яндырыгыз, безнең Саимә шулай эшли,—дип үзенең берничә бөртек чәчен йолкып алып Зәйтүнәгә бирде дә хушлашырга ашыкты.

Капканы ачуга Шакир белән йөзгә-йөз бәрелә язды ул. Көтелмәгән очрашудан икесе дә югалып калдылар. Баш төзәтеп өлгергән Шакир үзен тизрәк кулга алды.

—Нишләп әле мин эштә чакта предколхоз безгә кунакка килә? Хатын чакырдымы, әллә үзең теләпме? Кемне сагындың: хатыннымы әллә аның бәбиенме?

—Җүләр сатма, Шакир абый. Оятынны, намусынны аракыга кушып эчмә инде. Атна буе эчкәненне костырасы булыр, пожалый. Бүген сөйләшүдән мәгънә юк. Иртәгә, тәмам айныгач, атларынны карагач сәгать тугызларга минем янга керерсең.

Һәм Самат кызу-кызу атлап китеп барды. Аның күңелен аңлаешсыз өермә биләп алды. Йөрәк тибеше ешайды, башындагы уйлары буталды. Шикле уйларыннан көне буе арына алмады.

Кичен, туйга да барасы булгангамы, Саимәгә бу хакта сөйләп торуны кирәк тапмады. Киемнәрен алыштырырга үтешли бала караваты янында тукталып, изрәп йоклап яткан Гүзәленә озаклап карады. Ания белән чагыштырганда безнеке күпкә зуррак, тазарак икән, дип уйлап куйды.

Туй халкы Саматларны җылы каршылады. Барысы да бәби белән котлады. Бәби туена килергә теләкләрен белдерделәр.

Фәридә туй киемнәреннән һәм тыйнак кына бизәнүдән тагын да чибәрләнгән. Үзен горур тота. Баладан соң сулыга төшкән Саимә янында үзен өстенрәк күрү ана рәхәт иде, күрәсең. И бу хатын-кыз заты! Сине аңлап бетермәле түгелдер... Ә менә Саматның мондый мәҗлес-кичәләрдәге гадәти шуклыгы сизелмәде. Әти кешегә әйләнүдәнме әллә бу? Әллә иңнәрендәге зур йөк, җаваплылык аны шулай җитдиләткәнме? Саматтагы үзгәреш Саимәгә һич ошамады. Бүген эштән кайтып кергәндә үк ире башка көннәрдәгечә түгел иде. Бала караваты янында торганда да йөзе яктырмады. Әллә Фәридәнең кияүгә Камилгә чыгуына пошынамы? Камил теге вакытта Фәридә белән Самат арасында нинди якынлык ятканын аңлатырга тырышып караган иде бит. Бәлки, аның сүзләрендә хаклык та булгандыр. Саимә ирен аңларга тырышып:

—Самат, эшеңдә берәр күңелсезлек булдымы әллә?—дип сорады.—Райкомнан шелтә-мазар юктыр бит? Син бүген әллә нинди шунда, үзенчә түгел. Алай итмә инде, гадәттәгечә бул. Үзенчә.

—Берни дә юк, барысы да нормально. Яшь бара бит, әти дә булдым. Солидныйрак буласым киләдер. Ә син юкка күңеленне төшермә. «Гөлҗамал»ны җырлагандагы Саимә бул.

Гонаһ шомлыгына каршы, беренче тәнәфестә үк Фәридә җаен туры китереп, Саимәгә зәһәр угын кадап өлгерде:

—Әбәү, Саимә, беренче балаңнан ук бөтенләй бетеренгәнсең, дип әйтимме? Икенчеләрен тапкач нишләрсең икән? Саматынның да сөмсере коелган. Йөзеннән елмаю качкан. Өч ел баласыз тилмертеп, чүт эчәргә сабыштырмадың үзен. Инде баланны тапкач та, Саматка Шакир кызын алып кайтып биргән, дип бөтен авыл шау итә. Аларныкы шәбрәк, матуррак идемени? Шәбрәкләрне таный беләсең, ул якка күзең очлы синең. Әнә Шакир абый көне-төне эчә, синең аркада хатынына көн күрсәтми икән. Күрәсең, син үз тирәндәге кешеләргә кайгы-хәсрәт кенә өләшәсеңдер. Минем күпме күз яшьләремне түктердең. Алар барысы да синең өскә төшкән. Белеп яшә, Шакир абый рәнҗешләре дә ерак китмәс әле...

—Фәридә, каян килә сиңа мондый еланлык? Кияүгә чыгуыңа сөенер чагың ич!

—Сөенәм бит, күрмисеңмени? Арагызга кара мәче булып, кеше баласы килеп кергәненә сөенәм! Бу нәрсә, салкын тамчыдай, һәркөн түбәгезгә тамып, акылыгыздан яздырачак әле...

—Ни сөйлисең син, безнең арага нишләп кеше баласы керсен?

—Берни белмәгәндәй кыланмасана! Бөтен авыл сөйләгәнне син генә ишетмәгән ди.

—Авызыңны үлчәп ач, Фәридә! Ату ничек япканыңны да сизмәссең!

—Ирем председатель, дигәч тә, әллә тотып кыйнатыр идеңме? Тик белеп тор: синеке председатель булса, минеке—көрәшче. Аннары мин үзем дә синең кебек сыек боламык түгел. Теләсәм, Саматыңны тартам да алам! Ир-ат алдында матур итеп сайрасаң, юмарт булсаң, йөрәкләренә ялкын кабына...

—Юмартлыгың белән дә карата алмадың бит әле. Ир-ат йөреп вакыт уздырыр өчен тиле юмартларны эзли, өйләнгәндә акыллы саранны сайлый.

Фәридәнең ачуы чиккә житеп кабарды. Кешеләр булмаса, ул Саимәнең чәченә ябышырга да күп сорамас иде, әмма бүген көне ул түгел. Бүген теш арасыннан ысылаудан узарга ярамый. Шуңа күрә ул бөтен сабырлыгын җыеп:

—Каян килгән акыллы баш! Бармакка чорнарлык акылың булса, иреңне ике бала арасында йөртмәс идең,—дию белән чикләнде.

—Их, Фәридә, ничек итеп тешләп, катырак авырттырыйм икән, дип тырышасың бит. Юк, җаным, көчәнмә. Безнең араны барыбер боза алмассың! Безнең йөрәкләр нәфрәт белән түгел, мәхәббәт белән бәйләнгән.

—Мәхәббәт, имеш. Үз баласын кеше баласыннан аера алмаган өй тавыгында нинди мәхәббәт булсын?! Урамга чыгып, кешеләр сүзенә колак сал ичмасам. Саңгырау булмасаң, хаклыкны ишетерсең. Саматың әнә, Зәйтүнә апаларга кереп баласын сөйгән...

Саимәнең түземе бетте. Бугазына каты төер утырды, сулышына капланып, күз яшьләренә буылып, урамга атылды. Зәйтүнәләргә йөгереп барып, барын да ачыкларга теләде. Ләкин, бу вакытта Шакирның өйдә булачагын искәреп, уеннан кире кайтты. Әмма туйга кире кермәде. Күңеле тарткан бердәнбер урын—өе иде, кызы Гүзәл һәм изге зат Хәдичә янына йөгерде ул.

Ә туй мәҗлесе кыза барды. Саимәнең кайтып китүен берәү дә абайламады. Самат та әнә керер, менә керер, дип сабыр гына хатынын көтте. Шулчак табын башлыгы:

—Саматларның «Галиябану»ны җырлауларын сорыйбыз,—дип белдерде.

—Минем Галиябануым кереп җитми бит әле, әллә Исмәгыйль урлап киттеме?—дигән булды Самат. Эзләп керим үзем...

Тик таба алмады. Бәлки, бала имезергә кайтып киткәндер, дип күңелен тынычландырырга тырышса да, кәефе тәмам җимерек халәттә иде.

Эшнең ничеклеген сизеп, Самат артыннан чыккан Сәгъди абзый:

—Әйдә, энем, керик, халыктан яхшы түгел,—диде.—Бераз утырыйк та, кешеләрчә хушлашып китәрбез. Саимә өчен борчылма, ул бала имезергә киткәндер. Беренче тапкыр аналык хисләрен татыган хатын-кыз мондый шау-шулы мәҗлестә ничек тыныч кына утырсын ди...

Керделәр, утырдылар. Ләкин Самат барыбер ачылып китә алмады. Фәридәнең:

—Нәрсә, Галиябануың әйтмичә дә тайганмы әллә?—дип усал тешләвенә каршы сүзсез генә рюмкасын бушатып куйды.

Тагын салды, тагын эчте. Шулай берничә тапкыр кабатлангач, Сәгъди абзый аны иплэп кенә алып чыгып китте һәм, берни дә сорашмыйча, өйләренә хәтле озатып куйды.

Ул төнне өйдә тавыш-мәзар купмады. Иртәгесен генә Самат:

—Кичә нигә миңа әйтмичә киттең?—диде.

Саимә яшереп тормады.

—Фәриданең тәнәфестә мине хурлаганын ишетсән, син нишләр идең икән? Самат белән безнең арага керден, ди. Синең белән миңа аның рәнҗешләре төшкән, янәсе. Мин беренче баладан ук мәлҗерәгәнмен, төсемне җуйганмын. Синең дә сөмсерең коелып йөри, имеш. Тагын әллә ниләр такылдап бетерде.

—Нәрсә җитми икән бу хатын-кызга,—дип кенә куйды да, Самат, эшенә китте.

Шакир вакытында килеп җитте. Аек, өстен-башын алыштырган. Кичәге тупаслыгы өчен гафу үтенде. Ә Самат аны гаепләргә җыенмый иде.

—Шакир абый, син кичә миңа нәрсә әйтергә теләден? Беркөнне дә табышмаклар кыстырып сөйләштең. Аңламыйм мин сине. Анык кына итеп, ирләрчә гәпләшик әле.

—Минем теләгем бер генә, һәркайсыбыз үз баласын үзе үстерсен. Шуңа күрә безгә кызларны алыштырырга кирәк.

—Нигә алай дисең?

—Мин алты бала атасы. Аларны мин күзләреннән, йөз-төсләреннән, хәтта ими суыруларыннан ук таныйм. Җиденче бала бөтенләй башка. Сиңа ничек аңлатырга да белмим, түлке бу бала минеке түгел. Син үзең дә күрдең бит инде, нужәли үзеңә ошатмадың, Алла колы. Сез бит инде без түгел, укыган кешеләр бит сез. Күрсәтегез миңа балагызны. Кемнеке икәнен бер күрүдә әйтеп бирермен. Моның өчен әүлия булырга кирәкми. Әйтәм ич, үз балаларымны керфек сирпүдән үк таныйм. Әй, нигә соң әле мин боларны сиңа сөйләп торам, кеше генә түгел, хайван да үз баласын таный лабаса. Әнә, казларны гына кара: чит бәбкәне үзенекеләр тирәсенә якын да җибәрмиләр. Низашту җибәрмиләр! Якыная башласа, муенын сузып чукырга да күп сорамыйлар.

—Шакир абый, аңлагыз минем хәлемне. Саимә өч ел буе балага уза алмыйча тилмерде. Ул аны үзенә килгән фаҗига итеп кичерде. Тәмам авыруга сабышты. Инде Ходай безгә бала бирде дигәч кенә күпме борчу өстәлде. Шул чаклы озак көткәннән соң, баласын беренче мәртәбә имезә башлаган ананы күз алдына китерегез әле. Бәхетле минутларын шул бала белән уртаклашты бит ул. Бүре кебек ул хәзер. Берәрсе бала караватына якынлашса да, өзгәләп ташларга әзер. Нервалары да какшаган. Балалар алышынган, дисәң, белмим, ай белмим ни булырын...

Күпмедер вакыт сүзсез утырдылар. Бераздан Самат:

—Шакир абый,—диде,—әйдәгез, болай килешик: балаларның икесен дә без үстерик. Икесенә дә тигез карарбыз. Рәнҗетмәбез. Игез балалардай үсәрләр. Сезнең яңадан җиде балагыз булыр әле, боерган булса. Безнең, бәлки, башы-ахыры шушыдыр. Саимә бик үк сәламәт түгел бит, хәтта бөтен яшәвем шушы бала өчен ди. Бар көчен, вакытын балага бирә. Хәтта минем барлыкны да кайчакта онытып җибәрә.

—Акылыгыз алтын икән... Ничек инде без алыштырмыйча гына бала бирик? Миңа үз балам бик газиз. Карасам, сразы белерием...

Шакирның бер үк сүзләрне тукуына Саматның ачуы килә башлады.

—Нигә әле син мәсьәләне үзең генә хәл итәргә тырышасың?! Зәйтүнәң ни уйлый? Җиде бала тапкан ана үзенекен чит-ят белән бутар микән? Ярый, Саимәнең тәҗрибәсе юк, ди. Ләкин синең хатының бу мәсьәләдә карт бүре бит инде.

Саматның сүзләрендә хаклык булуын аңлап, Шакыр басыла төште.

—Мине Зәйтүнәнең кыланышы ныграк аптырата шул. Шигемне әйтүгә чын күңеленнән рәнҗеде. Балага чат ябышкан. Җаны-тәне белән яклый.

—Димәк, үзенеке икәненә ышана!

—Ышанадыр инде, ышанмаса, алай кыланмас иде. Ләкин мин ышанмыйм! Минем күңелне нишләтергә? Күңелдәге шикләр абзардагы тирес түгел, аларны сәнәккә элеп ташлап булмый.

Бер хәсрәт берләштергән ике ата озак утырдылар. Бу хәлдән чыгунын төрле юлларын эзләделәр.

Ниһаять, Самат Шакирны балаларга бер яшь тулганчыга чаклы сабыр итәргә күндерде. Һәм бу турыда беркайда да сүз кузгатмаска килештеләр. Әйе, бер елдан охшашлыклар яки аерымлыклар аныкрак күренер. Шул вакытта мәсьәләне хатыннары белән бергәләшеп хәл итәргә булыр, дип кул бирештеләр.

Самат беразга тынычланып, язгы чәчү мәшәкатьләренә чумды. Алял бүлмәде, иртүк китте, соң кайтты. Райком вәкиленең дә бик вакчылын жибәргәннәр, кирәкмәсенә дә тыгылып йөрде. Бала туу белән өйдә дә тәртип үзгәрде. Бала һәм өй хәстәре Саимәнең иренә игътибарын киметте. Таба ризыклары сирәк пешерелде.

—Сөт белән ипи генә ашап кит инде, йә йомырка тәбәсе куыр. Күрәсең ич, һич кенә дә өлгерә алмыйм,—дигән сүзләр еш ук кабатланды. Үзе чүпрәкләр юу, кайнату, үтүкләү, гомумән, балага зарарлы микробларга каршы көрәшү белән көннәр буе кайнашты. Сөтем житеп бетми бугай, дип иртән төрледән-төрле ризыклар әзерләде. Баласы аз ашыйдыр кебек тоелып, үзәге өзгәләнде. Сабые йоклаганда, сәгатьләр буе аның караваты янында сакчы кебек утыра торганга әйләнде. Ә төннәрен йокларга үз янына салды. Самат диванга күчте. Болар, әлбәттә, Саматка ошамады, кызына үпкәләгәндәй итеп берничә мәртәбә:

—Әниеңне миннән бөтенләй тартып алдың бит, кызыкай,—диде.— Төннәрен генә булса да миңа калдыр инде әниеңне... Сиңа әнә нинди иплe, рәхәтләнеп йоклата торган карават алып кайттым ич...

—Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигән сүзең инде бу, Саматкаем. Ярар, түз инде, бәгърем, һаман алай булмас. Караватында ялгыз калдырырга куркам шул, йә егылып төшәр, йә мендәренә капланып тыны бетәр. Үз янымда йокласа, аңа да, миңа да тынычрак...

Ирен йомшак кына көйләп, Саимә һәрнәрсәне үзенчә хәл итәргә күнегеп китте.

Җәй узды. Гүзәл күзгә күренеп үсте, алгы тешләре чыкты, һөнәрләре артты. Өйләрне тутырып тупырдап торган балага әйләнде. Үз иркенә куйсаң бик тиз үрмәләп китә, чыркылдап көлә. Тәпи басарга маташа. Аның һәр яңа хәрәкәте ата-анага чиксез куаныч иде. Әнисе аны матур итеп киендерә. Кибеттән алырга әллә-ни матур балалар киемнәре булмаганлыктан, үзе тегә, чигә, бәйли. Әтисе дә бүтән кирәк-яракны ташып кына тора. Кичләрен алар өчәүләп шаярышалар. Бала белән бергә үзләренең үрмәләп китүләре гадәти хәлгә әйләнде. Читтән караганда, бу гаиләдә, бәхет һәм татулык тантана итә, дип уйларлык иде. Әмма борчулы уйлар, ныграк яшерергә тырышкан саен, үзләрен көчлерәк сиздерде һәм Саматның күңелендә «теге» баланы тагын бер генә мәртәбә булса да күрәсе килү теләге үскәннән үсте. Хәзер нинди икән. Үзгәрдеме, көрәйдеме икән? Гүзәл бик үзгәрде бит. Ә ничек күрергә? Берничә мәртәбә сәбәпсез-нисез генә Шакирлар яныннан да үткәләде. Бәлки, олырак балалары сабыйны урамга алып чыгарлар?! Әллә гел шул хакта уйланулардан инде Самат беркөнне гаҗәп төш күрде. Нәкъ бишектә вакытта күргән теге бала—Ания аңа таба кулларын сузып: «Әти, син— минем әти! Алып кит мине, мин сине яратам!»—дип әйтә, имеш. Төш аңа нык тәэсир итте. Әле таң беленер-беленмәс кенә булса да кабат йоклап китә алмады. Нәрсә соң бу? Ходай җибәргән хәбәрме? Ә бит Самат Гүзәлне чын-чынлап ярата башлаган иде инде. Үзе белән Саимәсенә охшаш яклар таба иде. «Теге» бала ничек икән хәзер? Самат Аниянe тагын бер кат барып карарга кирәк, дигән уйны күңеленә беркетте.

* * *

Ания ун айдан тәпи йөреп китте. Бер яшендә теле ачылды. Сакаулыгы да булмады, ә Зәйтүнәләрнең башка балалары өч яшьләре тулмыйча сөйләшмәделәр. Сакаулыклары озакка сузыла иде. Әнә, Әхмәтнең биш яше тулды, «р»—«г» авазларын һаман әйтә алмый. Ә Фәнияне, гомумән, аңламассың. «Менә сиңа тагын бер аермалык, аермалыкның да ниндие! Юк, иртәгә үк Саимәнең кызын барып күрергә кирәк әле»,—дигән уйлар белән Зәйтүнә Аниясен үз янына алып сөйләштерә башлады.

—Сөбханалла, балакаем, һәр сүзне бигрәк ачык, дөрес әйтәсең бит, күзләр генә тия күрмәсен,—дип кысып кочаклады.

Шакирга да кызык тоелды бу сөйләшү. Соклану хисләрен ул да яшерә алмады. Моны сизеп, Зәйтүнә:

—Шакир, йә, син дә бер кочаклап иркәлә инде шушы гөнаһсыз сабыйны!—диде.

—Кил әле үземә, акыллым!—дип әйтә башлавы булды Шакирның, Әхмәте: «Юк, юк, әти мине ялата, мине ялата!»—дип йөгереп килеп сарылды, аның артыннан Фәниясе кочакка ташланды. Кая инде ул алардан ычкыну...

Аниянең иң кызыккан әйбере абыйларының рәсемле китаплары иде. Бигрәк тә быел гына укырга кергән абыйсының «Әлифба»сы аңа аерата ошый. Бу китапка тынгылык күрсәтми Ания. Ул аны шыпырт кына ала да мич артына кереп сәгатьләр буе актара, кайбер рәсемнәрен хәтта ялап карый.

—Әни, Аниян тагын минем китапны алган, ерта бит ул аны,—дип абыйсы әнисенә зарлана, ә кайвакыт суккалап та ташлый.

Шакир Аниянең китаплар актарырга әвәслеген күреп:

—Карале, әнисе, безнең бу кыз профессор булмакчы, ахры, туу белән китапларга тотынды,—диде.—Зиһене дә әйбәт. Бер күргән рәсеменең исемен һич онытмый. Әллә соң Ходай Тәгалә махсус безгә бу кызны алыштырып бирде микән?..

—Юкны сөйләп утырма әле, әтисе!

—Ә нигә? Безнең гаиләдән ат караучы белән сыер савучы гына чыгарга димәгәндер. Балаларыбызның ничек укыганнарын беләсең. Уенчыклары да эт баласы белән сарык бәкәе булды. Шулай, әнисе, бу бала башкаларына аз гына да тартым түгел...

Соңгы вакытларда Шакирның өйдә кеше югында Анияне үчтек-үчтек иттергән чаклары да булды. Әгәр Ания үзенең йомшак куллары белән Шакирның битләренә кагылса яки мыегыннан тарткаласа, бик кәефләнә. Зәйтүнә, бала белән атаның якынаюына сөенсә дә, «балалар алышынган», дигән шик күңелендә үскәннән үсә барды. Һәм ул, Саимәләрнең Гүзәлен күреп кайтырга кирәк, дигән карарга килде.

Чынлап та, Зәйтүнә бер көнне кырык эшен кырык якка ташлап, Анияне җитәкләде дә Саимәләргә китте. Ике ара шактый ерак, теләмәсәң дә уйланырсың... Юл буе күз алдыннан ни генә уздырмады... Бала табу йорты. Ул көнге ыгы-зыгы. Ике сабый берьюлы дөньяга килде бит. Табиблар әле бер өстәлгә, әле икенчесенә йөгерештеләр. Шакирның беренче күрүгә үк: «Бала безнеке түгел»,—диюләре. Истә-оста югында Саматның үзләренә килеп баланы күрсәтүне соравы. Баланы күргәч, ул да сәерләнеп китте түгелме соң? Әйе, әйе, бик текәлеп карады ул аңа, әллә никадәр вакыт күзен ала алмыйча торды. И, Ходаем! Миңа бит бүлнистә чакта ук күршемдә генә яткан баланы рәхәтләнеп карарга була иде ләбаса. Шакир әйтмешли, бигрәкләр дә гамьсез-ваемсыз булганмын шул. Йокла да, йокла инде—сыер. Элек андый түгелием бит. Әллә бик еш бала табу мине шундый иттеме? Аннары бит ике бөртек баланы бутарлар, дип кемнең башына килсен? Әгәр дә балаларның алышынулары хак булса...

Ике ара шактый ерак булса да яшь ярымлык Ания әнисе белән

«янәшә бик кәефләнеп терек-терек тәпиләде». Әни, мине күтәр, димәде. Юлларында кечкенә көчек очрады. Ания аның белән бик уйныйсы иде дә, әмма әнисе ашыкты шул.

—Әни, бәби эт кая бара? Әнисе кайда? Ашыйсы килмәгәнме? Әйдә, өйгә алып кайтыйк аны... —Тик әнисе аның сүзләрен ишетмәде кебек.

Ишекне Саимә ачты. Көтелмәгән бу очрашудан йөзенә чыккан гаҗәпләнү һәм бераз куркып китү чалымнарын дә яшерә алмады ул. Бөтен игътибары Аниядә булды. Зәйтүнәне Саимәдәге үзгәрешләр аптыратты. Нәрсә булган бу яшь хатынга? Ябыккан, җыйнаксызланган. Бөгәрләнеп беткән халатыннан озынрак, йоклаганда гына кия торган эчке күлмәге идән «себерә».

—Абау, җаным, әллә авырыйсың инде? Ябыккансың ич. Икенчесенә уздың мәллә?

—Үзем дә шаккатам, авырткан җирем дә юк. Нигәдер йокымның рәте бетте. Бала мәшәкате белән үземне һич карый алмыйм. Гүзәл бераз җылый башласа, үләр, дип куркам. Ана ияреп, үзем җылыйм. Кышын бераз салкын тидердек. Ничек курыкканнарымны үзем генә белдем, ашаудан яздым. Самат, Казанга барып, профессорга күренергә кирәк, ди. Ана да игътибарым җитми.

—Җылаганга карап бала үләмени, җүләр. Үсәләр алар, тәгәрәпләр үсәләр! Беренче баладан ук изелеп төшкән хатыннарны ирләре бер дә ошатмый,—диде Зәйтүнә.—Иренә якты йөзең булсын, алдыннан кайнар ашың өзелмәсен. Авыртуларыңны, арыганнарыңны онытып, аның янында «ялт» итеп йөр. Төрле сылтау тапкалап теләгенә каршы килә күрмә тагы. Болай да эше бик авыр. Районга еш йөри. Анда чибәр-мут хатыннар буа буарлык! Саматың бик матур, килмәгән җире юк...

Зәйтүнә, артыгын сөйләшеп ташлавын сизеп, кинәт туктады. Саимәгә акыл өйрәтәсе юк лабаса, укымышлы хатын ул. Аннары нәчәлник хатыннары һавалырак булучан, акыл өйрәткәнне яратмыйлар.

—Син ачуланма инде, җаным, ирләрнең холкын белеп бетермәле түгел. Минем Шакирым да чыгымчылап алды, шуңа гына әйтүем.

—Нишләп ачуланыйм, рәхмәттән башка сүзем юк.

—Гүзәл кайда соң?

—Йоклый әле ул. Ул торганчы мин чәй әзерлим. Ания, менә бу уенчыклар белән уйный тор син, яме,—дип Саимә кухняга чыгып китте.

Зәйтүнәнең Гүзәлне йоклаганда булса да күрәсе килә иде, тик әнисеннән башка йокы бүлмәсенә керү ярамас, дип тыелып калды. Тиздән бала тавышы ишетелде. Зәйтүнәгә таныш кебек иде ул. Әйтерсең лә Фәниясе йокыдан уяна. Урыныннан сикереп торды да, тыны кысылып, катып калды. Саимә кухнядан атылып дигәндәй чыкты да:

—Хәзер, хәзер мин аны киендереп монда алып чыгам,—дип кызы янына ашыкты.

Озак кебек тоелды аларны көтеп алу. Ниһаять, менә алар... Зәйтүнә, сөбханалла, сөбханалла, диюдән башка сүзләр таба алмады. Гүзәл шәһәрчә кыска алсу ефәк күлмәктән, чәчендә күлмәге төсендәге зур бантик, аягында ап-ак оекбаш белән кызыл төстәге сандалик—коеп куйган тере курчак. Зәйтүнәнең үз кызлары да чибәрләр, әмма бу кыз... Тукта әле, әгәр дә Фәниясен, нәкъ шулай киендереп, Гүзәл белән рәттән бастырып куйсаң... Охшашлык... Зәйтүнәнең йөрәге чәнчеп алды, битләре уттай кызды. Шул мәлдә карашы Аниягә төште. Ул, бер курчакны күкрәгенә кысып, читтәрәк басып тора. Ә күзләре—Гүзәлдә, үзе яратуын белдереп сабыйларча елмая, менә хәзер аны кочаклап та алыр кебек... Зәйтүнә бер Аниягә, бер Гүзәлгә карады. «Юк, Ания дә ямьсез бала түгел, бик тә сөйкемле. Куе зәңгәр күзләре (ә безнекеләрнең ачык зәңгәр), дулкынланып торган коңгырт чәчләре. Мәхәббәтле бала. Тик, ябык, гәүдәгә Гүзәлдән шактый кечкенә»...

—Кызым Гүзәл, безгә кунакка менә нинди матур кыз килгән. Бергәләп уйнагыз. Уенчыкларыңны, курчакларыңны күрсәт әле үзенә,—

дип Саимә Анияне уенчыклар янына житәкләп китерде.

Ә Гүзәле усал итеп карады да Ания кулындагы курчакны тартып алды. Башка уенчыкларын да тиз-тиз генә читкәрәк күчерә башлады. Мондый тупаслык Аниягә ошамады, ул әнисенең уң беләгенә килепябышты. Әниләргә кырын карап, үпкәләвен сиздерде.

—Гүзәл, матурым! Бу ниткән хәл? Нигә бәбигә уенчыкларыңны бирмисең? Кәкәй кызлар гына шулай итә, ә син тәти кыз бит!

—Мин бәби түгел,—диде кинәт кенә Ания.—Гүзәл тәти түгел, кәкәй.

Моны ишетеп Саимә өнсез калды. Бик тә гажәпләнүен һәм соклануын яшерә алмыйча:

—Абау жаным! Ул шулай сөйләшәмени? Безнекенең әле исендә дә юк. Кая әле, акыллым, бер яратыйм әле үзеңне,—дип Саимә якыная башлагач, Ания арты белән үк борылып Зәйтүнәгә чытырдатып ябышты.

—Саимә, минем ни өчен килүемне чамалыйсыңдыр,—диде Зәйтүнә.—Үзең беләсең, авылда күптән безнең балалар хакында гайбәт йөри. Иркенләп сөйләшикче.

Авыр тынлык урнашты. Саимәнең тез буыннары йомшады, аның чарасызлыгын күреп, Зәйтүнә сүз дилбегәсен үз кулына алды.

—Гүзәлне күрүгә мин әллә нишләп киттем. Безнең Фәниягә бик охшаган ул. Гүзәл әле сөйләшергә уйламый да, дисең. Безнекеләрнең ник берсе өч яшькә кадәр сөйләшсен. Ә Аниянең яше тулуга ук теле ачылды. Безнекеләр барысы бергә мәш килеп уйнарга яраталар. Ания, чит оядан ялгышып кергән бәбкә шикелле, япа-ялгызы уйный. Тегеләренең моңа исләре дә китми. Ания минем тирәдә күбрәк булганга көнләшәләрме икән, дип тә куям. Әллә соң, балаларның алышынулары дөрес микән...

—Зәйтүнә апа, жаным! Син нәрсә сөйлисең? Бу бит мөмкин түгел! Үлсәм-үләм, әмма аннан аерылыр хәлем юк. Кызымны әтисе дә бик ярата,—дип, Саимә елап ук жибәрде.

Нәкъ Фәния кебек үк итеп Гүзәлнең елавы да кушылгач, Зәйтүнә бөтенләй каушап төште. Гүзәлне ихтыярсыз кочаклап алды да һәм аны аркасыннан сөя-сөя юатырга кереште. Гажәп, сабый читкә тартылмады, елавыннан туктап, Зәйтүнәнең мәржәнен тотып-тотып карый башлады.

—Саимә жаным, сүзләремә рәнжемәче. Без бәби тапканда буталчыклар булды бит. Врачлар әле синең, әле минем янга чабышты. Хәлең авыр булгач, боларны, бәлки, хәтерләмисеңдер. Әнә шул ыгы-зыгыда балаларны бутадылар микән әллә?..

—Булмас, булмас! Гүзәлемне беренче тапкыр имезергә китерүгә үк яраттым. Ул да миннән ятсынмады...

Ике ана озак сөйләште. Саимә бер утка керде, бер суга төште. Аның күңеленә дә шом йөгерде. Ул Гүзәлнең курчаклары белән онытылып уйнаучы Аниягә озаклап карады. Аниянең күзе, чәчләре Саматныкы кебек...» Ләкин барыбер жаны Анияне кабул итәргә теләмәде. Югыйсә, Зәйтүнә Анияне бик зиһенле дип тора. Ә Гүзәлдә әле андый сыйфатлар күренми. Зәйтүнә Саимәнең уйларын сизгәндәй:

—Без дә Анияне бик яратабыз. Хәтта Шакир абыең да хәзер аның өчен үлеп тора,—дип янә сүз башлады.—Тик, үзең беләсең, һәркемгә үз каны кадерле.

Алар тәгаен генә бер фикергә килә алмыйча аерылыштылар. Саимә Аниягә рәсемле китаплар бирде. Ания шатлыгыннан кулларын чәбәкләде. Саимәнең күзләренә яратып карап:

—Рәхмәт, апай!—диде.

Сабыйның нурлы күз карашы һәм аның рәхмәте Саимәне тетрәндереп жибәрде. Кунакларны озаткач, ул тәгәри-тәгәри елады. Әнисенә Гүзәл дә кушылды. Саимә кызын, башка вакыттагыча юатырга тырышты, ләкин бу вакытта аның үзен юатучы кирәгрәк иде.

* * *

Саматның күнелендә шом көчәя барды. Әмма бу шик-шом баласы өчен борчылудан гына түгел бугай. Мондый эчке тынгысызлыкны монарчы кичергәне юк иде әле аның. Пошынуы тикмәгә булмаган икән. Көндезге ашка өенә кайтып житүенә, артыннан ук, йөгерүдән әлсерәгән бер малай:

—Самат абый, сезне хәзер үк районга чакыралар,—диде.

Райкомның икенче секретаре чакырткан икән.

—Беренче суккан ашлыкны халыкка өләшкәнсең, дигән хәбәр алдык,—дип турыдан башлады секретарь.—Дөресме шул?

—Дөрес. Күптән түгел, хезмәт көненә йөзәр граммнан гына. Идарә белән килешеп эшләдек. Халыкның ашарына бетте. Ач халыкны эшләтеп булмый бит.

—Бик акыллы булып киттең, ә?! Тагын бер сорау: колхоз милкен урлаучыларны яшереп каласың икән. Монысы да дөресме?

—Гафу итегез, соравыгызны аңлап житмәдем.

—Аңлашылмый имеш! Бер колхозчының арба белән борчак саламы урлап кайтканын үзең үк күргәнсең бит. Эшне прокурорга тапшырмагансың. Нәрсә бу? Урлашуга юл куеп колхозны таратырга маташумы?

—Безнең колхоз кысылган йодрык кебек, аны алай гына таркатып булмый. Ә салам урлаучыга килгәндә, әйе, булды андый хәл. Ләкин ул кеше үзенең жәзасын алды. Без халыкка хезмәт көне исәбеннән борчак саламы өләштек. Теге бәндә үз өлешеннән коры калды. Урлашмаса, ике мәртәбә күбрәк аласы иде. Бу аның өчен гомерлек сабак булды.

—Димәк, сам хозяин, сам хужа, сам прокурор, сам судья булдың инде. Вазыйфаларың күпкәрәк киткән түгелме?

—Алай дип уйламыйм. Без колхоз уставына таянып эш иттек. Сугыш вакытында бер кесә борчак өчен төрмәләрне колхозчылар белән тутыруыбыз да бик житкән.

—Житте! Акыл сатма монда! Бу башбаштаклыкларың өчен сине бүген үк кулга алырга мөмкин. Киләсе атнада бюро. Бюро ничек хәл итәр. Шуннан соң карарбыз.

Саматның бугазына каты төер килеп утырды, ике чигәсенең сулкылдап кысуыннан башы кайнар кыршау эчендә калган кебек булды, йөзе агарды. Саматның бу хәлен сизеп, икенче секретарь ниндидер тантана белән:

—То-то, үзенә дә барып житте, ахры. Безнең илдә синдәй «акыллы» башларның урыны кайда икәнлеге һәркемгә билгеле. Китәргә мөмкин. Бюрога кадәр эшләп тор,—дип сүзен тәмамлады.

Самат туры өенә кайтты. Ишектән килеп керүгә кочагына омтылган Гүзәле дә күнелен күтәрә алмады.

—Әтисе, нигә чакырткannар? Юньлегә түгел, ахры, бөтенләй төсең качкан. Көне буе бер тәгам ризыксыз йөрдеңме? Әйдә, ашап ал, кайнар чәй эчеп жибәр. Аннары сөйләрсең...

—Чәй белән генә тынычланып булмас бүген. Син миңа мәен дә бир әле, Саимә.

Самат, каршына куелган рюмканы читкәрәк этеп, стакан сорап алды. Гомер кыланмаганны—аракыны тутырып салды да эчеп тә куйды. Теләр-теләмәс кенә ашын капкалады.

—Саимә, урын салыйк. Бәлки, йоклап китәрмен. Ә син, зинһар, борчылма. Иртәгә барын да сөйләрмен.

Әйләнде-тулганды, әмма йокы кермәде. Самат өчен «Кулга алып төрмәгә утыртсалар, Саимә ничек яшәр? Бала-бала дип эшеннән дә бизеп бара. Әни ничек күтәрер бу хәсрәтне?»—дигән борчулы уйлар аракыдан көчлерәк иде күрәсең.

Уйлар, уйлар... Күз алдына кайгылы йөзле әнисе килеп басты. Бала сөенече, колхоз мәшәкатьләре белән үзенең иң кадерле кешесен

бөтенләй оныткан ич... Үпкәли торгандыр, рәнҗи генә күрмәсен инде.

Агроном вакытларын исенә төшерде. Җирне, жир эшләрен яратты ул. Шуңа күрә бу эшкә бөтен көчен биреп эшләде. Ә жир ул сизгер анадай—үзен яраткан кешене өлешсез калдырмый. Самат агроном булып эшләгән елларда колхоз шактый күтәрелде. Их, нигә генә рәислек дилбегәсен кулына алырга ризалык бирде икән!

Самат уйларына бирелеп озак ятты. Таң алдыннан гына йокыга чумды. Гажәп, шул кыска гына вакытта төшендә әнисен күрде. Имеш, ул ниндидер дога укып анның битләреннән сыпыра. Үзе туктаусыз сөйләнә: «Улым, нишләп битең тулы бетчә? Егет чагың булса, дәрт бетчәсе дияр идең. Нигә битең бозылды, ни булды сиңа, балакаем?» Әнисенең битенә кагылуыннан Самат уянып китте. Күзләрен ачса, әнисе урынында битеннән сыйпап торган Саимәне күрде.

—Эшкә соңладым мәллә?

—Әйе.

—Бюроны исән-имин уздырсам, әнине алып килербез. Бераз тәрбияләп җибәрербез. Әнинең хәер-фатихасын аласым килә.

Самат чәй янында райкомда булган хәлләрне хатынына сөйләп бирде.

—Кемдер авылдагы бөтен хәлне райкомга җиткереп тора бугай. Безгә бик сак булырга кирәк,—дип көндәгеннән бераз соңрак калып эшенә китте.

Юнь хәбәр җәяүләп, ә юньсезе очып килә, дигәндәй, Саматның язмышын бюро хәл итәчәк, дигән хәбәр бөтен авылга таралды. Халык пошаманга калды. Бригадирлар, егетне харап итәргә жыеналар бугай, әллә бюрога кадәр колхоз исеменнән вәкилләр җибәрергә микән, дип кинәшеп алдылар. Бу көннәрдә авыл кешеләре рәисне яклау ниятендә иде. Әлеге хәбәр Шакирлар өен дә читләтеп үтмәде. Иртәгә бюро дигән көнне Шакир өйгә борчылып кайтты.

—Зәйтүнә, тыңла әле. Бүген әбиттән соң райком палнамучие кәнүшнигә керде. Миннән сораша башлады бу. Сүзе атлар турында түгел, ә Самат турында. Балниста синең хатын белән персидәтел хатыны бергә бәбиләгән икән, алар сезнең кызны алган, ди. Ә сез үз балагызны сорагач, персидәтел сезне куалап чыгарган, ди. Булдымы шундый хәл, ди. Ярый ла тел төбенә вакытында төшенеп өлгердем. Керә-керешкә ошамаганые аны, дапрус аламыный. Әйе, авылда шундыйрак сүз йөрде, дим. Тик монда Саматларның гаебе юк, салган баштан үзем чыгарган сүз бу, дим. Ә сүз, авызыннан бер ычкынгач, йөз төрлегә әйләнә, дидем.

Иренең бу гамәлен Зәйтүнә хуплады. Бала мәсьәләсенә райкомның кагылуын, шуның белән бу эшне катлауландырырга маташуларын теләми иде ул. Бездә һәрвакыт шулай бит: бер-бер гаебеңне тапсалар, сине бар яктан каралтырга тотыналар. Ничек йоклавына кадәр тикшерәләр.

Авыл халкының бу атнада аерата тырышып, көнне төнгә бәйләп эшләве, ашлык тапшыру буенча районда беренче урында баруы Саматның күңелендә якты өмет тудырды. Яклаучыларым бар икән дип сөенеп йөрде.

Әмма бюроның барышы анның бу өметләрен чәлперәмә китерде.

Беренче булып икенче секретарь сөйләде.

—Иптәшләр, «Алга» колхозы рәисе Самат Закировның җинаятьләре турында сигналлар ешайды. Тикшерү һәм Закировның үзе белән сөйләшү вакытында фактлар расланды. Язгы чәчүнең дәүләт планы үтәлмәде. Инде беренче суккан ашлыкны, дәүләткә тапшырасы урында, колхозчыларга өләшкән. Илдә, понимаешь, сугыштан соңгы торгызу эшләре, зур төзелешләр бара. Дәүләткә икмәк җитми. Партиянең төп бурычы—эшче халкын икмәк белән тәэмин итү. Ә Закиров нишли? Партия линиясен җинаятьчел рәвештә боза.

—Колхозчы дәүләт кешесе түгелмени?—дип каршы төште Самат.

Бюро утырышын алып баручы беренче секретарь өстәлгә сугып:

—Син нәрсә, Закиров, монда базар ясыйсың?! Әйтәсе сүзеңне

үзенә чират житкәч әйтерсен,—дип кычкырып жибәрде.

Самат имәнеп китте. Беренче мона кадәр ана мәрхәмәтле карый иде бит. Хәтта күп кенә эшләрен хуплый иде. Ә бүген йөзе үтә ачулы. Беренченең кычкырып куюы икенчене канатландырып жибәрде.

—Зөфәр Хәкимович, беседа вакытында да үзен яман да тупас тотты ул, гаебен танымаска маташты. Иртәрәк мактап жибәрдек без аны, масаюының чиге-чамасы юк. Шуна күрә хәзер үзенә әллә ниләр позволяет, колхоз милкен урлаучыларны да яшереп бара, димәк, караклыкка юл куя. Между прочим, безнең арада, то есть партия сафларында, мондыйлар булырга тиеш түгел! Минем тәкъдимем: партиядән чыгарырга, эшеннән алырга һәм судка бирергә.

Самат нәрсә юраса да монысын ук көтмәгән иде. Тәне кызыша башлады, маңгаеннан тир бәреп чыкты.

Икенче сүзне бюро әгъзасы—прокурор алды.

—Чыннан да, предколхозлар арасында закон бозуларга юл куючылар күренгәли. Күбрәк үз белдекләре белән эшләргә яраталар. Бу өлкәдә райком йомшаклык күрсәтмиме икән, дим. Бүген Закиров тиешле җәзасын алырга тиеш. Башкаларга сабак булыр. Мин әйтелгән тәкъдимгә кушылам.

Бу минутларда Саматның эчке кичерешләрен бирәү дә сизмәде. Аның партбилетын өстәлгә ыргытып: «Мәгез, авыл кешесенә кол итеп караучы, рәисләрнең аз гына булса да, үзе теләгәнчәрәк эшләргә хокукларын кысучы партия кемгә кирәк?! Ана бит мин бөтен күнелем белән ышанганыем. Бар көчемне биреп, ал-ялны белмичә эшләдем. Шуның өчен мина төрмә ишеген ачарга торасызмы? Мин үзем үк теләмимм бу партиядә калырга!..»—дип ишекне каты ябып чыгып китәсе килде. Хәтта талпынып ук куйды. Нәкъ шул мәлдә Беренченең җылы карашын тойды. Саматның ни эшләргә җыенганын сизеп: «Җүләрләнмә, кызма, сабыр һәм тагын бер кат сабыр»,—дия иде кебек бу караш.

Бюроның өченче әгъзасы, район гәзите мөхәррире күп сөйләмәде, алда әйтелгән фикерләргә кушылуын гына әйтте.

Күрше колхоз рәисе Хәлим абый сүз сорады. Күкрәге тулы орден-медальләр иде аның.

—Мин партиягә Сталинград өчен сугышкан чакта кердем. Үлә калсам, коммунист булып үлүне дәрәҗәгә санадым. Сугышта бер аягымны калдырып кайттым. Әйе, без сугышта илебез алга барсын, халкыбыз хәерчелектән чыксын өчен кан койдык. Сугыш бетте, фашизмны жиңдек. Шундый дошманны жиңгән халыкның туйганчы ашарга хакы юкмы? Әгәр дә без, коммунистлар, Самат шикелле егетләрне бер селтәнүдә төрмәгә тыга башласак, белмим, кая барып чыгарбыз икән. Мин аның ничек эшләвен күреп торам. Кайбер мәсьәләләрне үзенчәрәк чишә икән, бу нинди жинаять булсын. Ул—төпле белемле агроном. Безгә аны кыйнарга түгел, киресенчә, ярдәм итәргә кирәк. Ә кайбер хаталары өчен шелтә бирү житеп ашкан.

Саматның иелгән башы күтәрелә төште. Сүзне райкомның өченче секретаре алды. Ул утыз биш яшьләр чамасындагы хатын, чәчләрен җыйнак кына итеп артка өйгән, өстендә зифа гәүдәсенә сыланып торган кара костюм-юбка, костюм эченнән якасы бераз гына ачылган жете ак кофтасы күренеп тора. «Чибәр каһәре, килмәгән жире юк! Инде әйтәсе сүзе дә ягымлы булса»,—дип уйлады Самат.

—Иптәшләр, мин Хәлим ага ягында. Райком бюросы җәза бирү урыны гына түгел. Партиянең төп бурычы—дөрес тәрбия. Аерата Закиров шикелле яшь житәкчеләр белән тәрбия эшләре даими алып барылырга тиеш. Өлкә комитеты оештыра торган, житәкчеләрнең белемен күтәрү курсларына жибәрергә кирәк аны. Эшли башлавына биш ел да юк бит әле. Жибәргән хаталары—яшьлеге һәм тәҗрибәсезлеге нәтиҗәсе. Шуна күрә бүген шелтә белән чикләник.

Бу минутларда Икенченең башына: «Кара, ничек яклый, араларында гыйшык-мыйшык юк микән? Болар артыннан күзәтергә кирәктер, пожалый»,—дигән фикер килде.

Беренче секретарь:

—Бер бюро әгъзабыз, районбашкарма рәисе, Казанда кинәшмәдә. Хәзергә аның фикерен белә алмыйбыз. Әмма ул Закировның киләчәгенә зур өметләр баглый. Хәзер исә Закировның үзен тыңлап карыйк. Минемчә, ул үзенең хаталарын аңлагандыр,—диде.

—Әйе, бик күп нәрсәне аңладым. Моннан соң башкачарак эшләрмен...

Ул бу сүзләрне шундый итеп әйтте ки, аңлаган кешегә аның сүзләре партиягә һәм мондагы халык мәнфәгатенә төкереп караучыларга суд карары булып яңгырады.

Соңгы сүзне Беренче әйтте.

—Беренче юлга, эшендәге хаталары өчен, Закировка каты шелтә бирик. Киләчәктә төрле экспериментлар ясарга теләсә, элгәре безнең белән киңәшер...

Ике тәкъдим дә тавышка куелды. Дүрткә ике исәбе белән Беренче тәкъдиме үтте. Бюродан соң Саматны Беренче үз янында калырга кушты.

—Ну, герой, ни хәл? Ниләр уйлап утырдың?

—Әгәр сезне обкомга алсалар, сезнең урынга икенче секретарьне калдырсалар, бу эштә калып булмас, дип утырдым. Ул «беренче» булырга бик тырыша, диләр.

—Каян алып әйтәсең моны?

—Хәлим абый каяндыр ишеткән, ул да борчыла. Зөфәр Хәкимович, сезнең күчү хәбәре дөресме? Обкомга кем итеп алалар?

—Белмим әле, Самат, обкомгамы, әллә еракларакмы, хәзергә билгесез. Ә син саграк кылан, әтәчләнмә. Синең гамәлләреңне мин кеше буларак яклыйм. Әйе, ач халыкны ашатмыйча эшләтеп булмый. Әмма райком секретаре буларак сине җәзасыз калдырырга хакым юк иде. Үзең беләсең, бу сөйләшү ике арада гына калырга тиеш. Синең белән эш майтарырга була! Авыл хуҗалыгын аякка бастырырга, нәкъ менә синдәй житәкчеләр кирәк. Ярый, сау бул. Үзеңне югалтма!

Бюродан Самат каршылыклы уйлар белән кайтты. Үзен хаклы санады. Шиксез, халыкның тамагын туйдыру кирәк. Әмма зур гына житәкчеләрнең моны жинаятькә санавы бик гаҗәп. Беренче белән икәүдән-икәү сөйләшү генә аны бераз тынычландырды. «Әйбәт кешеләр дә бар бит әле дөньяда»—дигән уй ярсуын басарга ярдәм итте. Ут йотып, үзен көтеп утыручы Саимәсен күз алдына китереп, Самат туры өенә ашыкты. Капкадан керүгә ачык тәрәзәдән ишетелгән моңлы бер җыр күңелен айкап алды, хәтта туктап калды. Өр яңа җыр! Саимәнең күңеленнән моң үзәкләрне өзеп өргыла иде:

> Агыйделкәйләрнең суы салкын, Рамай,
> Икәү бергә ничек йөзәрбез?
> Икәү бергә ничек тә йөзәрбез, Рамай,
> Аерылышсак, ничек түзәрбез?

Самат тәрәзә каршына килеп:

—Нигә шулкадәр моңая икән минем сайрар кошым?—дип әйтүгә, Саимә ире каршысына атылып чыкты да аның кочагына ташланды.

—Ни хәлең бар, әтисе? Бюро ничек бетте?—диде.

—Начар ук түгел. Каты шелтә чәпәделәр. Зөфәр Хәкимович урынында икенче секретарь кебек кеше булса, башны ашыйлары. Ай-яй, әшәке кеше икән ул!—дип Самат бюрода булган хәлләрне кыскача гына хатынына сөйләп бирде.

—Аллага шөкер! Ахыры хәерле булсын инде. Гүзәл бүген бик көйсезләнде. Әллә минем борчылуым сөт аркылы ана күчтеме. Елады да елады, үксеп бетте. Һич кенә дә юата алмадым. Көчкә йоклап китте.

—Бәлки, аны имчәктән аерырга вакыттыр. Үзең дә бетерешәсең. Тамагына ашамаса, бер хәлие, әйбәт ашый бит ул.

—Бигрәк тәмен белеп имә бит. Ике яшькә каләр имсен инде.

Имидән аерылу—баланың беренче хәсрәте, диләр. Зәйтүнә апайларныкы үзе ташлаган икән, яше тулганчы ук...

—Каян белдең?

—Беркөнне Зәйтүнә апа безгә килгәние, үзе сөйләде.

—Үзе генәме?

—Ания дә барые.

Самат кызыксынуын яшерә алмыйча:

—Йә, ничек? Җентекләбрәк карадыңмы кызына? Безнең берәребезгә охшаш чалымнарын күрмәдеңме? Гүзәлне күргәч, Зәйтүнә апа нәрсә диде?

Чыннан да, Самат хатынының ул баланы күрүен бик тели иде.

—Безнең кыз белән чагыштырганда Ания буйга күпкә кечкенә һәм ябык. Бик аз ашый икән. Безнең Гүзәлнең матурлыгын беркем белән дә чагыштыра торган түгел, әтисе. Мин аны сөеп туя алмыйм. Исән генә булсын берүк. Ания бик китаплар ярата икән. Бер яшьтән сөйләшә башлаган. Гүзәлгә дип алынган китапларның күбесен бирдем үзенә. Безнеке аларны ертып кына бетерә. Шактый гына өс-баш әйберләре бирдем. Ә охшавы... Ни әйтергә дә белмим, Самат...

—Кара әле, минем әни дә мине бер яшең тулуга телең ачылды, ди. Кешеләрне шаккатырганым шул булган, сакаулык бөтенләй булмаган. Өч яшьтә инде укымакчы булып азапланганмын. Менә хикмәт...

Саимә сүзне тиз генә бүтәнгә күчерде.

—Әтисе, кәнсәләрдә көтәләрдер үзеңне. Авылда барысы да синең өчен кайгыра. Халык әйбәт монда. Ә шулай да синең өстән райкомга кем язып тора икән? Мин, Фәридә түгел микән, дип шикләнәм.

—Булмас. Минемчә, аның хәзер бездә эше юктыр. Ипле гаилә корып җибәрде. Тугыз ае тулуга тупырдап торган игезәк малайлар тапты. Кияүгә чыккач ул хәтта тагын да чибәрләнебрәк китте.

Саимә бу сүзләргә тешен кысып кына түзде. Самат чыгып китүгә күз яшьләренә ирек куеп, диванга капланды. Сулкылдый-сулкылдый озак елады, Самат Фәридәне шулкадәр күкләргә чөеп мактар дип көтмәгән иде ул. Үзе гаепле шул, үзе. Күңелендә булса да әйтмәскә кирәк иде. Бигрәк тә бүген, Ания турындагы сүзләрне читкә борганнан соң. Теге көнне Саимә үзе дә, баланы күргәч, аның күз карашында Саматка охшашлык бар кебек булды. Әмма ул бу шикләрен читкәрәк куарга тырышты. Саматка да бу хакта әйтергә базмады.

Бала караваты селкенгән тавышка Саимә, күз яшьләренә чыланып беткән мендәрдән башын күтәреп, бер мизгел аптырабрак торды да кызы янына ашыкты. Каршысында әнисенең йөзен күргәч, Гүзәл елмаеп, йомшак куллары белән әнисенең муенына сарылды. Аннары ачык изүдән кулларын эчкә таба шудырып, әле бер имчәкне, әле икенчесен мәм-мәм, дия-дия сыйпый башлады. Әнисе изүен чишеп, баланы җайлап алдына салды. Ә нарасый, әнисе күзләренә туп-туры карап, бер кулын имчәк өстенә куеп, икенчесе белән әнисенең бил турысын сыпыра-сыпыра тәмләп имәргә кереште. Бу минутларда ана җанында туган искиткеч ләззәтне, тәненең бөтен күзәнәкләренә таралган гаҗәеп сихри рәхәтлекне бала имезүче ана гына тоя ала. Бу табигать ананың хатын-кызга биргән иң зур бүләге. Әле генә түккән күз яшьләре, Самат сүзләреннән хурлану, кимсенүләре әйтерсең лә җилгә очты да югалды. Баланың һәр суыруыннан ләззәтләнеп: «Бәхетем син минем, рәхәтем син минем»,—дип кызының кайнар битеннән үпте Саимә.

Истә-оста югында тилмереп бала көткән вакытлары, ике тулгак арасындагы хыялый минутлары күз алдыннан үтте: «Гаҗәп икән бу кеше дигәнең. Туганнан үлгәнгә чаклы тулгак эчендә яшисең кебек. Тулгак сине бер җибәрә, бер тота. Шул тулгаклар арасында бормалы-бормалы гомер юлы үтә. Бүгенге көнем генә дә күпме кире һәм уңай кичерешләр белән уралды. Аллага шөкер, Саматым исән-имин. Тик күңелен бөтенләй ачып салмады кебек. Миннән дә ризасызлыгы артканы

сизелә. Ни булса да хәерлегә генә булсын инде».

Самат ул кичне соң кайтты. Кичке нәрәдтән соң күрше авылга—Хәлим абыйларның өенә китте. Бюродан соң сөйләшү-киңәшү кирәк иде.

Хәлим абый аны:

—Мактап йөрисең икән,—дип каршылады.—Донбастан бертуган энем кайтып төште, менә шул хөрмәткә сарык чалдык. Әйдә, карчык! Китер ашыңны, чыгар итләреңне, шкаф артында «урыс малае» булыр, аны да өстәлгә утырт!

Өстәлгә, татар хатыннары гына кисә торган вак токмачлы аш, зур тәлинкәгә чөмәләкәй итеп өелгән кайнар бәрәңге белән ит чыгарылды. Яңа суелган сарык ите белән пешкән аштан һәм парлары чыгып торган кайнар иттән килгән тәмле хуш ис Саматның авызыннан сулар китерде. Ул ашый башлагач кына үзенең карыны ачканын тойды. Кунак шахтер белән Саматның серләре тиз килеште. Алар бик тиз уртак тел таптылар.

—Ал әле, энем, гармуныңны! Җырлап басыйк янган йөрәкләрне! Сизеп утырам, күршемнең дә бүген йөрәгеннән кан сава,—дип Саматка карады хуҗа—Бирешмә, туган! Безгә алардан хитрыйрак булырга кирәк. Ә син турыдан бәрмәкче. Туры әйткән туганына ярамый, диләр. Ә райкомныкылар тем пачи. Алар үзләрен Алланың кашка тәкәсенә тиң саный. Серкәләре су күтәрми.

Шахтер егет үзе уйнап, үзе җырлап җибәрде. Һәм күзләреннән кинәт бәреп чыккан яшь бөртекләрен сөртеп, кулындагы гармунын Саматка сузды:

—Уйныйсыздыр бит?

—Ничек кенә уйный әле! Вообщем, гармун уйный белмәгән татар юктыр,—диде хуҗа.

Самат әкрен генә, гаҗәп моңлы тавыш белән «Уел» көенә җыр башлады.

Арысландай киек һич курыкмас,
Каршысында биек тау торса.
Ирдәй генә егет һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса!..

—Ну өздерәсең дә инде, малай! Бюрода шулай итеп җырлап җибәрсән, нишләрләр иде икән әй! Валлаһи, шартларлар иде! Кайберләре дим. Кая мин дә «Алмагач»ларын сузып карыйм әле...

—Их, чорт возьми!—диде дә яраткан җырын башлады.

Алмачуар иде бит,
Сөеп җиккән атларым.
Бер нәрсәгә исем китми
Үтә егет чакларым...

Балаларны уятмагаек, дигәндәй, тыйнак кына көлешеп алдылар. Өчесенең дә кәефләре галәмәт шәп иде.

Кичке уңнарга чаклы Саимә тынычлыгын сакларга тырышты. Бер яктан, Саматның озак кайтмавы борчыса, икенчедән, бала турындагы шик-шөбһәләр җанын телгәләде. Гүзәлне үз баласы түгелдер, дип күз алдына китерергә теләмәде ул. Анияне күреп калгач, ул бала да якын кебек тоела башлады.

Кинәт көнеле яктырып киткәндәй булды. Әгәр Зәйтүнә апа тагын авырга узып, бер кыз алып кайтса һәм Анияне бөтенләйгә безгә бирсәләр?! Их, шулай гына булсачы!!. Икесен дә үзләренеке итәрләр иде.

Самат таңга таба гына шактый кызмача кайтты. Хатынына битараф караш ташлап:

—Ашарга әзерләмә, бар, ят, йокла,—дип чишенмичә генә залдагы диванга ауды.

* * *

Самат көне буена ашкынып йөрде. «Нигә шулай ашкынам сон? Йөрәк күкрәк читлегеннән чыгып очардай булып ярсый—хәерлегә булсын»,—дип капканы ачып җибәрсә, ни күрсен—ишегалдында әнисе басып тора.

—Әни, җаным! Өнемме бу, төшемме? Инде кайчаннан бирле сине алып киләм, дип җыена идем. Үзен килеп әйбәт иткәнсен. Мина рәнҗеп беткәнсендер. Күптәннән хәленне белә алмадым. Ничек, кем белән килден?

—Юк, улым! Рәнҗеп түгел, сагынып килдем,—дип әнисе күз яшьләренә тыгылды.—Үсеп җиткән балаларнын үз дөньясы, үз мәшәкатьләре тулып ашуын беләм ич мин. Сагынуларыма ничек тә түзгән булыр идем, ләкин сонгы вакытта нигәдер төшкә бик еш керәсен. Җитмәсә, гел малай чагындагы кыяфәттә, үзен күнелсез шундый. Сезнен районга килүчеләргә энен утыртып җибәрде. Ә аннары ашлык тапшыручы авылыгыз кешеләрен очраттым, рәхмәтләр яусын үзләренә. Ни хәлен бар, балам? Эшендә борчулар булды мәллә?

Шулчак монарчы күзгә чалынмыйча торган Гүзәл әтисенен аякларына килеп уралды. Әтисе аны күтәреп алды.

—Әни, Гүзәлне ошаттынмы? «Әббә» дип әйтмәдеме әле?

—Бу баланы да ошатмасан, Алла каргар. Сокланып туя алмаслык матурлык Саимәләр ягыннан киләдер инде. Безнен нәселдә дә ямьсезләр юк югын. Син үзен дә, Аллага шөкер. Әмма Гүзәл...

—Әни, Самат, әйдәгез чәем кайнады,—дип Саимә әтисе кулыннан баланы алды.

Саимә төчегә пешергән коймакны табын уртасына куйган. Олы түгәрәк подноста җиз самавыр гөжләп утыра. Табынга утырышканчы кунак әнисе сумкасыннан каклаган каз, бавырсак, баллы корт, бер банка каймак алып өстәлгә тезде, күчтәнәчләрен бирергә дә өлгермәгән икән әле ул.

—Минем нилэр яратканны онытмагансын икән, әни.

—Һи, үз баланнын гадәтләрен онытасын диме инде?.. Сөт аертканда сипарат тирәсендә кашык тотып бөтерелгәннәрен әле дә булса күз алдымда.

Саимә белән Самат көлешеп алдылар.

—Шулай каймак ярата идемени?—диде Саимә кайнанасына карап.

—Бәләкәй чакта каймакны, үсә төшкәч матур кызларны бик яратты.

—Шуна күрә озак өйләнми йөргәндер инде,—диде Саимә.

Саимәнен чәе сөтсез, коймагы ләчтирәк булса да, кайнана анымоны сиздермәде, улынын да, килененен кәефен бозасы килмәде.

Ә улы белән икәүдән-икәү калгач:

—Улым,—диде,—табыныгыз ярлырак. Чәйгә салырга ни сөтегез, табынга куярга ни маегыз, дигәндәй. Әллә сыерыгыз юкмы?

—Сыер бар иде дә, былтыр Хәдичә апаларнын сыеры зыянлагач, сыерны ана бирдек. Хәзер ул сөтне-майны кирәк булган саен безгә китереп тора.

—Хәдичә кем була инде?

—Үзебезгә йорт салып чыкканчы, без аларда торган идек.

—И улым, улым, авылда яшәп сыер да асрамагач, нәрсә була инде бу? Ин булдыксыз, ин ялкау кешеләр генә сыер тотмый. Хәтта сугыш елларында да без сыердан өзелмәдек, шунын белән тормышнын ертык җирләрен ямап тордык. Син сыер да асрый алмаслык бала булдынмыни, улым? Сарыкларыгыз да юкмы?

Самат әнисенен сүзләреннән уңайсызланды, билгеле. Әмма сер бирмәскә тырышып:

—Мал-туарнын мәшәкате ерып чыккысыз. Ашарына җиткермәле түгел. Колхоз рәисе башым белән курмы әзерләп йөрсәм, мин бүтәннәрне ничек тыярга тиеш, ди. Райком бу мәсьәләдә бик каты. Аннары Саимә дә шәһәр кызы. Мал-туар тотунын рәтен белеп бетерми.

Самат хатынының сыер сава белмәвен әнисенә әйтергә оялды. Әмма сизгер ана сүзсез дә улын төшенде.

—Тыңлап-тыңлап торам да, исем китә сиңа, улым. Райком, имеш, сугыш елларында бер кесә башак, бер кочак печән өчен төрмәгә утырталар иде. Аңа карап халык малдан аерылмады. Шуның белән илне дә, үзен дә ач үлемнән саклап калды. Мал-туарсыз ишегалды—баласыз йорт кебек ятим бит ул. Урам тутырып көтү кайтулары, шул көтүдә синең сыерың, сарыкларың булуы җан рәхәтлеге ләбаса. Ә сез коры кашык ялап утырасыз.

—Син, әни, бигрәк инде. Без сөттән-майдан аерылмыйбыз. Саимә яшь бала белән утыргач, мал-туар карарга вакыты юк дип кенә сыерны Хәдичә апаларга биреп тордык.

—Сыер бәләкәй арба түгел, аны кешегә биреп тормыйлар. Саимәнең дә сыер сауганнан укасы коелмас. Артык иркәләп җибәргәнсең бугай син аны.

—Бала имезә бит әле...

—Балагызны әллә кайчан имидән аерырга вакыт инде. Артык иркәләү баланы боза гына.

—Син дә безне иркәли идең, аңа карап бозылмадык бит әле,—диде Самат.

Зәйнәп улының бу сүзләреннән соң йомшара төште һәм:

—Хәйләкәр син, салам кыстыра беләсең,—диде.—Ләкин, улым, ир кеше—гаилә башы, нык булырга тиеш ул. Хатын ирдән аз гына булса да куркып яшәсен.

—Әни, сезнең заманнарда, бәлки, шулай булгандыр. Бер-береңә хөрмәт куркуга нигезләнергә тиеш түгел ич,—дип Самат үзенекен расларга тырышты.

Саимә, Гүзәлне имезгәч, самавыр яңартты. Ул арада сөтен-каймагын күтәреп Хәдичә килеп җитте. Бераздан хуҗабикә аш өлгертте. Кич буе туйганчы сөйләшеп утырдылар.

Хәдичә белән Зәйнәп күптәнге ахирәтләр кебек, хәтта сугыш чоры хатирәләрен яңартып алдылар. Соңыннан Хәдичә өстәл җыештырып йөрүче Саимәгә ымлап:

—Бигрәк пар килгәннәр инде. Ходай бәхетләрен бирә күрсен,—дип сүзне йомгаклап кайтырга җыенды.

Табак-савытларны юып бетерүгә Саимә урын җәя башлады.

—Самат, әнигә урынны диванга җәярмен инде. Син раскладушкада ятарсың.

—Ничек?—дип сорады Зәйнәп аптыравын яшермичә.—Әллә хәзер ир белән хатынның бергә йоклау мудысы беттеме?

—Минем янда Гүзәл йоклый, яныма Самат та ятса баланың ялгыш берәр җирен авырттырмагае дип куркам,—диде Саимә.

—Бала үз караватында йокларга тиеш!

—Аны бит төнлә имезәсе дә бар,—дип Самат хатынын яклады.

—Һы,—диде Зәйнәп,—имезәсе бар икән! Күпме имәргә була ул имине. Күптән аерырга вакыт. Ә син...—диде Зәйнәп Саматка уклы караш ташлап,— бөгәрләнеп раскладушкада ятарга җыенасыңмы? Әгәр мин әтиегезне раскладушкада яткырсам, өйдә мәхшәр кубар иде. Салыгыз баланы үз караватына.

Саматның күңеленә әнисенең бу сүзләре сары май булып ягылды.

Зәйнәп яңадан сүз куертып тормады, диванга җәелгән урынга барып ятты. Самат белән Саимә аңа тыныч йокы теләп кече якка чыгып киттеләр.

* * *

Самат район партконференциясенә үзенә бер горурлык белән җыенды. Юл буе эшенә күңеленнән йомгак ясап барды. Шөкер, дәүләткә ашлык тапшыру планы арттырып үтәлде. Колхозчылар да өлешсез

калмады. Бу мәсьәләдә бер тапкыр авызы пешкән Самат хәйләкәр эш итте. Урман буенда колхозның сугыш елларында исәптән сызылган берничә гектар җире бар иде. Самат шунда арпа чәчтерде. Арпа котырып унды. Колхозчыларга шуның уңышын өстәп өләште. Иртә өлгергән арпа, колхозчыларның караңгы келәтләренә кереп урнашты. Урак өстендә секретарь Каенлыга көн аралаш килеп, сугылган ашлыкны себереп диярлек дәүләткә тапшыртып йөрде. Әмма Саматның күңеле тыныч иде. Авыл кешесе кулына кергәнне авызына кабу юлын таба. Күпләрнең ярма ярдыру, он тарттыру өчен кул тегермәне бар. Төн йокысын йокламаса йокламый, әмма ризыгын эшкәртү әмәлен белә авыл кешесе...

* * *

Гаиләдәге үзенә карата җылылыкның кими баруы Саматны нык борчый. Саимәне аңлап җиткерә алмый. Узган төн аны аеруча аптырашта калдырды. Таң алдыннан матур бер төш күреп, җанытәне белән сөясе-сөеләсе килеп уянды ул. Һәм Саимәсе янына күңеле тулы наз белән ашыкты. Саимә дә йокламый икән. Йокы аралаш имчәк суырып яткан кызына үрелгән генә иде, йә Хода! Шул вакыт залдан төшкән зәгыйфь ут яктысында Саимәнең үтә кырыс карашы кадалды аңа.

—Күрмисенмени, бала имезәм бит! Бар, утыңны сүндер дә урыныңа чыгып ят, безне борчыма!

Әйтерсең Саматның битенә бозлы салкын су сиптеләр. Бөтен тәне калтыранып китте. Шулай да, сабыр булырга тырышып, карават читенә, хатыны кырыена килеп утырды.

—Болай яшәп булмый бит, Саимә. Мин яшь, тап-таза ир кеше. Эшемдәге һәрчак башымны тәеп торган борчу-мәшәкатьләрдән бераз арынырга, тынычланырга дип өемә ашыгам. Ә синең бөтен гамең көнетөне балада гына. Аны да гадәтсезлеккә өйрәтеп бетердең, үзең дә йокы күрмисең. Мин бу йортта бөтенләй артык кешегә әйләнеп беттем бугай. Сүз әйтер хәл юк, күз яшеңне агызырга тотынасың. Ни булды сиңа? Бала, диден, балабыз бар. Бер-беребезне иркәләп кенә яшәрлек бит, югыйсә. Нужәли синең үзеңдә бер нинди теләк тумый, нужәли шушы яшеннән бөтенләй сүнден?

—Миңа хәзерге вакытта баладан кала берни кирәкми. Шушы баланы исән-имин үстерә алсам, шул җиткән. Әгәр баласыз калсам, яши алмам, үләрмен... кебек,—диде дә Саимә иренең күкрәгенә башын салып елап җибәрде.

—Ярый, тынычлан. Бу нормальный хәл түгел. Казан врачларына күренергә кирәктер сиңа...

Уйларына бирелеп, ул конференциягә баруын да онытkan иде. Тәмам үз иркенә куелып барган атның кинәт туктап калуы гына аны уятып җибәргәндәй итте. Кай җиргә җиттек соң әле без, Акбәкәл? Ә-ә... Нәкъ шушы төштә Фәридә белән очрашуы исенә төште. Нигә? Бөтенләй истә-оста югында Фәридә...

Конференция Самат өчен көткәннән артыграк җай узды. Беренче секретарь отчет докладында (бәхеткә каршы, аны һаман Казанга алмаганнар иде әле) Саматның фамилиясен еш кабатламаса да, колхоздагы уңай якларны ышандыргыч итеп тәфсилләде. Фәкать өлкә конференциясенә делегатлыкка кандидатурасын караганда гына Икенченең:

—Аның партвзысканиесе бар, строгий выговор,—дигән сүзе залны тын калдырды. Кайсыдыр:

—Аны конференциягә кадәр үк снимать итәргә кирәк ие,—дип тәкъдим итте.

—Дөрес фикер,—дип хуплады Беренче.

Һәм Саматның муенындагы «элмәк» җайлы гына алынды.

Конференция тәмамлангач, Самат беренче мәртәбә өенә кайтырга теләмәде, гәрчә күңеле тулы шатлыклы хәбәрләр булса да. Ул бәйдәге Акбәкәл ягына борылды. Атның ялларыннан назлап торган Фәридәне күргәч, аптырап калды. Үз күзләренә үзе ышанмыйча:

—Фәридә, әллә син инде? Каян килеп чыктың, нишләп торасың монда?—дип сорады Самат.

—Отчет белән килгәнием. Акбәлне күрдем дә, авыл башына хәтле генә булса да утыртып алып кайтыр әле, дип сине көтәм менә.

—Әйдә утыр!—дип Самат Фәридәгә сынаулы караш ташлады. Аннары соклануын яшермичә: сөбханалла! Бала табу сине тагын да чибәрләткән,—дип өстәде.—Керфегеннән гөлләр тама, димме...

Фәридә комач кук кызарды.

—Ә син минем иң җүләр чагым хатасын гафу итә алмадың. Саимәне миннән өстен күрдең. Ә кәк же, ул бит югары белемле укытучы, моңлы итеп җырлый... Ә мин, шулай гына булсам да, иремә чит кеше баласын алып кайтып тоттырмадым.

—Тукта әле, Фәридә! Әллә нинди гайбәткә ышанып ничек әле бу сүзне әйтә аласың? Кеше сүзе кеше үтерер, диләр. Әллә Саимәне хурлау өчен генә тырышасыңмы?

—Башыма тай типмәгән. Авылда сүз таралгач, Шакир абыйларга үзем бардым, үзем карадым ул баланы. Күзләре, чәчләре, тән төсе нәкъ синеке. Бишектәге бала бишкә төрләнә, диләр. Үсә-үсә гел үзең төсле булыр әле, менә күрерсең. Сөйимче бер, дип баланы кулыма алдым да битләреннән, маңгайларыннан үбә башладым һәм егылып китә яздым: башыннан гел синең исең аңкыды... Икмәктер менә, икегездә дә бер ук ис. Нүжәли шул баланы барып карамадың, югыйсә авылда чыккан сүзләрне ишетми калмагансыңдыр. Мин бит Саимәгә әйттем бу турыда. Зәйтүнә апаның кызлары, кәнишне, бик матурлар. Сездәгесе дә шулай матур булса, Саимән, юләр баш, матурлыкка алданадыр. Ул бит аны беркая алып чыкмый. Дикрите беткәч тә эшкә чыкмады. Химия укытырга яңа кеше алдылар. Ул баланы гомер буе яшереп асрый алмассыз бит инде. Их, Самат, Самат, нишләдең син?

—Ярый, Фәридә, бу турыда сүз куертмыйк.

Берәрсе Гүзәл хакында сүз кузгатса аның ачуы ташый иде. Ул атын чыбыркылый башлады.

—Кумачы атыңны, үз көенә генә барсын. Әйтәсе сүзләремне әйтеп бетерим, тагын кайчан күрәм мин сине. Бүгенге очрашуны көтеп күпме хыялландым мин... Син дә мине яраттың бит, Самат. Арага Саимә кермәгән булса, без барыбер бергә булырыек. Сизә күңелем. Эшең әйбәт барса да, үзеңне еш мактасалар да, чын бәхетең юк бит синең, юк бит...—дип Фәридә, Саматның күзләренә туры карап, аркасыннан йомшак кына сөеп алды.

Самат як-ягына күз төшерде дә атын туктатты.

—Фәридә, син бу төшне хәтерлисеңме?

—Әйе, Самат. Мине иң бәхетле дә һәм иң бәхетсез дә иткән җир бит бу. Моннан үткән саен йөрәгем җәрәхәте гел тирәнәя генә бара. Әнә теге куаклык безнең иң сихри урыныбызга әйләнгәние. Авыр, бик авыр мина моннан үтүләре... Үткән саен яшь аралаш бер җырның сүзләрен кабатлап үтәм.

... Тарта күңел һаман, тарта сиңа табан,
Авыр миңа ялгыз чакларда.
Сөенечкә дисәм, көенечкә икән,
Очрашулар шушыякларда.

—Фәридә... Миндә тәмле күчтәнәчләр бар. Беразга гына борылыйк әле шул серле куаклыгыбызга,—дип Самат атны бора ук башлады, тик Фәридә аның кулындагы дилбегәне тартып:

—Юк, инде, Самат,—диде.—«Әйдә, әгәр балаларыңны ал да китик

дөньяның читенә»,—дисең икән, ике дә уйлап тормам. Ә болай юк, җаным! Миннән аны көтмә. Иремә хыянәт итмәм. Беркайчан да!

—Рәхмәт... Гафу ит, Фәридә. Монда үзем генә булса да тукташтыргаламын әле...

Калган юлны сүзне янартмыйча, тын гына уздылар. Акбәкәл инде әйтеләсе әйтелде, кызуласам да ярыйдыр дигәндәй, юырта башлады.

* * *

Беркөн, Самат фермадан уйланып кына кайтып килә иде. Кинәт Шакирлар капка төбендә басып торучы кыз балага күзе төште. «Тукта әле, бу сабый безнең Гүзәлгә охшаган түгелме соң?» Самат атын туктатып балага таба атлады. Ачык капкадан ишегалдына җәһәт кенә күз төшерде. Самат Гүзәлгә дигән конфетны кесәсеннән алып балага сузды.

—Ни атлы син, матурым, исемең ничек?

—Пәния.

—Әтиеннең исемен беләсеңме?

—Беләм, Сакир.

—Әниеннең исеме ничек?

—Дәйтүнә.

—Сенлең дә бардыр әле синең, аның исеме ничек?

—Әния.

—Сөбханалла! Син зур үскән, бик гүзәл кыз икәнсең ич!—дип сөйләнә-сөйләнә баланы күзәтте Самат.

Гаҗәп, Фәния белән Гүзәл арасындагы охшашлыклар күзгә бәрелеп тора икән ләбаса: икесенең дә түп-түгәрәк йөз, сап-сары чәч, сөрмәле зәп-зәңгәр күзләр, төз аяклар. Гүзәленә дә шулай сокланган чакларын күз алдына китерде. Чыннан да, балаларны бутаганнар икән, дигән уй җанын телгәләп үтте. Инде Анияне күрәсе килү теләге аны ихтыярсыз итте.

Керләр күтәргән Зәйтүнә Саматны күреп аптырап калды. Шулай да каушавын басып:

—И-и, исәнме, Самат! Нигә капка төбендә генә торасың, әйдә, өйгә кер,—дип кунакны үзләренә чакырды.

—Рәхмәт, Зәйтүнә апа! Менә Фәния белән гәпләштек әле. Шуннан Анияне дә күрәсем килеп китте. Таза-саумы, үсәме?

—Аллага шөкер! Бик әйбәт үсә кызыбыз. Ап-анык итеп сөйләшә. Апаларыннан әкиятләр укыта. Ишеткәннәрен сөйли ала. Рәхмәт төшкере, Саимә ана китаплар биргән иде. Чәчмичә-түкмичә шул китапларны укысаң, аңа бүтән берни дә кирәкми. Шигырьләрне дә ятларга маташа. Хәтта бер көнне:

Што такой биспокой,
Кияү чыкмый кызларга.
Менә хәзер тәпән алдым
Карт кызларны тозларга,—

дип җырлап та шаккатырды әле ул. Шакирның көлеп эче катты, кызлар да пырх-пырх килделәр. Олылары өйрәткән, җүнсезләр. Өйрәткәчөйрәткәч, матуррак җыру тапмадыгызмы, дигән идем, матур җырдан алай көлмәс идегез әле, әтинең күптәннән болай эче катып көлгәне югые,—дип тагын шаркылдап көлделәр. Шаккатыргыч бала булды ул! Безгә охшамаган диярсең... Зәйтүнә соңгы сүзләренә аерата басым ясады. Самат та моны яхшы аңлады.

—Шакир абый ул балага әле дә кырын карыймы? Электәге кебек тавыш чыгармыймы?

—Юк. Алланың биргәненә шөкер, бик тыныч йөри. Салгалавы да бик азайды. Аниягә дә үзгәрде. Хәтта еш кына: «Карчык, бу бала безнең

нәселдә бер дигән укымышлы зур кеше булыр әле!»—дип әйткәли. Тик Әхмәтем белән Фәниям бик көнче. Шакир аз гына Анияне сөя башласа, шунда ук араларына керәләр. Ә Ания үтә сизгер, алар килүгә читкә тайпыла. Әй, ул баланың зирәклеген сөйләп бетерә торган да түгел...

Бу сүзләрдән соң Саматның күзләрендәге монсулыкны Зәйтүнә йөрәге белән тойды һәм тирән сулап:

—И-и, язмыш, язмыш!—дип куйды.

—Зәйтүнә апа, Ания белән бездә булгансыз икән. Гүзәлне күргәч...

—Яшерен-батырын түгел, Самат энем. Гүзәл суйган да каплаган Фәниям. Кашларының уртадан бераз сынып торуына кадәр безнеке.

—Сез моны Саимәгә әйттегезме соң?

—Бәреп әйтмәсәм дә, аңларлык итеп сиздердем инде. Саимәне, үзең беләсең, алай гына ышандырып булмый.

—Анысы бар...

—Әгәр Гүзәлне Шакир абыегыз күрсәме, билләһи газим, тәгәрәп китәчәк. Фәнияне аерата ярата, әниемә охшаган, әнием истәлеге итеп Ходай бүләге ул миңа, дип сөя. Балалар үсеп җиткәнче төзәтергә кирәк безгә бу хатаны, Самат. Менә шуны сабыр гына аңлатырга тырыштым Саимәгә. Гүзәлне Фәния белән чагыштырып карарга куштым. Кая ул, Гүзәлне кочаклап еларга ук тотынды. Алыштыру турында сүз дә булырга мөмкин түгел, ди. Бирегез безгә Анияне, икесен дә тәрбияләп үстерәчәкмен, ди. Гүзәлдән аерылу миңа үлем белән бер, ди. Сездә булганымны Шакир да белә. Тик аңа Гүзәлнең тач Фәния төсле булуын әйтмәдем әле. Без бик аптырашта. Гүзәл дә күз алдымнан китми хәзер. Ник кенә бардым да, ни кенә күрдем икән, дип тә уйлыйм. Кызганам мин аны. Никадәр тәрбиядә булмасын, нинди генә затлы киемнәр кимәсен, ялгыз ул бала. Капкадан чыгарырга да курка бит аны Саимә. Кыргый булып үсә балакай. Ания уенчыклары янына бара башлагач, аңа бүрегә караган кебек карады. Үзем гаепле шул, үзем. Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, дигәндәй, күрәчәктер инде, нишлисең. Бүлнистә ятканда бер әйләнеп тә карамадым бит шул балага. Ул якка карасам да, Саимәнең сихерләнгән кеше шикелле бәхетле йөзенә соклanудан ары уза алмадым.

—Ярар, Зәйтүнә апа! Без болай килешик: әлегә бу сөйләшү ике арада гына кала күрсен. Сез берәр көнне Ания белән Фәнияне алып, безгә килерсез. Кайчанрак икәнен үзем хәбәр итәрмен.

—Әгәр, дим, әгәр син иртәгә кичке нәрәдтән соң үзең безгә сугылсаң, лутчырак булыр, Самат. Шакир абыеңның да сиңа сөйләр сүзләре бар. Анияне дә иркенләп карарсың. Үскән саен сиңа охшый бара ул.

Самат Фәнияне күрүенә, Зәйтүнә белән иркенләп сөйләшүенә канәгать иде. Аның уйлары Саимәсе тирәсендә чуалды. Бала тапкач, үзгәрде Саимә. Үзсүзлеләнде, һичкем фикеренә колак салмый, кызларның алышынырга мөмкин икәнлегенә ышанырга теләми. Анияне дә күргән бит инде. Нидән курка ул? Табибларның бүтән балага уза алмаячаксың, дигән сүзләре нервыларын әкрен-әкрен кимерәме? Күңеле берәр афәт сизәме? Әллә Гүзәлнең табигатьтә сирәк очрый торган гүзәллегеннән сихерләндеме?

* * *

Икенче көнне Саматның күңеле көр иде. Район үзәгенә барганда юл буе Шакирлар турында уйланды, җыелышта утырганда да онытылып киткәләде. Сөенечле хәл көтүдән җан рәхәтлеге кичерүе иде, ахры. Кибеттән әнисенә һәм Зәйтүнә апага матур кәшемир яулык, Саимәгә капрон оек, балаларга шоколадлар һәм башка тәм-том алды. Көндезен өйдәгеләрне куандырып бүләк-күчтәнәчләрен өләште. Зәйтүнәгә дигәннәрен портфеленнән чыгармады. Кичке ашка көтеп тормаска кушты,

үзенең бераз тоткарланачагын әйтте. Һәм Самат кичке нәрдтән соң Шакирларга китте. Зәйтүнә аны башта барлык балалары белән таныштырды. Чыннан да, Аниядән калганнары сары чәчлеләр, зәңгәр күзлеләр. Арада ин чибәре Фәния икән. Ә малайлар кыяфәтләре белән әтиләренә охшаганнар. Зәйтүнә, Ания белән Фәнияне генә үз яннарында калдырып башкаларын каядыр озатты.

—Кунак килгәч, монсыз ярамас,—дип Шакир өстәлгә бер ярты чыгарып куйды.

—Шакир абый, әйдә яртысыз гына сөйләшик әле,—дип аракыны читкәрәк этте Самат.

—Чәй эчеп алыйк,—дип Зәйтүнә сүзгә кушылды.—Бәрәңге пәрәмәчләре пешергән идем, тәмледерме инде.

Утырыштылар. Самат кызларга күчтәнәчләрен, Зәйтүнәгә бүләген бирде. Ә күзләре гел Аниядә иде. Бу жылы караштан Ания кыюланды, елмаеп Саматның каршына ук килеп басты. Пинжәк кесәсенә кыстырган ручкасын тотып карады. Ә Фәния, үз гадәтенчә, сенлесен читкә төрткәләп, ручканы үзе алмакчы булды. Ания барысын да шаккатырып:

—Әнә, әтигә бар, ул сине ярата. Тимә абыйның ручкасына,—дип Фәнияне бар көченә этә башлады.

—Кил кызым, Фәния,—дип Шакир аны үз алдына утыртты.

—Әти, мина да луска киләк...—дип еларга житеште Фәния.

Самат Аниядән күзен алмыйча, аны сөйләштерергә тырышты. Баланың ачык, матур сөйләменә хәйран калып, анарда үзенә охшаш якларны табып, кайчак сүзсез дә утырды ул. Чәчләренең дулкынланып торуы, мангаеның уң ягына бөдрәләнеп төшүе, күзләренең төсе, бармакларының озынлыгы—барысы да Саматныкы. Әнисе Саматка:—Бармакларың озын, музыкант булмагаен, ди торган иде.

—Зәйтүнә апа, оятрак булса да сорыйм әле, тик ачулана күрмә. Анын йомшак жирендә ясмык хәтлерәк миңе юкмы?—дип сорады Самат.

—Йә, Ходай! Уң ягында матур гына миңе бар! Әллә синдә дә бармы?—дип кабаланып сорады Зәйтүнә.

—Бар шул бар, Зәйтүнә апа!—дип көлеп жибәрде Самат һәм Анияне кочаклап алып алдына утыртты, бөтен тәне буйлап рәхәт бер дулкын узганын тойды.

Тын калдылар. Тынлыкны Шакир бозды.

—Йә, Самат, нишлибез инде? Ярый, сез Зәйтүнә белән барысын анлаштыгыз. Кайчан мина Гүзәлне күрсәтәсез? Ул кем төсле?

Самат белән Зәйтүнә тиз-тиз генә бер-берсенә карап алдылар. Әмма алар бер карарга килгәнче, монарчы тынлап утырган Ания:

—Әти, Гүзәл ул Фәния төсле усал, уенчыкларын мина бирми,— дип әйтеп салмасынмы!

—Әйе, Шакир абый, Гүзәл Фәниянен дәвамы. Әйтерсең лә, алар игезәкләр...—диде Самат.

—Их, жәмәгать! Гүзәл мина әнием төсе итеп Ходайдан жибәрелгән тагын бер бүләк булган. Белеп ярсыган йөрәгем. Анамның вафаты алдыннан теләгән теләген Ходай ишетеп кабул иткән булып чыга түгелме соң? Их, карчык-карчык! Гүзәлне күреп кайткач та теш араннан да чыгармадың бит. Болай булгач, Самат, әни турында сөйләмичә ярамас инде...

Шакир аракысын бер йотып куйды.

—Минем әни авылда гына түгел, бөтен тирә-юньдә дан тоткан ин матур кыз булган. Әнинен әнисе—минем әби инде—чибәрләрнен чибәре саналган. Әйе, матурдан матур туган.

Әби бик яшьли ятим калган. Унбер яшьләрендә аны туганнары Казанда яшәгән бер гаиләгә асрамага биргәннәр. Ә бабай буласы кеше яшьтән үк кырык тартмачы сәүдәгәр булган. Авылга сирәк кайтып йөргән. Әбигә уналты яшь тулыр-тулмас чагында язмыш аны бабай белән очраштырган. Беренче күрүендә үк бабай үлеп гашыйк булган. Әби дә охшаткан күрәсең, күп тә үтми өйләнешеп тә куйганнар. Берничә ел

Казанда яшәгәннәр, балалары булмаган. Революциядән соң авылга кайтканнар. Әти-әниләре аларны куанып каршы алган, киленне дә бик охшатканнар. Авыл кешеләре генә, Габделкадыйр маржа алып кайткан, дип авыз чайкап алган. Чөнки әби сап-сары чәчле, сөрмәле җете зәңгәр күзле, ап-ак тәнле сылу булган. Өстенә кигән киемнәре дә куфты-юфкы икән. Аны бит элек маржалар гына кигән. Авылның бөтен ир-атлары бабайны тәмам аптыратып бетергән. Чибәркәйне күрер өчен юк-бар йомыш табып туры өйләренә килү дисеңме, очраткан бер җирдә бабайны сөйләштерү дисеңме... Хәтта кайберәүләр бабайны: «Андый гүзәлләр бер ир хатыны гына булмыйлар алар, курыкмыйсыңмы? Көнләшмисеңме? Ничава, бәлки безгә дә өлеш чыгар әле»,—дип чеметкәләп тә алган. Бабай андыйларның берсенә шундый итеп кундырган, ди, теге бәндәнең алгы тешләре казнасы белән кубып чыккан. Шуннан соң гына сүзләр тынган. Озакламыйча әби нәкъ үзе кебек үк кыз бала тапкан. Ул минем әни булган. Аңа Бибигайшә дип исем кушканнар. Матур Гайшә дип тә йөрткәннәр. Менә каян килә безгә сары чәчле, зәңгәр күзле матур балалар. Мактанып әйтүем түгел, Самат, үзең күреп торасың. Әби белән әнинең хәер догалары алар, Алланың рәхмәте төшкереләре.

Шакир бераз тын торганнан соң хикәятен болай тәмамлады:

—Әни белән әти әйбәт яшәделәр. Тик әнинең гомере кыска булды, миңа уналты яшь тулган көнне кинәт кенә үлеп китте. Үләр алдыннан әтигә: «Үзеңә бер кыз табып бирермен дигән идем, вәгъдәмне үти алмадым инде, кичер мине, атасы. Миңа охшаган кызларны менә улым Шакир алып кайтыр. Баланың баласы балдан татлы була, ди. Син аларны миннән дә ныграк яратырсың!»—дигән иде. Әмма әтигә оныкларын күрергә насыйп булмады. Әни вафатыннан соң бик бетеренште. Кайберәүләр: «Әхмәтвәли, сиңа өйләнергә кирәк, болай үзенне-үзең ашап йөрмә»,—дип карасалар да, әти: «Минем Гайшәмне алыштыра алырлык җан әле дөньяга килмәгән»,—дип коры гына җавап бирә иде. Һәр көн әни каберенә барып җылый-җылый догаларын укыды. Кайчакларда мине дә ияртә иде. Ә менә әнинең кырыгы тулган көнне иртүк юынды, кырынды, чистарынды. Әни ярата торган зәңгәр күлмәген алып киде һәм үзе генә зиратка китте. Минем дә барасы килгәнне белгәч: «Юк улым, үзем генә. Әниеңнең үзенә генә әйтәсе сүзләрем бар. Коръән укытып, ашын уздыргач, икәү бергәләп барырбыз...»—диде. Шул вакытта әтинең яшь мөлдерәп торган, ачы хәсрәтле күзләрен гомеремдә дә онытасым юк.

Коръән уку сәгате җитте, чакырылган кешеләр дә җыелды. Ә әти юк та юк. Мине зиратка йөгерттеләр. Барып җитсәм, әти әнинең каберен кочаклап йөз түбән яткан. Йоклап киткән ахры, дип төрткәләп карыйм, дәшми. Кулыннан тотып торгызыйм, дисәм, кулы боздай салкын иде. Аркасына әйләндереп салдым, үзем калтырыйм. Әти бәгърем... Ә ул бичара җан, фани дөнья белән бәхилләшеп, әни янына ашыккан. Үзәкләре өзелеп сагынуына артык түзә алмаган...

Әнинең кырыгыннан соң әтинең җеназасы бөтен авыл халкын тетрәндерде. Хәтта бер атнадан үк «Матур Гайшә белән Әхмәтвәли бәете»н чыгардылар. Барысын да хәтерләп бетермим, исемдә калганнарын әйтим әле. Гаеп итмә, Самат.

Бисмилләһи вә билләһи
Житте корбан гаете,
Без әйтиек, сез тыңлагыз,
Матур Гайшә бәетен.

Ходай миңа матурлыкны,
Ниләргә бирде икән?
Гомрем нигә кыска булды,
Кем күзе тиде икән?

Газраил килде каршыма
Җаннарынны алыйм, дип.
Шушы зифа буйларыңны
Җир куйнына салыйм, дип.

Хәлем бетә барган саен,
Сабырлыклар сорадым.
Нинди гөнаһларым өчен
Җир асларына салдың?

Бик күнелсез монда мина,
Синсез Әхмәтвәлием.
Әле дә ярый яннарымда
Газиз туган әнием!

Шакир улым, кызын туса,
Мина охшатып сөярсен.
Сөйгән саен, әнкәемә
Дога булсын, диярсен.

Бердәнберем, сина телим,
Күп булсын балаларын.
Матур булсыннар, дип әйтмим,
Бирсәнче саулыкларын.

Әтиен дә мине сагынып,
Тилмерә бит, көн саен.
Ахры алырмын янына,
Гафу ит, балакаем.

Шакир сөйләп бетергәч, бераз сүзсез тордылар. Сөйләү барышында Зәйтүнәнең күзләре яшь агудан бушап тормады, гәрчә бу монсу хикәятне беренче генә тынлавы булмаса да. Саматнын да күнеле тулды. Аниянең алдына сенеп бетеп, селкенмичә дә тынлавына исе китте анын. Ә Фания читтә курчак уйнап утырды. Самат ихтыярсыз «Менә сина ат караучы Шакир... Әби-бабасынын, әти-әнисенең тарихларын ничек яхшы белә, ә ничек матур итеп сөйли тагын. Зәйтүнә апа да тикмәгә генә көнләшмидер... Матур кешеләр, матур гаилә бу! Кешеләрне аз беләбез шул әле!»—дип уйлап куйды. Зәйтүнәнен: «Безнең Шакир сөйләсә әртисләрең бер якта торсын»,—дип сүз башлавыннан, Самат уянып киткәндәй булды:

—Ну, Шакир абый, тан калдырдың син мине! Әйтәм аны Зәйтүнә апа бик сөйләттерергә теләгән иде. Рәхмәт, Шакир абый! Күп нәрсә анлашылды... Тиздән хатаны төзәтә алырбыз, минемчә. Тик иртәгә үк булмас. Кичә минем әни килде әле.

—И-и, әйтергә онытып торам икән,—дип кушылды Шакир.—Кичә ашлык ташучылар ат туарганда әниең турында кызык итеп сөйләделәр. Болар янына бер хатын килеп туктаган да Каенлыга алып кайтуларын сораган. Рәнҗетмәм, хакын түләрмен, дигән. Кайтканда юлчы хатын сораштыра икән:

—Персидәтелегез нindирәк кеше? Эчмиме? Сүгенмиме? Хатыннар белән гүләйт итмиме? Гаиләсе белән ничек яши?

—Юк, апа,—дигәннәр болары.—Безнең хужа әйбәт кеше. Тик менә авылыбыз кызына өйләнми бераз ялгышты бугай егетебез. Казан кызына өйләнде. Хатыны иркә бугай, укытуын да ташлады. Өенә бикләнеп ята. Бала тапкач, бигрәк йомыкыйланды. Үзләренә кешеләр кергәнне дә өнәми. Бәбиен котларга килүчеләрне дә кертмәгән, диләр. Авылдан өйләнгән булса, кадерле кияү булып, әби тәрбиясе күреп яшәр иде персидәтелебез. Хәзер ни әбисе, ни әнисе. Эше дә авыр, тәрбия житмидер үзенә. Шактый таушала төште.

Персидәтел турында бик күп мәгълүмат алгач кына юлчы хатын үзенен кемлеген әйткән...

—Безнең әнидән булыр!—диде Самат һәм рәхәтләнеп көлде. Анияне кочаклап, үбеп алдыннан төшерде һәм инде китәргә кирәклеген әйтте. Ания Зәйтүнә янына килеп анын колагына:

—Әни, матур абый тагын киләме?—дип пышылдады.

—Килер, килер, кызым.

Сабыйның «матур абый» дигән сүзе Саматның үзеген өзеп алгандай итте.

—Сина нәрсә алып килим сон, кызым,—дип әйткәнен сизми дә калды.

Ания Самат кесәсендәге ручкага карап:

—Ручка, әкиятләр,—диде.

Самат ручканы ана бирде һәм баланы үпте дә, күзенә тыгылган яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, китәргә ашыкты.

* * *

Баласын урлап китәрләр кебек тоелып, йокыдан коты очып уянгалый Саимә. Рәтләп йоклый алмагач көндезләрен гел кәефсез йөри. Вак-төяккә дә күнеле ярсый, кайчак һич сәбәпсезгә үкереп елап җибәрә.

Ниһаять, ире үгетли торгач, Саимә таныш профессорга күренергә ризалашты. Гүзәлне, әлбәттә, Саимә үзеннән калдырмады.

Профессор ханым аларны бераз шелтәләп, әмма ачык чырай белән каршылады.

—Мин инде, бәби булгач кирәгем бетте ахыры, дип уйлаган идем. Теләгегезгә ирешүгә бик шатмын, бәхетле бала булсын! Йә ни хәлләрегез бар?—дип сүз башлауга Саимә тыела алмыйча еларга тотынды, Самат баланы алып кабинеттан чыгып китү җаен карады.

Саимәне озак көтеләр алар. Бүлмәгә ак халатлы бер ханым кереп китте. Гүзәл борчыла башлагач, әллә урамга чыгып торыйк микән, дип кенә торганда, аларны кабинетка чакырдылар. Хатынының елаудан шешенеп беткән йөзен күргәч, Самат тәмам каушады.

—Тынычланыгыз, алай чамасыз борчылырлык нәрсә юк,—дип аңлатты профессор. Баладан соң кайбер аналарда була торган депрессия сезнең хатыныгызны да читләтеп үтмәгән. Саимә ханымның күнеленә курку оялаган. Аны әнә шул эзәрлекли. Моны «мания преследования» диләр. Вакытында дәваласаң, ул куркыныч чир түгел. Тик бераз соңаргансыз. Хәзер аны хастаханәдә бер ай, ай ярым тирәсе дәваларга кирәк булачак. Иртәгәдән дә калмагыз. Соң булса да уң булсын дигәндәй, хәзер бөтен көчне туплап, түземлек, сабырлык белән дәвалану гына ярдәм итәчәк. Бу минем кинәшем генә түгел, бик тәҗрибәле психиатрыбыз да нәкъ шушы фикерләрдә,—дип кабинетка соңыннан кергән ханымга күрсәтте профессор.—Менә сезгә юллама.

—Кайсы хастаханәгә?—дип сорап куйды Самат.

—Бу авыруны фәкать «шунда» гына дәвалыйлар,—диде профессор. Табибның «шунда» дигәне психик авырулар дәваланучы хастаханәне аңлата иде.

Бу җаваптан Самат хәтта агарып китте. Әмма нишләсен, башка чара юклыгын аңлап, үзен кулга алырга тырышты. Ә Саимә янадан бәреп чыккан күз яшьләрен күрсәтмәс өчен кызын ашыга-ашыга кочагына алып, сүзсез генә ишеккә юнәлде. Саматка, мондый очракларда авыруның тизрәк сәламәтләнүе өчен, аның иң зур ярдәмчесе булырга тиешлеген аңлаттылар.

Саимә, куенында йоклап киткән баладан күзен алмыйча, Саматны көтте. Аның йөрәген төрле уйлар яшен кылычларыдай туралый кебек иде. Үзен хастаханәдә ятырлык авыруга санамаганлыктан, докторның хәбәре, күкрәгенә тау аугандай, авыр тәэсир итте. Шулай да ул, Самат профессор яныннан чыкканда, бер карарга килгән иде инде. Ире күренүгә:

—Безнең монда әни ягыннан ерак кардәш тиешле апабыз бар. Ул хәзер пенсиядә. Шуларга барыйк әле. Гүзәлне карап торырга риза булмасмы,—диде.

—Әни янында калдырсак яхшырак бит! Сиңа илтергә тәмле-тәмле әйберләр пешереп торыр иде. Чит кешедә торуга караганда, үзебезнең өйдә Гүзәлгә дә әйбәтрәк инде.

—Юк, баланы авылда калдырмыйм,—дип кырт кисте Саимә. Самат аның теләгенә каршы килә алмады. Хастаханәгә ятудан баш тарта башлар, дип курыкты.

... Хастаханәдә дәвалану озаккарак сузылса да Саимә аннан сәламәтләнеп, төскә-биткә тулыланып, күтәренке күнел белән кайтты. Саматның ике айга якын Казан белән авыл арасында чабулары бушка булмады. Гүзәлне алып калган Бибинур да, гәрчә якын туган булмаса да, яшь гаилә өчен бөтенесен эшләде. Самат аңа мең-мең рәхмәтләр өстенә күчтәнәчләрне мулдан ташыды. Саимә белән бергә ятучы хатыннар:

«Булса да булыр икән шул кадәр түзем, игътибарлы ир! Бигрәкләр дә бәхетле икәнсен»,—дип мактадылар. Болар Саимә өчен зур шифа да иде.

Сабыр төбе сары алтын, дип юкка гына әйтмиләрдер. Хастаханәдән соң өйдә узган беренче төннен ләззәтен һәр икесе тигез татыды. Бер-берсенә карап та, иркәләшеп тә, сөйләшеп тә туймадылар. Беренче мәртәбә кавышкан чактагыча бәхетле төннәренен кабатлануы иде бу. Тан алдыннан гына бер жан булып дигәндәй изрәп йоклап киттеләр. Тик, бер-берләренә артык сусауданмы, мәхәббәтебезгә беркайчан да тап төшмәсен, озын гомерле булсын, дип теләргә оныттылар инде әллә...

Берничә көннән сон Самат:

—Саимә, әгәр без озакка сузмыйча, Зәйтүнә апаны ике кечкенә кызы белән үзебезгә чәйгә чакырсак, ә? Ничек уйлыйсын?—дип сүз башлады.

Бу хакта Саимә дә уйланып йөргән ахыры, иренен сүзен күтәреп алды.

—Күрәчәктән качып калып булмастыр. Аллага тапшырып, чакырыйк. Өчпочмаклар пешерермен. Табын янында сөйләшкәндә, бәлки, акыллырак фикерләр туар.

Кунаклар әйтелгән вакытка килделәр. Бу очрашуны алар да көткән иде. Ишектән керә-керешкә Саимә Зәйтүнәгә карап сокланды.

—Сөбханалла! Зәйтүнә апабыз тагын тулып килә түгелме сон? Кайчангарак көтәбез?

—Берәр атнадан Аллага тапшырасы булыр, дип торабыз,—диде Зәйтүнә.

—Сау-сәламәт, бәхетле бала бирсен Ходай! Әйдәгез, түргә узыгыз, хәзер чәй әзерлим,—дия-дия өстәлгә ашъяулык җәйгән арада Саимә Аниягә карап-карап алды. Ания исә:

—Менә, апа, син биргән матур күлмәкне кидем. Гүзәлгә кәнфит алып килдем,—дип бүлмә ишегеннән кыюсыз гына карап торучы Гүзәл янына барды.

Хуҗабикә үзе янына Зәйтүнәне, каршысына Анияне, анын янәшәсенә Гүзәл белән Фәнияне утыртты. Балаларнын күзләре өстәлдәге сыйларда иде.

—Әйдәгез, кунаклар, житешегез әле!—дип Саимә балалар алдындагы тәлинкәләргә өчпочмаклар салды.

Балалар кыстатып тормады, өрә-өрә тәмләп ашый да башладылар. Бу вакытта Саимәнен сынаулы карашы Гүзәл белән Фәниядә иде. Йә, Хода, никадәр охшашлык! Игезәкләр генә шулай буладыр. Боларнын бер ата-ана балалары икәнлеген күрү өчен менә шушылай янәшә утыртып бер карау да житә ләбаса. Ә Ания? Ул бөтенләй аерылып тора. Саимә, үз нәтиҗәсеннән каушап булса кирәк, авызындагы ризыгын йоталмыйча азапланды. Йөрәгенә килеп бәрелгән кайнар дулкын йөзенә бәргән иде.

Ашап-эчеп бетергәч, ул Гүзәлгә:

—Әйдә, кызым, кунак кызларына уенчыкларынны, китапларынны күрсәтик әле,—дип аларны икенче бүлмәгә чакырды, үзе дә беразга алар янында калды.

Гүзәлнен теле бик авырдан ачылды. Фәния дә, инде алты яше тулып килүгә карамастан, сакау сөйләшә. Ә Ания барлык хәрефләрне белә, иҗекләп укып китәргә маташа. Саннарны таный. Төс-бит ягыннан Саматка охшаш чалымнары да бар кебек. Әнә бит, тезелеп киткән вак-вак тешләренә кадәр Саматныкы! Көлгәндә Саматнын да тешләре ялтырап күренә. Балага күчкән бу елмаю үзенә бер ягымлылык, матурлык тудыра. Шулчак Саимә Анияне кочаклап күкрәгенә кысты. Ике бит уртасыннан үпкәннән сон йөзенә текәлеп карады. Бу дулкынланып торган коңгырт чәчләр, мөлдерәп торган күзләр Саимәгә нигәдер үпкәле кебек тоелды. Үзенен күзләренә мөлдерәп яшь тулды. Бу исә, баласын танып шатланудан бигрәк, аны кызгану яшьләре иде. Мондый халәтен сабыйларга күрсәтмәс өчен кызу гына зал ягына чыкты. Ә анда икенче ана үз уйлары, үз

борчулары белән тынып калган. Саимәнең яшь тулы күзләрен күргәч, әллә аны, әллә үзен кызганып күңеле тулды. Күпмедер вакыт икесе дә, нишләдек соң без, дигәндәй, тын гына елап алдылар.

Сүзне Саимә башлап җибәрде:

—Шакир абый хаклы булган... Чыннан да Гүзәлнең сезнең кыз икәнлегенә мин бүген тәмам ышандым,—диде ул авырлык белән.

Күңелендә туган бу хакыйкатьне кычкырып әйтү үзенең хаксызлыгын тану иде. Ә хаксызлыкны тану беркемгә дә җиңел бирелми. Моны икесе дә яхшы аңлый иде.

Зәйтүнә Саимәнең хастаханәдә тәмам терелеп, элекке Саимәгә әйләнеп кайтуына сөенеп, фикер йомгагын чуалтмаска тырышты.

—Мин дә каршымда утырган Гүзәлдән күземне ала алмадым. Кысып-кысып кочаклыйсым килде үзен! Синнән генә уңайсызландым... Рәхмәтләр яусын чакырып кунак итүегезгә. Алла боерса, алда да аралашып яшәрбез. Анияне без дә бик яратабыз. Гүзәл белән икесе бергә әле сезгә, әле безгә кунакка йөрерләр. Шулай итеп балалар чын әти-әниләренә ияләшерләр. Без аларга хакыйкатьне җаннарын яраламыйча гына аңлатырбыз. Тамчы тама-тама ташны да тишә дигәндәй, иншалла, дөреслек балалар күңеленә барып житәр.

Бу сүзләр Саимәгә дә хуш килде.

—Зәйтүнә апа, әйдә, болай итик. Бүген кызлар бездә калсын! Аларны әле Самат та күрмәде. Ул бит без иркенләп сөйләшсен дип, әбәдкә дә кайтмады. Кич буе уйнасын, сөйләшеп рәхәтләнсен үзләре белән. Беразга гына булса да дөнья мәшәкатьләрен онытып торыр. Соңгы вакытта әле райком, әле партком гел талкый үзен.

Зәйтүнә, кайтырга кирәк инде, дип кузгала башлады. Шуны ишетүгә балалар йөгерешеп чыкты. Саимә аларны бергә-бергә уйнарсыз, дип куна калырга чакырды. Ания риза булды, тик Фәния:

—Юк, мин әни белән өйгә кайтам. Безне анда әти көтеп утыла. Ания калсын,—дип әнисенең итәгенә килеп ябышты. Шулчак Зәйтүнә үзенә зәп-зәңгәр күзләрен тутырып сәерсенеп карап торучы Гүзәлне кочагына алды. Нарасыеның җылы сулышыннан, битләре битенә тиюдән искиткеч рәхәтлек тоеп онытылып торды.

—Балам, минем йөрәк җимешем бит син!.. Ания белән безгә кунакка килерсең, безнең кызыбыз булырсың, яме?

Әмма әти-әнисеннән башка кешеләрдән кочтырырга өйрәнмәгән Гүзәл, Зәйтүнәнең кочагыннан чыгып, Саимәгә килеп сарылды...

Самат каршысына йөгереп чыккан Гүзәл белән Анияне икесен берьюлы күтәреп алды. Ания шунда ук:

—Апа, апа! Мин бу матур абыйны беләм. Ул миңа тәти ручка бирде. Менә шуннан алып,—дип Саматның түш кесәсенә күрсәтте.

Моңа Саимәнең гаҗәпләнүен күргәч, Самат:

—Ярар инде, матурым, бөтен серне ачып бетермик,—дип Аниягә текәлде.

Самат кызлар белән мәш килгән арада Саимә тиз генә өчпочмакларын җылытып, яңадан табын әзерләде. Ашап туйгач идән уртасындагы урындыкларны читкәрәк җыеп Самат балалар белән уйнарга тотынды. Кызларның күңелен күтәрер өчен нәрсә генә эшләмәде ул. Кыз балалар, гадәттә, ир-атка тизрәк ияләшә. Саматны Ания бик тиз үз итте. Ат булып, идәндә дүртаяклап йөргән Саматның сыртына ук менеп атланды. Әлбәттә инде, аты булгач, йөгән дә кирәк. Ат караучы гаиләсендә үскән Ания моны әйбәт белә. Һәм әлләни арада Саимәнең халат путасын табып «атын» йөгәнләп тә өлгерде.

—«На, на, бахбай!»—дип Саматның ян-якларына аяклары белән төрткәндәй итте. Самат-ат кешни-кешни алга чапты.

Әтисенең өстенә Ания менеп атлангач, Гүзәлнең көнчелеге уянды.

—Тит аннан, бу минем әттәм,—дип ул Анияне әтисенең өстеннән төшермәкче булды.

Ләкин Ания жайдак роленә кереп өлгергән иде инде, Гүзәлгә бирешергә теләмәде.

—Бу уенны мин таптым,—диде ул. Самат кызларның һәр икесен үзенә якынайтырга теләп:

—Килегез әле, кызыкайларым, безнең бахбайның сырты зур, икегез дә сыярсыз,—дип Ания янына Гүзәлне атландырды.—Бер-берегезгә тотынып утырыгыз, юкса бахбай дулап китәр дә егылып төшәрсез, әй... Бу күренештән Саимәнең күңеле тулды, күзләре яшьләнде. «Мин дә укытучы булып йөрим инде, менә ул чын педагог икән бит...»

Уеннан барысы да бик канәгать иде. Шунда Саимә:

—Их, Самат, болар икесе дә безнеке булса иде,—дип куйды.

—Ходай исәнлекне бирсен, Саимәм! Ике дә, өч тә, дүрт тә булыр! Миңа иптәшкә малайлар да алып кайтырсың әле... Без кемнән ким ди?!—дип, Самат Саимәне күтәреп алды да бөтерелә башлады. Ә Саимә иренә туры җавап бирмәде, ул үзенең янадан балага уза алмаячагын Саматыннан да яшерә иде. Әмма күңелле ыгы-зыгының озаграк дәвам итүен чын күңеленнән теләгәнгә күрә, үз хәлен бүген дә сиздермичә уенга кушылды. Шулчак Ания:

—Безнең әтиләр болай уйный белмиләр,—дип өлкәннәрнең кәефен тагын да күтәреп җибәрде.

Аннары Ания табын янында яттан шигырьләр сөйләде. «Һәрвакыт булсын кояш»,—дип җырлап та күрсәтте. Саимә аңа сокланып туя алмады:

—Мин, җүләр, тәмле соклар эчереп, ризыкларның иң витаминлыларын гына ашатып, бөтен яктан сәләтле бала үстерәм, дип хыялланып йөрдем. Нәселдән килә торган дәвам турында уйлап та карамадым. Киресенчә, Ания нәрсә күрә инде ул йортта, дип хафалана идем. Алыштырырга каршы булуымның сәбәбе дә шул иде бугай. Зәйтүнә апаның барлык балалары да төскә матур, эшкә уңган, сүз тыңлаучан, тәртипле булсалар да, укуга никтер бик атлыгып тормыйлар. И Ходай, бу эшләрнең ахыры ни белән бетәр? Балаларны алыштыру—кием алыштыру гына түгел бит. Балаларияләшкән киемнәрен дә салырга ашыкмыйлар.

Саматны да шундый уйлар борчый иде. Үзләре генә калгач ул Саимәгә:

—Аниядә миңа охшаш чалымнар күрәсеңме?—диде.

—Күрмәгән кая! Җырлавын гына ал син аның. Моңы, тавышы бар. Ә бит Шакир абыйларның бер баласы да җырламый. Эчке бүлмәдә синең баяныңны кычкырткалап карады Ания. Үзе төймәләрен баса, үзе, нинди тавыш чыгар икән, дигәндәй, озаклап тыңлый. Безнең Гүзәл ул баянга тотынып та карамый.

—Йокларга яткырганда йомшак җирен кара әле Аниянең. Минеке төсле миңе юкмы икән?—дип серле генә итеп сорап куйды Самат.

Дуслашып өлгергән балалар йокларга ашыкмадылар. Алар Саимәнең көзге каршындагы иннеген алып битләрен, ирennәрен буяганнар. Биек үкчәле туфлиләрен берәр аякларына гына кигәннәр. Муеннарына мәрҗәннәрен асканнар. Кызларның кыланышын Самат белән Саимә шатланып күзәтте. Гүзәлнең моңа чаклы болай онытылып уйнаганы юк иде.

—Менә, Саимә, кызларың күбәйсә иннек-кершәннәрең үзенә тәтемәс тә әле,—дип Ания янына килде Самат.—Әллә безнең кызыбыз гына буласыңмы, матурым? Мин бик күп китаплар, ручка-карандашлар алып кайтырмын сиңа.

—Юк, мин әнигә кирәк. Иртәгә өйгә кайтам,—дип Ания Саматның күкрәгендәге значогын боргалады.

Әле генә сөенеп утырган әти-әни авыр сулап куйды. Хыяллары күгеннән тирән бозлы суга егылып төштеләр сыман...

Балалар изрәп йокыга чумгач, икесе дә әкрен генә алар янына керделәр. Самат чалкан ятып йоклап киткән Аниянең түп-түгәрәк матур миңеннән, аннан чәченнән үбеп алды. Өстен япмый йоклап киткән Гүзәлнең юрганын төзәтеп япты, дулкынланып торган сап-сары чәчләрен

йомшак кына сыпыргач, Саимәсенә күз төшерде. Ләкин хатынының бу минутларда нәрсә уйлавын белмәде. Ә Саимә: «Зәйтүнә апа тагын бер кыз алып кайтса, бәлки, бу ике сабый гел бергә шушы йортта калыр әле»,—дигән хыялга чумган иде.

* * *

...Зәйтүнәне ашыгыч кына район үзәгендәге бала табу йортына алып киттеләр. Самат бу хәбәрне хатынына әйткәч, Саимәнен йөзе май кояшыдай балкыды. Инде Аниянс карап торырга сораганын да белгәч:

—Йә, Раббым, Шакир абыйларга тагын бер кыз бирсәнче...—дип әйткәнен сизми дә калды.

Иртәгесен Зәйтүнәнең малай табу хәбәрен ишеттеләр. Аниянең киенә башлаганын күргәч, Саимә:

—Балам, кая җыенасың?—диде.

—Өйгә кайтам.

—Әниең кечкенә бәби алып кайтырга китте. Әниең кайтуга бәби карарга бергә барырбыз. Гүзәлне дә үзебез белән алырбыз, яме. Әлегә бездә торып тор. Без сине бик яраттык. Гүзәл дә сине җибәрмәскә куша. Шулаймы, кызым?

—Тулай. Ания титмәсен.

Бөтен игътибар үзенә юнәлтелгәнгәме, Ания ризалашты. Гүзәл гел Ания тирәсендә бөтерелде. Икәү бергә уйнау кызыклырак икән шул.

Өч көннән соң Аниянең түземлеге бетте. Иртәнге чәйне эчкәндә үк Гүзәл белән бергә үзләренә кайтарырга ялынды. Саимәнен үгетләүләре файда бирмәде.

—Ярар, барыгыз алайса. Көндезгә сезгә пилмән пешерәм. Матур абый сина тагын китап-дәфтәрләр алып кайтыр. Рәсемнәр ясарсыз, атка атланып уйнарсыз. Кайтыгыз, яме, без бик-бик көтеп торырбыз,—дип аларга киенергә булышты Саимә, Фәниягә күчтәнәчләр бирде. Үзе алар капкадан кереп киткәнче күренмичә генә артларыннан озата барды.

Әбәд вакыты үтте. Балалар юк та юк. Кич кырын, тәмам түземлеге беткән Саимә, Шакирларга үзе китте. Килеп керсә, ни күрсен: бер тезенә Гүзәлне, икенчесенә Фәнияне утырткан Шакир, икесен дә кочаклаган да, акрын гына елый. Ания идәндә, аларнын аяк очында. Гүзәл Саимәне күргәч, Шакирның тезеннән төшеп, әнисенең кочагына ташланды.

—Шакир абый, ни булды? Әллә бер-бер яман хәбәр бармы?

—Аллага шөкер! Зәйтүнә дә, малай да. Әнигә дога кылып утыра ием. Их, Саимә, дүрт ел буе шушы баланы миннән яшереп асрадыгыз. Без капчыкта ятмый бит. Мин дә, җүләр, сезнең хакны хаклап, өйдә генә тузгып йөрүдән ары уза алмадым. Гүзәлнең үз каныбыз икәнлеге сукыр кешегә дә күренә бит! Ә без һаман берни булмагандай яшибез. Ашыгырга кирәк, ашыгырга. Сезгә дә үз каныгыз якындыр бит!

—Шакир абый, җаным! Зинһар, бик ашыкмыйк. Безнең йөрәкләрнең ярасы төзәлер, балаларныкы яраланмасын иде. Бу хатаны кинәт кенә төзәтә алмабыз. Ике арада йөреп әкренләп ияләнерләр, аннарына керер...

Шул арада каяндыр Шакирларнын олы балалары кайтып керде. Аларның бөтен игътибары Гүзәлдә булды. Гүзәл исемле олы апасы:

—Син дә Гүзәл, мин дә Гүзәл, әйдә, мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм,—дип аны күтәреп, Саимәгә күз дә төшермичә, кече якка чыгып китте. Бу күренеш Саимәгә сәер тоелды, аптырап калды.

—Син аптырама инде, Саимә. Алар барысын да белә. Гүзәл бүген монда калсын әле. Иртәгә үзем илтермен. Ә Ания матур абыйларга барып кайта, әйеме?—дигән булып Шакир Аниянс киендерә үк башлады. Саимә дә аны тизрәк алып чыгып китү ягын карады.

Ания башта киреләнеп маташты, мин дә апамнар белән уйныйм,

дип балалар кайнашкан якка омтылып карады. Ләкин Саимә:

—Син дә безгә бармасаң, матур абыең белән без елашып үләчәкбез бит,—дип сагышлы күзләре белән карап торгач, Ания барасы итте, әллә бала акылы да мәсьәләне төшенде тагын...

Юлда кайтканда Аниянең кайбер сорауларына Саимә жавап та таба алмады.

—Бүген әти ник елады? Әти кешеләр дә елыймыни? Нигә ул Гүзәлгә син минем кызым, ди? Безнең Гүзәл исемле апай бар бит инде. Әхмәт мина:

—Син безнеке түгел, Гүзәл безнеке, диде. Нигә алай әйтә ул?

Бу сораулардан соң Саимә «иртәгә үк балалар белән ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк»,—дигән катгый карарга килде, гәрчә бу житди сөйләшү бик куркытып торса да.

Төнге сәгать беренче яртыларда ишек каккан тавышка Саимә сискәнеп уянды. Саматын уятып та тормады, йшекне ачарга үзе ашыкты. Өйалдындагы утны кабызып жибәрүгә тышкы яктан:

—Бу без әле,—дип, Гүзәлне күтәреп Шакир килеп керде. Кыз «әннә» дип Саимәнең муенына сарылды.

—Кичтән әйбәт кенә йөрде, ашын да яратып ашады. Йокларга зур апасы янына ятып, тыныч кына йоклап та китте. Аннары мин аны үз яныма күчергән идем. Сәгать унбердә уянды да, «әннә, әннә»,—дип еларга кереште, әй. Берничек тә көйли алмадык, аптырагач, сезгә килдек менә.

—Сездә калуына аптыраган идем мин анын. Күрәсең, уенга мавыкканга гына калгандыр шул. Бергә-бергә уйнау тансык бит аңа.

Аларның сөйләшкән тавышына Ания уянып торып утырды. Күзләрен уа-уа:

—Әти, әни бәбине алып кайттымы? Мин синең белән өйгә кайтам,—дип диваннан төшә үк башлады.

—Юк, юк, кызым, мин сине алмага бүтән килермен. Ә хәзер Гүзәл белән бергә йоклагыз. Бар, балакаем, ят урынына,—дип Шакир Анияне тынычландырырга тырышты.

Ә Гүзәл:

—Әннә, мин синең белән йоклыйм,—дип Саимәне тагын да кысыбрак кочаклады.

—И, Раббым, ярдәменнән ташлама. Йөрәктән каннар саварлык бит бу хәлләр... Сабырлык бирә күр—Шакирның күзләренә яшь тулган иде.—Берүк барыбызга да сабырлык бир... Самат, дим, кайда?

—И-и-и, йоклап ятмыйдыр ул да... Бу хәлгә аптырамыш инде...

Икенче көнне Саимә Саматка балалар белән ачыктан-ачык сөйләшүгә вакыт житкәнлеген әйтте һәм сөйләшүне эштән соң кичкә килештеләр.

Самат белән Саимә, балаларны каршыларына утыртып, чынбарлыкны зур түземлек белән аңлатырга тырыштылар. Саимә бу хәлне башта әкияткә әйләндерде хәтта.

—Борын-борын заманда ике куян яшәгән, ди. Бер дә бер көнне куяннарның икесенең дә кыз бәбиләре туган. Бу көнне урманда жилдавыл котырган. Әнкә куяннарның берсе бәби тапканда бик каты авырган. Савыктырыр өчен урмандагы жәнлекләр табибны чакырганнар. Шау-шу вакытында каяндыр бер хәйләкәр төлке сиздермичә генә бәбиләрне алыштырган да куйган. Моны әнкә куяннар озак кына белмичә йөргәннәр. Ә белгәч, һәр әнкә куян үз бәбиен үзенә алырга теләгән. Сезнеңчә ничек, куяннарның бәбиләре үз әнкәләренә кайтсыннармы, әллә үстергән әнкәләрендә калсыннармы?

Балалар ни әйтергә дә белмәделәр. Бераздан гына Ания:

—Үз әниләренә кайтсыннар ие алар... дип сузды.

—Ни өчен?

—Үз әнисе булган өчен.

—Ә бит бәби куяннар үзләрен ашатып, эчертеп, куеннарында йоклатып үстергән куяннарны үз әнкәләре дип белгән. Менә Гүзәл

Ания булып Зәйтүнә апаларга китте, ди. Ә Ания Гүзәл булып бездә кала, ди.

—Юк, диде Ания,—мин Гүзәл булмыйм.

—Мин дә Ания булмыйм!—диде Гүзәл.

—Ярар,—диде Саимә,—Ания—Ания булып, Гүзәл—Гүзәл булып калыр. Тик Ания бездә, Гүзәл Зәйтүнә апаларда торыр.

Кызлар елаша ук башладылар. Самат белән Саимә аларны көч-хәл белән юаттылар.

* * *

Май аеның җете кояшлы көне иде. Шакир, хастаханәдән хәбәр алгач, Кашкасын җигеп йөгертеп кенә өенә кайтты. Юынды, кырынды, кешелеккә генә кия торган киемнәрен киде. Зәйтүнәсе бала өчен әзерләгән төргәкне тарантаска куйды да күршеләренә юнәлде.

—Күрше дим! Гафифә, дим! Чыгып кына кер әле!—дип Шакир капка төбеннән үк сөрән салды. Бу тавышка Гафифә өй яны бакчасыннан курку катыш сәерсенеп атылып чыкты.

—Котны ала яздың. Ни булды? Шул хәтле кычкырмасаң...

—Кара әле, күрше, мин малайны алырга киттем. Зинһар, мунчаны ягып торчы. Суы ташылган, утыны кергән. Базда, Зәйтүнә бәбиләгәчкә дигән сарык ите бар. Аш та пешереп куйсаң мәңге онытмабыз үзенне.

—Ярар, ярар, Шакир! Күрче сине, карап-карап торам да, бигрәк көязләнеп киткәнсең, чистый кияү егете булгансың ич. Эшләрегез болай барса, Зәйтүнәне герой ана итәсең дә итәсең инде,—дип шаяртты күршесе.

Шакир Саматлардан Гүзәлне дә үзе белән аласы итте. Саимә белән жылы гына исәнләшкәннән соң:

—Гүзәл кызым, минем белән бәби алып кайтырга барасыңмы? Безне анда капка төбендә бахбай көтеп тора,—диде.

Һәм Шакирның сүзен раслагандай урамда ат кешнәгәне ишетелде. Гүзәлнең бахбайга утырып барасы килә иде бугай, рөхсәт сорап әнисенә карады. Әнисе:

—Бар, кызым, бар. Бәбине каян алып кайтканнарын күрерсең,— дигәч, Гүзәл киенә башлады. Ул арада кече яктан Ания килеп чыгып:

—Әти, мине алмага килденме? Үзебезгә кайтабызмы?—дип такылдарга тотынды.

—Юк, кызым, син әлегә матур абыйда калып тор.

—Мин дә бәби алырга барам! Бәби безнеке, Гүзәлнеке түгел.

—Син дә китсәң, менә бу матур апаңа күңелсез булыр бит. Ул елый башлар. Әнә, кара әле, инде хәзер үк еларга тора.

Бу минутларда Саимәнең хәле чынлап та бик мөшкел иде. Аның хәтта йөрәге чәнчеп-чәнчеп алды, күзләре яшьләнде. Ания күзләрен кыса төшеп икеләнеп калды. Шуннан файдаланып, Шакир тизрәк Гүзәлне алып чыгып китте. Икесе генә калгач Саимә Анияне кочагына алып:

—Бәби карарга сине мин үзем алып барырмын, ярыймы, матурым,— диде.—Ай Аллам, бәбигә алып барырга күчтәнәчебез юк икән ич! Ә-ә, болай итәбез: Бүләкләр алырга матур абыйга кушабыз,—дип Анияне юатырга тырышты. Ишегалдыннан ук Саматның: «Кая әле, минем акыллы кызым? Менә мин аңа нәрсәләр апкайттым»,—дигән тавышы ишетелде һәм әкият китаплары, рәсем ясарга альбом, төсле карандашлар күтәреп кереп тә житте. Сыер рәсеме төшерелгән конфетлары да бар икән. Мондый конфетларны Аниянең беренче тапкыр күрүе иде. Елавыннан туктады, бер конфетны әрчеп кабып та жибәрде. Ания бүләкләр белән мавыккан арада Саимә Саматка:

—Әтисе, син тиз генә безне станциягә озаттыр,—дип пышылдады.— Мин, Анияне алып, дүрттәге поезд белән Казанга китим. Гүзәл Шакир абый белән. Без өйдә булмагач, ул монда кайтам димәс. Бәби дә булгач, Гүзәл анда тизрәк ияләнер. Анияне үземә ияләндерергә Ходай биргән ин кулай вакыттыр бу, Самат...

—Мин сине аңладым, Саимә. Чыннан да, анда сыеныр урының да бар. Баланы төрле җирләргә йөртерсең. Акча ал. Берни дә кызганма, нәрсәгә күзе төшсә—шуны ал. Берничә көннән үзем алмага килермен, бергәләп кайтырбыз,—дип хатынының фикерен хуплады.

* * *

Казан Казан инде, Ания бөтен дөньясын онытып циркта тамаша карады. Икенче көнне көне буе зоопаркта йөрделәр. Арганын да сизмәде. Өченче көнне Саимә кызын паркка алып барды. Анда аңа атлар өстендә әйләндерә торган карусель аеруча ошады. Бибинур апасына кайткач, көн буена күргәннәрен, ашаган туңдырмалары, эчкән тәмле сулары турында бәйнә-бәйнә сөйләде. Баланың зирәклегенә, матур итеп сөйли белүенә сокланып бетә алмады Бибинур.

—Бу бит бөтенләй башка бала, Гүзәл белән чагыштыра торган да түгел. Сиңа ничектер, мин анда Саматына охшашлык күрәм. Әле ярый соңрак булса да аңыгызга килгәнсез,—дип Саимәнең ышануын ныгытты Бибинур.

—Үзем дә сөенеп бетә алмыйм, Бибинур апа! Тик күпме генә тырышмыйм, ниләр генә эшләмим, мине әни дип танудан бик ерак әле ул. Бүген, өйгә кайтыйк инде, әнине сагындым, бәбине күрәсем килә,—дип әйткәндә күзләренең моңсулыгын күреп, йөрәгем өзелеп төшә дип торам. Гүзәлем дә ятсам—төшемдә, торсам—өнемдә. Ул да мине сагынып өзгәләнәдер...

—Шулайдыр, җаным, хәлеңне аңлыйм,—диде Бибинур.—Тик син хәзер Ания турында күбрәк кайгыртырга тырыш. Бу баланы фәкать түземлек, тирән акыл белән генә җинә алырсыз. Син аны авылга кайткач күбрәк тегe балалар белән аралаштыр. Барам, дисә, Зәйтүнә янына барудан тыйма. Кайвакыт балалар өлкәннәрдән акыллырак булып чыга. Бала күңеле бик сизгер. Ике якны да яхшылык белән җиңәргә кирәк. Көчләү башландымы—бала карыша, киресен эшли,—дип үз киңәшләрен бирде Бибинур.

Көннәр үтә торды, ә Самат күренмәде. Саимә борчыла ук башлады. Аниянең:

—Өйне сагындым, әнине сагындым,—дип кабатлаулары ешайды. «Детский мир» кибетенә бергәләп баруны планлаштырган булсалар да, Самат күренмәгәч, баланы үзе генә алып китте.

—Әйдә әле, кызым, сиңа бизәкле күлмәк, аягыңа матур туфли алыйк,—дип өскә, киемнәр бүлегенә алып менмәкче иде, Ания астагы уенчыклар бүлеген күреп, шунда таба йөгерә башлады. Шулчак Саимә, бераз артка калып ана:

—Кызым, Гүзәл, тукта, мине көт, әниең алай йөгерә алмый бит,—дип әйтеп карады.

—Мин Гүзәл түгел! Мин Ания! Минем әни бәби янында калды ич!

Баланы озак юатты ана. Ниһаять, кыз үзенә һәм бәбигә, дип алган уенчыкларга һәм матур киемнәргә бик сөенде. Өйгә көлешә-көлешә, кайтып керделәр. Әмма ләкин шатлыклары озакка бармады.

Ишектә нык борчылган, аягында көчкә басып торган Саматны күргәч, Саимә ни дип әйтергә белмичә аптырап калды.

—Зинһар... Барысын да иртәгә сөйләрмен, идәнгә урын гына салыгыз, мин ятыр ием...

—Нәрсә булды? Гүзәл бик борчыла мәллә? Нигә монарчы килмәдең?

—Иртәгә, иртәгә... иртә...—дип чишенмичә үк йоклап та китте Самат.

Саимә төне буе керфек тә какмады. Уйламаган уе калмады. Җитмәсә, күкрәк читлегеннән чыгардай булып каккан үз йөрәк тибешен үзе ишетеп яту күңеленә өстәмә шом салды. Соңгы вакытта, юк-юкта, Саматның салмыш кайтулары бер-бер артлы күз алдыннан үтте. «Нәрсә бу, Ходаем? Язмыш миңа тагын нинди сынаулар әзерли икән?»

* * *

Самат таң алдыннан башы чатнауга чыдый алмыйча уянды. Шактый вакыт кайда ятканын чамалый алмыйча гаҗизләнде. Авыр керфекләрен күтәрүгә райкомдагы күңелсез вакыйгалар—икенче секретарьнең мәгънәсез бәйләнүләре, мыскыллап көлүләре исенә төште.

Саимә, иренең үзенә нидер әйтергә теләвен, ләкин моңа көч таба алмавын тоеп:

—Самат, бәгърем, нәрсә булды? Йокың йокы булмады, тоташ саташып яттың. Яшермә, сөйлә,—дип, Саматка кайнар тәне белән елышты.

—Саимә, чүмеч белән салкын су китер әле, эчем яна... Аннары...

—Кайнар, каты чәй әйбәтрәк ич. Әйдә, кухняга,—дип Саимә иренә торырга булышты.

—Кайнар чәйләр генә ярдәм итмәс шул. Бер-ике йотым аракы кирәк миңа... Бибинур апаның маясы юкмы икән...

Иренең мөлдерәгән карашы, мескен кыяфәте Саимәне әллә нишләтеп җибәрде. Һәрвакыт горур, төз гәүдәле Самат аның каршында бөгелеп басып тора. Нәрсә бөгә Саматны?

—Балалар язмышы борчыймы сине? Эштә күңелсезлекләрең күпме? Аракыга хирыслыгың юк иде ләбаса. Соңгы вакытта салгалаганыңны сизсәм дә, тешемне кысып түзә килдем. Эше шундый, кемнедер көйләргә, кемнедер сыйларга кирәктер, дип уйладым. Ә бүгенге рәвешеңә бөтенләй чыгырдан чыгарлык. Инде тормышыбыздагы иң тирән упкынны сикереп үтәбез, дип куанып йөргәндә синең менә болай сәрхушләнүеңне аңлап та, яклап та булмый! Моңарчы әле берәүнең дә аракы белән ни хезмәтен, ни язмышын җиңеләйтә алганы юк,—дип өзгәләнде Саимә.

—Саимә, туктачы, җаным, бераз гына битәрләмичә тор. Хәзер мин сиңа барысын да сөйләрмен. Моңарчы син райкомдагы күп нәрсәне белмәдең. Аларны сөйләп сине борчырга теләмәдем.

Самат арлы-бирле йөренде.

—Син Казанга хастаханәгә китүгә, кинәт кенә бездән Беренчене алдылар бит. Безгә аны башка эшкә күчү сәбәпле, дигән булдылар. Ләкин аның хәзер кайда икәнлеген ачык кына бер кем белми. Каядыр, чит өлкәдә түбән генә бер эшкә куйганнар икән дигән сүз ишеткән идем. Рәзе бездә халык мәнфәгатен яклаучы җитәкчене тоталар инде! Аның урынына Икенче менде. Башта аны вакытлыча гына дигәннәр иде. Ике атна элек безгә обком читтән икенче итеп секретарь җибәрде. Теге юньсез тәки Беренче урынына утырды. Менә шуннан соң куерды инде хәлләр. Райком планны бернинди исәпләүләргә нигезләмичә арттырды да куйды. Аның иң мул өлешен райком безнең колхозга сылады. Билгеле инде, мин каршы төштем. Шул җитә калды, элеккеге үчләрен дә ала башлады бу. Кичәге ике арадагы сөйләшү бөтен кысаларны җимерде. «Син районның язгы чәчү планын боздың. Син, бодай чәчәсе урынга, арыш чәчтен». Фәлән дә фәсмәтән. Китте тезеп, китте. Түзеп кенә тор. Акланырга дип авызымны ача башлаган идем, өстәленә йодрыгы белән сугып: «Молчать!»—дип акырды. Син, ди, туган партиябезнең карарларын боза-боза тәмам череп таркалгансың! Хәтта самовольно балалар алыштыруга кадәр барып җиткәнсең, ди. Мондый эшне райком белән килешеп эшләргә тиеш идең, ди. Әхмәдиевнең мактауларыннан башың әйләнде, ахры, үзенә управа юк, дип уйлый башладың, болар гына җитмәгән, хатыныңны психбольницага илтеп тыктың, ди.

«Сез минем шәхси тормышыма тыгылмагыз,—мин,—дидем,—кая барсам шунда кәнтәйләрнең итәк астын капшап йөрмим»,—дидем.

Үзенә тигәнне аңлады бугай, йөзе бөтенләй зәңгәрләнде: «Вон отсюда!»—дип кычкырды. Димәк, мин аның белән эшли алмаячакмын...

Самат сөйләп бетергәч өйдә беразга тынлык урнашты. Соңыннан Саимә:

—Борчуларыңны миңа элгәрерәк әйтәсе идең... Үзеңне дә, мине дә ялгыз йөртеп акыллы эшләмәгәнсең. Райкомдагыларның барысы да диярлек бер чыбыктан сөрелгән, серкәләре су күтәрми. Үзләренең кыңгыр эшләрен

йөзләренә бәреп әйтүне тынлыймы соң алар... Мәлҗерәмик әле, Самат. Җан биргәнгә җүнен дә бирер...

Төн пәрдәсен ерткан кояштай балкып икенче бүлмәдән Ания атылып чыкты да:

—Матур абый, минем әнине күрдеңме? Бәби нинди? Матурмы? Еламыймы?—дип сорау арты сорау тезде ул.

—Ания, кызым, әнә бит әниең чәй әзерләп йөри. Ә мин синең әтиең булам,—дип башлаган иде дә Самат, Ания сүзсез генә борылды да, моңаеп тәрәзәдән урамны күзәтергә тотынды. Самат Аниянe үзенә якынайтырга теләп бәби турында сөйли башлады.

—Ания, үпкәләмә инде, кил алдыма утыр әле. Зәйтүнә әниең бик матур бәби апкайткан. Әсхәт исемле.

Самат аннары Саимәгә Шакирның малаен алырга баргач кылган маҗараларын сөйләде.

—Баланы кулына тоттырмакчы булганнар моның. Ә ул, сез тагын чит кеше баласын бирмәкчедер әле, чишегез биләвен, үземнеке булса, алырмын, дип әйткән, ди. Барысы аптырап калган. Сез нәрсә, ничек монда бала чишендерик, дигәннәр ана. Шакир абый барыбер үзенекен иткән. Малайның мул хәзинәсен күргәч: «Сөбханалла, үзебезнең тамгабыз бар»,—дип тынычланып малаен кулына алган.

Ания өлкәннәрнең сүзен аңлап бетермәде булса кирәк. Шуна күрә аларның көлүенә сәерсенебрәк карады.

—Самат, син никтер Гүзәл турында берни әйтмисең әле. Янына барып кайта алдыңмы? Нихәлдә икән? Безне сагынадыр балакай.

—Янына үзем бара алмадым шул. Шакир абыйдан сораштым. Матур гына йөри икән. Анда аңа игътибар зур, билгеле. Гүзәл кайтканнан бирле күрше кызларын куалап та чыгарып булмый, ди. Бәбине дә бик ярата, ди. Төннәрен генә «әни» дип елаштырып ала икән. Ул бит гел синең кочагыңда йоклый иде. Кибетләргә йөргәндә Гүзәлгә бирәр нәрсә алдыгызмы соң? Кайту белән аларга барып килербез. Шулаймы, Ания кызым?—дип Самат бер кулы белән Анияне, икенчесе белән Саимәсен кочаклап алды. Аларга карап сокланып утырган Бибинур:

—И җанашларым, Ходай сезгә тигез һәм озын гомер бирсен,—диде.—Самат кияүгә карап-карап торам да сөенеп бетә алмыйм. Бер-берегнең кадерен белеп, иркәләшеп яшәү күпләргә эләкми бит...

Бибинур соңгы җөмләсен көрсенеп әйтте, иркәләнүләр ана бик эләкмәгәндер, күрәсең. Әмма бөтенесен эченә җыярга күнеккән ялгыз хатын хисләрен-кичерешләрен уртаклашырга ашыкмады.

* * *

Поездда Ания Саматка Казанда күргәннәрен юл буе сөйләп кайтты. Аның сүз байлыгына һәм эзлекле сөйләргә тырышуына Самат исе китеп куанды. Тик районга якыная барган саен күңелендә тынгысызлык артканнан арта барды. Ул аның йөзенә дә бәреп чыкты. Сабыйның чишмә төсле челтерәп торган тавышы да тоныкланган кебек ишетелә иде. Авылы кырларын күргәч кенә кәефе күтәрелә, дингез шикелле чайкалып утырган арыш басуы җанын иркәләп, борчуларын оныттыра төште.

—Саимә, матурым! Күзләреңне тутырып кара әле, мондый хозурлыкны тагын кайда күрергә мөмкин?! Бу басулардан аерылсам, мин яши алмам...

Саимә аның тел төбен яхшы аңлады.

—Райкомда әрләгән саен төшенкелеккә бирелә башласаң,—диде ул.— Эт өрер, бүре йөрер диләр бит. Эшләрсең, Алла боерса, җир җимертеп эшләрсең!

—Хикмәт эшләүдә генә түгел. Гаделсезлек, эшләгән эшеңне күрмәү җанны талый. Райком «айт» дигән саен «тайт» дип йөрүчеләрнең түше тулы орден, ә үзләренең колхозчылары ачлы-туклы. Без ел саен колхозчыларга хезмәт көненә күп булмаса да икмәк өләшәбез.

—Бик әйбәт! Үз авылдашларың алдында йөзең ак булсын. Ә калганына төкер!

Бу сөйләшүне тыңлап кайткан Ания: «Нишләп болар бәби турында сөйләшмичә әллә ниләр сөйләшә икән? Әнием, әтием турында да сөйләшмиләр. Минем аларны сагынуымны белмиләр микәнни?»—дип уйлады.

Самат, өенә дә кереп тормыйча, туры эшенә китте. Ания:

—Мин ашамыйм! Өйгә кайтам!—дип тынгысызланды. Казанда алган яңа киемнәрен, китап-уенчыкларын җыя ук башлады. Саимәнен:

—Кызым, монда каласыларын күтәреп йөрмик, барыбер монда кайтабыз бит. Аягына, өстенә яңа киемнәренне үзең сайлап ки. Гүзәлгә һәм бәбигә дигәннәрен генә алыйк,—дип искәртүенә, ризасызлык күрсәтмәсә дә, шатлыктан очынган баланың кинәт күңелсезләнеп китүе Саимәгә авыр тәэсир итте, җанын тагын шом басты. Хәтта ул капкадан чыккан чакта: «Йә, Раббым! Рәхмәтеңнән ташлама! Әгәр шушы капканы Ания белән сөенеп ачып керүне насыйп итсәң, Тайбә апага бүген үк сәдака бирер ием»,—дип нәзер әйтте.

Ишектән килеп керүгә «әни» дип Ания бала имезеп утырган Зәйтүнәгә ташланды. Әнкәсеннән иркәләнеп туйгач, Ания зур кызыксыну белән бәбине карый башлады. Ул арада Фәния белән Әхмәт, Аниянең өстендәге яңа киемнәрен, башындагы ак бантигын тотып карый-карый, моңарчы кайда булганлыгын белергә теләп сораулар яудырдылар. Менә китте әңгәмә... Ания Саимәгә күрсәтеп: «Менә бу апа мине Казанга алып барды»,—дип, анда ниләр күргәннәрен йотылып-йотылып сөйләргә тотынды. Балаларның берсен-берсе сагынулары, күрешүдән сөенүләре йөзләренә бәреп чыккан иде. Саимә балаларның бәхетле мизгелләрен карап туя алмыйча, ирексездән Зәйтүнә белән Шакирның үзләреннән күпкә бәхетлерәк булуларын тоеп, көнләшеп куйды.

Зәйтүнә, йоклап киткән бәбине бишеккә салып, Ания янына килде.

—И-и кызым, син тазарып, тагын да матураеп киткәнсен ич. Матур апаң сине ничек итеп киендергән! Түфлиләрен генә күр син аның, үзләре биеп китәргә тора.

Бу сүзләрдән соң Ания тыпырдап куйды.

—Гүзәл...—соравын биреп бетермичә туктады Саимә.

—Ул күрше кызлары белән чыгып киткәние. Моңарчы матур гына йөрде. Балаларга да тиз ияләште. Сине күргәч нишләр тагын. Төннәрен генә сине сорап аптыраткалады. Баштарак, өйгә кайтасы килә, дип елаштыргалады, олы кызым ишегездәге йозакны күрсәткәч, тынычланды үзе.

Күп тә үтмәде, Гүзәл үзеннән кечерәк ике кыз белән кайтып керде. Саимәне күрүгә «әннә», дип аның кочагына атылды. Кайда уйнаганнардыр—битләре, куллары пычранып беткән. Өстендәге күлмәге дә тапланган. Үзләрендә баланы гел өф-өф итеп кенә тора, аз гына таплана башлаган киемен шунда ук алыштыра иде. Баланы бу хәлдә күргәч, Саимә тетрәнеп китте. Гүзәл бик кызганыч булып тоелды аңа. Ул ирексездән чыккан күз яшьләрен балага күрсәтмәс өчен читкә борылды.

Гүзәл исә, берни булмагандай Саимәнең кочагында елмая. Сакау теле белән нидер сөйли. «Монда миңа күңелле, монда миңа рәхәт»—ди түгелме соң аның бөтен кыяфәте?!

Саимә каршылыклы уйларыннан бераз арына төшкәч:

—Зәйтүнә апа, без китик инде. Тиздән Самат та кайтып җитәр. Ания, әйдә,—дигәч, Ания:

—Юк, без уйныйбыз әле!—дип карышты, балалар шау-гөр килеп чыгып киттеләр.

Башта аптырабрак торган Гүзәл дә аларга иярде. Озак вакыт читлектә асрап, ирекә чыгарып җибәргән кошны хәтерләтә иде ул. Аны урамның шау-шуы, үзе кебек балаларның күплеге, аларның әллә нинди уеннар белүе тәмам әсир иткән иде.

* * *

Балалар ишегалдында онытылып «кач-кач» уеннары уйныйлар иде. Саимә туктап, аларга карап торды. Шунда үзенен балачагын хәтерләде. Әнисе аны беркая чыгармады. Начар балалар йогынты-сына ияреп харап булырсың, дип гел кисәтә иде. Саимә тора-бара йомыкыйланды. Яшьтәшләре белән сирәк аралашты. Әнисенең шушы тәрбиясен җанына сендергәнгәме, Гүзәлне дә урам йогынтысыннан сакларга тырышты. Баксаң-күрсәң, балалар урамда үзләрен әнә ничек иркен тоталар икән. Саимәнең шулчак бөтен дөньясын онытып, сабыйларга кушылып уйнасы килеп китте. Аның бөтен игътибары Ания белән Гүзәлдә булды. Торып-торып Аниядә Саматка охшаш якларны күбрәк күрә барды. «Кара әле, йөгергәндә, аякларын борып алуларына кадәр гел Саматныкы икән бит»,—дип янә күңеленә салып куйды. Шул мизгелдә йомшак түшендәге нәкъ Саматныкы төсле миңен дә күз алдына китерде һәм үкенечле сыкрап җибәрде. И-и, язмыш... Ниләр генә булды икән аңа ул вакытта? Әллә инде чыннан да Гүзәлнең әкиятләрдә генә сурәтләнә торган матурлыгы сихерләде микән?.. Хәер, алай дияргә дә нигез юк кебек. Баласын беренче тапкыр кулына алганда, матур белән ямьсезне аерыр хәлдә түгел иде Саимә...

Ул уйланып торган арада күрше-тирә бала-чагалары да өстәлеп уен шулкадәр кызып китте ки, хәтта Саимә уенны туктатып, Ания белән Гүзәлне үз янына дәшәргә көче җитмәячәген аңлады, өйгә кире керергә мәҗбүр булды.

Бала имезеп утырган Зәйтүнә Саимәнең борчулы йөзен күреп:

—Ай-й Алла, мондамыни әле син,—дип аптырады.

—Балаларны уеннарыннан бүлдерергә көчем җитмәде...

—Әйе, уенга бер мавыксалар, дөньяларын оныта инде алар. Ә син борчылма, Саимә. Сине Ания дә, Гүзәл дә бик ярата. Ания синең белән Казанга барып кайткач бөтенләй икенчеләнгән. Бик зирәк бала бит ул. Барысына да тиз төшенә. Алла боерса, без дигәнчә булыр. Тик беразга ирек бирик үзләренә. Монда калабыз, дисәләр, калсыннар. Иртәгә җайлап үзем алып менәрмен.

Саимә салмак кына Зәйтүнә каршындагы урындыкка килеп утырды. Бала имезгән анага төбәп карап торуның ярамавын белсә дә, үзен тыя алмады. Ана булган затның сокланып туя алмаслык бу гүзәл халәтен якыннанрак озаклап күрәсе һәм үзенең дә шундый бәхетле минутларын исенә төшерәсе, кабат ләззәтләнәсе килде аның.

Ана бала имезә! Йә, Хода, нинди матур күренеш! Күпме рәссамнар бу күренешне үз картиналарында мәңгеләштергән. Шагыйрьләр никадәр җырлар, шигырьләр иҗат иткән. Әмма бала имезүнең ләззәтен бары тик аналар гына белә. Ул хисне картиналарда гына чагылдырып бетереп булмыйдыр. Бала имезгән ананы күрү әллә нинди усал, үчле кешеләрнең дә күңеленә җылылык, миһербанлылык орлыклары саладыр. Иң кырыс йөзле бәндәләрнең дә ул минутларда эчкерсез сокланып елмаймыйча калулары мөмкин түгелдер.

Сигезенче баласын имезеп утыручы Зәйтүнәнең нарасыена караганда күзләреннән аккан якты нур өй эчен тутырган. Алмадай кызарган ике бит уртасыннан, елмайган иреннәреннән яшьлек бөркелә. Йөзенең алсулыгына, хәтта имчәгеН балага җайлап тотуына аның эчке матурлыгы, изгелеге бергә кушылган. Бәхетле Зәйтүнә! Бәхеттә йөзә ул... Саимә кинәт аның сөт тулы ап-ак күкрәкләренә күз төшереп: «Зәйтүнә апага ничә яшь икән хәзер?»—дип уйлап куйды. Гаҗәпләнмичә дә мөмкин түгел, инде сигезенче балага шул күкрәкләр сәламәт яшәү көче бирә. Ә нарасыең күрчеләп-зәңгәр күзләрен җемелдәтеп әнисенең күзләренә шулкадәр матур итеп карый, гүя шул гөнаһсыз карашы белән әнисенә үзенең чиксез яратуын һәм рәхмәтен әйтә сыман. Анарга әле ул гына аз кебек. Биләвеннән кечкенә кулын тырыша-тырыша чыгарып, әнисенең күкрәгенә үрелмәкче. Үзе, әнә, ашыгып суыруданмы, әллә сөтнең мул булуыннанмы—ризыгын йотып бетерергә өлгерә алмый. Авыз читеннән чыккан сөт муенын юешләргә шуыша...

Саимәнең күнел күпере аша беренче мәртәбә Гүзәлне имезгәндә тойган бәхетле минутлары йөгереп үтте. Хәтта бала имезгән вакыттагыча имчәкләре чеметкәләгәндәй булды. Әйтерсең лә күкрәкләренә шаулап сөт төшә. Ул үзе дә сизмәстән күкрәкләрен капшап алды. Тик кисәк кенә шул чиксез бәхетле минутларын 3 ел буе чит кеше баласы белән уртаклашуын, ә үз йөрәк җимешен бүген имеп яткан малай урынында күз алдына китереп, бөтен тәне куырылып куйды. Йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып кага башлады. Аяк-кулларына боз салкынлыгы инде. Күзләреннән ихтыярсыз яшь атылып чыкты. Саимәнең хәлен Зәйтүнә сүзсез дә аңлап алды. Тиз генә улын бишеккә салып Саимә янына ашыкты. Нәкъ шул вакыт ишегалдында акырып елаган бала тавышы ишетелде.

—Абау, җаным, бу бит Гүзәл тавышы! Нәрсә булды икән?—дип Саимә, ишеккә атылды.

Гүзәлнең бөтен бите пычранган, борыныннан кан ага иде.

—Әннә әбү итә, өф ит,—дип ул ике кулы белән борынын күрсәтте. Куллары канга буялганны күргәч, тагын да кычкырыбрак еларга кереште.

—Хәзер, хәзер, матурым, битеңне тәти иткәч тә әбүең бетәр,—дип; баланың елавына карамыйча, битен юарга тотынды Саимә.

Ул арада башка балалар да өйгә керделәр. Хәлнең ничек булганын Ания ашыга-ашыга сөйләде. Һәм кинәт:

—Минем бәбине күрәсем килә,—дип кулларын Зәйтүнәгә сузды.

Ниһаять, Гүзәл елавыннан туктап:

—Мин дә бәбине калыйм,—дип Ания янына килде. Зәйтүнә аның бераз сыдырылган маңгаеннан йомшак кына үпте.

Саимә калган бөтен көчен туплап, сак кына:

—Зәйтүнә апа, без китик. Гүзәл, Ания, әйдәгез, балакайларым, өйгә кайтыйк. Әтиегез көтәдер,—дип сүз башлап карады.

—Әннә, бәбине дә алыйк, мин аны биик ялатам,—дип Гүзәл бишек янында басып торуын дәвам итте.

Ания, сүзсез генә куе зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, нәкъ Самат шикелле, бер Зәйтүнәгә, бер Саимәгә карап алды. Шулчак Фәния:

—Монда калсыннал, безгә алал белән кызык,—диде. Әхмәт аңа кушылды. Зәйтүнә дә:

—Ярар, Саимә, бая сөйләшкәнчә итик инде,—диде.

—Зинһар, иртәгәдән дә соңга кала күрмәгез, Зәйтүнә апа, ишеттегезме,—дип килеште Саимә.

Саимәнең кәефе кинәт бетте. Капканы ябып бер-ике атлауга ук бөтен гәүдәсе хәлсезләнеп, башы әйләнергә тотынды. Чигәләре, кайнар тимер кыршау кидергәндәй, кызышты. Буыннары тәмам йомшады. Коймага тотынып бераз хәл җыйды...

Инде, Ходаем, Фәридә генә очрый күрмәсен. Бу хәлемдә күрсә, исерек иде, дип гайбәт таратырга да күп сорамас. Болай да кеше аркылы күпме сүз ишеттереп тора. Саматның аракыга тартыла башлавын да миннән күрә. Имеш, райком алдында Саматның дәрәҗәсе төшкән. Тиздән рәислектән алып атарга җыеналар, имеш. Карга өй түбәнә кунып озак каркылдаса, өеңә бәла китерер, диләр. Алла сакласын, Фәридәнең каркылдавы да бәлагә юлыктырмагае. Ул-бу булса, Саимәнең йөрәге күтәрә алмас аны. Болай да бу бала борчуы тәмам талкыды. Бәлки, эшемә кире кайтсам, тынычланырмын, дигән иде. Ләкин мәктәптә аны колач җәеп каршыларга ашыкмадылар. Психбольницада ятуын каяндыр белгәннәр. Югыйсә беркемгә дә сиздермәгәннәр иде кебек. Мөгаен Фәридә эшедер. Каян килә аңа шулкадәр явызлык? Карап торышка акыллы гына хатын бит инде. Ике баласы туды, сөенеп кенә шуларны үстерәсе канә. Нигә соң каргышы үз башына төшәр, дип уйламый икән? Ата-ананың кылган гөнаһлары аркасында газиз балалары интегәчәген белми микәнни соң?

Шушы уйлар Саимәнең йөрәген юл буе каезлады. Үзен ачулана-ачулана ямьсез уйларын күнеленнән куып та карады. Юк бит, юк, берсе артыннан берсе, үзәкне тагы да өзә торганнары чорный барды. Әле бүген кичергәннәре дә күз алдын томанлады. Гүзәлнең: «Әннә, өф ит»,—дип

сарылуы, Аниянең «әни» дип Зәйтүнә кочагына атылуы, ә иң авыры Саимә чыгып киткәндә икесенең дә тыныч кына Зәйтүнәләрдә калулары...

Өенә житәрәк кинәт тагын хәле бетте. Аяк буыннары бөтенләй какшады, барган жиреннән абынмады югыйсә, әмма йөзтүбән егылды.

Һушы югалып күпме яткандыр, моны белешмәде. Күзен ачып жибәргәч үзенә таба иелгән Хәдичәнең борчулы йөзен күрде.

—Нишләдең, балакай?—дип Хәдичә Саимәне торгызмакчы булды, тик көче житмәде. Һәм үтеп баручы бер малайны туктатып:—Бар, үскәнем, тиз генә фельдшерга чап, килсен!—диде.

Ниһаять, Хәдичә Саимәне өенә кертеп салды.

—Бераз ятып тор, хәзер сөт жылытам.

Озакламыйча фельдшер кыз килеп житте. Саимәнең кан басымы бик нык күтәрелгән икән—укол кадады. Ул арада, каяндыр ишетеп, тыны кысылып, еш-еш сулап Саматы кайтып керде.

—Котларымны алдың бит, жаным! Ни булды сиңа? Хәзер үк район хастаханәсенә киттек!

—Юк, юк, Самат! Әйтә генә күрмә шул хастаханәләрне. Мин хәзер үземне әйбәт сизәм. Беркая да бармыйбыз.

Фельдшер Саматны читкәрәк дәшеп:

—Хатыныгызның кан басымы бик тә югары, кан савуы ихтимал. Аны һәр төрле борчу-дулкынланулардан сакларга кирәк,—диде.

—Барын да аңладым,—диде Самат.—Хәдичә апа, син ашарга берәр нәрсә әмәллә. Ә Саимә, син зинһар урыныңнан тора күрмә. Мин хәзер кайтам!—дип кабаланып чыгып та китте. Очты гына. Һәм бераздан Гүзәл белән Анияне житәкләп, авызын ерып кайтып та керде. Балалар Саимә янына килеп бастылар.

—Бу дөньяда синнән дә сизгер жанлы кеше юктыр, бәгърем!—дип Саимә иренә назлы караш ташлады һәм балаларны кочагына чакырды... Сөенече эченә сыймады, татлы күз яшьләре булып тышка бәреп чыкты.

* * *

Балалар жәйне-көзне ике йорт арасында йөри-йөри уздырып жибәрделәр. Һәр ике як балаларны тигез күрде, аларның дуслыгына сөенеп бетә алмады. Инде кышка кергәндә, кызлар төп йортларын дөрес аералар иде. Гүзәл гаиләсенә Аниягә караганда тизрәк ияләнде. Саимәләргә килүләр сирәгәя барды. Ания әлегә Саимәгә бер тапкыр да «әни» димәсә дә, көннән-көн аңа якыная барды. Баланың сүзсез генә үзенә килеп сыенуы, урамда күргән-ишеткәнен шатланып сөйләве, Саимәнең үзенә атап әйбер алуына сөенүе, сөйләгәндә элеккечә ятсынып читкә тайпылмавы Саимә күңеленә кем әйтмешли, сарымай иде. Ания Саматны аерата якын итте, аны яшьтәше кебек күреп, кирәксә—ат, кирәксә—маэмай ясады.

... Ләкин, ни кызганыч, бу гаилә өстендә кара болытлар куерганнан куера барды. Колхоз беренче мәртәбә, башка елларга караганда күпкә арттырылган дәүләт планын үти алмады. Елы да коры килде. Самат, план үтим, дип ашлыкны кырып-себереп дәүләткә тапшырырга ашыкмады. Ул үзен киләчәктә бу эштә калдырмаячакларын сизә иде. Шуңа күрә, халыкны аз булса да икмәкле, терлек азыклы итү чараларын күрде. Саматның бу башбаштаклыгын гафу итмәделәр, билгеле. Райком бюросының чираттагы утырышында аны партиядән чыгарып, эшеннән алдылар.

* * *

Бюрода әйтелгән сүзләр Саматның колагында гел яңгырап торды. Беренче секретарь булып калган теге юньсез ана:

—Сине агроном итеп тә эшкә куймаячакбыз!—дип акырды.—Кара син аны, колхоз байлыгын таратып, колхозчыларга әйбәт булып күрен-

мәкче! Шалишь, брат! Партия синен мәкеренне күреп-белеп тора! Колхозны таркатуын гына җитмәгән, үзеннен кул астында эшләүче Шакир Фәсхетдинов семьясын җимерергә тотынгансың. Үз семьясында тәртип урнаштыра алмаган кешегә ничек инде партия колхоз тикле колхозны ышансын!

—Минем гаиләмдә, Аллага шөкер, тәртип,—дип әйтә башлаган иде дә Самат, секретарь өстәлгә йодрыгы белән китереп сукты.

—Стоп! Партийный башың белән нинди Алла тагын? Бәлки әле син өеңдә намаз да укыйсыңдыр? Менә синең череп таркалуыңның тамыры кайда икән... Юкка гына хатыныңны психбольной ясамагансыңдыр...

Секретарь тагын ниләрдер әйтте, төкрекләрен чәчә-чәчә кычкырды, тик бу сүзләрне Саматның аны кабул итмәде. Бюро тәмамланганда ул башына күсәк белән тондырылган кеше хәлендә иде. Саф һавага чыккач кына бераз күзе ачылды.

Эшеннән алуларына, партиядән чыгаруларына әллә ни исе китмәгән иде Саматның, әмма секретарьның, үз семьяңда да тәртип урнаштыра алмыйсың, дигән сүзләре аның бәгыренә ук булып кадалды. Шулай да монда хаклык та бар иде бугай. Саимә белән Саматны үзара бәйләгән мәхәббәт җепләре ныклы булып чыкмады шикелле. Саимә, бала табу белән барлык назын, күңел җылысын нарасыена күчерде. Ә инде балаларның алышынганлыгын белгәч, Саимә белән Самат арасында упкынлы киеренкелек туды шул. Бу җан тартышы һәр икесенең сабырлык тамырларын акрынлап кимерде. Электән үк сәламәтлеккә туймаган Саимә өчен бу аерата авыр булды. Нервлары тәмам какшады. Самат исә борчу-кичерешләрен аракы томаны белән капларга тырышты.

Менә бүген дә, райкомнан чыгуга, кибеткә кереп ике шешә аракы, балаларга дип күчтәнәчләр дә алды. Ул юлга чыкканда караңгы төшә башлаган иде инде. Җитмәсә, көтмәгәндә буран котырынырга тотынды. Самат, бераз җылынырга теләп шешәсен ачты һәм аның авызыннан гына йоткалады. Иртәннән бирле тәгам ризык капмагангамы, хәмер башына тиз китте. Исерә төшкән саен уйлары ныграк чуалды. Күз алдына әле Фәридә, әле Саимә килде. Вакыт-вакыт алар берләште, Самат аларны бер-берсеннән аера алмый башлады. Чанасы кинәт салулап китеп, карга тәгәрәгәч кенә айныгандай булды. Бәхетенә, дилбегәсе сул кулына уралган икән, акыллы кара айгыр дилбегә тартылуга туктады. Самат айгырның башыннан сөя-сөя сөйләнде:

—Их, тугрылыклы малкаем минем. Бик акыллы бит син. Хуҗаңны юлда ташлап калдырмыйсың. Ә кешеләр алай түгел. Кешеләр бәгырьсез. Алар бер-берсен җәберләүдән тәм табалар...

Буран басылып алды. Самат якында гына агач полосасы күрде. «Нәкъ шушы төштә кайчандыр Фәридә белән татлы минутлар кичергән идек,— дип уйлап алды.—Чана юкка гына салуламас, димәк, монда тукталырга, шул ләззәтле мизгелләрне күңелдә генә булса да яңартырга кирәктер».

Ул атын полосага таба борды. Агачлар артында гына салам эскерте бар икән—атны шунда туктатты. Яман хәбәр, начар кәеф белән өенә ашыгасы килми иде: эскертне бераз чокып, шул ояга кереп ятты. Атына чанадан печән алып салды. Монда ышык, җылы иде. Ул әкренләп аракысын йота-йота уйлары буранына кереп чумды.

Саимәгә өйләнеп бәхетле булдымы ул? Нәрсә тартты аны Саимәгә? Мөгаен, җыры-моңыдыр, Самат, үзе дә җырга-моңга гашыйк кеше булганлыктан, Саимәнең күңеленнән ташыган җыр елгасында коенудан рәхәтлек кичерә, ана үз җанының сагышларын да кушып тыңлый иде. Халыкта, моңлы бала—бәхетсез була, диләр. Әллә дөрес инде... Моң-кичерешләрнең ургуы язмышның тормыштагы чагылышы. Саимә күпвакыт әнә шул моң эченнән чыга алмыйча азаплана. Моң аның күңелен басып торучы авыр йөк. Өйдә аш пешергән чакларда җырлап кына бу йөктән бушанып булмый. Юкка гына артистлар сәхнәгә ашкынмыйдыр. Күңел байлыкларын башкаларга ачып салырга омтыла алар. Саимә һөнәрне дөрес сайламаган, ахры. Ана җырчы булырга, җанын урталай ярып күрсәтердәй эш кирәк булган. Аның әнә шул ачылмаган таланты туа алмыйча интектергән бала кебек гел борчып торадыр. Шул аны үз-үзенә йомылырга мәҗбүр итә.

Ә Фәридә... Ул бөтенләй бүтән холыклы... Дәртле, кайнар. Тиз ярсый, тиз кабына. Ул сина моңланып, уйланып утырырга жай калдырмый. Өермәдәй бөтереп алып болытларга күтәрә дә, кулында тотып тора алмыйча, жиргә ыргыта. Кайсысы белән бәхетлерәк буласы иде икән Самат? Әй-әй, мондый сорауны бирү үзе гөнаһтыр. Саимә аның күнелендә пыскып яткан мәхәббәтне «Гөлжамал»ы белән әнә ничек дөрләтеп жибәргән иде бит. Шул жыр Саматның жанын актарып ташлады. Бәхет шундый мизгелләрдән тормыймы? Бәхетнең олылыгын яки кечелеген үлчи торган бизмән юк лабаса...

Ә нишләп соң, илаһи көч, дәрт, бәхет белән мөлдерәмә тулы гомер көткәндә, язмыш мина мәрхәмәтсез?.. Бөтенләйгә сындырмакчы буламы?

И мөкаддәс моңлы сазым
Ник уйнадың син бик аз.
Син сынасың...

Юк-юк, жырның ахыры кирәкми. Мин бик яшь бит әле. Үземне кулга алып, бу район белән мәңгегә хушлашып, туган ягымда өр-яңадан яши башларга...

Саматны йокы баса башлады. Күз алдыннан Ания белән Гүзәл йөгереп үткәндәй булды. «Балакайлар! Мин бит сезнең икегезне дә бик яратам. Менә күчтәнәчләр алып кайтам үзегезгә...» Кинәт үзе ялан тәпиле кечкенә Саматка әйләнеп, ямь-яшел арыш ужымы арасында йөгерә имеш... Нинди рәхәт... Жаны тыныч, бөтен тәнен йомшак жылы жил назлый...

Кара айгыр иртәгесен буш кошевка белән кайтып кергәч, авыл халкы дәррәү күтәрелде күтәрелүен. Тик Самат туңып үлгән иде инде...

* * *

Саматның жансыз гәүдәсен күрүгә Саимәне йөрәге тотты. Авыл фельдшеры ана беренче ярдәм күрсәтте. Район хастаханәсеннән табиб килеп житкәнче Саимәгә һуш керсә дә, хәле әйбәт түгел иде, жыелган кешеләргә гажәпләнеп карап ятты ул. Ни калган боларга бездә? Әллә балаларга бер-бер хәл булганмы? Ания, Гүзәл, кайда сез?»

Ул кычкырырга теләде—тавышы чыкмады. Йөрәк турысына утлы таш куйганнар диярсен—шулкадәр өтепме өтә. Әллә соң аны тулгак тотамы? Әйе, әйе, тулгак тота. Бала табарга ята ич ул. Менә тулгагы жибәрер дә, Саматына тупырдап торган малай алып кайтып бирер. Кыз тапты ла инде ул, монысы малай булыр... Ә Самат кая? Нигә ул үзенең кызын күрергә килми? Самат! Самат...

Кәгазь калынлыгы гына ачылган иреннәр арасыннан исеме чыгуга Саимәнең баш очында утыручы Хәдичә апа иелде.

—Нәрсә, жаным?

—Самат кая...

—Олы якта...

—Нигә минем янга килми ул? Әйтегез, яныма килсен...

—Тынычлан, жаным, тынычлан. Самат синең яныңа килә алмый шул әле...

Саимә, бер саташып, бер аңына килеп, атна буе ятты. Башына кан сауган иде. Табиблар авыруны хәзергә урыныннан кузгатмаска булдылар. Ирен жирләү, аның өчесен уздыру Саимәнең аңына-акылына томан катламы аркылы саркылып кына барып житә язды.

Зәйтүнә белән Хәдичә Саимәне үз ярдәмнәреннән ташламады. Саматның әнисе Зәйнәпнең килүе дә бик вакытлы иде. Ул, акылы белән киленен кабул итеп бетерә алмаса да, бу көннәрдә аны да жәлләде. Күзләреннән яшь кибеп тормады. Өч хатын, куллагы бармаклардай берләшеп, өйдәге бар эшне эшләде. Тәрәзә пәрдәләрен, урын-жир әйберләрен, идәннәрне юып чыгардылар. Өчесен, жидесен уздыру өчен аш-су әзерләгәндә хатыннар аерата күп көч куйды. Һәркем үзе генә белгән тәмле ризыкларны пешерергә тырышты. Әмма Зәйнәпнең ачы хәсрәтен нидәр генә басар...

Хәдичә белән Зәйтүнә аны юатыр өчен бар көчләрен куйдылар.

—Саматынны авыл халкы ярата иде,—диде Хәдичә.—Гаделлеге, ярдәмчеллеге өчен халык үз итте аны.

—Шулай шул,—дип кушылды Зәйтүнә.—Хәтереңдә микән, Хәдичә, бервакыт Шакирның бер аты зыянлады, аратага кысылып аягын сындырды. Язгы чәчүгә төшәр чак. Бүтән персидәтел булса, моның өчен ат караучыны судка тартыр, әллә нинди җәзалар табар иде. Ә Самат аягы сынган атны суйдырып, итен авылдагы ялгыз карчыкларга, тол хатыннарга тараттырды. Райкумдагылар моның өчен аның башыннан сыйпамагандыр. Тик шунысы хак: Шакирга бер авыр сүз әйтмәде. «Тиктомалдан ат суеп булмас иде, чәчүгә чыгучылар өчен берничә көн кайнар аш оештырырбыз,—дигән.—Их, эш кешесенең кадерен белмибез әле без»,—дип, суелган атны түгел, кыерсытылган халыкны җәлләп йөрде.

Хәдичә белән Зәйтүнә бер-берләрен бүлә-бүлә Саматның яхшы якларын санадылар. Улы турында әйтелгән һәрбер җылы сүз ана йөрәгендәге ярага шифалы яфрак булып ябыла барды. Беркөнне Зәйтүнә Саимәләргә Гүзәл белән Анияне алып килде. Моңарчы, балаларның күңеленә җәрәхәт салудан куркып, аларны кайгылы йорттан ераграк тотканнар иде. Әмма балалардан яшереп буламыный.—Алар Саматның үлүен инде ишеткәннәр, ләкин әле үлемнең ни икәнен аңлап бетермиләр иде. Үлем—алар өчен качышлы уйнау кебек. Өйгә килеп керүгә эчкәрге бүлмәдән әти-әниләре атылып чыгар кебек тоелды.

Саматның җансыз гәүдәсен, өлкәннәрнең бер-берләреннән яшерә-яшерә күз яшьләрен сөртүләрен дә күрмәгәч, бу югалтуның авырлыгы алар күңеленә барып җитмәгән иде әле.

—Әннәм кая, әттәм кая?—дип беренче булып Гүзәл сораша башлады.

—Хәзер әннәң янына керәбез,—дип сүзне бүтәнгә борды Зәйтүнә.—Әйдә, битләреңне юыйк. Күлмәгең якаларын рәтлик.

—Мине да матурла,—диде Ания.—Саимә әнием янына мин дә керәм.

Балалар хәзер әнә шулай «Саимә әнием», «Зәйтүнә әнием» дип әйтә башлаганнар иде. Бала акылының һәрвакыт төгәл төшенчәләргә нигезләнүен башта Шакир аңлап алды. Һәм бу аңлашу зирәк акыллы Аниядән башланды.

—Әтием, нигә Әхмәтләрнең, Фәнияләрнең әниләре берәү генә, ә Гүзәл белән минеке икәү?—дип сораган иде ул.

Шакир башта аптырап калды. Соңыннан, шөкер, җавабын тапты.

—Гүзәл белән сине әниләрегез бер үк көнне, бер үк больнистан апкайтты. Шуңа күрә һәр икегез безнеке дә, Саимә әниегезнеке дә булды. Ике әниле, ике әтиле булу бик әйбәт бит...

Баланы шушы җавап канәгатьләндерде, ахры, яңадан сораулар биреп Шакирны тинтерәтмәде. Шакир белән Зәйтүнә соңгы көннәрдә, «менә Саимә әниегез янына барырбыз, Саимә әниегез сезне бик сагынгандыр»,—дип тукып торгангамы, Ания «Саимә әнием»не шактый еш әйтә башлады.

Зәйтүнә уйлавынча, әгәр Ания Саимәгә «әни» дип дәшсә, аның өчен бу барлык дарулардан шифалырак булачак. Шуңа күрә, балаларны бу очрашуга ныклап әзерләде. Икесенә дә Саимә алып биргән ак күлмәкләрен кидерде. Һәр икесенең чәчләрен матурлап үрде.

Балалар, үзләренең матурлыкларын тизрәк күрсәтергә теләгәндәй, Саимә яткан эчкәрге бүлмәгә ашкынып керделәр. Аларны күрүгә Саимә урыныннан күтәрелә башлады.

—Кузгалма, кузгалма!—дип Зәйтүнә аны урынына яткырырга ашыкты.

Курчактай ике кыз Саимәнең ике ягына килеп басты. Саимәнең өянәгеннән соң сул кулы хәрәкәтләнми иде, ул сәламәт кулы ягында басып торган Аниягә үрелде.

—Кызым, кил әле якынрак...

Саимә Аниянең муеныннан кочып үзенә таба иелдерде. Ирексездән күзләреннән яшь бәреп чыкты.

—Саимә әнием, елама. Ату йә мин дә елармын... Мин сине бик яратам бит!

Аниянең үзенә беренче тапкыр «әнием» дип әйтүен ишетү Саимәнең

күнел дингезен айкап ыргытты. Күзләреннән яшь чишмәдәй акты. Олы кешеләрнең елавын күрмәгәнгәме, балалар аптырашып басып тордылар. Гүзәл бераз үпкәләде дә бугай, чөнки ул әнисенең кочагына беренче булып керергә уйлаган иде. Саимә инде аны иркәләргә теләде, ләкин караватның икенче ягына кулы җитмәде. Боларның һәммәсен күреп торган Зәйтүнә тиз генә Гүзәлне Ания янына китереп бастырды. Бу минутларда Саимә бәхетле иде, сулышын еш-еш алып:

—Зәйтүнә апа, балаларны бездән алып китмә...—диде.

—Юк, юк!—диде Зәйтүнә.—Тыныч кына ят, тизрәк савыга күр.

Гүзәл монда үзен хуҗа итебрәк тотты, курчакларын, уенчыкларын берәм-берәм әнисе яткан бүлмәгә ташый башлады. Зәйтүнә моңа каршы төшмәкче иде дә, Саимә:

—Монда уйнасыннар, Зәйтүнә апа,—дип балаларга ирек куйды.

Балалар Саимәнең авыру икәнлеген әллә аңлап җиткермәделәр, чабыша-чабыша уйнарга тотындылар. Аларның бар дөньяларын онытып уйнаулары, кычкырып-кычкырып көлүләре Саимәнең яралы җанына бальзам белән бер иде. Ул аларның шат йөзләренә карап, әкрен-әкрен уйлар дәрьясына чумды. Уй-хыялларының иң татлылары Саматка барып тоташты. Әнә ич, Саматы басып тора. Әнә генә ул... Алар клубта, Саимә «Гөлҗамал»ны җырлый икән...

Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы... Ничек кенә авыр...

Саимә үз тормышында булган вакыйгаларны күнелендә кабат-кабат янартырга ярата. Күнел кылларына салып кат-кат чыңлата торгач, күптәнге гап-гади нәрсәләр дә икенче төсмер, икенче мәгънә ала. Бәлки композиторлар җаннарында ярала башлаган көйне әнә шулай хисләр, кичерешләр матурлыгы белән бизи-бизи кешеләр таң калырлык җырга әверелдерәдер. Тик Саимәнең күнел дулкыннары яңа җыр булып тышка бәреп чыга алмый...

Аның хисләре, агып китә алмаган бозлар кебек, өсте-өстенә өелә, көчле агым ул бозларны ярга кыса бара. Бозлар шартлап-шартлап ярыла, кайберләре яр өстенә үрмәли. Елга агымы белән бозлар тартыша. Саимәнең хәзерге халәте дә шул тартышны хәтерләтә. Бер яктан Саматның вафаты күкрәккә ташкындай бәрә, икенче яктан Гүзәл белән Аниянең бәхетле чыр-чулары ташкынны туктатмакчы, бозларны рәхәтләндереп йөздермәкче була... Җанда кайгы белән шатлык көрәшә... Саимә вакыт-вакыт уйлар йомгагының очын югалта да вакыйгаларның эзлеклелеге дә җуела. Гомернең аерым көннәре елга борылышына килеп тыгылган бозлар кебек йә ялтырап өскә калка, йә агым аларны билгесезлеккә чумдыра. Менә кинәт шул бозлар өстеннән йөгерә-йөгерә Самат килеп чыкты. Саимәсенә таба йөгерә!

—Батасың бит, Самат бәгърем! Нигә язгы боз өстенә кердең?

—Сине алырга килүем, Саимәм... Синсез күнелсез...

—Ә балалар...

—Аларны Зәйтүнә апаларда калдыр...

—Беләсеңме, Самат, Ания миңа «әнием» диде...

—Җан тартмаса, кан тарта, диләр бит, Саимәм. Кан тартуыдыр.

—Мин бик бәхетле, Саматым...

—Ә мин?..

Самат сүзен әйтеп бетерә алмады, баскан бозы ярылды да, Саматны көчле ташкын эчкә бөтереп алды. Саимә: «Саматым, мә минем кулларыма ябыш! Бир кулларыңны»—дип алга ыргылды.

... Бу омтылышы аның соңгы хәрәкәте булды, гел авыр тулгаклардан торган гомер җебе шартлап өзелде... Саимәнең ике күз карасына ак күбәләктәй ике кыз—Ания белән Гүзәл мәңгелеккә сеңеп калды.

Гомер елгасы шаулап акты. Кышларын калын боз белән капланды. Язларын ярларына сыеша алмыйча, ярсый-ярсый ташыды. Гайрәтле дулкыннар дәү-дәү боз кисәкләре белән, ярдан читтәрәк үсеп утыручы, нәзек сабаклы пар талга селтәнмәкче булды. Әмма аларны, тамырларын тирәнгә җибәргән, кодрәтле Мәһабәт өянкеләр саклый иде.

# ШИГЪРИЯТ



Әхмәт
Гадел

## КҮТӘРЕЛӘ БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛДӘН АЙ

### Моң

Кимсетмәгез, рәнҗетмәгез моңны.
Без бит тоташ бер моң баласы.
Моң дәвасы әгәр сибелмәсә,
Һич йомылмас еллар ярасы...
Моң сыенган каен кочагына,
Моңның нуры аша күкләргә...
Сагышлардан моңга чаклы безгә
Бик күп кирәк әле үтәргә.
Ә бармы соң моңга ахыргача
Күңелендә урын бирүче?!
Моң алдында сәждә кылучы да,
Моң алдында башын июче?..
Бармы әле арабызда безнең
Моңны яклап утка керер зат?!
(Акыруны татар кабул итми,
Оран салу, фөрьяд—безгә ят!)
Татар җаны моңнан тукылгандыр,
Тетрәндерә алсу кичәләр...
Чишмәләр дә, безнең күңелләргә
Ятып, утлы моңнар эчәләр...
Якты еллар моң үстерә—чәчеп
Идел-Урал йортым җиренә.
Моң очыра безне сибеп-чәчеп,
Моң кайтара тагын илемә!
Моң язларны безгә бүләк итә,
Ник торасың әле тыңлап тын?
Күзләреңә багам, син бит татар,
Күзләреңдә, кардәш, чиксез моң!
Мәңге китмәс иде язлар-җәйләр...
Аһ, бу җилләр нигә котыра?!
...Ап-ак карлар салып иңнәренә,
Язмышларны җиңгән Моң тора...

## Вакыт

Көн үтә, үтә сәгатьләр—хыяллар үтә...
Вакыт—рәхимсез хаким, ул гомерне сүтә.

Күз яше кибә йөзләрдә, елмаю китә...
Вакыт, шуңа карамастан, шатлыкка илтә.

Ай, Кояш калмас бер заман, хәят та китәр...
Вакыт Җирне, кешелекне бер йолдыз итәр...

Тик Вакыт калыр җиһанда!
Аңла—белегез:
Бар нәрсә фани дөньяда.
Вакыт—үлемсез!!!

Вакыт түндерә Искене. Таба яңаны.
Әмма булмый тудырып йә үтереп Аны!

❊

Моңсуланып йөрмә, дисең,
Кайгырма да уйланма.
Сагынып үткән язларны,
Ил юлларын буйлама.
Яшьлегемдәге җырларым
Әле яши исемдә.
Түгелә кояш нурлары,
Дулкынланам-җирсенәм...
Шул моңнарны кабат-кабат
Очырам кошлар сыман.
Тәкрарлыймын: ярат, ярат
Үткәнең... Моңга тулам.
Һәм ишетәм яшь чагымда
Ишеткән моңлы җырны.
Һәм күрәм туган ягымнан
Офыкка киткән юлны.

И җырлыймын, и моңланам,
Күз алдымда яшь чагым:
Чыккандай була томаннан,
Чәчәк тулы кочагы...
«Гөл утырттым, гөлләр чәчтем,
Алсу гөлләр бакчага...»
Яшьлек килде дә китте шул,
Табып булмый акчага...
Канатлана ярсу җаным,
Күтәрелә биеккә...
Күңелем оча кошсыман
Болытларга тиеп лә...
...Әйтерсең лә сөю язым,
Өметем киләчәктә...
Басып торам җир йөзендә,
Ак шомырттай чәчәктә...

❊

Елама, уйлама:
Үткән юк, ишет, юк!
Сәламдәй, уйларга
Керә нур, үтә ут.

Йокладыңмы—үлдең,
Эшләдең—уяндың:
Күкләргә бактың да,
Гамьләндең, уйландың.

Мәңгелек—әзәллек
Теләктә—хыялда...
Йолдызлар кочудан
Тарсынма, оялма!

Гомерләр—аккан су,
Хыяллар—бер чеслә...
Син, күрәм, аргансың:
Ял кыйммәт ул, түлә!

*

Менә көз дә житте инде.
Урман—алтын тәңкәләр...
Усаклар кызыл күлмәктән...
Гамьдә барча әнкәләр...
Менә көз дә житте инде...
Кыр-урман өсте томан.
Әбиләр чуагы гүя
Уйлый да, кыла гөман...
Калды җәйге болынлыклар
Җыр һәм шатлыклар тулып...
Пәрәвезләр—көмеш ятьмә—
Оча истәлек булып...

Күңелдәге моң дөньяны
Кочкан да чолгап алган...
Үткәннәр генә—хакыйкать,
Киләчәк... гүя ялган.
Көзге урман буйлап менә
Барам уйларга чумып.
Бер тетрәнәм, бер эсселим,
Кинәттән китәм туңып...
«Әбиләр чуагын» тотып,
Көз ялгыз китеп бара...

Фасылларны һәм яшьлекне
Туктатып, тотып кара!
Юк дөньяда андый куәт,
Буйсынмый кешегә мәл.
Тик киткән-үткән гомерләр
Кызганыч, валлаһи, жәл!..
Әйтәсе иде яшьләргә:
Юкка тыз-быз тузмагыз.
Аллаһы биргән гомерне
Изеп-таптап узмагыз!
Асыл яз һәм матур җәйләр,
Моңлы көз, салкын кышлар...
Гомер бер, аңлый алсагыз,
Аллаһтан бүләк, бушлай!...
... Менә көз дә житте инде...
Тәгәри алга тормыш...
Йә, кемне чакыра торналар,
Кемнәрнең көзе узмыш?!
Елмаеп карыйм күкләргә:
Ни ул тормышны куу?!
... Мәгълүм түгелдер күпләргә:
Үлем дә—кабат туу!

## Шулай!

Ерак еллар ярларына карыйм чорлар аша:
Идел кайный, Идел ага, ярсый Идел, таша!
Ераклардан килә миңа серле матур моңнар,
Дулкыннардан чыга, гүя, батыр бабам болгар.

Идел өсте бәйрәм төсле—кайный көймә, каек...
Минме сезгә, бабаларым, түгел бүген лаек?!
Сезме миңа, минме сезгә чиксез бер риваять?!
Безнең тормыш, сезнең булмыш үзе бер зур хәят!

Озын-озын юл үтелгән—үлеп югалмаган:
Казаннарда кайнап-кайнап «касмакка калмаган».
Болгар йортта күтәрелде, үсте бөек татар:
Тере шаһит—Бөек Казан исән, күкрәр чаклар!

Шушы, дибез, татарларның изге башкаласы!
Монда безгә, гасырларда калкып, баш аласы!
Канатлар да яралардан арыначак бугай,—
Киләчәккә күтәрелә безнең күңелдән Ай!

## *Яңа исемнәр*



*Матбугатта күренгәләсә дә, укучы бу исемне бик белеп бетерми шикелле. Дөрестән дә, аның әле яңа чишмә кебек ачылып кына килгән чагы. Әмма бу чишмә үзенә игътибарны җәлеп итә: аның саф тавышы башкаларныкына охшамаган.*

*Нурзилә исемле бу чишмәнең башы-башлангычы—Кукмара төбәгенең Түбән Өскебаш авылында. Шунда туып, мәктәбендә сигез класс тәмамлагач, ул Арча педагогия училищесында һөнәр ала. Аннан соң янә туган авылына кайтып, башлангыч классларны укыта, урта мәктәптә татар теле мөгаллимәсе була. Ул арада Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый. 1 сентябрь иртәсендә мәктәп сукмагыннан түгел, Казандагы мәшһүр Матбугат йортына илтүче урамнан атлап китүенә дә инде берничә ел үткән. Хәер, бу урамга ул ялгышып кына килеп чыккан зат түгел. Мәгариф эшендә башлаган сукмагын-юлын дәвам итә Нурзилә (Нотфуллина Нурзидә Камил кызы)—«Мәгариф» нәшриятында, мәктәп дәреслекләре һәм балалар китабы чыгару хезмәтендә.*

*Шундый ук эзлеклелек аның иҗатка омтылышында да күренә. Беренче әкият, хикәя, шигырьләре «Яшь ленинчы»да, «Ялкын»да басыла (рәхмәт яусын балалар матбугатында эшләүче изге затларга). Шигырьләр язуын Нурзилә әле дә дәвам итә. Шулай да, безгә калса, нәсер (проза) жанрына ул ныграк тартыла, бу юлда нәтиҗәлерәк эшли кебек. Иҗатка карата «эшләү» дип әйтү, бәлки, кемгәдер ошамас та. Әмма күңел-иҗат гөлләрен үстерүгә дә күңел хезмәте куела бит. Үзе әйтүенчә, Нурзилә хикәяне бик «җиңел» яза—бер утыруда, бер талпынуда. Нурзиләнең теле йөгерек, саф, сурәтләре җете буяулар белән төшерелгән. Аның егәрле-тыгыз итеп язарга яратуын, кайчакта җыйнак кына хикәя сюжетына повесть-кыйсса материалын сыйдырырга тырышуын күрәбез. Каләмен хискә һәм хыялга манып-манып алгаласа да, хикәядә бары үзе кичергән тойгыларны гына сурәтләргә тырыша ул. Аның нәкъ шул омтылышын хуплыйсы килә: хәтта уйлап чыгарылган сюжет һәм каһарманнарга да ышандыра торган бердәнбер көч бит ул тойгылар чынлыгы. Шул чынлыкка ирешә алган автор гына бәхетле.*

*Ходай биргән сәләткә өстәлеп, Нурзиләнең каләменә кайчандыр җылы яңгыр кебек яуган бишек җыры да, ялан тәпиләре белән тойган туган җир җылысы да ярдәм итә. Тагын—балачак дуслары, авылдашлар, ниһаять, 91 яшен тутырып килүче (сөбханалла!) Саҗидә әбисе... Оста телле акъәбинең хәтере әле дә шәп, оныгы белән ярышып җырларлык матур тавышы һәм дәрманы бар икән. Нурзилә чишмәсенең бер юмарт чыганагы ул—Саҗидә әбекәй!*

*Республика матбугатында инде шактый күренсә дә, бу хикәя—«Казан утлары»нда яшь каләмдәшебезнең дебюты. Хәерле теләктә калыйк: Нурзилә чишмәсенең юлы дәвамлы, илһам чыганаклары юмарт булсын!*

*Редакция*

Нурзилә

# КАШЛЫ БАЛДАК

...Тып-тып-тып... Җил көчәеп киткәндә генә ешаеп ала да һаман шул бертөрле көйгә тәрәз пыяласын кага тамчы. Бу төн мәңге бетмәс кебек, Чәчкә инде аның кайчан башланганын да онытты. Тулай торакның кеп-кечкенә бүлмәсе тәрәз төбендә, кыеклап яуган көзге яңгырга битен куеп, гел шулай утыргандыр шикелле. Бер канаты ачык тәрәзәдән каршылыксыз гына узган җил, юешләнеп бөдрәләнгән күксел чәчләргә сак кына кагылып алгач, иркенләп, бүлмәне әйләнеп килде. Бермәл аптырап торды, аннары, пәрдәләр белән кул чәбәкләшкәч, кызыйның авыр уйларын үзенә ияртергә теләгәндәй, кабат чәчләреннән сыйпап узды.

...Тып-тып-тып... Янаклар буйлап тәгәрәгән әллә яшь, әллә яңгыр тамчылары шунда, инде белеп тә булмый... Сулыш та алмый кебек иде бит, шөкер, кузгала әнә, дип куанды җил, сары яфраклы каен толымнарын чайкалдырып, һәм, кайдандыр табып, кызга бер яшел яфрак сузды. Битенә "чәп" итеп яфрак кунгач кына Чәчкә калтыранып куйды, гүя моңарчы җилне тоймаган да иде ул.

Авыр сулап, йомарлап күкрәгенә кыскан сул учын ачуга, яңгыр аша өзек-өзек яктырткан урам утында ике балдак җемелдәп китте. Зуррагы кочагына сыенган кечкенәрәк балдактагы нәни асылташка тамчы тамып, карангылыкка бер уймак ап-ак балкыш чәчелде.

...Сул учына ике балдак кочып, Чәчкә инде җиденче туган көнен каршылый. Ралифтән башка. Бер ялгызы. Сөйгәненнән соңгы истәлек булып кипкән бер кочак ак розадан тыш, кызга башкача чәчәк бүләк итүче булмады. Янәшәсендәге бәллүр вазада сары роза—туган көненә үзенә бүләге. Таҗ яфракчыгында әллә яшь, әллә яңгыр тамчысы ялтырый... Чәчкә, балдаклы учын йомып, күкрәгенә кысты. Күзен дә йомды, һәм яңгыр толымыдай күксел чәчле башы кабат тәрәзә яңагына терәлде.

...Тып-тып-тып... Яңгыр тамчылары белән аралашкан ачы яшьләр алсулыгы инде сизелерлек унган янаклар буйлап акты да акты. Кыз хәзер сулкылдамый диярлек, тик ябык иңнәре генә вакыт-вакыт дерелдәп куя.

...Тып-тып-тып... Менә җиденче ел инде Чәчкә бары тик туган көнендә, берүзе калгач, яңгырга ияреп, төн буе елый. Күз яшьләре ел әйләнәсенә җитәрлек коелгангамы, ике туган көн арасында, никадәр генә кыен булмасын, бөртек яшь тә күрсәтми кыз. Күнеленең әрнү чишмәләре мөлдерәп тулса да, аларны чайпалдырып түгәрлек көч булмагангадыр бәлки, барлык үпкә-рәнҗешләр күкрәгенә таш булып урнаша. Җәрәхәтле җаны шул әрнүгә бераз гадәтләнгәнче, атналар буе тирән сулый алмаган чаклары күп була...

...Ралифе аңа туган көнендә ничә яшь булса, шулкадәр ап-ак розалар бүләк итә иде. Бергәләп каршылаган соңгы туган көнендә сөйгәненең тәбрикләп әйткән татлы сүзләрен, кайнар иреннәрен кинәт бүгенгедәй ачык тойды Чәчкә. Аннан соң... Нефтьчеләрнең Төмәндә чираттагы вахтасы... Никләргә генә иптәшләреннән аерылып калган соң ул?! "Туган якларга бөтенләйгә кайтам, башкача сине калдырып китмим, мәңге бергә булырбыз..." дигән соңгы хаты... Аннан инде... тимер табутта кайтарылган җансыз гәүдә... Шактый вакыт үтсә дә, ул көннәрнең ярасы һаман яңа... Ралифнең ялгыз әнисе дә, Чәчкә дә бу коточкыч фаҗигадән катып калган көн... Бердәнбер улының ачы хәсрәтен эчкә йоткан ананың, таш

сын кебек торган Чәчкәне кочагына кысып: "Ела, кызым, ела, син дә харап буласың бит",—дип өзгәләнүе...

Аяз көнне яшен суккан кебек бу кайгы бичара ананы "сары йорт"ка илтеп тыкты, Чәчкәне дә сындырып ташлады. Аяк-куллары хәрәкәтсез калган Чәчкәне, айлар буе бер хастаханәдән икенчесенә күчереп йөртә торгач, бераз кеше рәвешенә кертеп, кабат тормышка кайтардылар. Икенче группа инвалидлык биреп... Ап-ак чәчле табибнын, дөньядан кичкән шикелле торган кызнын сул кулыннан алып, тыныч тавыш белән әйткәннәре, жепкә тезелгән сәйләннәрдәй, Чәчкәнең анында тагын янарды: "...Без булдыра алганның барын да эшләдек, калганы үзеннән тора. Онытырга тырыш... Башка шәһәргә күчеп кит, тыныч эшкә урнаш, сиңа борчылырга ярамый... Артыгын шатланма, бернигә дә кайгырма, үз жаенны гына кара... Жанына да, тәненә дә авырлык китермәсән, яшәрсен... Элеккеге тормышыннны оныт, күнел тәрәзәләренне яп та, үткәннәренә, шакысалар да, ачма... Оныт, барын да оныт..."

Шуннан соңгылары исә саташулы төштәге кебек кенә булды. Нерв авырулары буенча гипноз сеанслары тәэсирендә, Чәчкә, хастаханәдән чыгуга, ин беренче эш итеп, туй күлмәген утка якты. Тоташ капроннан тегелгән өрфия күлмәк күз ачып йомганчы эреп бетте, мич төбендә, яраланган йөрәккә охшап, сынар учка сыярлык кап-кара күмер калды. Аннан соң кыз зиратка китте, исәбе—үләр алдыннан кинәт анына килеп Ралифнең әнкәсе Чәчкәгә тапшырырга кушкан пар балдакны—сөеклесенең соңгы истәлеген—кабергә күмү иде.

...Тып-тып-тып... Тимер чардуганнын салкын челтәренә маңгаен терәп, Ралиф үлгәннән соң беренче тапкыр елады Чәчкә. Вакыт агышы тукталгандай булды. Әмма туганнары әниле-уллы ике кабергә бергә куйган көмеш төсенә буялган чардуган аша үрелә алмады кыз. Пар балдакны кочып йомарланган сул кулы зиратта ачылырга теләмәде... Шул жәйне ул туган шәһәреннән китте. Еракка...

...Чәчкә, тирән сулыш алып, күзләрен ачты: күнеленә урнашкан таш—ел буена жыелган яшьләр шактый кимегән. Офык читендә тан шәүләсе тоемлана, ахры...

Барысын да юктан, нульдән башлау шулкадәр кыен булыр дип башына да китермәгән иде ул. Элеккеге эше, дуслары, хезмәттәшләре төшләренә кереп йөдәтте. Тик Ралиф кына... ялгышып та, бер тапкыр да күренмәде. Аны уйламаган киче юк та бит Чәчкәнең. Өстәвенә, һәр яна танышын, ихтыярсыздан, Ралиф белән чагыштыра һәм, авыр сулап, кире кага иде. Оныта алмады Чәчкә сөйгәнен, оныта алмас та... "Күремчегә барма, башына бәла алма" дисәләр дә, югалтасы әйберем барыбер юк, дип, анда да булды кыз. Тегесе исә, ин авыры—жиде ел, аннары жиңелрәк булыр, диде... Ышанды Чәчкә, көтте, һаман да көтә.

Яна эшенә ияләшә алмады ул. Хезмәттәшләре аны гел шат күнелле, уенчак, жор сүзле, башкалар кәефен дә күтәрә алырлык, бер дә боекмас кыз дип беләләр иде. Эх, алар маска киеп яшәүнен никадәр авыр икәнен дә аңласалар! Юк, күнеле ятмады Чәчкәнен ят шәһәргә дә, хезмәттәшләренә дә, сон чиктә—эшенә дә. Бөтенләй очраклы рәвештә генә килеп эләккән яна коллективка сиздермәс өчен, эшкә урнашканда, инвалидлык группасын да алдырган иде. Авыру кеше кайда да артык бит. Әмма уйлап бетермирәк кылган әлеге гамәле үз башына булыр, ахры: соңгы вакытта торган саен ешрак кузгалган авыруын авызлыклау өчен көннән-көн көчлерәк дарулар кирәк иде... Үзәк шифаханәдән исемлек белән генә сатылучы уколлар коточкыч кыйммәт, группада булмагач, аңа берниндә дә ташлама каралмый. Быел яз, дәвалау курсы өчен уколларга акчасы житмәгәч, асылташлы балдагын сату нияте белән барды. Һәм исе китте: тыйнак кына жемелдәгән нәни таш бриллиант икән! Әле ярый ис кенә китте, акыл булса, ул да китәсе икән, дип елмаеп чыккан иде кыз комиссионкадан: никах балдагын гажәеп кыйммәтледер дип уена да китермәгән иде бит! Хәтта берничә ел укол-дарулар кайгысы, тәгәлрәге,

аларны алырлык акча кайгысы бетәчәк иде, әмма соңгы минутта кире уйлады Чәчкә. Хезмәт хакы җәй буе бурыч түләүгә китсә китте, тик Ралиф кулларының җылысын тойган балдаклар кызда калды... Әгәр башкача җан асрар чарасы булса, бер минут тормас иде монда. Әмма, яшь барган саен, тагын барысын да яңадан башлау куркыта иде Чәчкәне.

...Тып-тып-тып... Төн буе коеп яуган яңгыр бераз тына төште. Ходаем, инде тагын ничекләр барыйм эшкә, дип әрнеп уйлап алды кыз. Ул сул учын йомып күкрәгенә кысты, бөтен гәүдәсе белән тәрәзә янагына сөялде. Елап яшьләре дә беткән, кузгалырлык та хәле калмаган иде Чәчкәнең...

Кинәт кыз яңгыр аша үзен чакырып кул изәгән Ралифен күрде. Бер кочак ап-ак розалар күтәргән сөеклесе елмая, тик, никтер, дәшми. "Китмә, көт мине, мин хәзер!" дип кычкырырга теләсә дә, Чәчкәнең тавышы чыкмады.

...Таң атты. Яңгыр да туктады. Көзге җил, ашыга-ашыга, кызның чәчләрен, юешләнеп гәүдәсенә ябышкан юка күлмәген киптерде. Ник һаман уянмый соң, нигә шулкадәр авыр сулый, тәне ут яна бит, дип борчылды үзе, кыз аша үтәли исеп. Бары кич авышкач кына килеп кергән күршесе Чәчкәне авыр хәлдә табачагын да, үпкәсе шешеп, реанимациядә берничә көн яткач, тәмам хәлсезләнгән тәнен калдырып, җанының Ралифе янына китәчәген дә, күкрәгенә кыскан сул учын күмгәндә дә ачтыра алмаячакларын да белми иде әле көзге җил...

## КУЯН

Өстәл уртасындагы зур тортка кадап куелган кечкенә шәмнәрне санарга керешкән Айсылу ханым гаҗәпләнүдән аһ итте: егерме дүрт урынына егерме биш шәм балкып утыра иде! Каян килеп эләккән соң әле ул? Артык шәмне алырга сузылган кулы исә һавада эленеп калды. Юк, аны алсаң, татлы сарайның бөтенлеге, матурлыгы югала икән бит! Калсынсана, хәерлегә генә булсын, дип уйлап куйды Айсылу һәм өр-яңа күлмәк киеп көзге алдында боргаланучы кызына сөеп карап, шахмат тактасыннан аерыла алмаган улларын ашыктыра башлады:

—Җәһәтрәк булыгыз, балалар. Озакламый кунаклар да килер...

Теле бер нәрсә сөйләде, ә хәтерендә исә, никтер, моннан нәкъ ун ел элек булган вакыйгалар яңарды. Әйтерсең, алар, менә бүген генә булгандай, бөтен ваклыклары белән күз алдына килделәр дә бастылар. Әйе, гаҗәеп сәер, аңлаешсыз һәм серенә әле бүген дә төшенеп бетә алмаган вакыйгалар иде шул алар.

Айназга өч яшь тулган көн... Төшендә үзе хәтле уенчык песи күргән икән кызчык. Әле җитмәсә, ул песи, ямь-яшел күзләрендә очкыннар биетеп: "Минем исемем Куян, мин сиңа кунакка киләм, каршы ал!"—дип тә әйткән икән.

—Әни, шул песи килер микән?—диде Айназ, әнисенә сырпалана-сырпалана.

—Кунак булып кына килмәс, без аны үзебез барып алырбыз, бөтенләйгә үзебездә калыр,—дигән иде Айсылу.

И сөенгән иде Айназ, кулларын чәбәкли-чәбәкли сикергәләгән иде:

—Минем Куяным була, минем песием була. Әнием, бүген үк барып алабызмы?

"Балалар дөньясы" кибетендә беренче күргән песигә чат ябышты Айназ:

— Әнием, менә ул "Куян"!

Шатлыктан кызның алтынсу бөдрәләренә кадәр көлә иде сыман. Ул зәңгәрсу мамык тунлы, койрык очы бантиклы, үзе хәтле уенчык

песине кочаклап та алды һәм дөньясын онытты. Бу "Куян" нәкъ шул төшендә күргән песи икән бит!

Кассага акча түләп торганда, Айсылу үзенә текәлгән икенче бер нәни малайга игътибар итми кала алмады. Бала күз явын алырлык тәтиләргә дә, шул уенчыклар тирәсендә бөтерелгән яшьтәшләренә дә карамый. Ул бары тик, алларына чыга-чыга, хатын-кызларның йөзләренә текәлә, кемнедер эзли шикелле иде. Аның болыт төсле күксел-зәңгәр күзләре мөлдерәгән, менә-менә яңгыр башланыр кебек тоела иде.

Ул арада бала, чарасызлыктан арып, тәтиләр тирәсенә лып итеп утырды да кычкырып елый башлады. Уенчыклар бүлегендәге күңелле шау-шу кинәт тынып калды. Нәниләр дә, олылар да малайга борылдылар. Аның янына сатучы хатын белән бергә бер үк вакытта Айсылу килеп житте, баланың житендәй аксыл чәчләреннән сыйпап алды.

—Нигә елыйсың, акыллым, елама. Син зур малай бит инде,—диде ул, баланы тынычландырырга тырышып.

—Әниемне югалттым,—диде малай үксүеннән тыела алмыйча һәм, көтмәгәндә, Айсылуның итәгенә капланды.

—Хәзер табабыз әниеңне, ул үзе дә сине эзли-эзли йөдәгәндер инде...

Кибет директоры бүлмәсенә малайны өчәүләп: кызы Айназ, улы Айваз һәм Айсылу бергәләп озаттылар. Әниләренә сыенган балаларны күреп, малай тагын үкси башлады. Аны юата-юата, әнисен көтә-көтә шактый вакыт үтте, кибет радиоузелыннан кабат-кабат әйтүгә карамастан, малайны эзләп килүче күренмәде.

Ләкин болай озак торып булмый иде. Айназ белән Айвазның туган көненә чакырылган кунаклар жыелыр чак житкән, кайтырга ашыктылар. Ишектән чыгышлый, Айсылу ханым тагын малайга әйләнеп карады, кәнәфи почмагына елышкан сабый тәрәзәгә багып тынып калган иде...

Ә өйдә бәйрәм! Әтиләре өстәл әзерләп өлгергән, балалар, кошчыклардай чыркылдашып, Айназны сырып алдылар; китте көлеш, котлау, жыр-бию, күңелле уеннар! Кызы белән улының бәхет балкыган йөзләренә караган саен, Айсылуның күз алдына кәнәфи почмагына сыенып елаган малай килде.

...Тәмледән-тәмле ризыклардан рәхәтләнеп бушап калган савытларны юганда да, бәйрәм ыгы-зыгысыннан йончыган бүлмәләрне жыештырганда да малайны онытмадылар.

—Ул үзенә өч яшь икәнен әйтә дә белми, менә болай итеп күрсәтә,—дип тәтелдәде Айназ, нәни бармакларын тырпайтып.

—"Ш" хәрефен дә дөрес әйтә алмый икән, исемен "Саса" диде,—дип дәвам итте Айваз һәм бик белдекләнеп өстәде,—әле фамилиясен дә белми, әтисенең исемен—"папа", әнисенекен "мама" дип әйтте!

Айсылуның күңеле тыныч түгел иде. "Баланны югалтсаң, акылыңнан язарсың",—дип кызганды ул Сашаның әнисен. Ахырда түзмәде, балаларын йокларга яткыруны иренә калдырып, шәһәр үзәгенә урнашкан зур кибеткә йөгерде.

Кабинетта бер милиционер белән директордан гайре беркем дә юк, алар исә малайның әнисе килер дип өметләнәләр иде күрәсең, ишек ачылганда икесе берьюлы диярлек борылып карадылар.

Курчак кебек итеп затлы чит ил киемнәренә киендерелгән бу малай да кемнеңдер кадерлесе, багалмасы бит. Айсылу бәгырен кисеп узган шушы уйдан айный алмый интекте. Тик малайдан сораштыру бернинди дә нәтижә бирмәгән. Ул бары тик үзләренең машина белән "озак-озак" килгәннәрен генә әйтә алган.

Кибет ябылыр вакыт житте. Шәһәр урамнарын караңгылык пәрдәсе чорнап алды. "Балалар дөньясы"ның этажларында да бер-бер артлы утлар сүнә башлады. Баланы кая куярга белмичә аптыраган директор белән милиционерны гажәпкә калдырып, Айсылу малайны житәкләп алды да ишеккә таба атлады.

—Хәзергә бездә торып торсын, әти-әнисенә эзләп табу да уңайрак булыр,—диде ул, үзенең тәвәккәллегенә үзе шаккатып.

Шул ук кичне телевизордан табылдык малайны күрсәттеләр, аны кайдан табарга мөмкинлекне тәгаенләп, Айсылу ханымнарның адресы әйтелде.

...Йокларга яткырыр алдыннан Сашаны юындырганда, күлмәгенең эчке кесәсеннән кат-кат бөкләп тыгып куелган 100 долларлык кәгазьне табып алгач, Айсылу телсез калды. Димәк, сабыйны махсус адаштырып калдырганнар!

Көне буе үксеп хәлсезләнгән бәләкәчне елый-елый юындырганы, төшендә дә вакыт-вакыт сулкылдап куйган баланы кочагына кысканы әле дә бүгенгедәй хәтерендә Айсылуның.

...Көннәр үтте, атналар, айлар бер-бер артлы артта калды, көн саен телевизордан Сашаның рәсемен күрсәтеп, адресны кабатлауга карамастан, малайның әти-әнисе күренмәде.

Саша Айназ белән Айвазга ияреп татарча сөйләшергә өйрәнде, тик яңа гаиләгә бик авыр ияләште. Кыңгырау чыңлаган саен ишек төбенә йөгереп барып кемнедер көтте, көн дә диярлек Айсылуны "Балалар дөньясы" кибетенә әйдәде; баруга, үзе онытып калдырылган йомшак уенчыклар бүлегенә йөгерде, аннан инде бичара малайны кибет ябылганчы алып китеп булмый иде. Әмма ни гаҗәп: "Куян" исемле песине Айназдан да ныграк яратты Саша.

Айсылу исә баланы кая куярга белмичә гаҗизләнде: ятимнәр йортына тапшырырга кызганды, сабыйны махсус ташлаганнар дигән рәхимсез дөреслек белән һич тә килешә алмый иде ул. Аннары Сашаны уллыкка алуны рәсмиләштерделәр. Әтиләре Алмаз да каршы килмәде: алар җитеш тормышта яшиләр, өченче баланы тәрбияләрлек мөмкинлек бар иде.

...Еллар үтте. Саша аз сүзле, басынкы, тыныч бала булып үсте. Әмма, буш вакыт тигән саен "Балалар дөньясы"на йөгерүе гадәт булып калды. Айсылу белән Алмаз "улым" дип дәшсәләр дә, аны Айназ белән Айваздан һичкайчан аерып карамасалар да, Саша бер генә тапкыр да, хәтта ялгышып та аларга "әти", "әни" дип әйтмәде. Беренче күргәндәгечә, аның өчен алар һаман "тетя, дядя" булып калды. Моны берничек тә аңлатып булмый иде.

Туган көнен Айназ белән бер көнгә, үзе табылган көнгә билгеләделәр. Ләкин Саша кызчыктан гәүдәлерәк булып, таза, матур булып үсте, яңа әти-әнисенә әлләни мәшәкать тудырмады. Кечкенәдән шахмат белән мавыкты, яхшы укыды, малайның ни житте гаиләдән түгел икәнлеге дә ачык аңлашыла иде.

...Уйларыннан бүлеп, сискәндереп ишек кыңгыравы челтерәде, әмма кунакларны каршы алырга йөгергән Айназның яңгыравык тавышы шактый аптыраулы ишетелде: "Сезгә кем кирәк?"

"Әниең өйдәдер бит",—дигән ят тавыш Айсылуны да ишек катына чакырды. Бусагада озын буйлы чибәр яшь хатын басып тора иде. Ананың йөрәге, ниндидер көтелмәгән хәл буласын сизенгәндәй, кысылып куйды. Шулай да, чакырылмаган кунакны түргә дәштеләр.

"Мин Сашаның әнисе булам",—диде ханым, бер мизгелгә генә Айсылуның күзләренә текәлеп. Ана телсез калды.

—Ник? Ничек әнисе буласыз? Тугыз ел буе кайда йөрдегез соң сез?—диде ул, бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч.—Балагыз турында ник бүген генә искә төшердегез? Ни өчен бу көнгә кадәр бер хәбәрегез дә булмады?

—Дәрәҗәле фирма ирем белән икебезгә Европага барып эшләргә тәкъдим ясады, өч елга контракт төзеде; анда берничек тә бала белән барырга ярамый иде, шунлыктан без малайны бирәр балалар йортына тапшырып китәргә уйладык,—дип, гадәти әйбер хакында сөйләгән кебек кенә сүз башлады хатын.—Ә аны, бездә ятимнәр дә күп, дип, беркайда да алырга теләмәделәр, югыйсә, вакытлыча гына иде бит. Шуннан инде

ирем бу хәлдән чыгуның үзенчәлекле юлын тапты: зур шәһәргә илтеп, берәр җирдә калдырыйк та кем алып киткәнен карап торыйк, илгә кайткач, өйгә кабат алырбыз, дип уйлаштык һәм тиз үк тормышка да ашырдык, калганы инде сезгә мәгълүм. Сез, зинһар, мине дөрес аңлагыз, анда бармый калырга һич ярамый иде. Тик шунысы: без чит илдә озаграк тордык, өстәвенә, анда туган кызыбыз да гомерле булмады, дүрт яшь тулып килгәндә, урамда машина бәрде үзен. (Шул мәлдә, Айсылуны чиксез гаҗәпләндереп, аның кара күзләрендә яшь тамчысы күренде.) Бу улыбызны, инде шактый вакыт та үткәч, онытканда да шикелле идек, тирәндә калган йөрәк яраларын яңартып йөрмәскә уйлаган идек... Әмма табиблар, башка балаң булмаячак, диләр. Ләкин миңа бала кирәк! Бирегез миңа үз улымны! Сезнең тагын икәү бар бит...

Залда тынлык урнашты. Айсылу ханымның башы эшләми иде, мондый хәлләр буласын күз алдына да китермәде бит ул! "Ичмасам, әтиләре дә кайтып җитми",—дип өзгәләнде ана, чарасызлыктан ни кылырга белмичә. Балаларның да тавыш-тыны чыкмый, өлкәннәр сөйләшкәндә алар комачаулап йөрмиләр.

— Саша зур инде, ни эшләргә кирәклеген үзе хәл итсен, ул ничек әйтсә, шулай булыр,—диде Айсылу үзе дә көтмәгәндә, малайның һаман әле "әни" дип дәшмәвен хәтерләп.

— Әйе, нәкъ бер айдан ана 13 яшь тула,—Нинаның тавышы калтырап китте,—мин аның ниндирәк булуын да күз алдыма китерә алмыйм бит, йә Ходаем!

Көч-хәл белән кузгалып, ана балалар бүлмәсенә китте, шахмат тактасына иелгән малайга бер мәл моңаеп карап торгач, Сашаның иңнәреннән кочты: "Бар, улым, сине әниең чакыра..."

Малайның күзләрендә шатлык та, хәвеф тә берьюлы чагылып китте, ни әйтергә белми бераз утырды һәм, кинәт сикереп торып, кунак бүлмәсенә атылды. Айсылу исә, хәлсезләнеп, Сашаның урынына сыгылып төште. Бераздан, үзен кузгалырга мәҗбүр итеп, зал ишегенә килде, әмма керергә кыймады; сагаеп калган балалары янына үтеп кызын кочаклады да аның йомшак чәчләренә битен куйды. Тик ул халәттә дә озак тора алмады, кунак бүлмәсенә кабат барды, бераз икеләнеп торгач, түзмәде, ишекне кинәт ачып кереп китте.

Саша диван кырыена гына утырган, үтәли карашы әнисенә "кадалган", үзе бер сүз дә дәшми; хатын исә гаепле тавыш белән сөйли дә сөйли...

"Юк, сез минем әнием түгел, әни димим, әни диялмыйм мин сезгә, әнием мине ташламаган булыр иде, ничә еллар буе бер дә күрмичә түзә алмас иде!"

Улларының бу кадәр катгый хөкеменнән ике ана да катып калды. Ул арада Саша атылып-бәрелеп чыгып йөгерде, урамга ук чапты бугай, тышкы ишек тә шапылдап ябылды.

Беренче булып ят хатын телгә килде: "Ярый, мин китим, без бөтенләй чит кешеләр икән, ул инде хәзер минем балам түгел..." Ханым ашыгып урыныннан кузгалды, тик ишек төбендә генә исенә килеп рәхмәт әйтте һәм, башкача борылып та карамыйча, тиз генә чыгып китте. Айсылу һаман әле аңына килеп бетмәгән иде. Ярый әле, балалары, әнкәләрен ике яклап кочып алганнар да, бер сүз дәшмиләр.

Шулай күпме торган булырлар иде, кинәт ишек ачылды, анда, ишек яңагына сөялеп, Саша басып тора иде. Аны күрүгә, Айсылу елап җибәрде. Малай аның янына йөгереп килде һәм, "Әнием!" дип, ананың кочагына сыенды.

# ШИГЪРИЯТ



## Флера Гыйззәтуллина

### ШУЛ КӨННӘРДӘН ТӘСБИХ ТЕЗӘМЕН

#### Каеннардан мин тибрәлеш көтәм

Тумышымнан килгән уңышым бу:
Калдырмадым юлда онытып.
Бәхет эзләп чыккан һәр юлымнан
Кайтам берәр моңлы җыр отып.

«Илгә кайту» җырын җырлый-җырлый
Ак каенга килеп сөялəм.
Безне көтеп торган ил хәстәрен
Иңнәренә каен төягән...

Менә безнең гомер каеннарын
Тибрәлдерә җилләр сак кына...
Каеннардан мин тибрәлеш көтәм
Җырланасы җырым хакына.

#### Чәчләремне җилләр тарады

Илдә чакта башым түбән исәм дә,
Түбәнлеккә күңел бер дә күнмәде.
Кылганнарын сибелдереп үрдәге—
Таулар мине биеклеккә өндәде.

Үр менгәндә тау ташына абынсам,
Таш өстенә тамды кайнар яшьләрем.
Тауларга мин кара кайгы чәчмәдем:
Ак кылгандай ап-ак инде чәчләрем.

Чәчләремне минем җилләр тарады,
Алтын иде ул җилләрнең тарагы.
Илләр белән якынайтып араны
Язмышларны дәвалыйсы бар әле...

## Кайту

### I

Сагындым туган ягымны...
Табылса берәр юлдаш
Туганнар, дуслар янына
Бер кайтып килми булмас.

Елгалар кичмичә булмас
Яфрактан басма түшәп.
Яфрактай сарыла җанга
Башлардан ашкан исәп.

Урманнар булып чайкала
Күзләргә тулган сагыш.
Сезнең күз карашларыгыз
Таныш, туганнар, таныш!

Хакым бар сезгә, хакым бар:
—Туганнар!..—дип әйтергә.
Ал таулы Азнакаем да,
Әсәем дә хәтердә.

Аз түгел Азнакаемда
Үрләрнең бормалысы.
Менәсе үрләргә бәйле
Җырларның җырланышы.

Ризыкка, туфракка бәйле
Күңелнең үсүләре...
Ни тора ипи-күмәчләп
Туя чәй эчүләре?!

Безгә артыгы кирәкми,
Ипи-чәй булса ярый!
Кайтабыз, каршы тауларга
Сокланып карый-карый.

### II

Сез минем таудай өметнең
Юлдашы, юлчылары.
И, газиз Азнакаемның
Фидакарь җырчылары.

И, мәшһүр игенчеләре
Үрле басуларымның.
Сездә кояшлы ярсуы
Язгы кар суларының.

Яктыра сезнең холыкта
Урманнар, таулар күрке...
...Миндә дә сезнеке төсле
Сагыну-яну ирке.

Бу ирек тагын да арта
Төбәлсә күзләр-күзгә.
Тауларга карап тау булу
Бәхете язсын безгә.

III

Азнакай, күзлисең мине
Үрелеп узган чордан—
Арада Себер... чит юллар...
Кара төн!.. Кара урман!

Төнката ага да ага
Гомерләр—ярсу елга.
Сагынмый, ярсымый кара,
Тумыштан ярсу бул да!

Ялганмый кара таңнарга
Җаннарың балкышында...
Минем җан сайрар кош булып
Һәр таңда кайта шунда.

Терелтә чорлар хәтерен
Уйларым, хыялларым.
Азнакай, сине һичкайчан
Мин күреп туялмадым.

... Китсәм дә, китмәдем синнән
Әйләнеп кайтмасларга.
Береккән мәңгелек гамем
Авылдаш, якташларга.

Шул гамьне иңгә күтәреп
Йөргәндә еракларда...
Йотлыгып карыйм таудагы
Кылганлы зиратларга.

Бер гамьсез, ямьсез чит җирдә
Каласым килми ятып.
Үкси җил ерак чорларның
Хәтер капкасын шакып.

Кушыла шуңа өметнең
Чит җирдә киселгәне.
Өметсез узган һәр чорның
Исемдә исемнәре.

Исәптә, бәгырь кисәктә
Әйтәсе соңгы сүзем...
Шушы сүз аша чор башы
Танытыр әле үзен.

Сибелер минем өлешкә
Кылганнар дөрләп үрдән...—
Тәкъдирем мәхрүм итмәсә
Җәсәдем көткән гүрдән!

## Китәм әле кабат Донбасска мин

*Китә казлар, китә казлар,*
*Китә казлар Донбасска.*
*Китәләр казлар Донбасска,*
*Гомергә кайталмаска.*

Халык җыры

Хәтеремә каз каурые кадап,
Китәм әле кабат Донбасска.
Кара көндә нигә шахталардан,
Шахтерлардан гыйбрәт алмаска?!

Таныш эш ич миңа шахта эше,
Таныш төпсез караңгылыгы.
- Нишлим?—диеп анда үз-үзеңне
Кызганырлык чараң булырмы?

Вагоннарга төяп эткән чакта
Ат тарталмас авыр йөгемне,
Мин бит минутка да онытмадым
Татар кызы икәнлегемне.

Татарчалап анда сөйләшсәм дә
Урыс, хохол мине аңлады.
Мунча кереп җир карасын юдык,
Йөз карасы мине алмады.

Каралудан сез дә курыкмагыз
Мунча ягып суын ташырлар—
Мин шаһитмын: һәммә эшкә уңган
Татарлардан туган «хохоллар».

Язлар шаһит: анда җиде ятның
Кире кагып биргән үгетен...—
Илгә алып кайтып мин ир иттем
Хохоллашкан татар егетен.

Татарстанымда бер ир артты
Һәм ул тартты атка аркалык...
Шул сәбәпле илдә татарларым
Бетмәгәндер, бәлки, таркалып!

...Китәм әле кабат Донбасска мин:
Гомерлеккә калмам, кайтырмын—
Иңбашына ак мамык шәл ябып
Күкрәп килгән яңа гасырның...

## Яфрагын коя карурман

Аккош күлләрен буйлыйм да
Сагышка чумам җәйдән үк...
Парлап йөзәсе күленә
Аккош кайтмады әйләнеп.

Яралы татар әрнеше
Яралган аккош зарыннан.
Саргаеп җәйге күлләргә
Яфрагын коя карурман.

Аттылар мәхәббәтемнең
Аккошын, каракошын да...
Саклагыз аны туганнар!—
Киләчәк—канат очында!

Атырлар йөрәгемә дә...—
Мин бу афәткә ышанам:
Дөнья мәхшәргә охшаган,
Замана канга сусаган...

## Сизәмен...

Җырлап илгә илһам кайтарсам да,
Түккән көчем түгел кайтырдан...
Илһамланып, янып богауланам,
Мин иҗатта—ялсыз каторжан!

Көч-куәте җанның кимесә дә,
Кайтавазы җырга үрелсен!..
Каторжаннар богау чылдырдатып
Эзләп таба, диләр, бер-берсен.

Минем дә бар табыласы көнем!—
Якын инде ул көн—сизәмен!
Чылдыраулар өзгән үзәгемә
Шул көннәрдән тәсбих тезәмен.

Иҗаттагы сөю ирегемне
Багышлыймын илдәшләремә,
Ирексездән тулган Ил кайгысын
Күчергәндә күз яшьләремә.

❄



## Луиза Янсуар

### ЯФРАК ЯРАМ, КОШКА ӘВЕРЕЛӘМ...

*

Нинди төн бу? Күбәләкләр
Атыла ут кочагына.
Бусагамда—ялгыз шәүлә...
Ялкын дөрли—учагымда.

Нинди төн бу? Сәгатьләр тын.
Талпына җан—учларымда.
... Кемдер каккан Сөюеңне
Сыендырдым кочагыма...

*

«Читлекләргә ябып саклар идем
Ят күзләрдән»,—дисең.
Кысаларга сыймас горур җаным
Түзә алмас, бел син!

Күзләремнең зәңгәр дәрьясыннан
Ни эзлисең шулай?!
«Тынычлыгым җуйдым синсез»,—дисең,
Шикләнәсең, бугай.

«Былбыл коштай ябып саклар идем
Алтын читлекләрдә...»
Аһ, белмисең! Җаным күптән инде
Азат бу чикләрдән.

*

Бөтерде дә алды дулкын
Кочагына.
Сулар шашып үргә ага...
Учларыма
Сузылды иң нечкә ботак
Сылу талдан.
Коткарырга теләдеме?!
Белә алмам...

*

Күкрәү иңсә Күкләр тарафыннан,
Утлы яшен үтсә чагылып,
«Аннан хәбәр...»—диеп, исеңә ал
Яшеннәрдәй ялкын чагымны...

Ә мин, җанның читлекләрен ачып,
Юнәлтермен Күккә карашым...
Һәм кайтырмын сиңа—
бер мизгелгә—
Мәңгелектән гүя адашып...

*

Һәр аерылган саен
Йөрәгеңнән
Тамырларым белән аерылам.
Синсез очсам,
Тарая күк Күкләр,
Канатларым җилдә каерыла...

Кабат кайтам сиңа—
Күкрәгеңдә
Яфрак ярам, кошка әвереләм.
Без бербөтен
Булганбыздыр, бәлки,
Җирнең тик яралган дәверендә?!

## Учак яктым

Җиде ят арасыннан берәү якын.
Далада аның өчен учак яктым.
Ак атым чапты, өзеп тезгеннәрен...
Ымсынган, ярсынганнар без генәме?!

Учагым очты үрләп-үрләп Күккә...
—Син икән,—дидем,—бердәнберем көткән...
Төн япты Җиргә йолдыз—канатларын.
Оялган Айны болытлар каплады.

... Кешнәде атым җилпеп җилгә ялын.
Таңнарның гүзәллеге!.. Хәйран калдым.
Җиде ят арасыннан иттем якын.
Далада аның өчен учак яктым.

&

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

**Гариф Галиев**

# КАРАКОШ СЫРТЫНДА

## I

Кырык жиденче елның кышы иде. Тышта күз ачкысыз буран, ул бүген гүяки бөтен авылны кар астында калдырырга тырыша, капка төпләренә күз ачып йомганчы сырындылар ясый, читән буйларына көртләр өя, каралты түбәләрен кар таулары белән тигезли. Һичбер нәрсәгә карамыйча, бөтен дөньяны туздыруында дәвам итә.

Шушындый март бураннары башланган көннәрнең берендә, нәкъ төн уртасында, Сабир картның капкасын шакыдылар.

Карт, өйдән чыгып капканы ачуга, атның Ташлыяр авылыннан икәнлеген белде һәм, көч-хәл белән капканы жилгә каршы тотып, атлы кунакны ишегалдының түренә, лапаска таба уздырып жибәрде.

Чанадан төшкән кеше озын толыптан иде. Беренче карауга ук аның гәүдәсен туры тота алмавы күренде. Ул, абына-сөртенә, картның каршысына килде:

—Бабай, исәнме!—диде, авызын жыя алмыйча.—Исәнме, бабай,—дип кабатлады шуның артыннан ук.

Карт үзенең шәһәрдә укучы кияве Фатихның моннан берничә көннәр элек Ташлыярга хатыны Мәликә янына кайтканлыгын ишеткән иде. Беренче сүздән үк Фатихның исерек икәнлеген аңлап алды, аңа өйгә узарга кушты. Исерек каршы килмәде, кикерә-кикерә, өзек-өзек сүзләр белән картка әйтте:

—Алай булгач, ба-бай, мин Сәйләнне дә алып керим, син атны үзең, үзең кара инде, ба-бай.

Сабир карт Сәйлән исемен ишетү белән, тугара башлаган атны тәртә арасында калдырып, Фатих янына килде.

—Әллә Сәйләнне дә үзең белән алган идеңме?

Исерек тагын кикерә-кикерә жавап кайтарды:

—Әйе, аны да алып кайттым, әбисе сагынгандыр,—диде.

Сабир карт үз күзенә үзе ышанмыйча янадан килеп чананы карады. Анда бер култык яшел печән белән бер чыптадан башка юк иде.

—Баланы кая калдырдың, кая куйдың баланы?—дип кычкырды Сабир карт, исерек киявенең каршысына килеп.—Кая калдырдың баланы, тизрәк әйт, миеңне карга чукыган нәрсә?!

Фатих кинәт уянып киткәндәй булды. Нәрсәнедер хәтерләп алды һәм исерекләргә генә хас бер тавыш белән сөйләнә башлады:

—Шаулама, ба-бай, шаулама... Так, мин аны, бабай, Каракош сыртында утыртып калдырган идем бит...

Карт, акылыннан шашар дәрәжәгә житеп, эшнең ничек булганын сорашырга тотынды. Исерекнең өзек-өзек сүзләреннән бер бөтен тупланды. Сораша торгач, Каракош сыртына житкәндә генә атның, нәрсәдәндер өркеп, чананы аударганлыгы һәм шул чакта Фатих белән Сәйләннең

чалуга егылып калганлыгы аңлашылды. Фатихның, чанадан егылып төшкәч, Сәйләнне төреп, юл буенда утыртып калдырганлыгы, үзенең ат артыннан берничә чакрым йөгергәнлеге һәм, атны тотканнан соң, Сәйләнне таба алмаганлыгы, ниһаять, аны онытып, чанада йоклаган килеш авылга кайтып кергәнлеге беленде.

Карт, өйгә кереп, хәлне карчыгына сөйләде. Икәүләп аһ орып тышка чыктылар, яртылаш тугарылган хәлдә, тәртә арасында торган атны ашыга-ашыга яңадан җигә башладылар. Карчык күршегә кереп бик тә тиз фонарь алып чыкты, аның артыннан ук фонарьның хуҗасы Хаҗиәхмәт үзе килеп керде, кызулыгы белән Фатихка сугып җибәрде.

—Исерек килеш бала утыртып йөрергә сиңа кем кушты! Башыңа ат типкән нәрсә!..

Бик тиз атны җигеп, Фатихны чанага төртеп аудардылар да, карт түргә, Хаҗиәхмәт чана башына утырып, Сәйләнне эзләргә чыгып киттеләр.

Буран торган саен котыра барды. Алга да, артка да, як-якка да карарга ирек бирми, туктаусыз йөзгә кар бәрә. Сабир карт дилбегәне тотып атны әйди, Хаҗиәхмәт, кулына фонарь тотып, маяк төпләрен карап, юлның читеннән бара.

Менә алар Каракош сыртына килеп җиттеләр. Икәүләп чанадан төштеләр, Фатихны да аягына бастырып, баланы кайда калдыруын сораша башладылар. Ул берсенә берсе капма-каршы сүзләр сөйләде, үзе, башын тота алмыйча, алга төнтәйде, туктаусыз төкеренде. Фатихтан мәгънә чыкмагач, Хаҗиәхмәт белән Сабир карт, юлның чалулы урыннарын айкап, Каракош сыртын берничә тапкыр урадылар. Сабир картны ат янында калдырып, Хаҗиәхмәт үзе юлдан эчкәре, кар белән капланмаган шәрә җирләргә кереп чыкты. Картның кинәше буенча, җил уңаена Каракош сыртының буена барып карады. Ләкин бала табылмады.

Буран көчәйгәннән-көчәйде, ат та тыңлаусызга әйләнде, үзләре һәр икесе дә манма тиргә батты, бу исә аларның үзләренең туңып-катып калу куркынычларын тудырганлыктан, Хаҗиәхмәт кире авылга кайтып, күбрәк кеше белән чыгуны кулай күрде. Бу фикергә Сабир карт та каршы килмәде. Каты буран булуга карамастан, Хаҗиәхмәт чанага аягүрә басып, дилбегәне тотты. Карт үзе атка аркасы белән кучер урынын алды. Икесе дә бер карауга бөтен басуны күрердәй булып, як-якка карана-карана, авылга таба юнәлделәр.

Төннең бик вакытсыз чагы булуга карамастан, бала югалу турындагы хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән иде.

Кайтучыларны урам буенда ук каршы алдылар. Бик тиз кайсы кая таралышып, ярты сәгать эчендә яңадан җыелып җиттеләр. Егерме бишләп ир, колхозның иң яхшы атлары җигелгән берничә чанага утырып, Каракош ягына киттеләр. Күбесе сугышта йөргән һәм дөньяны күргән ирләр иде. Чана саен бер кешене юлдан җибәреп, башкалары фонарьлар тотып юлдан эчкәрерәк керделәр һәм, бер-берсенә тавыш бирә-бирә, баланы эзләделәр.

Бөтен ачуы белән котырынган буран баланы гүя шушында, аяк астында гына яшереп тота, аны гүя үзенең дәһшәтле канаты белән басып улый шикелле иде. Ул эзләүчеләрнең күзләренә бәрелә, авызларына каплана, вакыт-вакыт аларны аяктан егарга маташа иде.

Сызылып кышкы таң атты. Каракош сырты артыннан кып-кызыл кояш күтәрелде. Күк йөзе чалт аяз төс алды. Һава суытып җибәрде. Төн буе буранлап яуган җепшек кар иртәнге салкын белән җиргә ябышты. Кинәт бөтен дөнья яктырып китте. Юл буйларында карга күмелеп бетмәгән маяклар калыкты, ап-ак кар эчендә утырган кечкенә өйләр күренде. Каршыдагы Каракош сырты, зур тартышлардан җиңеп чыккан арслан кебек, бөтен гәүдәсен сузып ял итәргә яткан иде. Төнге вакыйгадан соң ул авыл каршында зур бер көч иясе кебек күренә. Гүя, әйдәгез, аяз көндә тагын бер сынашып карыйк, дигән шикелле, халыкны көрәшкә чакыра, аларга тагын бер кат үзенең гайрәтен күрсәтергә җыена иде.

Урамда Сабир картның капка төбенә җыелган бер төркем халык әледән-әле Каракош сырты ягына карый, янадан һөҗүм итәргә хәзерләнә иде.

Төне буе эзләп тә Сәйләнне таба алмыйча борылып кайткан халык төш алдыннан үзеннән-үзе туплана башлады. Ин элек, кулына агач көрәк тотып, Хаҗиәхмәт килеп чыкты.

—Сабирның да, карчыгының да исәп белән башлары каткан. Болай тору ярамый, әйдәгез, янадан эзләп карыйк, сабыйны ничек тә табарга кирәк.

Авыр хәсрәтне барысы да үз йөрәкләре белән кичерәләр, Сәйләннең югалуы һәрберсен әрнетә иде. Берәү дә каршылык күрсәтмәде. Бик тиз арада берничә чанага утырып, Каракош сыртына таба янадан чыгып киттеләр.

Хаҗиәхмәт, үз гомерендә күп юл йөргән, бозлы яңгырлар, каты бураннар күргән кеше булганлыктан, арада иң тәҗрибәлесе иде. Авылдан чыгар алдыннан гына башланган җәяүле буран турында үзенчә фикер йөртте:

—Безнең өчен иң кирәге шушы. Мондый җәяүле буран кар өстен себерүчән була. Белмәссең, сабыйның берәр әйберсе табылыр,—диде һәм шулай булганда эзләүнең җиңеләячәген сөйләде.

Иртүк Ташлыярга, Мәликәгә хәбәр иткәннәр иде. Халык Каракош сыртына менеп житкәндә, каршы яктан туры ат җигелгән чанага ниндидер бер яшь кеше белән утырган Мәликә күренде. Елый-елый халык арасына кереп, бергәләп Сәйләнне эзли башлады.

Яшь ана, юлдан берничә генә адым эчтә, бер төп янында кинәт туктап калды һәм, калтырана-калтырана, башкаларны чакырып алды да кар астыннан аз гына очы күренеп торган бер төенчекне күрсәтте.

—Ай, бу бит Сәйләннеке!

Төенчек табылган урынны бик тиз казый башладылар. Берничә көрәк кар алып ташлауга, сабыйның ап-ак бәйләм оек кигән кечкенә тәпиләре күренде...

Казып бетергәч, күз алдына гаять дәрәҗәдә аяныч күренеш килеп басты: сабый үзенең аягындагы итекләрен салып баш астына куйган; сыңар кулы белән кечкенә бер төенчек тоткан, ул төенчектә юлга чыккан чакта әнкәсе биргән чикләвек, конфет кебек әйберләр төйнәлгән; бишмәтнең изүләрен чишеп җибәргән дә гүя гамьсез, рәхәт бер йокыга талган...

Аһ орып Фатихны каргадылар да сабыйның гәүдәсен алып кайтып киттеләр.

Мәликә исә аны күмәргә бара алмады, башына килгән бу авыр кайгыдан түшәккә ятты.

Бу җан әрнеткеч вакыйга болай гына калмады, эшнең ничек булуы белән хөкем органнары кызыксындылар. Тикшерү озакка сузылмады. Фатих төрмәгә утыртылды. Карчык башына төшкән бу хәсрәтне күтәрә алмады, шул көннәрдә үк дөнья куйды.

Сәйләннең гәүдәсен беренче күрүдән үк акылы зәгыйфьләнгән Мәликә көннән-көн кипте, корыды, хәлсезләнә барды. Ниһаять, акылыннан язды. Бөтен авырлык Сабир карт өстенә төште. Ул Мәликәне бу хәлендә калдыра алмады, аны, Ташлыярдан алып кайтып, үзе тәрбия итә башлады. Ләкин Мәликә рәтләнмәде, һаман артка китте. Сабир карт аның савыгуыннан тәмам өметен өзде.

## II

Шушы кечкенә авылның бер өендә кышкы озын төннәр буе тоныкк кына булып ут яна. Анда Сабир карт үзенең акылдан шашкан кызы Мәликә белән җәфалана, аны бер ачулана, бер

юата. Мәликә исә тәрәзә янына җәелгән урында, түшәмгә карап яткан хәлендә, һаман да саташа, яшенле яңгырлар астында ниндидер сазлыклар аша чыгуын сөйли. Кайчакларда, сикереп урыныннан тора да, әтисеннән үзенең ниндидер курчакларын таптыра. Сабир карт авыз эченнән генә:

—Әй бала, бала, харап булдың бит, шул исерек аркасында никадәр кайгы-хәсрәткә баттык!..—дип, аңа Сәйләннен кечкенә-кечкенә ситсы кисәкләре, һәртөрле пыяла ватыклары тутырылган тартмасын китереп бирә.

Мәликә башта мәгънәсез бер тавыш белән көлә башлый.

—Кара әле, бусы—минем киявем. Әйе бит,—дип атасы Сабир картны сүзгә тарта.

Шунда ук, курчакларны онытып, сәкедән төшә һәм, тузгыган чәчләре арасыннан әтисенә куркыныч караш ташлап, ишек янына килә. Андагы чөйдән картның сары тунын алып кия башлый.

—Соңга калабыз, анда Сәйлән көтәдер, әйдә инде, тизрәк бул,—дип картны ачуланырга тотына.—Нигә ике чана җикмәден? Каракош сыртына барабыз ич. Сәйлән барып та житкәндер инде,—дип бер-берсенә бәйләнешсез сүзләр сөйли.

Ике-өч минут үтми, Каракош сыртына баруны онытып, өстендәге сары тунның төймәләрен ычкындыра, янадан сәкегә килеп утыра. Алдына тагын курчаклар китертеп, картны йөдәтә:

—Син ашка чакырышлы уйный беләсеңме, әйдә, уйныйк,—ди.

Шул арада ук карт тотарга өлгерә алмыйча кала, Мәликә яшен тизлеге белән ишекне ачып, яланаяк, яланбаш килеш тышка чыгып йөгерә. Котырынып искән салкын җилгә каршы такта капканы ачарга маташа. Җил ачарга ирек бирми, Мәликәне капка белән бергә этеп йөртә. Ул ямьсез тавыш белән әтисенә кычкыра:

—Кил инде, ачыйк, Сәйләннәр кайткан бит, нәрсә карап торасың?

Җил һаман көчәйгәннән-көчәя. Мәликәне көйләп тәмам арыган карт аны тагын юата башлый:

—Кайттылар шул, кайттылар. Ул сине әллә кайчан өйдә көтеп утыра инде, әйдә, керик,—ди.

Мәликәне үз җае белән генә өйгә алып керә. Үзе һаман сөйләнә:

—Әй бала, бала, харап булдың бит. Гайнетдиннекеләр алар гомергә җинел акыллы булдылар. Аларга башта ук катнашасыбыз калмаган да бит, ни кыласын, чәчләребез бәйләнгән булгандыр инде,—ди.

Аны көйләп урынга яткыра, өстәлдәге лампаны кысып, үзе дә мендәргә башын төртә. Ләкин әллә нинди куркыныч төшләр күреп уяна да озак вакытлар йоклый алмый. Картның күз алдына Каракош сыртындагы иманлек килеп баса. Анда, юан бер агач төбендә, баш астына кечкенә итекләрен куеп, бәйләгән оеклы тәпиләрен сузып Сәйлән яткан. Кулына, бик нык кысып, бәләкәй генә яшел кульяулыгына юлга чыкканда әнкәсе төйнәп биргән чикләвек, конфетлар тоткан. Йомшак мамыктан сырылган бишмәтнең чабулары ачылган, башындагы шәле чишелгән, бер кулындагы бияләе салынган...

Карт, күз алдына шушы күренешләрне китергәч, мендәрдән ихтыярсыз башын ала да тезләрен чәнчеп торып утыра. Үзенең дә саташуыннан курка башлый. Өстәлдәге лампаның филтәсен калкытырга уйлый. Шунда ук Мәликәнең тынычсызлана башлавын күреп, кире урынына утыра. Өй эчен тирән бер тынлык ала.

Шулай озын төннәр үтеп, якты таңнар ата. Әмма Мәликә савыкмый, карт төнлә дә, көндез дә айлар буе аны сакларга мәҗбүр була.

Кыш үтеп, язлар җиткәч, Мәликәнең хәле тагын да авырая төшә, кинәт ашый алмас була, аз сөйләшә башлый, вакыт-вакыт бөтенләй хәрәкәтсез яткалый.

Бу хәл Мәликәне шифаханәгә илтү фикерен тудыра. Шул хакта өлкәннәр белән киңәш иткәннән соң, апрель башларында, дымык һавалы

бер көндә Сабир карт, Мәликәне үзе белән янәшә утыртып, зур шәһәргә юлга чыга.

Аны озатырга барлык авылдашлар килә һәм алар, барысы бердәй тавыш белән ачынып, тирән сулап куялар:

—Әй бу аракыны... Ниләр генә китерми адәм башына!

*1954*

ИСКӘРМӘ

Гариф Галиев (1903—1985) Азнакай районындагы Урманай авылында туган. Мәдрәсә елларында ук матур әдәбиятны яратуы белән шәриктәшләре арасында аерылып тора. Сонрак, укытучылар семинариясендә укыганда, әдәбият-сәнгать (сәнагы нәфисә) түгәрәгенә йөри. Башта газеталарга хәбәрләр, кыска очерклар яза.

Беренче хикәясе Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасында 1925 елда басыла. 1927 елда беренче хикәяләр китабын чыгара. Ватан сугышы елларында фронт газеталарында очеркларын, хикәяләрен еш бастыра.

Г. Галиев авыл кешеләренең күркәм сыйфатларын игенче хезмәтенә хас булганча тәфсилләп ачуны иҗатында үзәккә куйды. Менә кайбер китаплары исемнәре үк—«Җир турында җыр», «Без—авылныкылар»—дәлил. Аның бер пәрдәлек пьесалары, балалар өчен махсус язылган хикәяләре дә бар. Кайбер әсәрләре рус һәм немец телләренә тәрҗемә ителде.

Ул ун елга якын «Татарстан авыл хуҗалыгы» журналының баш редакторы булды. Бу кадәресе дә язучының игенчене үз хезмәте белән олылавын раслый. Гариф абый Галиев бөтен иҗатында һәм тормышында үзен игенчеләрчә тыйнак-горур тота белде. Әдәбиятыбызны күп хикәяләр белән баетуын да игенченең бәрәкәтле һәм мул җимешле хезмәтенә тиңләү хак.

... Гариф абый әле биләүдә чакта ук дөньяның иксез-чиксезлегенә сөенеп елмайгандыр да шул ихлас көләчлеген гомере буена җуймагандыр кебек тоела миңа. Сәламәтлеге какшап киткәндә һәм иҗат газаплары кичергәндә дә кешеләрнең үзара дус була алуына һәм ахирәт юлдашлар булырга тиешлегенә ышанычы елмаю чаткыларын саклый белергә көч биргәндер аңа.

Сирәк очрашулардан-исәнләшүләрдән, хәл белешүдән узар-узмас әңгәмәләрдән шундый олпат зат булып хәтеремдә калды ул. Миңа кайчан да булса бик тә, бик тә авырлык килә калса (Ходай күрсәтмәсен!), мин Гариф абый катына барачак идем, һәм ул миңа теләп ярдәм итәчәк иде. Әлбәттә, минем урында бүтән берәү булса да, ул, елмаюлы йөзен яшермәячәк, аркасы белән борылмаячак иде. Гариф абыйны шәхес буларак аз белсәм дә, аның хикәяләренең сафлыгы күңелемдә шундый ышанычны риясыз беркетте.

*Әсәрне журналда бастыруга*
**Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Факил Сафин

# ҖАЕК БУЕ–ЯУ ҖИРЕ

*"Мәзлүм, мәгъсүм күз яшьләре кебек мөлдери,*
*иманлы күңелләр кебек тилбери иде. И җаекъ!*
*Син кай илләрнең күз яше, нинди хәсрәт*
*силләренең юлдашысың!.."*

Дәрдмәнд.

## "Йолдызлар миңа пышылдый күк..."

"ГАЛӘМ ЭЧЛӘРЕНДӘ галәм..." Кайчандыр үзем язган шигырь юллары искә төшеп, күңел түрен кисәк кузгатып куйды.

Төн үзәгендә Чаллыдан башланып киткән өлеге сәфәр мине моңарчы аяк басмаган җир-төяккә, Оренбур якларына, минем өчен яңа бер галәмгә алып бара иде.

Оренбур ягы. Борынгы бабаларыбыз яшәгән, көн иткән, эз калдырган серле яклар. Серле диюемнең сәбәбе шул, Идел-Урал арасында яшәгән төрки бабаларыбыз хакында мәгълүматлардан болай да киштәләр сыгылып тормый. Шул ук вакытта соңгы гасырлар тарихы да галимнәребез тарафыннан бик үк җентекле өйрәнелмәгән. Сәфәр алдыннан, бераз мәгълүмат туплау исәбе белән китап-журналлар актара башладым. Әмма, кайчандыр татарның рухи, мәдәни һәм матди мәркәзләренең берсе булган Оренбурга багышланган тикшеренүләр, бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек тарихи язмалар юк диярлек.

Төнге юл тыныч, көндезге ыгы-зыгының әсәре дә юктыр дип уйлаган идем, без юнәлеш тоткан тарафтан каршы машиналар еш очрый. Күрәсең, шоферлар өчен җәйге матур төннәрдә ял итүгә караганда, алга бару хәерлерәк.

Таң атканны Ютазы район җирендә каршыладык. Матур яклар. Бер генә нәрсә җитеп бетми, бу якларга сирәк килеп чыгучы сәяхләр өчен мондагы юллар шактый мәшәкать тудыра—җүнле-башлы күрсәткеч язулар юк. Һәр юл чатында туктап сорашмасаң, йә Самара-Бөгелмә ягына, йә туп-туры Башкорт дусларның Октябрьский каласына китеп баруың бар.

Өлкә чиген үтеп, Абдуллин районы буйлап баргач, ял итәргә туктадык. Юлдашларым Марат ага Дәүләтъяров, аның улы Әхмәт һәм шофер егет Рәис машинадан төшеп, җәйрап яткан дала киңлекләренә

тын гына карап торабыз.

Без басып торган калкулык астыннан тимер юл үтә—поезд килеп чыкты. Бөтен килеш-килбәте, саңгырау тавыш белән ялкау гына сызгырып куюы таңнан качып баручы сөер җан иясен хәтерләтә. Тирә-як иртәнге салкынча эңгер эчендә. Ара-тирә еракта бүрек-бүрек урманнар күзгә ташлана. Һәр тарафта атаклы Бәләбәй-Бөгелмә калкулыклар тезмәсенең эреле-ваклы түбәләре таралып ята. Алар офык чаршавын этеп-төртеп диярлек киңәйтәләр, каршы якта күтәрелеп килүче кояшка ымсынып, алга томырылырга ниятлиләр. Күңелдә ниндидер ямансулык. Хәсән Туфан: "Уяныр да бәлки нәсел хисе, сискәнеп бер, уйга калырсың,"—дип язган иде. Әнә шундый гаҗәп бер хис уяна җанда. Җан хәтере сүлпәнләнсә, кан хәтере бар, тамырларда кан кызыша, колакта чакмаларга бирелеп очкын чәчрәткән тояк тавышы, өзәңгеләр чыңы. Мин бу җирләргә әллә кайчан ук килергә тиеш идем кебек, киле алмавым өчен бабайлар рухы алдында гаепле дә идем кебек. Ходай уң кылып, бу якларга килеп чыктым, иртәнге саф, дымык һаваны күкрәк тутырып сулыйм, төрки бабамнар рухын ядь итәм.

Поезд хәлсез генә сызгырып куйды. Буш вагоннар тартып, ашыкмый гына мөрәләп бара ул. Каршысына янә бер поезд килеп чыкты. Монсы да алтмышлап буш вагон таккан. Шушы күренеш Рәсәйнең бүгенге халәтен төп-төгәл чагылдыра сыман. Ерак Көнчыгышта, армиядә чакта бер нәрсә аңга сыешмый иде—Владивосток, Находка якларына көн-төн агач, такта төягән поездлар чаба. Каршыга, туктаусыз диярлек шул ук портлардан нәкъ шундый ук йөк төялгән вагон көрваннары шпал саныйлар. Гаҗәп иде инде, карап торсаң. Хәзер йөк түгел, буш вагоннар куалар икән. Элекке мәгънәсезлеккә караганда әллә бусы мәгънәлерәк тә микән? Сәфәремнең шушы бушлыкка охшап калмавын тели иде күңел, талымсызлана төшеп, күргән-ишеткәннәрне хәтер сандыгына тутыра башладым.

Борынгы Нугай даругасы буйлап, юлыбыз Каргалыга, без барасы атаклы татар авылына ашыга. Әхмәт белән Рәис руль артына алмашып утыралар, барасы җир ерак, эшләр байтак әле.

## "Идел—йортның ишеге, Җаек—йортның түре"

КЫЗГАНЫЧКА КАРШЫ, дип әйтимме, бүгенге Татарстан биләгән мәйданнар татар халкына "бүлеп бирелгән" борынгы дәүләтебезнең ишек-тупса тирәсе генә шул. Бер галим, моннан егерме еллар ук, сөйләшеп торганда, "Татарстан—татарларга резервация өчен генә бүлеп бирелгән җир кисәге, чынлыкта, татар дәүләте гасырлар буе биләгән гаять зур мәйданнарда таралып көн итүче миллләттәшләребезне, территориаль-административ яктан бүлгәләп, кискәләп, аларны яшәгән төякләрендә халык саны ягыннан сыегайтып, бетәргә дучар итәләр,"—дигән иде. Хәзер хәлләр ничек соң?

Юлыбыз Абдуллин, Александровский, Пономаревка, Шарлык, Сакмар районнары буйлап уза. Академик Зәкиев күрсәткәнчә, Шарлык сөйләше дигән төшенчә дә бар. Ул мишәр диалектын үз эченә алган уникә сөйләшнең берсе. Муса Җәлилнең туган авылы Мостафа Шарлык районына керә. Сугышта һәлак булган авылдашларына салган истәлек обелиск белән рәттән Муса Җәлилнең бюсты тора. Юл авыл читеннән уза, Мостафаның каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең туган авылы икәнен күрсәткән язу да бар.

Һәр егерме-егермә биш чакрым киткән саен—татар авылы аша үтәбез. Юлкүрсәткеч такталарда Зерокла, Юзеево, Калычева, Садак, Наурузова, Янгыз, Бакалы (бага-лы, күз төшкән җир, уңайлы әйбәт җир дигәнне аңлата), Сакмары, Биккулова һ.б. дигән атамалар очрый. Зирекле, Кылыч кебек авылларның исемнәрен бөтенләй бозып язып бетерсәләр дә, "дөрес язмагансыз" дип, чит өлкә урысларына үпкәләп

булмый. Әле Татарстанда да урысчалап гариплəндерелгəн бер генə татар авылы исемен төзəтеп язган кеше юк. Җəмəгатьчелек бу мəсьəлəне кат-кат күтəреп шау-шу тудыруга карамастан!

Өлкəнең түренə кергəн саен, үсемлеклəр дөньясы, иген кырлары без Татарстан-да күнеккəн рəвешне югалта бара. Шарлыктан соң, урман массивлары бөтенлəй күзгə ташланмый, буй-урманнарда ("урман полоса"сы) каен агачы күренми башлады, гел өмеркə акациясе һəм зəйтүн тирəклəре. (Акация өмеркəдəн килсə дə, борынгы төркичə "агач" дигəнне аңлата, диеп күрсəтə М.Зəкиев.) Бу чүп-агач, шулай итеп, табигате белəн килмешəк булса да, исеменə төркилек "элəктереп" килеп чыккан икəн татар яшəгəн якларга. Хəер, килеп




чыккан дию дөрес түгел, мең еллар элек Әмеркə ярларына аяк баскан төрки бабаларыбыз телендə акац—агач булып сакланып калган ул үз төркилəрне баскынчылар "индианнар" дип атый башлап кына, аларның теллəре үзгəрмəгəн, билгеле. "Акац" əллə нинди гыйбрəтле хəллəрнең, фаҗигалəрнең шаһите, кире үз туган кыйтгасына əйлəнеп кайткан. Их, теле булса... Әллə нилəр сөйлəп бирер иде дə бит, юк шул, агачлар сөйлəмилəр, эсседəн əлсерəп, юлдан үтүчелəргə моңаеп карап калалар, ара-тирə җил иссə, дөнья җəннəтен татыган кебек, кинəт яктырып, каядыр чабып китмəкче булып, талпынып алалар. Инде барасы җирлəрегез калмагандыр акац—агачкайларым, дөнья тирəли əйлəнеп кайтып ата-бабаларыгыз җиренə баш төрттегез, кая томырылмакчы сез, кая ашкынасыз, сезне тагын нинди иллəр, җирлəр тарта?..

Оренбур якларын тип-тигез дала икəн дип уйлаучылар ялгышалар, без үткəн юл өлешендə калкулык, таулар да, елга-инешлəр дə, чокырсу җирлəр, үзəннəр дə җитəрлек иде. Кыскасы, физик географиясе шактый кызыклы. Юлның ике ягында игеннəр өлгереп килə. Татарстан басулары белəн чагыштырганда, игеннəрнең торышы җир белəн күк арасы сыман тоелды. Мондый чүпле басуларны гомеремдə дə күргəн юк иде. Кайбер басуларда аерып булмый, əллə бодай, əллə билчəн, өрем чəчкəннəр. Бик күп кыр мəйданнары сөрелмəгəн, ташландык хəлдə. Анда инде өрем белəн ярыша-ярыша кылганнар гына үсə. Ял итəргə туктап, юл читенə килеп басуга, черки-саранча сырып ала. Шулай да, дөресен əйтергə кирəк, бик матур үскəн, чип-чиста иген кырларын да күрдек. Бигрəк тə Абдуллин районы басулары бу яктан күз-күңеллəрне иркəли. Икенче сокланганым—гаять киң мəйданнарда үстерелгəн көнбагыш басулары. Сап-сары басулар. Кояш тəгəрəп төшкəн кебек, яктылыгы җаннарны иркəли. Карабодай басулары ап-ак чəчкəдə. Тын күл сыман оеп кына утыра иксез-чиксез аклык.

Район үзəклəре Шарлык, Пономоревка, Сакмар, нигездə, бер катлы өйлəрдəн тора. Күп катлы йортларның булмавы, якында зур суларның юклыгыннан килə торгандыр инде. Кибетлəрдə товар бəялəре Татарстандагы кебек, əмма кибетлəр бездəгегə караганда нык ярлы. Хəтта район үзəге Сакмарда бер юлдашыбыз үзенə күлмəк сатып ала алмады. "Кием-салым сатылмый, Оренбурга барып алабыз,"—дилəр Сакмарлылар. Ә бензин арзанрак. Сакмарда саман кирпеч сугып төзелгəн йортларның күплегенə хəйран калдым. Соңгы чорларга кадəр саман кирпече, табигый тау ташы үтемле төзү материалы булып саналган. Хəзер инде кирпечтəн, ара-тирə сап-сары нарат бүрəнəдəн өй җиткерүчелəр бихисап. Шəхси йорт төзелеше бик интенсив бара өлкəдə. Күзгə ташланганы шул.

Машина борынгы Нугай олысының үзəге буйлап җилдерə. Көн

эссе. Ак ташлы калкулыкларга сибелгән кылганнар куып тотмакчылар, ахры, җилләр белән узыша-узыша безнең машина артыннан җилдерәләр, үзләре нәүмизләнеп безгә эндәшәләр кебек: "Әй мосафирлар, бер генә тынга тукталыгыз, як-ягыгызга караш ташлагыз, башыгызны күккә, мәңгелек кояшка күтәрегез, офыкларга текәлегез, туфракка тезләнегез, җаннарыгызда тарих, төрки бабаларның тузан-көлләргә әйләнеп тә, һаман да яши бирүче бөек үткәннәре телгә килмимени соң?"

Килә шул, килә. Мәңгелек шаһитлар—туфрак, ташлар, җилләр, кояш—күңелдә тарих кайтавазы булып уяна. Чорлар, дәверләр аша тарих дәшә...

Бу кызган дала буйлап барганда, хәтердә Дәрдмәнднең шигъри юллары яңарды:

Көн кызды!.. Кызды һава монарланып,
Сагымлап, кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык, шылт итми!.. Кысылды тын:
Ягъмур көтә җирнең йөзе комарланып.

Миңа еш кына "без кемнәр соң?" дигән аптыраулы сораулар ишеткәнгә күрә, кайбер тарихи фактларны, галимнәребезнең Идел-Җаек, Оренбур татарлары хакындагы эзләнүләреннән өземтәләр китерүне урынлы санадым. Тарих хәтерсезлекне яратмый. Сәхифәләрен кузгатып торган саен тарих яшәрә ул. Шул ук вакытта Риза казый Фәхретдиннең "һәр нәрсә дә игътидал вә үзенең үлчәвеннән үтеп китмәү яхшы" дигән сүзләрен дә истә тотарга тырыштым.

Идел-Җаек киңлекләрендә борын-борыннан төркиләр яшәгән. Алар бу якларга моннан ике мең еллар чамасы ук элек килеп чыкканнар. Элгәре төрки бабалар өчен дала җирләре яшәү, тормыш алып бару өчен уңайлы булса, урманлы төбәкләрдә исә борыңгыдан урманга сыенып, аның белән бербөтен булып яшәүче фин-угыр кабиләләре гомер кичергәннәр. Безнең эрага кадәр 155 елда һуннар, үз җирләрендә барган сугышларда җиңелеп, Көньяк Уралга килеп чыгалар. Бу хәл бу төбәктәге төркичелекне тагын да үстереп җибәрә. Чөнки һуннарга кадәр дә монда төрки телле ырулар булмагандыр дип әйтеп булмый.

Ә инде Идел буенда VIII-X гасырларда болгарлар килеп дәүләтчелек төзегәч, Идел-Җаек арасындагы кабиләләр Болгар дәүләте кул астында көн итә башлыйлар. 921 елда Багдадтан изге миссия белән Болгарга килгән Әхмәт ибн-Фадлан үткән җирләр бу. Ул чагында ук башкортларны аерым күрсәтеп китүне кирәк таба гарәп илчесе.

1229 елда Батый гаскәрләре Урал якларына да килеп чыгалар. 1236-37 елларда мангол яулары белән башкортлар аяусыз сугышлар алып баралар, әмма көчләр тигез булмый, алар көньяк-көнбатыш Урал ягына чигенәләр. Озак та үтми, Болгар дәүләте дә баскынчылар кулында кала. Катлаулы тарихи шартларда гаять зур мәйданнарны биләгән Алтын Урда дәүләте барлыкка килә.

Идел-Җаек арасының аннан соңгы дәвере нугай атамасы белән тыгыз бәйләнгән.

Дәшти Кыпчак (Алтын Урда) дәүләте таркалу барышында Җучи ханның оныгы Ногайга әтисеннән Днепр һәм Днестр арасындагы җирләр кала. Ногай үзенә тигән мангытлар олысын киңәйтеп, Алтын Урда хакимлегенә ыргыла, әмма, 1303 елда һәлак була. Ногай олысы яшәүдән туктый, ләкин Ногайның туганының улы Идегәй гаскәр туплап, Алтын Урданың бер өлешен аера башлый, аерылып чыккан өлештәге халыклар үзләрен нугайлар дип атый башлыйлар. Бу чит атама болгар-казанлыларга да үтеп керә, ә Нугай урдасы төзелгәч, андагы бар төрки телле халыклар да нугай дип йөртелә башлыйлар. (Хәзер дә Оренбур, Җаек якларында яшәүчеләр арасында үзләрен нугайлар дип атаучылар, яки "нугай" кушаматлы кешеләр очрый. Мәсәлән Каргалыда "нугай" кушаматлы нәсел кешеләре яши.)

1391 елда Алтын Урда ханы Туктамыш гаскәрләре Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә, бу сугышта Туктамышның элекке

әмире, соңыннан аның дошманы Идегәй дә Тимер ягында үз гаскәре белән катнаша. ("Идегәй" дастанында бу сугыш хакында бәян ителгән.) Җиңүдән соң Идегәй Мангытка—Идел-Җаек төбәгенә кайта, Нугай Урдасын төзи. Нугай Урдасы соңыннан үзе дә башында морзалар торган бернечә олысларга бүленеп китә. Нугай морзалары арасында иң күренеклеләреннән берсе Йосыф морзаның кызы Сөембикә Казан ханы Җангалинең, аннан соң Сафагәрәйнең хатыны була.

XVI йөзнең ахырыннан алып Нугай Урдасы, бигрәк тә аның Идел-Җаек арасындагы көнчыгыш өлеше вак-вак бәклекләргә бүлгәләнү аркасында, элекке бердәмлеген дә, хәрби-сәяси көчен дә югалта башлый. Тора-бара бу региондагы нугайларның этник йөзләре дә үзгәрә: бер зур өлеше казакъ кабиләләре белән аралашып, соңрак формалашкан казакъ ханлыгы составына керә, икенче төркем башкортлар арасында "эри", өченче өлеше, һичшиксез, татар халкының формалашуына йогынты ясаган. Бер төркем нугайлар Түбән Идел, Төньяк Кавказ, Кырым якларына күчеп киткән. Кайчандыр Казан ханлыгының шактый зур өлешен тәшкил иткән "Нугай даругасы" (даруга—административ-территориаль бүленеш, өлкә мәгънәсендә) халкы һич тә изрәп җиргә сеңмәгән, тотәп күккә ашмаган, бәлки аларның шактые шул рәвешчә татарлар һәм башкортлар составына күчеп беткән дигән белән академик М.Госманов хаклы. Хәзерге көндә Чиләбе өлкәсендә нагай-бәкләр этник төркеме, Астрахань өлкәсендә, Дагстанда, Ставрополь краендагы нугайлар кайчандыр Идел-Чулман-Җаек буйларында гомер кичергән нугай кардәшләребезнең кан туганнары.

Нократ татарлары нәселенә "нигез салган" Карабәк тә (шәҗәрә материаллары буенча) ул якларга Җаек, Сакмар буйларыннан килгән нугай булган. Татар теленең казакъ, нугай, каракалпак һәм башкорт телләренә аерата якынлыгын тәэмин итүдә татарларның тамырларында агучы "нугай каны" турыдан-туры йогынты ясавына ишарәли М.Госманов.

## "Авыллары Каргалы, бар да тимер арбалы"

КАРГАЛЫГА иртәнге сәгать тугызларда килеп кердек. Вакыт аермасын исәпкә алсак (Оренбур өлкәсендә вакыт Мәскәүнекенә караганда ике сәгатькә алдарак "йөгерә"), монда инде көн үзәге дияргә була.

Марат ага Дәүләтьяров юл буе Каргалы хакында зур дәрт һәм горурлану белән сөйләп барды. Каргалы авылы—аның нәсел башы. Әтисе—Әхмәтсафа Дәүләтьяров заманында Татарстан АССРның Халык комиссарлары рәисе булган, Сталин репрессиясе корбаны. Каргалы, Оренбур якларына килүебезнең төп сәбәбе дә Әхмәтсафа аганың яшьлек эзләре буйлап йөрү, истәлек-хатирәләр туплау иде.

Каргалы—Сакмар суы буендагы шактый сузынкы калкулык итәгенә урнашкан гаять зур авыл. Авылга керүче юлның ике ягыннан калкулык буйлап еракларга таралып киткән зират. Зиратта каберләргә койма-фәләнне соңгы елларда гына куя башлаганнар, бу якларда мәрхүмне җирләгәч, баш очына язулы таш кую гына гадәттә йөргән. Зиратлар мәйданы белән дә зур. Бер-берсенә тоташып диярлек өч зират булдырган авыл халкы. Хәзер дә, әйтүләренә караганда, өч зиратка җирлиләр икән. Зиратлар элек-электән бик тә оста итеп тау ташы белән әйләндереп алынган. Таш койманы хәтта татарның төзү осталыгын күрсәтүче архитектура һәйкәле дип тә игълан итәргә мөмкин. Юка гына ташларны шулкадәр төгәл һәм күңел биреп өйгәннәр, сокланып карап торырга гына кала. Цемент кулланып өймәгәннәр, ниндидер башка катнашма. Ни сәбәптер койманың кайбер өлешләре җимерелгән, һәм аны соңгы чорда төзәтеп өйгәннәр, шулай ук таш белән төзәткәннәр-ныгытканнар, әмма борынгы осталар төгәллеге юк тек юк инде. Цементы да начар булган—төзәтеп өйгән койманың кабаттан җимерелгән урыннары да күренгәли.

Әйткәнемчә, авыл Сакмар суының уң як ярында, Җаек елгасына кушыла торган җиреннән 18-20 чакрым югарырак урнашкан. Сакмарның сул ягында куе булып усак урманы үсә, ул як түбәнрәк тә. Шуңа күрә язгы ташу чорында авылны су басу куркынычы юк диярлек була. Авыл шактый төзек булса да, борынгыда саман (кызыл балчык белән туракланган салам кушып эшләнгән) кирпеченнән салынган йортлар байтак. Урам-тыкрыклар күп. Урамнарга Тукай, Җәлил, Пугачев һ.б. исемнәрен кушканнар.

Үзәк урамнан Сакмар ягына борылган урында яртылаш җиргә сеңгән таш сарайны Әхмәт әфәнде Пугачев явы чорында (1773-1774 еллар) "ялган патшаның" Каргалыдагы штаб-квартирасы булган дип аңлатты. Әйтергә кирәк, Пугачев җитәкчелегендәге халык кузгалышында Каргалы казаклары актив катнашканнар. Бу хакта урта мәктәп бинасында истәлек тактасы да куелган.

Каргалы татарларының Пугачев явында катнашуы хакында В.Имамов "Татарлар Пугачев явында" дигән әсәрендә җентекләп бәян итә.

1773 елның утызынчы сентябрь көнне Пугачев инде Оренбургтан егерме сигез чакрымда урнашкан Чернореченск крепостен яулап ала,— дип яза автор.—Шушында "падишаһ" каршына Каргалы татарлары юллаган махсус делегация килә һәм алар Пугачевны кунакка чакыралар.

Каргалыда да Җаек буендагы гаҗәп хәлләр турында күптән хәбәрдар булалар. Оренбург губернаторы генерал И.Рейнсдроп әмере буенча Каргалының өч йөз татары Әхмәр Әбләзов дигән старшина җитәкчелегендә Пугачевка каршы җибәрелә. Ләкин Пугачевның Татищево крепосте янында полковник Елагин һәм бригадир Билов отрядларын тар-мар итүе турында ишетүгә үк, алар туган авылларына борылып кайталар.

Пугачев Каргалыга беренче октябрь көнне килә. Татар халкы "падишаһ"ны мәйданга затлы келәмнәр җәеп, келәм уртасына зур кәнәфи куеп, җиргә тезләнеп каршылый. Бай крестьяннар, сәүдәгәрләр Оренбургка качкан була. Әмма Каргалы бу вакытта инде Оренбургның үзенә караганда да зуррак пункт булып исәпләнә. Каргалының үз халкыннан тыш, бирегә әле тагын Казан өязеннән килеп, бай сәүдәгәрләргә ялланып эшләүче биш йөзләп ир була (С.Алишев). Пугачев килгәч, каргалылылар арасыннан биш йөздән артык ир фетнәчеләр сафына кушыла. Алар арасында Казан өязенең Тимершык, Олы Кандалы, Балыклы, Ачы, Үр, Ашыт, Кече Тархан, Урта Шөн, Кече Шөле, Каратай, Яңавыл авылларыннан килеп эшләүче татар крестьяннары да була. Каргалыдан Муса Алиев дигән сәүдәгәр



*Оренбург өлкәсе Сәгыйд бистәсе зиратының бер өлеше*

әлеге полкның командиры итеп билгеләнә. Шушы ук көнне Каргалы татарлары "падишаһ" исеменнән махсус мөрәҗәгать һәм указлар язып, ышанычлы кешеләр аша аларны Уфа провинциясендә, Оренбург—Казан юлында яшәгән татар-башкортларга тараталар. Аптыш Тангаев дигән татар казакъларның Кече Җүз ханы Нурали янына ук озатыла. Нурали хан "падишаһ" эмиссарына ике йөз кешелек отряд биреп җибәрә. (Тангаев соңыннан, 1774 елның июлендә Җаек каласында кисәкләргә чапкалап үтерелә.)

Каргалы фетнәчеләрнең тыл базасы буларак та хезмәт итә. Авыл халкына ышаныч зур була, хәтта Соколов-Хлопуша үз гаиләсен Каргалыда тота. Татищев бистәсе янындагы җиңелүләрдән соң Соколов-Хлопуша ерерме икенче март көнне (1774), гаиләсен алып китү өчен, Каргалы бистәсенә килә. Габделрәфыйк Габдуллин, Рәхмәтулла Госманов, Габделрәхим Габделмәҗитов кебек байлар аны кулга алалар һәм егерме дүрте көнне Оренбургтагы Рейнсдропка илтеп тапшыралар (С.Алишев).

Без күңелебезне тырнап торган җитди бер төгәлсезлек белән укучыларны да таныштырырга мәҗбүрбез,—дип, дәвам итә В.Имамов.— Петербург галиме Ю.Лимонов 1975 елда нәшер ителгән "Емельян Пугачев и его соратники" дигән китабында Хлопушаны кулга алуда бөтенләй катнашы булмаган, алай гына да түгел, бәлки киресенчә, бөтен татар халкының, димәк, Каргалы авылының да горурлыгы булырлык каһарман шәхес исемен каралта. Мөселманнарның исем-фамилиясен дә юньләп аера белми торган шушы "галим" "Хлопушаны авыл старшинасы Муса Алиев "тимер богаулар кидертеп" Рейсдроп кулына илтеп биргән", дип күрсәтә. Шушы ук ялгышны соңыннан Ростов университетының "атаклы галиме" Х.Муратов та кабатлый. Ә без Муса Алиев исемен инде күп тапкырлар телгә алып уздык. Муса—беренче октябрьда Каргалы татарларыннан төзелгән полк командиры. Биккол, Йөзәй, Оренбург, Татищево янында батырлыклар кылган каһарман. Ул әле Пугачев белән бергә озын юл узачак һәм Казан янында унбишенче июль көнне булган яуда гына карательләр кулына эләгә.

Каргалы байларын Хлопушаның бер үзен генә (яшерен комиссия әгъзалары Лунин һәм Марвин карары буенча Хлопуша 1774 елның унсигезенче июлендә Оренбургта җәзалап үтерелә) җәлладлар кулына тапшыру аз булып тоела, күрәсең. "Әби патша"дан олы бүләк өмет иткән хыянәтчеләр Татищево яныннан кайтып кергән авылдашларын да кызганып тормыйлар. Бистә старшинасы Габделрәфыйк Габдуллин һәм ахун Габделнасыйр Габделгалләмов җитәкчелегендәге байлар егерме өченче—егерме бишенче мартларда кырык ике кешене кулга алып, Оренбургка илтеп бирәләр. Оренбургка җибәрелмичә, Каргалының үзендә базларга ябып куелган фетнәчеләр дә була. Шундыйлардан берничә кеше нindидер юллар белән ирекка чыга һәм Бирдәдәге "падишаһ" янына килеп, бүтән тоткыннарын коткаруга ярдәм үтенә.

Егерме алтынчы мартта Пугачев ике мең кешелек отряд алып Каргалы бистәсенә килеп җитә. Базларга ябылган татарлар азат ителә. Үзләрен бәйләп ташлаган байлардан хәзер инде шулар үч ала башлый. Ике байның йорты яндырыла, биш хыянәтче дарга асыла (С.Алишев). Алар арасында Каргалыдагы бишенче—Кызыл мәчетне 1759 елда төзеткән сәүдәгәр Мөхәммәткул Бикчәнтәев белән аның ике улы— Искәндәр һәм Әбүбәкер да була. Моңа җавап итеп югарыда телгә алынган Каргалы байлары тагын йөзләп кешене каратель гаскәрләренә тотып бирәләр.

Урыс әдәбиятында Пугачев явында татарларның, башка халыкларның ролен кечерәйтеп күрсәткән әсәрләр, тарихчылар шактый. Имеш аларны пугачевчылар "гомуммасса" өчен генә яуга алганнар. Татарларны, башкортларны куркаклыкта гаепләп, яу кырын ташлап китүче хыянәтче итеп күрсәтеп язган "әсәрләрне" укып шаккатасың. С.Есенин "Пугачев" поэмасында "скуломордая татарва" хакында нинди генә хикмәтләр язмый. Башка халыкларны яуга күтәрүен (Есенинча) Пугачев болай аңлата:

"Мы подымем монгольскую рать!
Нам мало того простолюдства, которое в нашем крае.
Пусть и башкирец бьются за бараньи костры среди юрт!"

Ә инде яуга кушылган халыкларның батырларча сугышып, азатлык өчен каһарманнарча һәлак булуларына дан җырлыйсы урынга Есенин Крямин дигән герое авызыннан безнең каһарман бабаларыбызга мондый бәя бирә:

"Знаем мы, знаем твой монгольский народ,
Нам ли храбрость его неизвестно?
Кто же первый, кто первый как не этот сброд
Под Сакмарой ударился в бегство?
Как всегда, эта дикая гнусь
Выбирала для жертвы самых слабых и меньших,
Только б грабить и жечь ей пограничную Русь
Да привязывать к седлам добычей женщин.
Ей всегда был приятней набег и разбой,
Чем суровые походы и житейской хмурью"

Аракыдан айнымаган, фөхешлектән бушамаган адәмнең Ходай биргән талантын халык кадәр халыкка шундый яла ягуга исраф иткәне өчен генә дә аны җир күтәрә алмас иде... Есенин Пушкинның "Капитанская дочка" әсәренә эпиграф итеп алынган "Береги честь смолоду" дигән мәкальне укып тормаган булса кирәк. Хәер, Пушкин үзе дә "Капитанская дочка" әсәрен язганда, әллә никадәр юллар үтеп, әллә никадәр кешеләр белән очрашып та, әлеге яуда татар-башкортларның катнашуы хакында җүнле-башлы телгә алмый. Жаек буйларында "полудикий" халыклар яшәвен искәртеп китә дә, Белогорск крепосте коменданты Иван Кузьмичның тирә-як авылларга Пугачев ярлыгын таратып йөрүче башкорт картын җәзаларга боеруын тасвир кылып, комендантның сүзләрен Юлай исемле калмыкның әлеге башкортка татарча тәрҗемә итеп бирүен язып үтә, ягъни "образауный" урыс язучылары татар белән башкорт, калмык арасындагы аерманы бөтенләй белмәүләрен күрсәтәләр. Үзләре тарих язарга азапланганнар, җитмәсә..

"Пугач йортыннан" өстәрәк мәчет бинасы. Таштан эшләнеп, акбур белән акшарланган бинага зур итеп "1726 ел" дип язылган. Ягъни мәчетнең төзелү елы күрсәтелгән. Ләкин кешеләр белән сөйләшкәндә, бу мәчетнең Каргалыда гасыр башында (1918 елда), иң соңгы булып төзелгән Аллаһ йорты икәнен ишетергә туры килде.

Сөйләшү дигәннән, Каргалыда матур итеп, саф татарча сөйләшәләр. М.Зәкиев болай дип яза: "Урта диалектның төп җирләреннән күченгән вәкилләре килеп утырган яңа төбәкләрендә, җирле тәркиләр белән укмашып, тагын җиде сөйләш барлыкка китергән". Шуларның берсе каргалы сөйләше. Бу сөйләшнең хәзерге әдәби телдән никадәр аермасы бардыр—бик сизелми. Апа кешене—апай диләр. Егет яки кызга: "Сөйгән ярың бармы?"—диясе урынга, "кәсең бармы?" диләр. Гомумән алганда, күзәтүләрдән чыгып, Каргалы халкының сөйләше урта диалектның Казан арты сөйләше белән Минзәлә сөйләшенең бергә укмашуыннан барлыкка килгән дип әйтергә була.

Олысы да, кечесе дә, безнең Татарстан номерлы машинадан чыгып килүебезне күрсәләр, "Казан кунакларына сәлам" дип, киң елмаеп исәнләшәләр. Татарстан өчен горурланып та куясың, үзеңдә җаваплылык та тоясың. Ни дисәң дә, Казаннан ярты мең чакрымнан артык кителгән, мондагы халык Казан, Татарстан турында Мәскәү радиосыннан, яки ара-тирә өлкәдә чыгучы "Южный Урал" газетасындагы саран мәгълүматлардан һәм безнең кебек бу якларга нииндидер йомыш белән килеп чыккан кешеләрдән генә ишетеп белә. Телевизордан Казанны карый, тыңлый алмыйлар, радио чәршәмбе көнне генә беркадәр вакыт татар җырларын тапшыра. "Азатлык" радиосын азлар гына тыңлый.

Бу яктан башкортлардан үрнәк алсаң да була. Әйтик Мөслим районы белән чиктәш Бакалы тирәсенә куәтле телевизион манара утырттылар да, хәзер бөтен Мөслим татары кич буе башкорт программаларын карап "рәхәтләнә".

Каргалы—Оренбургтан унбиш-унсигез чакрым ераклыкта. Сакмар суы аша салынган күперне чыгып бераз баргач та, шәһәр сулышы сизелә башлый. Шәһәр чите Кушкүлгә авылдан унбер чакрым. Без Каргалыда үзебез тукталыш ясарга тиешле йортка килеп җитү белән, ашкынып агып ятучы Сакмар суын күреп, бу борынгы дәрьяга сокланып

карап тордык һәм хуҗалар кунаклар каршы алу ыгы-зыгысы белән мәш килгән арада, биек ярдагы сукмак буйлап елгага төшеп киттек. Без килгән "сыңар канатлы" урам Сакмар яры буйлап сузылган, ярга биш-алты метр гына ара иде. Сакмарның суы чагыштырмача чиста, җылы, тиз агышлы. Белешмәләрдә: "Сакмар—Көньяк Уралдагы елга. Урал елгасының уң як кушылдыгы. 798 чакрым озынлыкта. Түбән агымында суднолар йөрешле", дип язылган. Әмма быел җәй шактый коры килү сәбәпле, елга шактый саеккан, елганы теләсәң, йөреп тә кичеп була иде. Эрерәк суднолар күптән йөрми инде, сай төпле катерлар, көймәләр белән генә йөзешле,—дип аңлаттылар безгә. Элек моннан сал агызганнар. Каргалы халкының бер өлеше сал агызуда эшләп көн күргән. Елга балыкка бай диючеләр булды, элекке чак түгел инде дип тә әйтәләр. Һәрхәлдә корбан, түбәнавыз (подус), чуртан, җәенне балыкчылар әле хәзер дә күпләп тоталар. Икешәр метрлы җәен тотучылар да бар икән.

Сакмар елгасы атамасының килеп чыгышы бу төбәкләрдә борынгы заманнарда яшәгән төрки телле сак (скиф) кабиләләренә барып тоташадыр дип уйларга нигез бар. Скифлар үзләрен сак яки сака дип тә атаганнар. Алар Идел-Җаек араларында безнең эрага кадәр I меңьеллыкларда ук яшәгәннәр. Оренбур өлкәсендә скиф курганнары табылуы, аларны казыганда археологларның борынгы төрки мәдәниятенә кагылышлы шактый күп табылдыкларга тап булулары күп нәрсә хакында сөйли. Димәк, Сакмар елгасының беренче өлеше—сак, саклар иле, борынгы төрки бабаларга кагылышлы дигәнне аңлатса, мора монголча зур су дигәнне аңлата. (Русларның моресы да шушы сүздән алынган.) Сакмарны, кайбер чыганаклар күрсәткәнчә, Сакмара дип әйтү урынлы булыр иде кебек тә, әмма аны безнең бабайлар борынгы чордан ук, шул рәвештә атап йөртәләр. Сакмар—саклар елгасы дигәнне аңлата булып чыга. Без—менә шундый тарихи елгада кулларны, битләрне юдык, юл тузаныннан арындык.

Каргалы авылы өч өлештән тора: Каргалы ягы, Дунай ягы, Сакмар ягы. Авылда гасыр башында унөч мең кеше яшәгән, унбер мәчетнең уналты манарасы күккә ашып торган. Татар халкының рухани, рухи һәм мәдәни тормышында гына түгел, матди байлыклар тудырып, татар капиталын, татар гамәлиятен (промышленностен), татар сәнәгатен тудыруда төп урыннарны биләгән, шул рәвешле татарның милләт булып формалашуына зур йогынты ясаган авыл ул. Бүгенге көндә авылда алты меңнән артык кеше яши дип әйттеләр. Соңгы вакытта шәһәрдән авылга кайтып йорт салучылар күбәйгән. Урта Азиядән качаклар сыйфатында кайтучылар да ишәйгән.

Каргалы авылы атамасының килеп чыгышын авыл буйлап агып ятучы Каргалы елгаларына нисбәт итәләр. Олы Каргалы, Урта Каргалы, Кече Каргалы. Әле Коры Каргалы дигән елгачык та бар. Каргалы атама буларак, карга сүзеннән килеп чыккан дип әйтәләр.

Ни дигәндә, авыл Сакмар буендагы зур кичү янында урнашкан. Җаек ягына мал чыгарганда төрле тарафлардан куып китерелгән көтү-көтү мал, кичү чираты көтеп, шушы тирәгә тупланган. Мал тупланган җирдә бихисап калдык, тизәк җыелган. Болар инде карга дигән кошка "Ходай биргән" табыш. "Иле белән" карга җыелган монда, имеш. Шуннан, бу урынга авыл салып утыручылар, күп уйлап тормыйча, яңа салага Каргалы дип исем кушканнар. Мантыйкка сыешлы булса да, болай аңлату бик үк дөрес түгелдер. Гайнетдин Әхмәров күрсәткәнчә, мишәрләр яшәгән төбәкләрдә карга кошына бәйле рәвештә бирелгән шактый күп атамалар очратырга була. Чистай районында Татар Каргалысы, Самара өязендә Карга-куак, Уфа губернасы Бәләбәй өязендә—Каргалы (татар морзалары Еникеевлар, Терегуловлар яшәгән авыл. Алар Тамбов губернасының Темников якларыннан күченеп килгән мишәрләр) һ.б. Әмма Казан татарлары яшәгән авылларга карга компонентлы исем бирелми икән. Әйткәнемчә, авыл калкулыкта утыра. Кырын урында. Борынгы төркиләрдә кыр—яссытау дигәнне аңлата. Кыр—географик термины катнашып шактый атамалар барлыкка килгән. Мөслим районында

Кырын-тау дигән авыл бар. Каргалы сүзе дә кыр—гала—калкулы, яссытаулы урынга урнашкан шәһәрчек дигәнне аңлата (Кыркала). Халык телендә тора-бара атама Каргалы рәвешен алган дип уйларга кирәктер. Гадәттә, торак пунктына елга исеме кушыла, бу очракта киресенчә булып чыга. Башта торак атамасы, аннан атама елгага кушылган. Каргалының Дунай очы дигән атамасында Дунай компоненты Каргалы казакларының 1812 елгы француз сугышында катнашып, Дунай буйларында йөреп кайтып, шул очта яңа җир алып, нигезләр коруыннан калган, ягъни "ияреп кайткан" атама. Ф.Гарипова: "Татар гидронимнары арасында да кечкенә генә елгаларның Урал, Дон, Днепр, Дунай һ.б. дип аталу күренеше бар"—дип яза. Бәлки ул чорда бер Каргалы елгасын "Дунай" дип атап җибәргәннәрдер?! Әмма ул атама елгага ябышып калмаган, төбәккә бөйле рәвештә үзаерым яши башлаган.

Авылның тарихы 1744 елдан башлана дип исәпләнә.

Казан татарлары электән үк Урта Азия яклары белән тыгыз сәүдә эше алып барганнар. Хәтта Казан арты авылларында шушы юлны биш бармагы кебек белгән "кәрван башлары" да булганлыгы мәгълүм.

Явыз Иван Казанны буйсындыргач, Урта Азия шәһәрләре, Һиндстан, гарәп илләре белән сәүдә эшләре туктап кала диярлек. Казан ханлыгы җирләрендә баскыннар белән туктаусыз бәрелешләр булып тора.

Җәзалап, сугыш-ут белән генә татарларны буйсындырып булмаганлыгын аңлаган Елизавета патшабикә татарларның сәүдә эшенә маһирлыгын, Урта Азия халыклары белән тел-дин кардәшлеген, ягъни кавемнең табигый эчке хасиятен файдаланмакчы була. Урта Азия, Һиндстан белән сәүдә мөнәсәбәтләрен торгызу мөһим була. Ә татарлар, шушы чорда, Казан яулап алынганнан соң, өллә никадәр авырлыклар күреп булса да, үзләре генә белгән кәрван юллары аша һаман Хива, Бохара төбәкләре белән сәүдә элемтәсен саклап кала алганнар. Әнә 1714 елда патша Петр I заманында урыс сәүдәгәрләре белән пайтахеткә килеп җиткән Хуҗа Нәфес дигән төрекмән патшага үтә кызыклы хәбәр җиткерә: "Әму елгасында алтынга бай ком бар. Хивалылар аны русиялелердән яшерәләр, шуңа күрә елганы буып, Хәзәр диңгезеннән Аралга таба бордылар. Әгәр Әму елгасын элекке хәленә кайтарсаң, бик күп алтын табарга мөмкин булыр иде,"—дип сөйли. Петр I ике экспедиция оештыра. Бер экспедициягә гвардия капитан-поручигы, чиркәс кнәзе Александр Бекович җитәкчелек итә. 1717 елда Бекович 2300 кешелек гаскәр белән Хивага юнәлә. Бекович офицерлары арасында майор Алексей Иванович Тәфкилев тә (Котлымөхәммәт Тәфкилев) була. Юлда Петр I дән яңа фәрман килә: ул тарафларны яхшы белгән бер кешене башлык итеп, экспедиция оештырып Һиндстанга җибәрергә. Бекович бу эшкә Тәфкилевне җибәрә, үзе "алтын эзләргә" Хивада кала. Тәфкилев мең бәлалар белән кире Рәсәйгә кайтып егыла, ә "алтын эзләүче" Бековичны Хива ханы Ширгази хан терелей тиресен тунатып, башын кылыч белән чабып өзә.

Янә биш елдан Петр I Тәфкилевне яшерен эшләрдә баш тылмач итеп куя—нияте кыргыз-казакъ урдаларын сугышсыз гына кулга төшерү була. Инде тәхеткә Анна Иоановна утыргач, 1733 елда Кече Урда башлыгы Әбелхәер һәм аның кул астындагы кешеләр Тәфкилевнең зур тырышлыгы нәтиҗәсендә урыс патшасына ант бирәләр. Болар хакында Э.Нигъмәтуллин: "Урыс хезмәтендәге татар илчеләре" дигән мәкаләсендә җентекләп яза. (Идел. №10-11, 1991 ел.) Күренгәнчә, гомумән, сәүдә юлын хәрәкәткә китерү өчен, нәкъ менә татар сәүдәгәрләрен файдалану, ә моның өчен аларга кайбер ташламалар ясау көн тәртибенә килеп баса. Урта Азиядә сәүдә эшен җанландыру юнәлешендә татар факторын киң куллану мәсьәләсендә Тәфкилевнең кулы уйнавы бәхәссез кебек.

Ниһаять, патшабикә Сакмар суының Җаекка коя торган тирәсендә татар сәүдәгәрләре колониясен оештыру хакында ярлыкка кул куя. Монда күчеп килгән кешеләргә дин иреге һәм мәчетләр төзергә рөхсәт

бирелә. Шуны да истә тотарга кирәк, татар сәүдәгәрләре үзләре дә Каргалы тирәсендә җир бирүләрен сорап патшага үтенеч язган булганнар. Сәүдә юлында көчле терәк, утрак тормышлы кальга булу Казан якларында сәүдә алып баручыларның эшен шактый көйләп җибәрергә мөмкинлек бирәчәклеген күптән төшенгән булалар безнең кыю һәм иҗтиһатлы сәүдәгәрләребез. 1744 елның сигезенче мартында Рәсәй сенатының махсус Указы нигезендә, күчеп килгән кешеләргә ташламалар ясау, хаксызга җәберләмәү турында патшабикәнең анты белән әлеге төбәк сәүдәгәрләргә бүлеп бирелгән. Өстәп әйтергә калганы шул—бүлеп бирелгән җирдә элегрәк тә берәр сала яки шәһәрчек булмаган дип әйтү нигезсез кебек. Шыр яланга килеп утырмаганнардыр безнең бабайлар.

Сәүдә эшенә керешкән татарлар кузгалыш-яулардан басылырлар дип тә уйлагандыр патша. Чөнки сәүдә белән яу-кырыш капма-каршы нәрсәләр бит.

1745 елда Сәгыйть Салих углы (кайбер чыганакларда Аит улы) Хәялин җитәкчелегендә ике йөз гаилә Саба якларыннан (нигездә) Каргалыга килеп урнаша. Ул чактагы гаиләләрнең дүрт-биш кешедән дә ким булмавын искә алсак, Каргалыга ким дигәндә җиде йөз кешелек "десант" килеп төшә. Бистәне күпчелек Сәгыйть яки Сәит бистәсе дип йөртәләр. Тиз арада бистә кечкенә шәһәрчек рәвешен ала.

Сәгыйть Хәялинга кадәр бу тирәдә нинди дә булса кавемнәр яшәгәнме, яшәсә, алар кемнәр? Башкортлармы, нугайлармы, болгарлармы? Юкка гына авыл мәчете стенасында "1726 ел" дигән дата ярылып ятмый торгандыр ич?!

Каргалыда булганда шуңа игътибар иттем, монда авыл тарихы белән кызыксыналар, нәсел-нәсәп хакында еш уйлыйлар. Әзерлек, мәгълүматлык җитеп бетмәүдән, бу якларга Татарстанның "кулы" җитмәвеннән болгарчылар (Оренбур—болгарчыларның теоретик-методик үзәкләреннән санала) һәм башкорт туганнар оста файдалана. Татарның, башкортның милләт булып формалашуында, сүз дә юк, бу төбәкләр, монда яшәүче кавемнәр билгеле бер урын биләгән. Югарыда әйтеп кителгәнчә, Нугай Урдасы чорында да, аңа кадәрле кавемнәр дә күккә дә ашмаган, җиргә сеңеп тә юкка чыкмаган. Алар бүген дә шул җирләрдә яшиләр, тик тел ягыннан да, гәүдә, төс-кыяфәт ягыннан да монда килеп утырган башкалар белән аралашып, катышып, укмашып беткәннәр. Яңалар "эретү" ягыннан агрессив булалар, шуңа күрә элгәргеләрнең эзләрен табу бик үк җиңел түгелдер. Инде болгар теориясенә килгәндә, монда академик М.Госманов фикерен куәтләү муафыйк булыр: хәзерге татар тарихы Алтын Урда тарихыннан таррак, болгар тарихыннан киңрәк. Артык купайту да, кечерәйтү дә милләт файдасына түгел, безнең интересларга уңай тәэсир итми. Шуңа күрә Каргалыдагы кан кардәшләребезнең болгарчылык белән артык мавыгуы белексезлек билгесе генә ул. Әйе, Идел-Җаек буйлары—ул болгар дәүләте җирләре дә булган, Казан ханлыгы җирләре дә. Татарның төүге дәүләтчелекләре җимерелгәч, "безхозный" булып торганда, аңа күпләр ымсына, күпләрнең күзе кызыга. Әмма ул татар җирләре. Мондагы татарларның килеп чыгышын унсигезенче гасыр башындагы күчешләр белән генә бәйләп аңлату шулай ук безнең файдага түгел.

Каргалыга килсәк, "Сәгыйть бистәсе" дип нигезләнгәнлектән һәм гади авыллардан зур булганлыктан, аны "шәһәр" дип тә атау гамәлгә кергән. Авыл үзәгендәге бай йорт-утарлар шәһәр җирендәгечә икешәр катлы итеп салынганнар, мәчет һәм кибетләр, өйләрнең аскы өлешләре зур итеп, тау ташыннан күтәрелгәннәр һәм каладагы биналардан һич кенә дә ким җирләре булмаган.

Татар халкының борынгы "Гаделбану" дигән җырында мондый юллар бар:

"Алмалы ла гөлләр алмалы,
Бик зур шәһәр диләр Каргалы..."

Авылда яшәүче татарларның этник составына килгәндә, әйтеп үткәнчә, Казан арты татарларыннан тыш, унсигезенче гасыр ахырында аларга Касыйм татарлары да кушыла. Аз санда Урта Азия халыклары—хивалылар, бохаралылар да була.

Авылда 1761 елда 1158, 1796 елда 3180 кеше яши. Льготалар нигезендә алар рекрут бирмиләр (башка төбәктә яшәүче татарлар өчен дворга бер рекрут), патшабикә анты белән ныгытылган башка льготалар да була. Менә шушы чаралар бистәдә халык санының тиз үсүенә китерә. Баштагы сословиеләр нигездә купец, мещан булса да, соңрак крестьян сословиесе дә арта. 1788 елда казак сословиесе кертелә. 2674 кеше казак сословиесенә күчерелә. XIX гасыр башында казакларның бер өлеше "башкорт" сословиесенә күчә,дип яза Д. Исхаков. XVIII гасыр башындагы күчешне күз алдына китерү өчен: 1747 елда Башкортостанда 57500 типтәр, 10100 мишәр исәпләнә. XVIII гасырда Башкортостанда дүрт йөз унике мең кеше яшәп, шуның ике йөз меңе күчеп килгән халыклар булган. Болар сословиесен үзгәртә-үзгәртә 1920 елда башкортларның саны биш йөз егерме дүрт меңгә җитә. (В.Имамов.)

Әйтелгәнчә, бистәгә нигез салынуга, мәчет, аның каршында мәдрәсә төзелә. Атаклы имамнардан, мәдрәсә тотучы һәм укымышлылардан төүдә түбәндәгеләрне искә аласы килә. Шагыйрь Ишнияр бине Ширнияз. Ул 1776 елларда Дагстаннан Рәсәйгә килеп, Татарстандагы авылларда, соңыннан күп вакытлар Каргалыда мәдрәсәләр тоткан, балалар укыткан, китаплар язган. 1780 елда язган "Гаканде Болгария" ("Болгар ышанулары") хәзер дә кульязмаларда саклана. Габделкәрим бине Балтай бине Ишмөхәммәд (1756 елда вафат), аның улы Исхак бине Габделкәрим (1801 елда вафат) Каргалының агач мәчетендә имам булып торалар. Габделкәримнең бер улы Әбелхәсән Оренбурда имамлыктан чыгарылып, Казанга килә, аны "Каргалы мәхдүме" дип йөртүен искәртә Мәрҗани хәзрәтләре. Ул "Каргалы галимнәре мелла Габдерәшид, мелла Габдерахман" хәзрәтләрен дә искә ала.

Каргалы тарихында Габдессәләм мөфти хәзрәтләре аерым урын тота.

Габдессәләм бине Уразмөхәммәд бине Колмөхәммәд бине Колчура (1700-1762) Казан өязе Алат даругасы Мәңгәр авылында (хәзерге Арча районы, Олы Мәңгәр авылы) туа. 1746 елда, кырык алты яшендә Сәгыйть Салих углы чакыруы буенча Каргалыга күчеп килә. Габдессәләм Ташкичүдә (Мәңгәргә күрше авыл) имам була, анда 1755 елдагы татар-башкорт кузгалышы җитәкчесе Батырша укып белем ала. Батырша үзенең патшага язган мәгълүм хатында, халыкны кузгалышка чакырып өндәмә язганда, Габдессәләм ахун белән киңәшүен күрсәтә.

1799 елда Габдессәләмне Оренбурга мулла итеп чакыралар һәм ул анда таш мәчет төзетә (казна хисабына), 1805 елда бу мәчет ачыла.

Патша Александр I үзе дә шул чорда Оренбурга килеп урындагы хәлләр белән таныша. Габдессәләм патша белән очрашуга бара һәм аны патша "бик ошатып", мөфти итеп раслый. Бу хакта икенче шагыйрь—Гомәр Мөхәммәт улы —Каргалыда белем һәм тәрбия алган шагыйрь язып калдырганнардан укый алабыз.

Габдессәләм шагыйрь булып та танылa. "Казан утлары" журналының 1995 ел 6 санында шагыйрьнең "Илаһи бәетләрен" укырга була. (Марсель Әхмәтҗановның сүз башы белән.)

Хәзерге Чирмешән районы Яңа Кади авылында 1754 елда туган Габдрәхим Утыз Имәни дә Каргалыда белем ала. Аңа Каргалының икенче мәчете каршындагы мәдрәсәдә Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әмин дәресләр бирә. Таҗетдин Ялчыголның (1768-1838) Каргалыда эзе калган. Аның әтисе Ялчыгол хаҗ сәфәренә Каргалы аша китә.

Каргалының данын бер баскычка күтәргән кеше, һичшиксез, танылган шагыйрь Әбелмәних Каргалый (1782-1826). Ул Габдессәләм мөфтинең оныгы. Шагыйрь бабасының күренекле галим, остаз булуы белән горурлана. Әбелмәних укыган чор мәдрәсәнең шаулап торган

чагы. Монда үз мәдрәсәләрен калдырып, белем алырга Утыз Имәни, Әхмәт Шырданилар килгән була.

Әбелмәних мәдрәсәне тәмам иткәч, Урта Азиядә белем ала, хаҗ кылып, дөнья гизеп Каргалыга кайта. Туган якларына кайткач шагыйрь абызагайлар хәрәкәтенә кушылып китә. Абызагайлар—үз чорындагы укымышлыларны дөрес юлдан бармыйлар дип гаепләүчеләр, фәкать элеккеге галимнәрнең генә дөрес һәм изге булуларына ышанып яшәүчеләр. Әбелмәних: элеккеге галимнәр—гөл, хәзергеләре тигәнәк, дип атый. Бу юллардан соң, бераз читкә китеп булса да әйтик, ислам динендә ислахлык, ягъни реформачылык белән кадими консерватизмлык һәрвакыт үзара җәдәлләшеп яшиләр. Диндә реформа кирәклеге хакында әле VIII гасырларда, хәнифәләр династиясеннән хәзрәти Мансур ук күтәреп чыга. Гасырлар үтеп, татар зыялылары Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Тукайлар чорында да әлеге бәхәс тынмый. Зур хәрәкәт—җәдитчелек барлыкка килә. Җәдитчелекнең килешмәс дошманы Ишмөхәммәд Түнтәри кебек шәхесләр була. "...Ләкин кадим үлмәгән, ул аш мәҗлесендә, базар чатында, һәркайда үзенең "иске-изге, җәдитләр—динсезләр" дигән нигез белән көрәшеп алып бара..."—дип яза Галимҗан Ибраһимов XX гасыр башындагы әлеге көрәш хакында. Тәрәккыятькә каршы кешеләр арасында Г.Ибраһимов Каргалы имамы Садыйк Госмановны да күрсәтә. Ул Зыя Камалига каршы "Фәлсәфә гыйбадәткә рәддия" (Гыйбадәт философиясен кин ачу) исемле әсәр язып, аны "Дин вә мәгыйшәт" журналы аша китап итеп бастырып, халыкка тараткан. Әмма бу каршылыкның һәр ике ягында ислам динен яхшы белгән тирән укымышлы кешеләр, шәхесләр була. Безнең көннәрдә бер төркем шома кешеләр, бүгенге "абыз-абзыйлар", "абыз-түтиләр" әшнәләшеп үзләрен үтә диндар, тәкъва итеп күрсәтеп, башкаларны динсезлектә, кәферлектә гаепләп әллә нинди "хикмәтләр" чыгара башладылар. Әмма бу кемсәләрнең киң җәмәгатьчелек ниндирәк бәндәләр икәнен яхшы белә, алар ни дини белем алмаган кешеләр, ни мәчет, мәдрәсә хадимнәре түгел, фәкать болганчык суда балык тотып калырга ашыгучы "әртис"ләр, шамакайлар гына. "Тарих дигәннәре—шул күрәсең инде: кичә Ишмиләр кебек кадим гөруһларга каршы көрәшкән "җәдиди"ләр бүген яңа идеаллар, яңа фикерләр белән янган яңа әмелле буыннарга каршы үзләре шул кадим булып калалар икән шул,"—дип язган Галимҗан Ибраһимовны аңларга була.

Әбелмәних укымышлы булуына карамастан, указ алмый, муллалык эшенә керешми, иген игеп көн күрә һәм кабат хаҗга барышлый юлда вафат була.

Каргалы мәдрәсәсендә шагыйрь Вәлиэтдин Багдадыйдан белем алган янә бер олуг зат—Һибәтулла Сәедбаттал улы Салиховны (1794-1867) телгә алмый булмый. Аның түбәндәге сүзләре бүген дә васыять сыман яңгырый:

> Әй, дуслар, бу хаин фани дөньядан гыйбрәт алыгыз,
> Зарары аның йөз меңнән артык, зәһәре—еланнан яман:
> Елан чаккан—шешә дә бетә, дөнья чаккан—үлгәч кенә китә,
> Беренчесенә дәва бар, икенчесенә дару юк.

Каргалы—борынгы мәгърифәт үзәге. Анда яшәгән, белем алган әллә кемнәрне искә алып китәргә мөмкин булыр иде.

Октябрь түнтәрелеше Каргалыдагы гыйлем-тәрбия эшен тамырдан үзгәртә. Мәчетләр, мәдрәсәләр тора-бара ябыла, имамнар, хәлфәләр кайсы-кая тарала, байтагы репрессия корбаннары була. Якты киләчәк өмет итеп, яңа тормыш корабыз дип йөргән Әхмәтсафа Дәүләтьяров, Саттар Ишбулдин, Габдрахман Рәхимов кебек дистәләгән яшьләрнең өметләре акланмый. 1937 елларда Татарстан Автономияле Республикасының Халык комиссарлары председателе Ә.Дәүләтьяровның гомере фаҗигале төстә өзелә—Сталин репрессиясенә эләгеп, Черек күл козгыннары шактый газаплар күрсәткәннән соң, аны 1938 елның 9 маенда атып

үтерәләр. Хатыны—Каргалыда мөгаллимәлек эшчәнлеген башлап җибәргән гүзәл Рабига ханым (танылган режиссер Ширияздан Сарымсаковның бертуган сеңлесе) шулай ук төрмәгә ябыла һәм 1943 елда Мордовия урманнарында эштән, ачлыктан, авырулардан җәфа чигеп вафат була. Уллары Марат белән Марлесны балалар йортларына җибәрәләр. Ансы аерым бер кыйсса.

Марат ага Дәүләтъяров инде берничә ел нәсел шәҗәрәсен өйрәнә, үз ыруын барлый, әти-әнисенең якты рухларын сөендереп, алар хакында истәлекләр туплый, тарихи дөреслекне халыкка җиткерергә омтылып яши: "Дәүләтьяровлар нәселенең очы XV гасырга барып тоташа. Нигез ташлары Болгар җирендә. Нәсел башында Дәүләтьяр Гази углы тора (1470 нче елларда туган). Аның сигезенче буын бабасы Болгар сәете Карабай булган,—дип яза ул.

Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Карабай сәет 1250 нче елларда Батый хан гаскәрләре белән каты сугышлар алып бара, ахыр чиктә, үзенең яраннары белән Нократ елгасының югары агымы буйлап кача һәм Чепцы елгасы янында Нократ исемле авылга нигез сала.


Соңыннан Карабай токымы төрле тарафларга күчеп утыра башлый. Кайбер юрамалар буенча, Дәүләтьяр нәселе Арча якларында гомер кичергән (аның бертуган абыйсы Касыйм Арча сәете).

Дәүләтьяр бабайның исеменнән нәселебезнең фамилиясе башлана һәм гасырлар дәвамында үзгәрешсез сакланган. Мондый хәл татарлар арасында сирәк очрый торган күренеш.


"Кызык өчен түгел, тарих өчен бу шәҗәрәмне күрсәтеп китү урынлы булыр",—ди Марат ага.

## ДӘҮЛӘТЬЯРОВЛАРНЫҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ

### НӘСЕЛНЕҢ ТАМЫРЛАРЫ




### "КАЕШ" КУШАМАТЛЫ ДӘҮЛӘТЬЯРОВЛАР ШӘҖӘРӘСЕ



## Арыслан сурәте төшерелгән мөһер яки "Родина"да ни эшләр бетереп яталар?

АНЫ ЯХШЫ БЕЛГӘН кешеләр, "Каргалының ата милләтчесе" дип йөртәләр. Урыслар "ярый националист" дип тә җибәргәлиләр икән. Сүзем—без тукталган йортның хуҗасы—Мохтар Әхмәтхан улы Дәүләтъяров турында бара. Мохтар әфәнде уртача гәүдәле, нык бәдәнле, авылын, халкын яратып, хөрмәт итеп яшәүче кеше, Оренбург өлкәсе Сакмар районы "Родина" колхозы рәисе. Милли мәсьәлә хакында сүз кузгалса кыю, фикерле, шактый мәгълүматлы шәхес. Өй китапханәләрендә тарихи китаплар шактый. Эш өстәлендә А.Гумилевның "Древние тюрки" китабы ачылып ята. Укый, өйрәнә, мондагы урыс дусларына Җаек буйларының төрки, болгар, татар җирләре булуын даими "төшендереп" торучы милләтпәрвәр дисәк тә хата булмас. Кайбер "өлкән туганнар" чыгымчылап: ник кирәк инде бу "милләт" дип баш ватуларын, ызгыш чыгарырга маташкан кебек,—дип, бүселеп тә йөргәлиләр икән. Аларга Мохтар Әхмәтхан улы ярымшаяртып: "Шту сез, мин бит хан нәселеннән, геннар җанны кытыклап тора!"—дип җавап кайтара. Нәселләрендә хан булганмы, юкмы, әмма шәҗәрәдән күренгәнчә, борынгы бабалары Карабай—болгар сәете булган. Нократ авылына нигез салучы санала. Сәет—пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) нәселеннән булган кешеләргә әйтелә торган күркәм аттыр.

Мохтар Дәүләтьяровның безнең белән иркенләп сөйләшеп утырырга вакыты юк. Кырларда уттай эш өсте. Август башлары. Урып-җыю бара. Түрәнең (бу якта начальник—"башлык" кешене "түрә" дип атау гадәткә кергән) күңеле тыныч түгел. Быелгы корылык күп планнарга киртә куя. Көтелгән уңыш, ягъни хуҗалыкны азмы-күпме икътисадый бөтенлеккә тотарга мөмкинлек бирәчәк ашлык муллыгына исәп тотып булмый. Җитмәсә, табышлы тармакка әйләнеп барган терлекчелеккә зур зыян килгән, сыерларда кан авыруы табып, сөт сатуны тыйганнар. "Инде эшләр көйләнә, озакламый тыюны алырлар,"—дип өметләнә ул.

Мохтар әфәнде районда һәр яңалыкның башында баручы, мөхтәрәм җитәкче. "Шундый тактика кулланмыйча җай юк,—ди ул җитдиләнеп.—Без бит райондагы иң эре авыл, җитмәсә, татар авылы. Авылда кайчандыр алты бригада бар иде. Хәзер, эш технологиясен дә исәпкә алып, ике бригада калдырдык Каргалыда, тагын бер бригада—урыс авылы Майор бар. Бусының ни җире, ни эшче көчләре юк. Шул авыл аркасында "Родина"—урыс исемле татар хуҗалыгы булып йөреш инде. Эч поша билгеле. Татар авылы, татар җитәкчесе дип, кырын карауны сизеп куйган чаклар бар. Кыскасы, татар булуыбызны онытмас өчен сәбәпләр җитәрлек монда. Шуңа күрә иң авыр чакларда да сынатмаска тырышабыз.

Мохтар әфәндене авылдашлары яхшы белә. Алар күз алдында үскән "түрә" ул. 1976 елдан колхозда эшли. Механик булган, 1985 елда иң җаваплы тармакка—игенчелек буенча бригадир итеп сайлап куелган. Юл төзү техникумын, соңрак Мәскәү юридик академиясен тәмамлаган. Дөньялар үзгәрә башлагач, 1989 елның 16 февралендә колхоз рәисе итеп сайлап куйганнар аны. Хәтерегездә булса, демократик җилләрнең әле саф чагы, чып-чынлап сайлау була бу. Ягъни альтернатив юл белән. Көндәше, озак еллар шушы ук колхозны җитәкләгән кеше, шулай ук эшчәнлегенә дә артык тел-теш тидерерлек булмый. "Өйрәнгән яу-сугышмага яхшы" дигәндәй, югарыдагылар иске түрәне яклыйлар, "басым ясау" кебек сайлау чорының "үз технологияләре" дә эшкә җигелә. Әмма колхозчылар яңа чор кешесен, яшь җитәкчене хуп күрәләр. Нәрсәдән башлаган ул эшне?

—Бригадир чактагы алымны кулландым—төгәл исәп-хисап булдырдым. Баштагы елларда һава шартлары яхшы килү, яңа җитәкче буларак, миңа Ходайның ярдәме булды инде. Игеннәр мул булды, терлек азыгын да җитәрлек әзерли идек—йөз илле мең центнер силос

кына салдык, яңа урыннар өзерләп. Ә 1995, 1997 еллар авыр булды. Корылык. Инде, килеп, быел эссе җәй игеннәрне яндырды. Уңыш та бер гектардан ун центнер чамасы гына. Алты мең сигез йөз гектар сөрүлек җире бар, шунын өчтән берен гамәлдән чыгарырга туры килде. Элек чәчүлек җирләре унөч мең гектар иде, авыл халкының маллары өчен шактый мәйданны көтүлек өчен бүлеп бирдек. Указ чыкты бит бу хакта, аннан авыл кешесе мал асрамаса яши алмый.

М.Дәүләтьяров артельнең горурлыгы булырлык шактый исемнәр атады. Сыер савучылар Х.Мөлекова, З.Ишмөхәмметова һәр терлектән өч мең литрдан артык сөт савып алалар. Механизаторлар отряд методы белән эшлиләр. Кырларда унике комбайн эшли. Масагутов Илдар, Исмәгыйлов Җәүдәт башкаларны үз артларыннан ияртәләр. Эшләвенә карап акчасын алалар. Артель рәисенә, ягъни Мохтар әфәндегә гомуми хезмәт хакы фондының ике проценты бирелә. Баш белгечләргә рәискә тигән хезмәт хакының җитмеш проценты "тама" икән. Бер караганда, әгәр рәиснең нәфесе "уйнаклый" торган булса, артель әгъзаларына күбрәк хезмәт хакы яз да, үз кесәңне калынайт. Әмма Мохтар әфәндедән җене сөймәгән нәрсә—эшләми баерга омтылу.

—Андыйлар белән шундук хушлашабыз,—ди ул.—Күзәтчелек шурасы бар, киңәшләшеп эш итәм. Киңәшле эш таркалмый, диләр бит. Хезмәт хакы азрак дип зарланучы була икән, күзенә карап әйтәм: нигә сыкранып йөрисең, дим артельдә. Үзең башка чык, җир паеңны ал (ул һәр кешегә ун гектар чамасы), эшеңне үзең оештыр, үзең хуҗа бул. Инде дә булмаса—артельдә башка эш тәкъдим итәм. Эшләп карасын, күрсәтсен үзен.

Фермер хуҗалыклары шактый нәтиҗәле эш күрсәтә. Тәүге егермеләп фермер хуҗалыгы чын хуҗалар булып үсеп җиттеләр. Һәръяклап аларны яклыйм. Мурсалихов Муллахмәт алдынгы шофер иде. Бу чын фермер инде. Кашаев Фәрит, Мурсалимов Абдулла, Бәширов Зариф, Ягъфәров Әхмәт—барлык авылдашларга үрнәк фермерлар. Матур гына, тату гына яшибез. Иң яхшы үрнәк—фермерлар арасында кемгәдер үпкәләп, сыктап йөрүчеләр юк. Янә ике йөзләп кеше үз пае белән артельдән чыктылар. Алар җирләрен арендага йә фермерга, йә колхозга бирәләр. Шунсын да әйтергә кирәк, укытучылар, шәфкать туташлары, ягъни бюджет сферасында эшләүчеләр җирләрен фермерларга арендага бирделәр. Өлкәнең фермер хуҗалыклары ассоциациясе җитәкчесе Глеб Комов белән очрашып, фикерләшеп торам.

Шулай да, фермерлар белән хәл итүе четерекле бер мәсьәлә бар икән. Ул да булса—колхозның төп фондлары белән исәп-хисап ясау. Фермерлар аерылып чыкканда техника сорыйлар, ә төп фонд булган—терлек биналары, техника парклары, башка биналарны исәпкә аласылары килми. Белгәнегезчә, үзгәртеп коруның баштагы чорында, кат-кат бәяләнә торгач, объектларның кыйммәтләре гаять югары чиккә җитте. Хәзер реаль бәяне беләсең килсә, шәһәрдән аудит фирмаларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә алар акчаны каера белә. Шуңа күрә элек артель балансында торган балалар бакчасын, мәдәният йортын авыл советы каравына тапшырдык.

—Яңа йортлар салучылар күп бездә,—дип дәвам итә Мохтар әфәнде.—Үзем йортны 1985 елда ук өлгертеп кердем. Ягъни рәис булып сайланганчы. Сайлаганда авылдашлар әйттеләр: инде яңа өе бар, урлашып өй саласы юк.

Әңгәмә барышында Мохтар әфәндегә танылган язучыбыз Аяз Гыйлаҗевның сүзләрен искәртүне кирәк таптым:

—"Әгәр татар авылында чучка асрыйлар икән, ул татар авылы булудан туктый",—дигән иде Аяз ага. Сез, курыкмыйча, татарлыкны калку итеп күрсәтәсез, ә бу мәсьәләдә хәлләр ничек?

Мохтар Дәүләтьяров кырт кисте:

—Бездә дуңгыз күптән юк. Асрамыйбыз. Мулла бабай да

хупламый,—һәм сүзен икенчегә борды.—җирләребез—дала туфрагы. Гумус катламы өч сантиметрдан артмый. Татарстанда күп районнарда бонитет (җирнең уңыш бирү сәләтлеге) илле-алтмыш процент булса, бездә ул унбиш-егерме процент. Шуңа күрә "Көньяк Урал" фәнни-тикшеренү институты, аның генераль директоры А.Г.Бельков белән элемтәдә торабыз. Майор бригадасындагы мең җиде йөз гектар таулы җирдә фәнни тәҗрибә, эксперимент рәвешендә туфракны саклауның яңа ысулын—ландшафтлы җир эшкәртү технологиясен кулланып эш итә башладык. Төп максат—туфракны җил, яңгыр эррозиясеннән саклау. Таулы урыннар буй урманнар утыртып, кишәрлекләргә бүленә. Кишәрлекләр эчендәге мәйдан икегә бүленеп, берсенә бөртекле культуралар, икенчесенә күпьеллык үлән чәчелә. Күпьеллык үлән үскән җир өлеше, биш-алты елдан соң, сөрелеп аңа бөртекле культура чәчелә, ә иген үскән җиргә үлән чәчеп, ул берничә ел "ял" итә, ныгый. Моның белән Рәсәй авыл хуҗалыгы академиясе президенты үзе кызыксынды. Принципта яхшы, әмма махсус техника булмавы кулны тота.

Мохтар әфәнде, хатыны Рәисә ханым белән өч бала үстерәләр. Өлкән уллары—Марс шулай ук әтисе кебек үк юридик академияне тәмамлап, диплом алган. Кызлары Венера—унсигез яшьлек чибәр, өлгер кыз шул ук академия талибәсе. Айдар—әле Каргалы урта мәктәбендә укый.

—Илдәге ыгы-зыгы, һәрвакыт яңалыкка омтылып яшәү, гаилә белән ял итәргә вакыт калдырамы соң—дип сорыйм Мохтар Дәүләтьяровтан.

—Күп нәрсәгә өлгереп тә булмый торгандыр инде,—ди ул көлемсерәп.—Авыл хуҗалыгында эшләүченең ялы басу-кырлар инде аның. Көнгә бер урап кайтсаң, уңыш та әйбәт булса—җанга дәва, ял. Мин үзебезнең Каргалыны, анда яшәгән татарларымны яратам. Тарихи авыл, болгар бабаларымның изге җире. Оренбургка кадәр элек төзелгән бистә дип исәплим. Шуңа күрә исән калган мәчет кашына 1726 ел дип яздырып куйдым. Юри яздырдым, уйлансыннар дип. Чын тарих ерак яшерелгән шул. Ныклап шөгыльләнергә вакыт җитми. Үземне рәис итеп сайлап, колхозда үзгәртүләр башлангач, яңа мөһер ясаттым. Әле Татарстанда дәүләт туграсы—герб кабул ителмәгән иде. Безнең мөһердә ал аягын күтәреп торучы гайрәтле арслан. Җитмәсә, үзе—канатлы. Тарихтан килгән ул безгә, киләчәккә бара. Татар җирен саклаучы символ. Ә татар җирләрен сакларга бик кирәк. Татарстан белән элемтә йомшак. Безгә Татарстаннан галимнәр, иске кульязмалар эзләүчеләр киләләр, әмма аларның бу яктан нинди мәгълүматлар алып китүләрен, ул табылган хәзинәләрнең нинди хезмәтләрдә урын алуларын белмибез диярлек. "Кире элемтә" дигән нәрсә җитми. Башкортлар алай түгел, һөҗүмчән, үҗәт эш алып баралар. Концертлар белән килүчеләр дә сирәк. Зөһрә Шәрифуллина, Айдар Галимов Оренбур өлкәсенә килсәләр, Каргалыга кермичә китмиләр. Башкалар хәзер читләтеп үтәләр. Артистлар да "крутой"га әйләнделәр, ахры, милли мәнфәгатьләр урынына, акча алга чыга. Ә бит әйтүләренә караганда, сөргеннән кайткач, илленче еллар ахырында Каргалыга Хәсән Туфан да килеп, әдәби кичәдә катнашкан, шигырьләрен укыган.

Кыш көне, вакыт табып ауга йөрергә яратам. Сакмар, җаек буендагы урманнарда күп төрле киек яши. Быел шәхси рекорд куйдым—ике йөз килограммнан артык булган кабан дуңгызын атып алдым. Аучылар моның нәрсә икәнен белә.

Мохтар Дәүләтьяров белән аз гына аралашулардан белеп—төпченеп кала алганнардан укучыларга җиткерәсе килгәннәр шулар.

Татарстаннан еракта Казанны, Татарстанны сагынып яшиләр Каргалы авылы кешеләре. Татарларга хас эшчән, максатчан халык яши биредә.

## "Милли мәктәп булдык, милли мәктәп булып калачакбыз!"

КАРГАЛЫГА КИЛЕП тә, мәктәп—авылдагы тәгълим-тәрбия үзәге белән танышмыйча китү ярый торган эш булмас иде.

Авылда ике мәктәп бар. Берсе урта мәктәп, Каргалы яралганнан бирле, төбәктәге тәгълим-тәрбия эшләренең дәвамчысы һәм, икенче мәктәп, Оренбур өлкәсендәге барлык акылга зәгыйфь балалар җыелган ярдәмче мәктәп-интернат. Каргалы халкы мондый мәктәпнең нәкъ менә алар җиренә китереп урнаштыруларын тәүдә өнәп җиткермәсә дә, хәзер артык хафаланмый. Ни дисәң дә, кемгә күпме акыл салу Ходайның эше, татар халкы гомер-гомергә ятим-җилпе, гарип-горабага ярдәм кулы сузган, игелек кылган, шул рәвешле Ходайның рәхмәтенә өмет итеп яшәгән, тагын шунсы да бар, авылда әлеге мәктәпнең булуы хәзерге гомумэшсезлек чорында азмы-күпме эш урыны да булып тора. Урам яктан карап киткәндә күренде: анда эшләүчеләр җиң сызганып мәктәпне яңа уку елына әзерлиләр иде.

Каргалы урта мәктәбенә килсәк, бай тарихлы мәктәп булуы хакында янә дә бер искәртәсе килә. Борыннан авылда күпме мәдрәсә булган, анда гыйлем бирү, дин һәм дөньяви тәрбия эшләренең торышы ни рәвешле булган, заманында күп төрле дини агымнар (абызагайлар, нәкыш бәнди һ.б.) хөкем сөргән, алар барыбер мондагы халыкның каннарында сакланадыр, вакыт-вакыт үзен сиздереп тә куядыр сыман. Бүгенге мәктәпне үткәннәрнең лаеклы дәвамчысы итеп күрәсе килә.

Чынлыкта, хәлләр ничек соң?

Урта мәктәп беренче чыгарылышын 1941 елда үткәргән. Авылда исән калган мәдрәсә, мәчет биналарында төрле сыйныфлар белем алган, ягъни бөтен авыл буйлап таралган мәктәп булган ул.

1974 елның март аенда колхоз көче белән җиткерелгән өч катлы типовой мәктәп ишекләрен ачып, беренче укучыларны кабул итә. Мохтар әфәнде мәктәп турында сүз чыккач: "Үз кулларыбыз белән төзегән мәктәп!"—дип, горурланып куйган иде. Мәктәп төзелгән чорда һәркем кулыннан килгәнчә ярдәм иткән: таш, кирпеч бушату, өю, измә ташу—авыл өчен гаҗәп төзелешкә бәрәү дә битараф булмаган ул чакта.

Яңа мәктәп сафка басканнан бирле директор булып Зәбиров Илдус Сәмикович эшли. Ул үзе Новосергеевка районы Белогор (Актау) (Пушкинның Гриневы "иза" чиккән крепость) авылында туып үскән, әүвәл 1955 елда Желтыйдагы татар-башкорт педучилищесын тәмамлаган. Нәкъ алар укыган чорда училищены русча укытуга күчергәннәр. Шул дәвердән бирле Каргалы мәктәбе дә үз милли йөзен саклап калу өчен көрәшә. Монда "көрәш" сүзен туры мәгънәсендә дип аңларга кирәк.

Армия хезмәтеннән соң, Илдус әфәнде Оренбург пединститутының тарих-филология бүлеген тәмамлап, Каргалыга килә. 1966 елдан уку-укыту мөдире, ягъни завуч, аннан, әйткәнемчә, егерме биш ел шушы мәктәпнең директоры.

Мәктәп ике сменада укый. Алты йөз өч бала белем ала. Узган уку елында кырык бала унберенче сыйныфны тәмамлап, Рәсәй сәясәтчеләре тудырган һәм болганчык суны хәтерләткән "яңа дөньяга" чыгып киткәннәр. Укытучылар үз укучыларының алдагы язмышлары өчен бик тә борчылалар. Укучыларга ныклы белем бирелә дип әйтергә нигез бар, чөнки быел мәктәпне тәмамлаган укучылар юридик, икътисад, табиблык һ.б. белгечлекләр буенча югары уку йортларына уңышлы имтихан тотканнар.

Соңгы чорларда мәктәпкә район, өлкә мәгариф бүлекләреннән милли статусны бетерергә кушып күрсәтмәләр бирүчеләр табыла башлаган. Укытучылар шуңа борчылалар. Әмма Илдус әфәндедән дә,

укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасар Низаметдинова Тәүхидә Фәрит кызынын да сүзләре бер һәм катгый:

—Милли мәктәп булдык, милли мәктәп булып калачакбыз!—ди алар ныклык белән. Бу позицияне өлкәдә яхшы беләләр, ни дисәң дә, Каргалы урта мәктәбе милли статуска ия бердәнбер уку йорты. Башка төбәкләрдә, басымга түзә алмыйча, татар мәктәпләре урысча укытуга күчеп беткәннәр. Татар теле предмет буларак атнага ике сәгать керсә керә, кермәсә—аның өчен мәгариф җитәкчеләренең башы авыртмый. Татарлыкны саклап калу милли җанлы укытучылар һәм аз сандагы милләтпәрвәрләр кулына калган. Ә андый кешеләр елдан-ел кими...

—Татарстанга карап күзләребез талды инде,—ди Тәүхидә ханым ачынып.—Ник бер ярдәм, ник бер кызыксынучы булсын мәгариф эшлеклеләре тарафыннан. Казанда, Чаллыда оештырылган укытучыларның белемен күтәрү курсларына чакырмыйлар бит безне. Үзебезнең акчага барабыз, өстәмә бернинди мәшәкать тудырмас идек, юк, әллә кемнән, әллә нәрсәдән куркалар. Китаплар җитми, ярдәмче әсбаплар юк—мөрәҗәгать итсәк тә, безнең җан авазы җавапсыз кала.

Бу—күптәнге чир. Галимҗан Ибраһимов тел-әдәбият мәсьәләре хакында уйланганда, бу хакта уфтанып язган. "Язуда, басуда шул чаклы зур хезмәт күрсәтелсә дә, дәүләт нәшрияты басылган әсәрләрне таратуда бөтенләй эшлексез, гаҗиз, тәрбирсез булды. Көз көне Казанда чыккан әсәр әле һаман да Чистайга барып җитмәгән. Соратабыз—"җибәрә алмыйбыз" дип җылап язалар. Шул чаклы әсәр басылганы хәлдә, Мәскәүдә, Уфада, Әстерхан, Оренбургта бездән әсәрләрнең һичберен диярлек күрә алмыйлар."

Әлеге мәсьәләләр хакында, бүген дә Каргалы мәктәбе җитәкчеләре белән ачынып сөйләшеп утырдык без.

—Дөрес, монда Казаннан язучылар да, журналистлар да, галимголәмә дә килеп чыга анысы, әмма, еш кына, Татарстанга кайткач, мондагы хәлләр турында, безнең эшебез хакында төгәл информация бирмиләр, фактларны бозып күрсәтәләр,—дип дәвам итте Илдус Сәмикович,—без моңа бик нык рәнҗибез. Бер мәлне Казаннан шактый танылган язучы килеп, мондагы хәлләр белән танышты. Өлкәдә мәктәптән милли статус исемен алу буенча зур "эшчәнлек" җәелдереп җибәргән чор иде. Без җан-фәрман тартышабыз. Төки бирешмәдек, татар мәктәбен саклап кала алдык. Ә язучыбыз матбугатка язып чыкты—имеш, Каргалыда татар мәктәбе ябылган, укытучылар татарлыкларын онытып, урысча укытып яталар икән. Мәктәптәге алтмыш-җитмеш укытучының намуслы хезмәтенә, җанына пычрак ату дип кабул иттек без бу хәлне.

Бүгенге көндә мәктәп өлкәдә күренекле мәгърифәт учагы. Өлкәдәге милли уку йортларының (татар, чуваш, мордва һ.б.) база мәктәбе булып саналабыз. Педагогия институты, педучилище, укытучыларның белемен күтәрү институтлары Каргалы урта мәктәбендә теләп курслар оештыралар, өлкә семинарлары уздырып, мәгариф работникларының белемнәрен күтәрүдә мондагы эш тәҗрибәсеннән мул файдаланалар. Мәктәптә илле алты укытучы—барысы да Каргалыда туып-үскәннәр.

Колхоз белән аңлашып эшлиләр кебек. Мохтар әфәнде—колхоз рәисе белән Илдус әфәнде баҗалар. Ике баҗа, ике милләтпәрвәр өлкәдәге бердәнбер татар мәктәбен үтә дә кыен шартларга куймаслар, дип ышанасы килә.

Авыл мәктәпләрен иң борчыган проблема—әхлак мәсьәләсе. Балаларга әхлак, әдәп тәрбиясе бирүнең үтемле формалары кирәк. Мәктәп укытучылары яңа төшенчә—укучыларны социальләштерү дигән төшенчә белән очраштылар. Чор таләпләре югарылыгында балаларны тормышка хәзерләү дип әйтергә була аны кыскача. Рухи кыйммәтләр үзгәрә, шуңа күрә Каргалы мәктәбе укытучылары балаларның дини тәрбия алуларын хуплыйлар. Мәчеттә дин тәрбиясе түгәрәге оешкан, балалар теләп йөриләр.

Урта Азиядән качак булып кайткан кешеләрнең балалары укый башлагач, шәһәрдән дә "тик тормый торган" балаларны авылга кайтарып, мәктәпкә бирү гадәте көчәеп китте, мәктәптәге тәрбия эшләренә яңача килү тиешлеген укытучылар үз җилкәләрендә татыйлар. Үткән уку елында да шәһәрдән килгән ике кыз шактый мәшәкатьләр тудырган. Авылга яман гадәт—наркотик куллану үтеп керә башлаган. Бу йогынтыдан мәктәпне ничек саклап калырга—укытучылар баш вата. Авыл баласының эшкә кулы ята, хуҗалыкларда мал-туар асрыйлар, өйдә әти-әниләренә ярдәм итәләр инде алар, әмма җәйге ял чорында балаларның бик азы гына колхозда эшкә урнаша. Аларның үз хезмәт көче белән акча эшлиселәре килә. Бала-чаганың уңай психологик сыйфаты ул, ә аны файдаланып булмый.

Әйе, Каргалы урта мәктәбе дә Рәсәйнең хәсрәт сәясәтчеләре тарафыннан тудырылган авырлыклар белән тарткалашып, өзгәләшеп яшиләр, мәктәпнең данлы тарихи йөзен саклау өчен җан фәрман тырыша.

Каргалы мәктәбен тәмамлаган кешеләр арасында күп шәхесләр үсеп чыкты. Казан дәүләт университеты укытучысы Наурүз Гали улы Имангалиев, аның энесе, полковник Рөстәм Имангалиев, Рәсәй Герое Фәрхәт Ситдиков, табибә-профессор, Оренбур медицина академиясе укытучысы Венера Сөет кызы Хәбибрахманова, "Кара йөзләр", "Сөембикә" операларын иҗат иткән мәшһүр композитор Бату Мулюков та алар якташы, кинооператор, алтын "Ника" призын алган Рафаел Рәхмәтулла улы Хәялин кебек укучылары Каргалы урта мәктәбенең борынгыдан килгән данын киләчәккә илтәләр.

## Оренбурда татарча сөйлиләрме?..

ОРЕНБУР УРАМНАРЫ буйлап йөрим. Күңелдә—Ризаэддин Фәхретдиновның зар кылып әйткән сүзләре. "Әй тырыш һәм чыдам бабаларыбыз! Сез әле күптән түгел генә бу илдә гомер сөрә идегез. Мәчетләр һәм мәдрәсәләр торгызып, мәдрәсәләрнең тормышларын тәэмин итә идегез. Мәхәлләләр мәчетләр белән, олы шәһәрләрдәге, мәшһүр авыллардагы мәдрәсәләр чалмалы шәкертләр белән тулы буладыр иде. Һәр ел йөзләрчә имамнар җитешеп торадыр иде. Сәүдәгәрләрегез Төркестан һәм Фирганәләр, Сәмерканд һәм Бохаралардан үтеп, Әфганстан һәм Һиндстанга, Багдад һәм Кашганнарга тоташтан йөреп торадыр иде.

Бу көндә бу хәлләргә ни булды?.. Үзегез кайларга киттегез?.."

Оренбур шәһәре хәзерге татар матбугатында төрлечә язылышта йөри. Мин исә халык телендә кулланылганча һәм әйтү өчен дә уңайлы Оренбур атамышына тукталдым.

XVIII гасыр башларында урыс хөкүмәте башкортлар яшәгән тарау төбәкләрне тикшереп, чикләрне аныклау, бу төбәкне ныклап сәяси-икътисадый үзләштерү максатыннан һәм Рәсәйнең Көнчыгыш чикләрен ныгыту, алга—көнчыгышка таба империя чикләрен киңәйтү сәясәтендә мөһим урын тотачак Оренбур экспедициясен оештыра. Экспедиция проектын 1734 елда И.К.Кириллов эшли. Башкорт җирләре чигендә ныгытмалар системасын төзү белән бергә, Оренбур экспедициясенең төп бурычларыннан—Урта Азия төбәкләре белән сәүдә эшләрен торгызып, җанландырып җибәрү, файдалы казылмалар турында дөрес мәгълүматлар туплау була. Асылда, бу үзгәртеп корулар монда яшәгән халыкларның иреген чикләүгә китерә. Экспедициягә татар тарихын өйрәнүчеләр өчен билгеле В.Н.Татищев, И.И.Неплюев кебек патша чиновниклары җитәкчелек итәләр. Аларның турыдан-туры катнашында борынгы төрки-татар җирләрендә Орск, Оренбур кебек кальгалар төзелә. (1744 елда Оренбур губернасы төзелгәч, Оренбур экспедициясе яшәүдән туктый.)

Бу чиклөүләрне татар-башкорт халкы ничек каршылаган соң? Габделбари Баттал бу хакта җентекләп яза:

"Беренче баш күтәрү ничек башланган? Рус хөкүмәте башкортларны казакъ-кыргызлардан географик яктан аеру һәм башкортларны камап тоту уе белән 1734 елда җаек (Урал) елгасына Үр (Ор) елгасы койган урында бер кала төзергә карар бирә. (Бу кала башта Оренбург дип исемләнгән булса да, соңыннан, хәзерге Оренбург шәһәре яңа җирдә төзелгәч, Ор елгасы тамагында урнашкан кала Орск исемен ала.) Ул көннәрдә Петербургта булган башкорт аксакалы Теләкәй Тукчура угылы хөкүмәтнең бу карарын ишеткәч, башкортларның алдынгы кешеләреннән булган Килмәк абызга хат язып, бу карар турында хәбәр итә. Бу карарның максаты нидә булуын белдерә һәм русларның бу омтылышларына коралланып каршы тору кирәклеген кинаяле җөмләләр белән аңлата. Рус авторы В.Витебский болай ди: "җаек һәм Ор елгалары кушылган урында кала төзелгәч, үзләренең һәр яктан камалган хәлдә калачакларын башкортлар дөрес күзаллыйлар иде".

Килмәк абыз кешеләре Уфа каласыннан йөз алтмыш чакрым ераклыкта Кириллов отрядына һөҗүм итәләр, әмма аның алга хәрәкәтенә киртә куя алмыйлар. 1735 елның унбишенче августында иске Оренбург каласының нигезе салынган. Моңа да карамастан, башкортлар бу вакыт казан кебек кайнаганнар. Һәр җирдә русларның җәзалау отрядлары белән бәрелешләр, рус калаларына һәм гаскәри постларына каһарманнарча һөҗүмнәр дәвам иткән.

Бу фетнәне бастырганда рус гаскәре башлыклары ул вакытларга кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән вәхшилекләр эшлиләр. Фетнәче башкортларга каршы "Нугай юлы"нда хәрәкәт алып барган майор Станков җаек белән Сакмар елгалары арасында алты йөз башкорт әсирен кылычтан үткәргән. Алексей Тәфкилев исемле бер гаскәр башлыгы (рус хезмәтендәге бер сатлыкҗан татар морзасы, мөселманча исеме Котлымөхәммәт булган, господалар тарафыннан бер "яхшылык" кебек итеп, үзенә Алексей исеме бирелгән) "Себер юлы"нда 50 башкорт авылын яндырудан тыш, Сөянтес дигән авылда караңгы төндә башкорт йортларына төбәп ут ача. Бу юлы авылдагы мең кешелек халыкның зур өлеше үтерелгән. Ахырга кадәр каршылык күрсәтергә карар биргәнлекләре беленгән йөз дә биш кеше кереп бикләнгән амбарны терелөй яндырганнар. Генерал Румянцев тарафыннан әсир ителгән башкортлардан тагын биш йөз кеше Минзәлә каласында асылганнар. Әмма бөтен бу вәхшәт башкортларны тынычландыруга ирештермәгән, киресенчә, ризасызлыкларны гына көчәйтә төшкән.

1737 елның башында башкортларның каршы торулары җимерелә, фетнәнең җитәкчеләре булган Килмәк абыз, Акай, Күчем, Йосыф һәм башкаларны руслар кулга алалар. (Килмәк абыз Табын каласы янында 1737 елның февралендә кулга алына. Биредә исемнәре аталган өч кеше Петербургка җибәрелә, башкалар исә Минзәләдә асып үтереләләр.)

1740 елның мартында бик киң мәйданны эченә алган фетнә башлана. Бу юлы баш күтәрүне Юрматы төбәге башкорты Карасакал кушаматлы берәү җитәкли.

Карасакал гаять дәрәҗәдә кыю, салкын канлы һәм түзем була. Уңышлардан башы әйләнми, уңышсызлыклардан җебеп төшми. Гүя ул туганда ук җитәкче булып яратылган диярсең. Аның аннан-моннан ни әләксә шуның белән генә коралланган кешеләре рус регуляр гаскәренә каршы каһарманнарча ташланалар; туптан башка һичбер нәрсәдән—җәяүле гаскәрләрдән дә, атлы гаскәрдән дә куркып качмыйлар.

Хөкүмәт фетнәне ничек бастыра иде? Бу фетнә көннәрендә Урусов берсе Минзәләдә, икенчесе Оренбургта булган ике "Хөкем комиссиясе" оештыра. Әсир төшкән башкортларны бу комиссияләрдә сорау алып җәзалаганнар, утка атканнар, казыкка утыртканнар, кабыргаларын

сындырганнар, башларын кискәннәр һәм асканнар. Бу вәхшилекнең тәэсире астында башкортларны курку баса. Бу дәһшәт фетнәчеләр качкан тау һәм урман эчләренә кадәр барып житә. Инде шул сәбәпле Карасакал казакъ-кыргыз далаларына чигенергә мәжбүр була. 1740 елда Урусов белән Соймонов: башкортларның бары тик үз теләкләре белән законлы хөкүмәткә буйсынулары аша гына үзләрен, гаиләләрен үлемнән, милекләрен көл ителүдән коткара алачаклары турында игълан тараталар. Башкортлар рус түрәләренә бирелә башлыйлар. Әмма, Витевский язганча: "Фетнәче башкортлар арасында кулда корал тотып үләргә карар кылганнар, жәзалауларга зур ныклык белән түзгәннәр, куркыныч үлем жәзасын да кыю каршылаганнар, төрмәдә ачлык игълан итеп үлгәннәр дә бар иде.

Кабатлап әйтергә туры килә, монда сүзне башкорт халкының каршылык күрсәтүе генә дип аңламаска кирәк. Хәрәкәттә мишәр, типтәрләр дә катнаша. Г.Баттал З.Вәлиди белән яхшы таныш булып, аның "башкортчанлык" фикерләрен хуплаучыларның берсе булуын да онытмаска кирәк.

Менә шундый тарихи аяусыз көрәшләр нәтиҗәсендә төзелә Оренбур каласы. Әмма беренче язда ук, ташу вакытында калачыкны су басып, һәлакәт чигендә кала. Аны 1737 елда Жаек буйлап түбәнгәрәк, ә инде 1743 елда хәзерге урынында—Нугай Урдасының Актүбә шәһәре урынына төзи башлыйлар. "Тарихта 1237 елларда Батый хан гаскәрләренә ныклы каршылык күрсәткән солтаннарыннан Бачман солтан мәгълүм",—дип яза Марсель Әхмәтжанов.—Дәфтәри Чыңгызнамә" әсәрендә дә Бачман ханның Сакмар тамагында кала тотып яшәгән урыны хакында язылган. Анда: "Актүбә Бачман ханның йортыдыр,"—дип күрсәтелә.

Оренбурның бер кырые әле гасыр башында да Актүбә очы дип йөртелгән. Актүбә халкы бу афәтне ни рәвешле кабул иткәндер, әмма Каргалы бистәсе ныклап төзелә башлагач, урыс чирүеннән жык булган татарларның күпләп Каргалы ягына чыгып утырулары бик мөмкин. Бистәнең кинәт кенә ныгып, үсеп китүенең бер сәбәбе шул да булырга мөмкин.

Шәһәр хәзерге урынында—Сакмар елгасы жаек елгасына койган жирдә тупләнеп кала.

Бу якларга халыкны куып та китереп утыртканнар, шул ук вакытта патша хөкүмәтенең миссионерлык сәясәтеннән качып килүчеләр дә житәрлек булган.

Петр I үлгәннән соң императрица Анна Иоановна үтә диндарланып, Казан төбәгендәге миссионерлык эшчәнлеген тагын да "жанландырырга" боерып 1740 елда яңа фәрман чыгарган, ул егерме өч бүлектән торган. Фәрманда яңа чукынучыларга кызыксындыру чаралары да күрсәтелгән: өч ел дәвамында налоглардан, гаскәри хезмәттән тулысынча азат итү, төре үпкән жинаятьчеләрне төрмәдән азат итү.

Унберенче сентябрь фәрманының унбишенче маддәсендә "изге төре"не кабул иткәннәргә түбәндәге бүләкләр бирелечәге санап күрсәтелә: һәр кешегә алты мыскал авырлыгында бер бакыр төре, бер киндер күлмәк, бер данә саржа кафтан, бер данә калфак, бер пар алъяпкыч, бер пар оек, бер пар аяк киеме бирелә. Хатыннарга киндер күлмәк, баш яулыгы, янә һәммә кешегә яшенә, мөлкәтенә, женесенә карап акчалата "премия" бирелү дә каралган.

Татарлар бу афәттән, качып котылу чарасын күрәләр. Шактый кеше Жаек буйларына да килеп чыга.

Танылган галим Г.Саттаров күрсәткәнчә, болгар һәм иске татар телләрендә уар—ор-ур географик номенклатура термины тирән чокыр, елгачык, елга төшенчәләрен белдерә икән. (7. 96 б.) Республикабызның Арча төбәгендә Ор, Орнаш, Оры дигән елгачыклар бар. Оренбур төбәген ныклап өйрәнүчеләрнең берсе П.Н.Рычков Ор елгасының килеп чыгышы турында: "Ор—төрки сүз, аның мәгънәсе бар. Беренче

мәгънәсе—"перекоп, линия", икенче мәгънәсе— "устье, отверстие, ворота"— дип яза. (7. 97 б.) Оренбург шәһәре менә шушы төрки атамалы елга исеменнән ясалган һәм чыннан да заманында Рәсәйнең Көнчыгышка бару юлында капка вазыйфасын башкарган. Моның шулай икәнен Г.Баттал да күрсәтә. "Үз заманында патша Петр I баш тылмач Алексей Тәфкилевкә: "Казакъ-кыргыз урдасы далада яшәгән һәм артык нык булмаган бер ил булса да, бөтен Азия өлкәләре һәм илләрнең капкасы һәм ачкычы",—дип, әгәр Тәфкилев бу Урданы Рәсәйгә буйсындыруны үз өстенә алса, бу эшне оештыру өчен үзенә бер миллион сум акча бирәчәген әйтә. Менә шул "ачкыч" кинәт Рәсәй кулына күчә башлый. Мәсьәлә шуннан гыйбарәт: Кече Җөз казакъларының ханы Болгаер (Әбдүлхәер), Җунгариядән күчкән калмыкларның яу чабып талауларыннан туйганга, рус патшасы ярдәменә сыеныргa мәҗбүр була. Ягъни 1730 елда императрица Иоан кызы Аннага мөрәҗәгать итеп, үз Урдасын рус подданствосына кабул итүен сорый. Әмма Болгаер шул ук вакытта ике шарт куя: 1) ханлык дәрәҗәсен Болгаер токымына багышлау; 2) хан өчен кара көннәр килсә, Ор елгасы тамагына төзеләчәк калада сыену урыны бирү.

Казакъ ханының бу гозере сөенеп кабул ителә.

Тәхеткә утыргач (1762 ел) Екатерина II үткәргән сәясәтнең максаты да Төркестанга сәүдә кәрваннары оештыру һәм казакъ-кыргыз далаларын яшәрлек бер хәлгә китерү була.

1784 елда Оренбург крае губернаторы итеп—барон Иглстром билгеләнә. Бу кешенең тәкъдиме буенча, Екатерина II хөкүмәте 1785 елдан башлап казакъ-кыргыз далалары чикләрендә булган рус калаларында казна хисабына мәчетләр төзергә карешә. Шул ук елда Оренбург һәм Троицк шәһәрләрендә мәчетләр ачыла. Бу мәчетләрнең ачылу хәбәрен алган патшабикә, барон Иглстромга шул ук елның 14 сентябрендә җибәргән фәрманында түбәндәге сүзләрне яза: "6 нчы августта язып җибәргән рапортыгыздан, Троицк һәм Оренбург калаларында төзелгән мәчетләрнең ачылу хәбәрен ишеткәч, һич кенә дә икеләнмичә әйтә алам: мондый гыйбадәтханәләр чикләребез тирәсендә яшәгән күчмә халыкларны да җәлеп итәчәк. Бу хәл исә аларны киләчәктә буйсынмас булудан ваз кичтерер өчен көчле чараларның да иң көчлесе булачак". Екатерина шул ук ярлыкта генераль-губернаторга: телгә алынган шәһәрләрдә "Казан мәдрәсәләре" ачарга, мөселман сәүдәгәрләрнең эшенә ярарлык кәрван-сарайлар яки сәүдә йортлары төзергә, "мөселман гадәтләре буенча ничек тиеш икәнлеген татарлардан сорашып", мәчет тирәләрендә таш диварлар тотарга киңәш итә.

Болардан күренгәнчә, Екатерина II хөкүмәте дин һәм хәреф таныту дигән булып, мулла һәм мөгаллимнәрне рус хөкүмәте мәнфәгатенә хезмәт итүче пропагандачы һәм сәяси агент итеп кулланырга теләгән. Бу мулла-мөгаллимнәрнең үзләренә Екатерина һәм Иглстром тапшырган вазифаларын ни дәрәҗәдә һәм ничек үтәүләрен белмәсәк тә, шунысы ачык мәгълүм: барон Иглстром, казакъ-кыргыз иле белән идарә итү рәвешен тамырдан үзгәртергә карар биреп, Нурали ханны Уфага сөрә. Болгаер хан уллары белән Сарым батыр арасында килеп чыккан гаугаларны бөтен көченә күпертә һәм казакъ-кыргызларны "акылга утырту" өчен ике-өч мәртәбә рус гаскәрләрен җибәрә.

1789 елда Иглстром Екатерина II фәрманы буенча Уфа шәһәрендә русча исеме "Оренбургское могометанское духовное собрание" булган "Оренбург мөселман дини нәзарәте"н оештыра". Каргалы ахуны Мөхәммәтҗан Хөсәен улы беренче мөфти итеп билгеләнә.

Шәһәрнең татар тарихында тоткан урыны бәяләп бетергесез. Бүгенге шәһәрдә татар тарихын чагылдырган бик күп биналар, атамалар сакланган. Әмма алар вакытлар үтү белән шәһәр халкы

хәтереннән җуела бара. Мин кайбер урамнарның күренекле татар шәхесләре исемнәре белән аталулары хакында ишеткәнем булса да, көн буе йөреп тә алар күзгә ташланмады. Бары тик "Төркестан" проспекты булуы гына, шәһәрнең Урта Азия ягына илтүче зур сәүдә юлына урнашуына ишарәле. Оренбурда Муса Җәлил, Шәриф Камал, Җәүдәт Фәйзи, Риза Фәхретдинов һ.б. олуг шәхесләргә истәлек такталары куелуы хакында да беләбез. Әмма Муса Җәлил истәлегенә, ул укыган "Хөсәения" мәдрәсәсенә куелган уч төбе кадәр тактада нинди язылуын укый алган кеше үзен "очлы күз" бәйгесендә (әгәр оештырылса) һичшиксез җиңүче дип саный ала. Язу ифрат авыр укыла. Башкалары ничектер, анда яшәүче татарлар үзләре белә инде... Бусы Рәсәйнең бүгенге империячел сәясәтенә мисал—бер генә нәрсә дә төбәкнең татар җире икәнлеген күзгә бәреп, искәртеп торырга тиеш түгел дип, санныйлар, ахры, мондагы түрәләр. Сәясәт алар кулы белән тормышка ашырыла. Ә Татарстан "чит өлкәләр эшенә тыкшынмый" тек тыкшынмый инде. Югыйсә, Оренбурны төзүдә татар-типтәрләр, мишәрләр турыдан-туры катнашканнар. Татарлар кулы белән төзелгән шәһәр ул.

Шәһәр урамнарыннан үтәм... Моннан берничә көн элек "Мәдәни җомга" газетасының (30 июнь 1999 ел) "Ырынбурда инде безнеңчә көйләмиләр" дигән мәкаләсен укыган идем, шуны бераз үзгәртеп, "Оренбурда инде татарча сөйләшмиләр" диярге кала. Кемнәрдер сөйләшә торгандыр, билгеле. Әйтик, яңа уку елыннан шәһәрнең көньяк округына караган 38 нче санлы гомум белем бирү мәктәбе татар мәктәбе итеп үзгәртелгән. Мәктәптә ике йөз илле алты укучы белем алачак, аларга утыз укытучы хезмәт күрсәтәчәк. Беренче сыйныфка ике төркем җыелган. Татар җәмгыятьчелеге татар мәктәбен ачу буенча күптәннән эш алып барган. Иң элек Җәмигъ мәчетендә унҗиде бала татарча укый башлаган. Мәктәп ачылганда өлкә мөфтие Габделбарый хәзрәт тә катнашкан, чыгыш ясаган. Өлкә татар милли-мәдәният мохтарияте төзелеп, аның җитәкчеләре, активистлары да шәһәрдә, өлкәдә татар тормышын җанландыруга күп көч куялар. Тик әле бу мәсьәләләрне хәл итүгә гаять зур җегәр, вакыт кирәк булачак.

Совет урамы буйлап атлап, утызынчы еллар очучылары киемендә сынландырылган В.Чкалов һәйкәленә килеп чыктым. Янәшәдә генә Ю.Гагарин укыган очучылар мәктәбе. Һәйкәл урнашкан сквер артында тирән яр астында Җаек елгасы елтырап ята. Йөгерек, дәртле агышлы елга. Хәзер карталарда Җаек дигән атама юк инде. Елга исеме халык җырларында гына сакланып калыр, ахры:

Җаек суларының, әй агуы,—
җигүле җирән атның баруы;
Кайсы кибетләрдә сатыла икән
Безнең янган йөрәкләр даруы?

1775 елда Екатерина II (Әби патша), Пугачев җитәкчелегендәге кузгалышның (1773-1775) хатирәләрен халык күңеленнән йолкып ташлау максаты белән Җаек атамасын Урал дип, Җаек шәһәрен дә Уральск итеп үзгәртергә әмер бирә. (Түрәләр элек тә, хәзер дә географик атамаларга битараф булмаганнар инде. Соңгы елларда, кайбер түрәләрнең ихтыяры белән борынгыдан килгән тарихи атамаларны бозу күренеше шул хакта сөйләми мени?! Әмма шунысы хак, аларның кыланмышы тарихка нәкъ менә шул мөнәсәбәттә—кире мисал рәвешендә кереп калачак, ә тарихи атамалар, гасырлар буена ничек аталса, барыбер үз эзенә төшеп, халык атаганча, дөрес итеп әйтелеп йөртеләчәк.)

Җаек елгасы ике кыйтганы—Аурупа белән Азияне аерып торучы чик. Елга аша бик матур асылмалы күпер төзелгән. Марат ага Дәүләтьяров белән әлеге җәяүлеләр өчен генә махсус эшләнгән күпернең тимер өсте буйлап, Азия ягына чыгып кердек. Елга буйлап

аяк белән әйләндереп хәрәкәткә китерелә торган катамаранга охшаш көймәләрдә ял итеп йөрүчеләргә карап, хозурланып тордык. 1906 елда, тормыш юлы Җаек буйлары белән нык бәйләнгән Мәҗит Гафури Аурупа белән Азияне сөйләштереп, алган:

> Аурупа: Ничә мең ел надан яткан, әй бичара!,
> Үз хәлеңә күзләреңне ачып кара!
> Үз-үзеңне сакларга да хәлең беткәч
> Минем халык өстеңне басып бара.
>
> Азия: Башладылар азиялеләр инде эшкә,
> Моннан соң тик ятмаса, калмас кичкә.
> Заманача гыйлем—һөнәр тәхсир итсә,
> Рөхсәтсез баса алмассыз безнең өскә.

Бу шигырь язылуга йөз еллап вакыт үткән, тәкәббер Аурупа белән иҗтиһад итүче Азия арасындагы мөнәсәбәтләр тамчы да үзгәрмәгән.

1989 елгы халык саны алу мәгълуматлары буенча, Оренбур өлкәсендә соңгы чорда 158564 татар яши. Рәсәй буенча, Татарстанны да исәпләп, алтынчы күрсәткеч бу. Казанда яшәүче галимнәребезнең кайсы өлкәдә күпме татар булуын исәпләп, хезмәтлр язып чыгаруын хуплаган хәлдә: "Менә бит ә! Без—татарлар нинди халык!"—дип, мактанып ятканда, чит өлкәләрдә яшәп, милләттәшләребез Казан, Татарстаннан бернинди ярдәм күрми, әкеренләп инкыйразга, бетүгә дучар. Билгеле, ул төбәкләрдә, шул исәптән, Оренбурда да татар халкын саклап калу өчен җан-фәрман тырышучы милләттәшләребез бар. Әмма шовинистик рухлы куәтле империя машинасына каршы алар үзләре генә озак каршы тора алмаячаклар. Татарстанның чит өлкәләрдәге татарларга ярдәме дәүләт сәясәте дәрәҗәсендә һәм ачыктан-ачык үткәрелмәсә—эшләр харап. Җәмәгать оешмасы статусыннан ерак китмәгән конгресслар, ТИҮлар гына, бик тырышкан хәлдә дә, нәтиҗәле эш күрсәтә алмаячаклар. Чөнки эшне башкару өчен иң беренче чиратта ният—сүз кирәк булса (ансы бездә җитәрлек), икенче чиратта акча кирәк (ансы инде дәүләт кулында).

*Ахыры бар.*

---

РАДИО
УКВ 73,97
Курай

*Курай радиосы —
яшь күңелле дуслар өчен!*

# АДАМ МИЦКЕВИЧНЫҢ «КЫРЫМ СОНЕТЛАРЫ»

Адам Мицкевич—полякларның бөек классик шагыйрьләреннән берсе, яна поляк шигъриятенә һәм әдәби теленә беренче башлап нигез салучылардан иде.

...Адам Мицкевич 1798 елның 24 декабрендә Новогрудка (хәзерге Белоруссиянең Гродно) шәһәренә якын булган Заосье утарында дөньяга килә. Шагыйрьнең атасы Николай Мицкевич урта хәлле бер жир биләүче алпавыт (шляхтачы) санала. Мицкевичлар гаиләсендә ирекка сусаучы поляк ватанпәрвәрләренең ганьганәсе (традициясе) әле бик көчле сакланып калган була. Мәсәлән, 1794 елда Тадеуш Костюшко житәкчелегендәге халык азатлыгы өчен көрәштә Николай Мицкевич үзе дә якыннан торып катнашлык иткән. Бу көрәш турыдан-туры Русь колониаль изүенә каршы юнәлтелгән була.

Мәктәп елларында ук инде Адам Мицкевичта туган поляк әдәбиятына карата тирән мәхәббәт хисе уяна. Ул Новгрудкадагы доминикан костелы каршындагы мәктәпне тәмамлагач, аларның гаиләсе Вильно шәһәренә күченеп килә һәм 1815 елда Мицкевич андагы университетка укырга керә. Студент елларында ул университет укытучысы Иоахим Лелевель лекцияләрен бик яратып тыңлаган була һәм соңыннан рухи яктан аның иң якын дусты булып китә. Лелевель исә үзенең барлык гомерен поляк халкының милли азатлык көрәшенә багышлаган ватанпәрвәрләрнең берсе санала. Аның житәкчелегендә, мәсәлән, Вильно университетында «Филоматлар жәмгыяте» белән «Филаретлар жәмгыяте» барлыкка килә. Мицкевич та бу яшерен революцион жәмгыятьләрнең фәгаль, ягъни актив әгъзасы булып санала.

1822 елда Вильно шәһәрендә Адам Мицкевичның беренче шигъри мәжмугасы басылып чыга. Бу китапка аның күренекле әсәрләреннән филоматлар гимны саналган «Адәм жырлары» белән «Яшьлеккә ода» шигыре дә урын алган була. Күп тә үтми, 1823 елда филаретларның оешмасы фаш ителә, ә Адам Мицкевич үзе төрмәгә ябыла. Аның бу оешмада әгъза булып торуын патша агентурасы дәлилли алмаса да, Адам Мицкевич Рәсәйнең караңгы бер губернасына сөргенгә сөрелә. Тик 1824 елда ул үзенә Петербургта яшәү өчен рәсми рәвештә рөхсәт алуга ирешә. Анда ул К. Рылеев һәм А. Бестужев кебек ирекка сусаучы атаклы декабристлар белән якыннан таныша. Ришелье лицеенда укытучылык итү максатыннан, А. Мицкевич Петербургтан Одесса шәһәренә юнәлә. Яңа эш алдыннан аңарда Кырымга сәяхәт ясау теләге туа. «Кырым сонетлары»—әнә шул тарихи сәяхәтнең бер жимеше буларак шагыйрь ижатында иң якты сәхифә калдыра. «Кырым сонетлары» Россия жирлегендә беренче тапкыр чәчмә рәвешендә тәкъдим ителүгә карамастан, укучыларда искиткеч зур тәэсир калдыра. «Ә асыл нөсхәдә инде тагын да гажәептер алар?»—ди В. Кюхельбекер үз язмаларында.

Ә инде безне Адам Мицкевич хәятенең турыдан-туры Кырым белән бәйле булган чоры нигә кызыксындыруы яхшы аңлашыла булса кирәк...

Шагыйрь гомерендә иң бай хәтирәләр уеп калдырган Кырым буенча сәяхәте асылда Севастополь шәһәреннән башланып китә. Ыгы-зыгыларга бай булган ямьле июль айларының жәйге иртәсендә бер төркем сәяхәтчеләр төялгән көймә Севастополь портына килеп туктый. Алар арасында үзенең чибәрлеге белән күз

явын алыр графиня—пани Каролина Собаньская белән аның ире, графиняның сөяркәсе генерал—пан Витт, аннары Бошняк атлы тагын бер билгесез кеше, Королинаның агасы—пан Генрих Ржевуский һәм, әлбәттә, үз иленнән сөрелгән һәм тарихның мәрхәмәтсез җилләре белән Кара диңгез ярларына килеп юлыккан ялбыр бөдрә чәчле 26 яшьлек Адам Мицкевич үзе дә монда була.

Хәзерге көндә инде Адам Мицкевичнын Кырымга сәяхәте шуннан биш ел элек Александр Пушкинның Кикинеиз, Чатыр-Даг таулары аркылы Гурзуфка, Алуштага һәм Ялтага шул ук тар сукмаклардан атта менгән килеш җилдереп үткән урыннар белән тәңгәл килүе яхшы мәгълүм. А. Мицкевич бар гомерен тоткынлыкта үткәргән хан кәнизәге турындагы Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» әфсанәсен (легендасын) дә яхшы белгән була һәм Мария атлы бу поляк кызына багышлап үзе дә «Потоцкаяның төрбәсе» исемле сонетын яза. Мәгълүм булуынча, нәкъ алтмыш ел вакыт үткәч, украин халкының атаклы әдибәсе Леся Украинка да үзенең «Кырым хатирәләре» әсәрендә бу әфсанәгә әйләнеп кайтып, Бакчасарайдагы хан сарае белән Бакчасарай төрбәсе турында үлемсез әсәрен язып калдыра.

А. Мицкевич гаять бай истәлекләр белән тулы Кырым сәяхәтеннән соң, 1824 елның көзендә Мәскәүгә юл тота. Берничә елдан соң анда Александр Пушкин белән якыннан танышу бәхетенә ирешә. Пушкин соңыннан бу турыда бик җылы искә алып, болай дип яза: «Ул үзенә бөтенләй ят булган безнең кавем арасында яшәде, эчендә безгә карата ачу-мазар сакламады һәм без дә аны яраттык. Ул басынкы, хәерхаһлы иде, безнең әңгәмәләрдә дә теләп катнашты. Без аның белән саф, эчкерсез хыялларыбызны һәм җырларыбызны да бергә бүлешә идек...» (Шигырь чәчмәдә бирелә. *Ред.*)

1826 елның декабрендә Мәскәүдә Мицкевичның «Сонетлар»ы нәшер ителә. Ә 1827 елның апрелендә, «Московский телеграф» журналында П. Вяземский тарафыннан чәчмәдә «Кырым сонетлары» тәрҗемә ителеп басыла. Үз тәрҗемәләренә язган кереш мәкаләсендә П. Вяземский шагыйрь турында менә болай дип белдерә: «Мицкевич сайлап алынганнарның иң яхшылары рәтенә керә, аның кебекләргә үз халыкларының әдәбият даны вәкиле хокукына ия булу кебек зур бәхет насыйп ителгән. Поляк шагыйре тарафыннан сайлап алынган шигъри калып һәм аңа тирән тойгылы тәэсирләрен кысып сыйдыруга ирешкән булуы үзе генә дә нәзакәтле бу сәнгать шәкеле шагыйрьне бер дә шүрләтмәгән булуын, чын шагыйрь өчен поэтик әсәрләр иҗат итүдә берниндә дә киртәләр вә чикләр юклыгын бише белән раслый булса кирәк. Бу сонетларны хәтта шигъри юл язмалары дип тә атап булыр иде. Байрон да үзенең «Чайльд Гарольд» поэмасындагы күпчелек строфаларны сәяхәтнамәсенә караган журналында нәкъ әнә шулай төзеде һәм поляк шагыйре сонетларыннан да кайберләрен бер дә икеләнмәстән инглиз шагыйренең иң яхшы шигырь юллары белән янәшә югарылыкка куярга мөмкин...»

Пушкин үзенең «Сонет» шигырендә, бу шәкел кебек искиткеч авыр жанрда иҗат итүче дөньякүләм күренекле шагыйрьләрнең исемнәрен телгә алганда, Данте, Петрарка, Шекспир һәм Камоэнслар белән рәттән Мицкевичны да искә ала:

Под сенью гор Тавриды отдаленной
Певец Литвы в размер его стесненный
Свои мечты мгновенно заключал...

XVI һәм XVII гасырларда беренче булып Кохановский, Анджей Морштын һәм башкалар тарафыннан поляк поэзиясендәге башлап җибәрелгән сонет шәкеленә Мицкевич яңадан җан өрде. Нәтиҗәдә «Кырым сонетлары», поляк шигърияты белән бергә, Мицкевичның үз иҗатында да яңа поэтик сүз буларак яңгыраш тапты. Сәмавиләрнең, ягъни романтикларның мәккәсе саналган Шәрык дөньясы Мицкевичның игътибарын үзе Вильнода чакта һәм соңрак Ковнода Гете вә Байрон әсәрләре белән якыннан танышканнан соң бигрәк тә нык җәлеп иткән була. Ул нәкъ әнә шул елларда үзенең «Ренегат» дигән балладасын иҗат итеп, Шәрыкка тирән хөрмәтен белдерергә өлгерә.

«Кырым сонетлары»н язганда А. Мицкевич электән үзенә мәгълүм булган чыганаклардан тыш, тагын кайбер яңа язмалар белән дә танышып чыга. Сонетлар соңында бирелгән искәрмә вә аңлатмаларга игътибар итсәк, без аның декабристлар хәрәкәтенең рухи атасы саналган И. М. Муравьев-Апостолның «1820 елда Таврида

буйлап сәяхәт» һәм ориенталист Сенковский хезмәтләрен, Гаммернын «Фарсы шигъриятенең сөйләм тарихы»н, Гетенең Шәрык темасына караган шигырьләрен бик тирәнтен һәм җентекләп алдан өйрәнгән булуына ипанабыз. Бер сүз белән әйткәндә, боларның барысы да «Кырым сонетлары» авторына искиткеч төгәл мәгълүматлар туплап, соныннан шуларга нигезләнеп ялкынлы хисләр белән сугарылган бай әдәби образлар, катлаулы поэтик тирән фикерләр галлереясен тудыруга шактый нык булышлык иткәннәр.

«Кырым сонетлары»нда Кырым табигате тасвирланганда, без анда чуар буяуларга бай Шәрык бизәкләреннән тыш, Мицкевич тарафыннан сәяхәтче-шагыйрь белән кырым татар морзасы арасында барган әңгәмәдә чагылыш тапкан «Шәрык акылы» хәзинәләренә дә хайран калабыз. Бу бигрәк тә «Потоцкая төрбәсе», «Чатыр-Даг» сонетларында үзенең якты чагылышын тапкан.

«Кырым сонетлары»ның башка халыклар телләренә һәм шул җөмләдән урысча тәрҗемәләре библиографиясен санап чыгу үзе генә дә бер дәфтәр тәшкил иткән булыр иде. «Кырым сонетлары»ның күп санлы тәрҗемәчеләре арасыннан без М. Лермонтов, А. Фет, А. Майков, И. Бунин, И. Козлов, В. Любич-Романович, О. Румер, В. Бенедиктов, К. Бальмонт, В. Крачковский, С. Соловьев, А. Кугушев, Н. Луговский, Н. Гербель, Н. Берг, И. Дмитриев һәм башка шуның кебек күренекле шагыйрьләрнең үрнәк булырдай уңышлы тәрҗемәләрен күрсәтә алабыз. Дөрес, А. Мицкевичның иң якын дуслары саналган Пушкин белән Боратынскийлар аның сонетларын тәрҗемә итмәгәннәр итүен, әмма алар поляк халкының бөек шагыйренә мәхәббәтләрен шигырьләре аша белдергәннәр.

«Кырым сонетлары» үзенә шулай бик күп шагыйрьләрнең игътибарын җәлеп итүнең төп сәбәпләреннән берсе шунда ки, алар барыннан элек шигъри яктан үзләренең югары әдәби зәвык белән иҗат ителгән булуына бәйле; икенчедән, бу сонетлар Җир шарының иң гүзәл почмакларыннан берсе саналган Кырым табигатенең сихри манзарасын үз эченә сыйдырганнар. Аларда Кырымның экзотик матурлыгы югары маһирлык белән сугарылган тулы канлы поэтик образларда үзенең җанлы вә тирән чагылышын тапкан. Адам Мицкевич сонетларының үзенә тарту көченең сере тагын шунда, ул кулланган уңышлы поэтик образлар үзләренең гадәти генә булмаулары, үз урынында файдаланылган троплар (метафора, метонимия, синекдоха, аллегория, гипербола, литота һ. б.), колоритлы буяуларның төрлелеге, билгеләмәләрнең нечкә вә төгәллеге, поэтик фикернең анык һәм кыска вә ачыклыгы белән аерылып торалар. Ләкин боларны татарча вариантында укучыларга сонетлар үзләре яхшырак сөйләп бирерләр дип әйтәсе килә...

1829 елда А. Мицкевич чит илгә чыгу өчен, ниһаять, үзенә рөхсәт алуга ирешә һәм май аенда инде ул «юылмаган Россия»не бөтенләйгә ташлап китә. А. Мицкевич бик күп илләргә сәяхәт ясый һәм 1855 елда рус-төрек сугышы дәвам иткән дәвердә, поляклардан торган легион оештыру максатыннан, Константинопольгә (Төркия) килеп юлыга, шунда тиф авыруыннан вафат була.

А. Мицкевичның «Кырым сонетлары» моннан 175(1825) ел элек язылган булуга карамастан, алар әле татарчага тәрҗемә ителмәгән. Бу юлларның авторы сонетларны тәрҗемә итүгә күпьеллык хезмәтен куйды һәм бүген аны татар укучыларына тәкъдим итүе белән бәхетле.

Адам Мицкевичның барлык сонетлары да турыдан-туры оригиналдан сүзгә-сүз, ягъни поляк теленнән адекват тәрҗемәгә нигезләнеп башкарылды. Безгә бу четерекле бурычны ахырынача башкарып чыгуда бүгенге көндә Кырымда яшәп иҗат итүче поляк шагыйре—Адам Мицкевич бүләге лауреаты М. Я. Тернавский белән Кырымдагы поляк мәдәни-агарту җәмгыяте рәисе пан Ю. Кравец ярдәм кулларын суздылар. Мин аларга рәхмәт сүзләремне җиткерәм.

**Әдхәт СИНУГЫЛ**

ഝ



# Адам Мицкевич

## КЫРЫМ СОНЕТЛАРЫ

### Аккирмән далалары

Йөзеп, чыктым сусыз океаннар иленә,
Биштәрем дә хәтфә үлән арасында
Шаулап үскән каракура[1] арбасында
Тибрәнә, гүя мәрҗән атавы җилендә.

Шәфәкъ батты... Шәйләмим юл, курганнарны,
Күктән эзлим юл күрсәткеч йолдызларны.
Җем-җем килгән еракларда—болытлармы?
Юк, Турла[2] бу... Аккирмәндә утлар янды.

Үле тынлык! Туктап тыңлыйм күктә очкан
Торналарны. Ут шытырдый—елан сыман...
Нечкә билле күбәләкләр куып очам.

Бу тынлыкта дулкынланам сәер шомнан.
Литвам миңа гел өн салыр кебек тоям.
Бер аваз юк... Юлны дәвам итәм шуннан.

### Диңгез тынлыгы

*Тарханкот биеклегендә*

Җилфердәп исеп иркә җил, байрак тибрәнә,
Кызына кояш нурында сулар култыкта.
Яшь кәләштәй чумып татлы хыял, шатлыкка,
Уяна да, тирән сулап, тагын тирбәлә.

Сугыш беткәч башын игән ал байраклардай,
Мачталарда җилкәннәр дә йокыга талган,
Кораб тора чайкалып—зынҗырда калган,
Юлчылар шат, матрос сакта—нәкъ маяклардай.

---

[1]Каракура—гади халык телендә ул «пәри арбасы» дип атап йөртелә *(Ә. С. искәрмәсе).*
[2]Турла—Днестр елгасы.

Диңгез! Синең әкәм-төкәм мәхлүгең—бар да
Җанланадыр һава аяз, тыныч торганда,
Үле тынлык саклый алар көн бозылганда.

Уйлар! Сездә хатирәләр еланы йоклый,
Бәла-каза, афәт купса, тыннары чыкмый,
Давыл тынса, агуыннан йөрәкләр сыктый.

## Йөзү

Шау-шу куба Диңгез казаны айкалып,
«Әзер булыгыз!» дип бирә берсе әмер...
Баскыч буйлап чаба чатыр-чотыр кемдер,
Үрмәкүчтәй үргән ятмәдә чайкалып.

Җилләр! Җилләр!.. Корабны дулкын очыра,
Бәргәләнә, чайкала, күбеккә бата,
Дулкын гаскәрен туздырып юлдан ата,
Җилкәннәре болыт явына очына.

Төпсезлек өстендә җаным күккә оча,
Хыялларның җилләрендә җилкенеп,
Кочак җәеп, барын шат елмаеп коча.

Кул изим мин буйсынмас ярсу корабка.
Күкрәгемә җилкәннәр өргән җил кебек
Җиңел шундый! Кошсыман очам канатта!

## Давыл

Җил ажгырып җилкән ава, штурвал чатный,
Диңгезчеләр кулыннан бар арканнар оча,
Үкерүче насосларның тесләре кача,
Баеп барган Кояш кына ышаныч саклый.

Давыл улап тантаналы ярга ыргыла,
Ташкындай кайный күпереп бар Диңгез иле;
Газраил да эшсез тормый, ул түгел тиле—
Канга сусап, әзер һәрчак ул җан алырга.

Берәү үлем хәлендә, берәве имгәнеп ята,
Дуслар белән бәхилләшеп кемдер чукына,
Тәңресеннән ярдәм сорап, кем нәзер әйтә.

Бер юлаучы өнсез калып читтә утыра.
Мондый чакта шул бәхетле: кем уйга бата,
Кем Ходайдан гафу үтенеп, дога укына.

## Кизләү далаларыннан таулар күренеше

*Сәяхәтче вә Морза*

**Сәяхәтче:**

**Кем? Алламы, кубарып диңгез бозларын,**
**Болытларда мәләкләргә Тәхет койган?**
**Гыйфритләрме Шәрыкка диварлар корган,**
**Буар өчен йолдыз кәрваны юлларын?**
**Ул нинди ут Күк илендә яна соң, ә?**
**Диңгезләрдә йөзгән адәм юлларында**
**Әллә Алла нур сибәме колларына,**
**Җиһан шәмдәлләреннән, төн карасында?**

**Морза:**

**Таныш җир ул... Туй итә анда чал кышлар,**
**Су эчә чишмә-инешләр ятып шуннан,**
**Аяк басмас хәтта анда тилгән кошлар.**

**Болытларның хәбәре юк мәңге аннан,**
**Патша итә фәкать монда яшен, ташлар...**
**Баш түбәмнән өстә йолдыз булып янган—**
**Чатыр-Даг ул!**

**Сәяхәтче:**

**—Ә-ә!!**

## Бакчасарай[1]

**Күркәм һаман, көл булса да Гәрәй ханнар!**
**Чәч белән җир себереп бил бөккән түрләр—**
**Шөһрәт тәхетләре, гыйш-гашрәтле җирләр**
**Чикерткә, көяләргә торак булганнар.**

**Тәрәзләргә яфраклар пәрдәләр корган,**
**Гөмбәзләрен, чаңлы диварларын урап;**
**Тудырганнарны адәм зиһене уйлап—**
**Вальтасар әмеренчә «хәрабә» кыйлган[2].**

**Хан Сараеның исән мәрмәр касәсе**
**Гыймәрәт уртасында чак торып калган.**
**Өзлексез күз яшь коеп хәрәм Чишмәсе:**

**«Ни калды,—ди,—мәхәббәт вә шөһрәт, шаннан?**
**Мәңгелек кебек иде сезгә барчасы,**
**Берегез юк... Мин һаман чылтырап агам.»**

---

[1]Бакчасарай —барлык яктан таулар бождрасы белән уратылып алынган үзән эчендә урнашкан бу шәһәр үз заманында Кырым ханнары саналган Гәрәйләрнең башкаласы булган. *(А. Мицкевич).*
[2]Вальтасар — легендар падиша. Пәйгамбәр Даниилдан., V. 5, 25, 27, 28. *(А. Мицкевич).*

## Төнге Бакчасарай

Азан моңы йотылып кичке бушлыкта,
Мәчетләрдән диндарлар кайта өйләргә.
Көмеш кияү[1] ашыга ары-төннәргә,
Офык йөзе кала нәкъ охшап якутка.

Күк хәрәмнәрендә шәмдәләр кабына,
Зәңгәр бушлыкта йөзә бер ялгыз болыт,
Күлдәге аккоштай ул йокыга талып,
Ак түшкәе саф алтыннан каела.

Манара, сәлбиләр шәүләсе һәркайда,
Әтрафларны камаган таш кыя таулар,—
Утыргандай шайтаннар Иблис алдында.

Кайвакыт, яшьнәп, бу таулар уяналар:
Җитез Фаристай[2] төн караңгылыгында
Буш кырлардан яшеннәр чәчрәп узалар.

## Потоцкая төрбәсе[3]

Яз илләре гөл багында төрбәң таптым,
Шул гөлләрдәй калгансың бик иртә шиләп!
Очкан ут күбәләгедәй янып-сулып.
Йөрәгемдә давыллы шомнар уяттың.

Шималь, Польшада да бихисап йолдызлар...
Бу тарафка ник алар күбрәк тезелгән?
Күзләреңнән—сүнәрдән алдын сибелгән—
Син яудырган нурлар түгелме ул эзләр?

Поляк кызы! Минем дә кан-яшьтә күзләр...
Эргәндә мин дә, уранып кәфен, ятыйм,
Сәяхәтчеләр мине дә кушып сөйләр.

Туган тел моңын тыңлап күңел юатыйм,
Сиңа багышлап чыгарса кемдер көйләр,
Минем төрбәмне дә көйләр—күреп якын.

[1] Көмеш кияү — айны күз уңында тота шагыйрь *(А. Мицкевич)*.

[2] Фарис —гәрәп бәдәвиләренең риваятьләрдә данлап җырлаган тиңсез пәһлеван *(А. Мицкевич)*.

[3] Хан Сараеннан бик ерак түгел бер урында Шәрык өслүбендә эшләнгән гөмбәзле төрбә бар. Кырымда халык арасында телдән-телгә сөйләнеп йөртелгән бер әфсанәгә (легендага) караганда, бу төрбә Кырым Гәрәе тарафыннан аның хәрәм сөеклесенә (кәнизәгенә) корылган ядкарьлек санала. Әйтүләренә караганда, тоткынлыкка сатылган бу әсирә польшалы Потоцкий династиясеннән булган, имеш. Декабрист Муравьев-Апостол үзенең «Таврида буйлап сәяхәт» атлы юлязмасында бу риваятьнең уйдырма булуын һәм әлеге каберлектә ниндидер грузин кызының (Тамара) дәфен ителгәнлеген яза. Без аның бу турыда нәрсәгә нигезләнеп язганлыгын белмибез. Шулай ук авторның XVIII гасыр уртасында татарлар Потоцкийлар кешесенең әсирлеккә төшерә алуына шик белдермәвен дә урынсыз дияр идем. Дөрес, Украинада казакларның баш күтәрүләре вакытында күп кенә кешеләр әсиргә алынып, татарларга сатып җибәрелделәр. Ләкин Польшада Потоцкийлар токыматын (фамилиясен) йөрткән шляхтачы нәселе кешеләре күпләп була. Шуңа күрә бу кызның Уман аксөякләре нәселенә карамавы да мөмкин, чөнки аларны татарлар вә казаклар кулына төшерү бик үк җиңелдән булмый. Халык риваятьләренә әсасланып, Бакчасарайдагы бу төрбә турында Александр Пушкин «Бакчасарай фонтаны»н язып чыга *(А. Мицкевич)*.

## Хәрәм каберләре

*Сәяхәтче вә Морза*

**Сәяхәтче:**

Алла табынына бик нык сайлап алган:
Бик яшь монда яшел йөзем җимешләре;
Монда Шәрык җәүһәр, мәрҗән, көмешләре
Мәңгелеккә вакытсыз йокыга талган.

Онытылу пәрдәсе билгесе булган
Таш чалмалар[2]—тезелгән гаскәрдәй монда.
Җуелмаган исемнәр калган һаман да—
Кабер ташларына хәттат язып уйган.

Сез—сылу җәннәт гөлләрен була аклап...
Тартынудан шилгән яфрактай төскә сез,
Кяферләр күзеннән һәрчак оят саклап.

**Морза:**

Туфрак булгач та көфер сүз ишетәсез:
Монда керткәнгә кяфернең яшен хаклап.
Пәйгамбәрем, зинһар, сез гафу итәсез!

## Байдар үзәне

Кызганмастан атым камчылап куамын:
Аяк астында калып мин чапкан чакта,
Урман, кырлар, таулар да чапкандай атта,
Җанга шуннан ярсып зур ләззәт табамын.

Уттай кызган ат җилә җилдәй ирektә,
Төн кәфененә чумган төсләр—күземә
Чагылгандай, бар да бер ватык көзгедә,
Урман, кырлар, әйләнә таулар өрәккә.

Җир йокыда... Минем күз генә тик ачык:
Суга чумам диңгез дулкыннарын кочып,
Баш иеп аннан мин кулым аңа сузам.

Баш өстемдә ургыла кайнар дулкыннар;
Әйләнчектә үземне ишкәктәй тоям,
«Батарсың»! дип бер мизгел туа шик, уйлар.

---

[1] Гүзәл гөл бакчасы эчендә зифа буйлы таллар һәм тат тирәкләре арасында ханнарның, солтаннарның вә аларның хатыннарының (ханымнарның), шулай ук аларның кардәшыруларының ак мәрмәр ташлы каберләре сакланып калган: үз заманында алар бик бай җиһазландырылган булсалар да, ике җимерек бина арасында торып калган бу каберләр хәзерге көндә тәмам хәрабә хәленә килгәннәр *(А. Мицкевич)*.

[2] Мөселман өммәтендәгеләр ир-ат вә хатын-кызлар дәфен ителгән урында төрле шәкелләрдә юнып ясалган таш чалмалар (кабер ташлары— Ә. С. искәрмәсе) куялар *(А. Мицкевич)*.

## Көндезге Алушта[1]

Таулар инде төн пәрдәсен аткан чөеп,
Алтын кырлар саба намазын әйткәндәй;
Дисбесеннән хәлиф[2] якутлар тарткандай,
Яшел чәчләрен тузгый урман баш иеп.

Ничек бирим чәчәкле кырларны сөйләп:
Күбәләкләр аллы-гөлле күлмәк кигән,
Җәйгор[3] күкне алмаз чатыр белән корган,
Саранча кәфен канатын атлый сөйрәп.

Диңгез эчендә ялангач таш бер кыя,
Ташып-кайнап дулкыннар монда пыр туза,
Юлбарыс күзедәй алар яныш куя.

Ачык диңгездә дулкыннар тыныч гизә,
Давыл алдыннан ярда кыямәт куба.
Аккошлар һәм кораблар коеныш йөзә.

## Төнге Алушта

Җиләс җилләр исеп, сүрелә эссе көн:
Чатыр-Дагка галәмнән шәмнәр нур сибә,
Җете кызыл очкыннар кабына, сүнә,
Адашкан юлчы тыңлый нидер, калып тын.

Таулар каралып, төнгә чумалар кырлар,
Төш аралаш чишмәләр килгәндәй телгә,
Чәчәкләр хуш ис аңкытып тирә-юньгә,
Үле тынлыкта саркый йөрәктә моңнар.

Әңгер-меңгердә дөнья йокыга талган:
Йокы кача метеор янгыннарыннан;
Үзән, таулар, күк йөзе алтынга манган.

Шәрык төне! Йокыга талыр алдыннан,
Кәнизәк кызларның чыкмый назы аңнан,
Йокым оча очкынлы күзләр угыннан.

## Чатыр–Даг[4]

**Морза:**

Тау итәкләрең үбәм ятып, Чатыр-Даг!
Кырым корабының син мәшһүр кальгасы,
Җиде кат күкләрнең Җиһан манарасы,
Барлык тауларга җирдә олпат падишаһ!

---

[1]Алушта — Кырымның иң гүзәл жирләреннән берсе санала; анда Шималь җилләре беркайчан да үтеп керә алмыйлар, шуңа күрә туристлар һәм ял итүчеләр хәтта ноябрь аенда да мәһабәт чикләвек агачы астында үзләренә җиләс урын сайлыйлар *(А. Мицкевич)*.
[2]Хәлиф — мөселманнарның югары дәрәҗәгә ия булган башлыгы санала *(А. Мицкевич)*.
[3]Җәйгор *(диал.)* — салават күпере *(күк кушагы)*.
[4]Чатыр-Даг — Көньяк Кырым ярларындагы тау тезмәләре арасында иң биек саналган тау исеме; ул бар тарафтан, хәтта 200 чакрым ераклыктан да, зәңгәр төстәге олпат бер болыт булып күренеп тора *(А. Мицкевич)*.

Күк капулары астында үзең калган,
Саклагандай Җәбраил[1] койнот[2] бакчасын:
Карурманнардан тегеп чапан япкансың,
Яшеннәр чигә телгәләп болыт чалмаң.

Кояш өтеп, саранча кырамы барын,
Кяфер безнең өйләрне уткамы яга,—
Чукрак гел син, кымшанмыйсың да һич аңа.

Җир белән ялгап төпсез Күк араларын,
Күк күкрәүләр, бәла-казаларны аңга
Кодрәтеннән дип гел тукыйсың Алланың.

## Сәяхәтче

Күз алдымда гүзәллек, муллыклар иле,
Баш очымда чалт аяз зәңгәр күк йөзе;
Кайда бакма, барының күркәм йөз, күзе,
Белмим нигә тартадыр йөрәк ят җирне.

Литва! Синең урманнар иде моңлырак
Салгыр[3] кызы вә Байдар былбылларыннан;
Якуттай бәдам вә инжир багларыннан
Миңа күпкә Төньяк тундрасы назлырак.

Ерак-еракларда туган җирләр калган;
Монда күпме «күктәге торна»лар[4] тарта...
Уйларымда юксынам тик: мин яшь чакта

Саф йөрәктә серле хыял булып янган,
Керсез сөйгән мәхәббәтем кайтмас якта,
Бәлки анда юктыр хәтта искә алган?

## Җөфүт каланың упкынлы юлы[5]

*Морза һәм Сәяхәтче*

**Морза:**

Кулыңнан тезгенне җибәр, укын, чукын!
Упкынны күз шәйләүдән тоя ат монда[6].
Җайдак җаны ат тоягы кулларында,
Тез бөкләп тояр тояктан ул яр читен.

---

[1] Җәбраил *(Гавриил)* —һәркемгә таныш исем булган Җәбраил атын калдырам; әмма, ләкин, риваятьләргә караганда, күктәге йолдызлар (Арктура йолдызлыгы) сакчысы булып Рамег— Ас семекеин саналса да *(А. Мицкевич)*.

[2] Койнот — космос.

[3] Салгыр - елга исеме; аның башлангычы Чатыр-Даг тавындагы чишмә суларына барып тоташа *(А. Мицкевич)*.

[4] «Күктәге торна»лар— кызыктыргыч буш хыяллар мәгънәсендә.

[5] Җөфүт кала—биек кыялар өстендә корылган кадим заманнарга караган Кырымдагы бер шәһәрчек; кыялар читендәге өйләр монда карлыгач ояларын хәтерләтәләр; тау читенә килеп терәлгән юл сукмагы гаять тә һәлакәтле *(А. Мицкевич)*.

[5] Кырым атлары үтүе кыен булган хәвефле урыннарда гаять зур сизгерлек вә сакчыллык күрсәтәләр; атлап йә сикереп үтү мөмкинме, түгелме икәнлеген чамалау өчен ул атлар башта аягын күтәргән хәлдә тоягы белән ташны яисә җирне капшап карарга өйрәнгәннәр *(А. Мицкевич)*.

Ат ыргылды! Күз ата күрмә упкынга.
Кулың канат түгел синең, кулың сузма;
Төпсез уйларга, абай бул, ирек куйма,
Ир булып кал, үзеңне-үзең ал кулга.

Перун төсле төпкә батмаган каектай,
Уең калыр ыргакка эленеп чүптәй,
Тирәнлеккә тартылган каек хәлендә.

**Сәяхәтче:**

Ә мин, морза, упкынга бактым ярыктан!
Мин күргәнне күз күрер фәкать ләхеттә,
Аңлатмалар юк моңа гавам телендә.

## Кикинеиз тавы

**Морза:**

Упкынга бак: күк белән япкандай дөнья;
Кош тавы да шунда ук, «Сәмруг кош»[1] атлы,
Диңгез җилкәнедәй ул каурый канатлы,
Салават күперенә хас бу таш кыя.

Су өсләрен кар атавы сарган аста,
Бушлыкларда йөзгән шул болыт атавы—
Төн яудырып ярты дөньяны каплады,
Каегында, күр, аның ни—утлы тасма?

Яшен тасмасы ул! Бераз ял алгач,
Каршымда торган упкыннан атым ыргыр,
Син дә минем арттан шуңа әзер булгыл.

Каурый күрсәң күздән мин югалып калгач,
Күз ачып бак: ул минем баш чалмам булыр,
Күрмәсәң, бу юл—җәһәннәмгә юлыгыр!

## Балыклавыдагы кирмән хәрабәләре[2]

Хәрабәгә әүрелгән гөлдәй кирмәннәр,
Сине дә саклаганнардыр алар, Кырым!
Хәзер бу җирләр инде ташландык урын,
Баш сөяген калдырган монда чын ирләр.

[1] «Сәмруг кош»—«Мең дә бер кичә» исеме белән күпләргә мәгълүм булган гарәп халык риваятьләрендә Шәрык шагыйрьләре тарафыннан күп тапкырлар тасвирланган Сәмруг исемле бу кош тау кадәрле олпат, кирмән (крепость) кебек ныклы һәм ул хәтта тәпиләренә эләктереп филне дә күтәреп китә ала дип күрсәтелә Фирдәүсинең «Шаһнамә» дастанында *(А. Мицкевич)*.
[2] Юнаннар (румлылар) тарафыннан корылган кала; соңыннан генуэзлылар бу урында Сембало шәһәрен корган булалар *(А. Мицкевич)*.

Кирмән башында кайбер ядкарьләр калган,
Каһарманнарның аты—туграда язган;
Хәтерләтә алар сугышларны һаман,
Йөзем яфраклары барын чолгап алган.

Бизәк уйган диварларга монда юнан;
Румлылар монголга мәгъдән яудырган,
Намаз укып Мәккә кунагы моңланган.

Ис тоеп бүген җәрәхәт, яралардан,
Зират өсләп козгыннар очалар моннан,
Матәм байрагы җилферди манарадан.

## Аю-Даг

Аю-Дагтан, яратам, багып ярларга,
Кара дулкыннар биюен мин карарга,
Кар-бураннар алар туздырган арада,
Салават күперләре уйный аларда.

Кыйпылчыкларга парчалап сай җирләрне,
Кит гаскәредәй камый дулкын ярларны,
Коры җирне яулагач дулкын яулары—
Чигенәләр, чәчеп энҗе, мәрҗәннәрне.

Шагыйрь йөрәгендә дә дулкыннар куба,
Анда да баш бирмәгән гыйсъяннар туа,
Илһам килсә, беразга йөрәге тына.

Кайбер җырлар дучар мәңге онтылуга;
Ә кем үлемсез җыр тудырып үлә,
Шул җырыннан гасырлар аңа таҗ үрә.

Полякчадан **Әдхәт СИНУГЫЛ** тәржемәләре.
*Кырым—Симферополь.*

**Рифат Сверигин**

# ҮТКӘН ЕЛ ПРОЗАСЫНА БЕР КАРАШ

Бер автор: «Биш йөз битле роман язган идем, инде өч ел көтеп йөрим, әсәрем турында бер кәлимә сүз ишеткәнем юк—бер җөмлә фикер, бәя әйтеп, язып чыкканнары юк», дип зарлана икән... Бичаракай, әсәрне күрмәмешкә салышып үтү—үзе тәнкыйтьнең бер формасы икәнлеген анламый торгандыр шул ул. Тик шунысын да искәртик: дәшмичә калып тәнкыйтьләү позасына нормаль тәнкыйте булган әдәбият кенә баса ала. Әлегә безнең җәмәгатьчелектә исә әдәби тәнкыйтьнең «дәшми калып тәнкыйтьләү» дәрәҗәсенә менеп җитә алганы юк. Шуңа күрә теге мескен, зарланучы агаебызның да хәленә керәсем, борчылуын уртаклашасым килә. Прозада авторларыбызның күбесе бүген шул агай хәлендә.

Бездә өем-өем хикәяләр, тыгыз сынлы повестьлар, кирпечтәй нык романнар тиешле бәяләрен алалмыйча тарих төпкелләренә кереп югалалар икән, моңа һәрвакыт аларның сыйфатсызлыгы түгел, ә үзебезнең күңел сукырлыгыбыз, тәнкыйтьнең ифрат та ялкаулыгы, оеганлыгы гаепле.

Үткән 1999 ел бүләк иткән проза әсәрләрен җыеп, туплап, колачлап алырга тырыштым, тик колачым җитмәде. Бу—чиксез зур байлык икән. Тәнкыйть дигәнебез ел дәвамында аның уннан бер өлешен дә бәяләргә өлгермәгән әле. Барысын да үзең карап чыгасы. Без—элеккеге белгечләр—әсәрләрне аерым киштәләргә урнаштырып, системалаштырып өйрәнергә күнеккән халык. Хәзер мәсьәләнең бу ягы да кыенлашты. Мәсәлән, жанрлар буенча өйрәним дисәң, жанр дигәнебезнең элеккеге чикләре шактый ук юылган, хәтта югалып ук бетә язганлыгы беленә.

Журналларыбызның кайберләре, нәшриятларыбыз (мәсәлән «Идел» журналы, Татарстан китап нәшрияты) әсәрнең исеме җисеменә муафыйк булырга тиешлеге хакында бигүк баш ватып тормыйча, жанр атамаларын башкачарак куярга керештеләр. Нәсер, бәян, кыйсса төшенчәләре янадан бик актив кулланыла башлады. Тик алар һәр очракта да традицион төшенчәләргә туры килеп бетәме? Әллә башкачарак мәгънәләрдә кулланыламы? Һәрхәлдә әлеге мәсьәлә китап сөючеләрдә, бигрәк тә әдәбият теоретикларында, яна сораулар уята: мәсәлән, Нәбирә Гыйматдинова бәяннары урта гасырларда киң таралган бәяннардан кайсы яклары белән аерыла, яисә Нияз Акмал кыйссалары Кол Галинең мәгълүм кыйсса традицияләрен дәвам иттерәме? Кайбер басмалар исә язмаларның жанрларын билгеләү белән мәшәкатьләнмичә, «әсәрдән өзек», «күләмле әсәрдән өзек» дип кенә котылалар (мәсәлән «Аргамак» журналы).

Кыскасы, бу мәсьәләгә бераз ачыклык кертәсе иде. Әлбәттә, яңачарак иҗат итү, жанрларны үзара кушу, аралаштыру тенденциясе әдәбиятның үз эчендә дә көчәеп килә. Прозаикларның фикерләве эссе дип аталган катнаш жанрга таба һаман авыша, тартыла

бара. Монысын да онытмыйк. Тик, шулай да, мәсьәләгә бөтенләй үк кул селтәмичә, әдәбият балаларына үз исемнәрен кушып, якты дөньяга чыгарып җибәрәсе иде.

Бәхеткә каршы, жанрларның классик бүленешләрен санга сугучы басмаларыбызның да яшәп торган көннәре. «Казан утлары», «Мирас», «Сөембикә» кебек журналлар жанрларны, жанр формаларын элек кабул ителгән мәгънәләрендә, төгәл атарга тырышалар. «Казан утлары» һәм «Мирас»ның еллык төпләмнәрен актарганда мин үзебезнен классик әдәбиятыбыз традицияләренә никадәр сусаганлыгымны, мохтаж икәнлегемне тойдым. Сусаганыма суны да бик тиз таптым: Әмирҗан Моталлаповның «Нигез» исемле кечкенә генә повесте шулкадәр җылы, ипле, бигрәк тә картларның күңелләрен күтәрерлек итеп язылган. Туган нигезен кайгыртып, авыл җирендә үзенә ямь табып көн итүченең хәлләрен автор Хисмәтулла карт образы аша бик матур тасвирлый алган. Бирелә аталар һәм балалар арасындагы мәңгелек проблеманың да үзенә күрә җайлы гына, идиллик яисә идеаль чишелеше табылган. Шәһәргә барып, йортка кергән авыл малае Исхакның әсәр ахырында хатынын—шәһәр кызы Алсуны—авылга, үзенең туган нигезенә алып кайтуы да ышандыра хәтта. Кешеләр гел шул Хисмәтуллалар, Исхаклар, Алсулар кебек булсаларчы!.. Язучы конфликтларны унайга хәл итә, булганнарын катлауландырмый, яналарын эзләп тормый, бу әсәрдәге күпне күргән авыл кешеләренең төпле, нигезле эш-гамәлләреннән ниндидер ышаныч, көч алгандай буласың.

Үтеп киткән ел тема-проблемалар җәһәтеннән генә түгел, сюжетның мавыктыргыч көче, образлылык, сурәтлелек, фикер тирәнлеге ягыннан да бер-берсенә охшамаган кызыклы проза әсәрләре бүләк итте. Камил Кәримовның «Ком сәгате», Марат Әмирхановның «Тәкъдир», Флүс Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет», Зәки Зәйнуллинның «Агыйделнең аръягында» романнары, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Атилла» исемле тарихи романы, Барлас Камаловның «Дөмбер Даниял», «Дулкынлана хәят», Нур Әхмәдиев, Мансур Вәлиев, Әсгат Салих, Фирдәвес Закир, Госман Гомәров, Вакыйф Нуруллин повестьлары, Радик Фәизовның хыялый повесте, Гариф Ахуновның документаль повестенең соңгы өлеше, Айдар Хәлимнең кечкенә романы моны раслап тора. Журналларыбызда шулай ук Мөхәммәт Мәһдиев, Әнәс Галиев кебек әдипләребезнең беркадәр элегрәк иҗат ителеп, бүген дә бик актуаль яңгырый торган әсәрләре дөнья күрде.

Болар бөтенесе ир-атларыбызның олы казанышлары. Ә хатын-кызларыбыз кайда соң? Алар—әсәрләрнең үзәгендә, әдәби героинялар рәвешендә авторларыбызны гел дәртләндереп, рухландырып торганнардыр дип ышанасы килә. Һәм мона нигез дә юк түгел. Камил Кәримов үзенең зур романын кисәкләргә бүлеп, әсәрнең һәр бүлеген бер чибәркәйнең исеме белән атый: Зөмәйрә, Фәризә, Әлфинә, Суфия, Хәмдия, Дinә, Язилә... Хәмдия белән Суфиядан башкаларының әлегәчә әдәбиятыбызда күренгәннәре юк иде сыман... Хикмәт исемнәрдә генәмени соң? Аларның һәркайсы образ буларак та яңача күренә. Шулар белән кат-кат очрашкалап йөри торгач, саллы гына романны укып бетергәнеңне сизми дә каласың. Чыннан да, мәхәббәт эпизодлары әсәргә ниндидер бер өстәмә ямь биреп тора.

Язучы Марат Әмирханов та «Тәкъдир» исемле романында хатын-кызларны бер дә күз уңыннан ычкындырмый һәм без наданнарны шушы мәсьәләдә шактый мәгълүматлы итә:

«Хатын-кыз ир-атка караганда гөнаһлырак икән.—Әмма әйбәтрәк—һәм әйбәтрәк, һәм гөнаһлырак. Ул хәйләкәр пәри заты да икән. Хатын-кыз—ләлә чәчәге кебек нәзберек зат. Ана бик саклык белән генә, иркәләп кенә кагылырга кирәк».

Тора-бара әсәрдә бәхәслерәк, хәтта бөтенләй шик уята торган урыннар да очрый башлый:

«Хатын-кыз ир-егетләрне юлдан яздыру өчен яратылган зат. Беренче гөнаһны да хатын-кыз кылган (?!)... Ана кадәр гомумән гөнаһ дигән төшенчә булмаган. Хатын-кызның бөтен килеш-килбәте, бөтен гамәле: кием дә, сөйләме дә, үз-үзен тотышы да ир-егетләрне яулап алу, кулда тоту максатына юнәлдерелгән. Аның күңелендә һәрвакыт шайтан ята...»

Шулай да Марат әфәнде белән бәхәскә керергә ашыкмыйк—бу бит аның героеның—Мансурның фикерләре. Героена карап—чамасы дигәндәй... Әсәрнең ахырына таба язылыш тоны бик нык үзгәрә—ул тетрәндергеч зур фаҗига белән тәмамлана: Мансур сөекле баласын—кызын һәм хатынын югалта. Бу хәл геройга

карата тәкъдир хөкеме генә түгел, автор хөкеме кебегрәк тә яңгырый.

«Тәкъдир» романында тормышның автор үзе бик яхшы белгән башка яклары да шактый тулы яктыртыла: мәктәп, уку-укыту, туган телебезне саклау, медицина проблемалары, журналистлар, зыялылар тормышы—боларны яктырту эшенә теләсә кайсы язучы тотына да алмый—бу дәрьяларда Марат Әмирханов суга җибәрелгән балык кебек йөзә. Тагын бер шигебез бар икән алай да: автор үзе маһирлык күрсәткән өлкәләрдәге бар тәҗрибәсен шушы бер әсәргә дыңгычлабрак урнаштыру белән дә шөгыльләнмәдеме икән? Әле без бит романдагы шушы дебютыннан соң, бу тәҗрибәле шәхеснең каләменнән яңа башка әсәрләр төшүен дә көтеп калабыз.

Язучы Флүс Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет» дип исемләнгән романы да—интеллектуаль проза дип аталган тармакның бер чагылышы. Андыйларны заман романы дип тә атыйлар. Вакыйгаларны бәйләү алымы бик үзенчәлекле: элеккеге «Идел-Урал» яшьләр оешмасының сәркатибе Әмирҗан Акчура, совет армиясе солдаты Хафиз Сабиров һәм махсус бүлек майоры Гыймаев 1945 елда Чәнчүн шәһәрендә очрашканда өчесе өч вазифа башкаралар.

Һәм менә шул кешеләрнең балалары 1972 ел җәендә Казанда, шәһәребезне шаулаткан Америка күргәзмәсендә очраша. Аларның берсе Нью-Йорктан күргәзмәне алып килгән, электрон җиһазлар буенча эксперт Илдар Акчурин, икенчесе Казан фәнни-тикшеренү институтларының берсендә эшләүче фәнни хезмәткәр Сирин Сабиров, һәм өченчесе—аларны карап, мәгълүматларны тиешле оешмаларга җиткереп йөрүче елгыр егет Дамир Гыймаев була.

«Алар өчесе өч сыйфатта иде һәм, табигый ки, араларында дустанә мөнәсәбәт була алмый иде. Инде менә 27 елдан соң аларның балалары изге Казан туфрагында. Алар да бүген өчесе өч сыйфатта. Ләкин аталарының кайчандыр очрашулары хакында белмиләр һәм кайчан белүләре дә икеле. Дөнья дигәнең шундый сәер һәм катлаулы инде ул.»

Әсәрнең нигезенә әнә шундый чын роман ситуациясе салынган. Ул уйлануган, анализлап укучан китап сөючеләргә атабрак язылган. Дөньялар үзгәрә-үзгәрә, дип сөйлибез—шулаймы икән соң? Дөрес, бу 1945—72 еллар арасы. Ә тоталитар режимнан демократик дип аталганына күчкәндә нинди үзгәрешләр булды? Һәм бу үзгәрешләр кем файдасына бара? Гади халык файдасынамы? Флүс Латыйфи укучыны тирәнтен уйландыра торган әсәр иҗат иткән.

Нур Әхмәдиевнең «Амбирак яки Кара каен кыйссасы» повестен, исеменнән үк бераз шикләнеберәк, шомланыбрак кулыма алдым. Артык шомланасы да, шикләнәсе дә булмаган икән. Бу исем үзе хикмәтле генә деталь, җыр, фольклор детале булып чыкты:

Амбирактин, җамбирактин
Кияү килә җырактин...

Яисә менә тагын бер җырулы сурәт:

Каенның каралары,
Ник язмыш араланы?
Көне-төне тынгы бирми
Йөрәгем яралары...

Текст буенча сибелгән әнә шундый халык җәүһәрләре вакыйга-хәлләргә үзенә бер төрле кабатланмас ямь биреп торалар. Гомумән, бу әсәрне әсәр иткән әйберләр—әнә шундый сагышлы лирик детальләр. Кешеләргә кайгы китерүче кара каен сурәт-детале повесть дәвамында күренеп килә, ул бәхетсез-сагышлы мәхәббәт вакыйгасына-тарихына әверелә һәм әсәрне мавыгып, монсуланып, хәсрәтләнеп укырлык итә. «Амбирак...»ның тагын бер матур ягы бар: автор Себер татарлары тормышын, сөйләшен, гореф-гадәтләрен бик яратып, нечкәләп, ышандырып сурәтли, моның белән шул төбәктә яшәүче кардәшләребезгә, аларның тел-шивә үзенчәлекләренә ихтирам һәм хөрмәт уята.

Тел турында сүз чыккач, телнең яңгырашына, мәгънәсенә бик талымлы, һәр җөмлә-фразага мәгънә салып яза белүче каләмдәшләребезнең күп булуларына сөенүемне дә әйтеп узыйм: Мәгъсум Хуҗин, Барлас Камалов, Фәнис Яруллин, Гариф Ахунов, Зәки Зәйнуллин, Айдар Хәлим кебек әдипләрдән яшь язучыларыбыз күп нәрсәләргә өйрәнә алыр иде. Андыйларның әсәрләре сүзгә экономияле, тыгыз мәгънәле

һәм тәэсирлеләр. Мәгъсум Хужинның «Кангый иләндә», Барлас Камаловның «Дөмбер Даниял», Айдар Хәлимнең «Татар вакыты»—әнә шундый тәэсирле тел байлыгын, фикернең мәгънәле җегәрен бергә кушып, бергә тукып эшләнгән, әдәби-эстетик магнит кырларын бер тирәгә туплаган әсәрләр.

Барлас Камаловның «Дөмбер Даниял», Айдар Хәлимнең «Татар вакыты», Камил Кәримовның «Ком сәгате» әсәрләрендә әдипләр: «менә, укучым, менә ул синең бүгенге тормышың, бүгенге халәтең, менә син кая омтылган идең дә, кая барып җиттең?» дип, безне, якабыздан эләктереп, хәзерге дөнья нәҗесен үзебезгә иснәтәләр, күрсәтәләр... Һәм бик дөрес эшлиләр. Алар дөньяларның кая таба баруын күреп, тетрәнәләр һәм безне дә тетрәндереп, тиешле нәтиҗәләрне ясарга ашыктыралар.

Әйләнә-тирәбездә Дөмбер Даниял кебек үз рәхәтен генә кайгыртып яшәүчеләр тулып ята. Без аларны күрмәмешкә генә салышып үтәбез.—Ачыйк күзләребезне, дөнья ич бу! Үзебез дә шул Дөмберләргә әйләнеп бармыйбызмы?..

Барлас Камалов заман чирләренең ничек барлыкка килеп, формалашуын һәм азуын күрсәтеп, шуның анатомиясен ачып бирә алган.

Айдар Хәлим укучы күнелен аяп, кызганып торучылардан саналмый. Бу—аның явызлыгыннан түгел, ә тормыш рәхимсезлеген, үзенең шуннан ризасызлыгын әдәбисәнгать чаралары аша укучыга җиткерә белүеннән килә. Дөньялары нәрсәгә әйләнде бит!.. Әнә, заманында гомерен, җанын аямыйча, кешелек бәхете өчен көрәшкән, сугышта сәламәтлеген югалтып, күзләре сукырайган Мотаһар Чанборисовны картлык көнендә нинди хәлгә төшергәннәр!.. Аның караңгы, тынчу, пычрак бүлмәсе дә, туганлык хисләрен генә түгел, инде соңгы кешелек сыйфатларын тәмам җуеп бетергән якыннары, балалары да, кырык ел үткәч, медаль биргән булып, комедия уйнап йөрүче формалист-чиновниклар да—тормышыбызның түбән һәм ямьсез якларын гәүдәләндерүче тәэсирле сурәтләр булып җанланалар.

«Татар вакыты»—кечкенә роман дип исемләнгән, бәхәсләшә алмыйм—бу шулай дөрестер дә, чөнки бу кечкенә генә әсәргә, чыннан да, роман җегәре тупланган. Мотаһарның үткән юлы—ул роман юлы. Ә без—шул юлның фаҗигале тәмамланышының шаһитләре. Кеше кадерен белмәгән җәмгыятьтә бу очраклы түгел, ә логик финал. Әсәр нигездә геройның уйлануларыннан, бәяләүләреннән тора—коммунистлар җәмгыятен һәм бүгенге демократик җәмгыять дип аталган режимны чагыштыру рәвешендәрәк эшләнгән. Боларның һәр икесен дә ветеран үзенчә бәяли, үз нәтиҗәләрен чыгара.

Мотаһардан тыш әсәрдә тагын бик кызыклы образлар—вакыт һәм стенага эленгән борынгы сәгать образлары бар. Алар безгә Мотаһарның газаплы хәлләрен, кичерешләрен һәм заман агышын анларга булышалар. Әсәрнең ахырына якты сызык, яктылык нуры булып, күршедә генә яшәүче татар малае Заһир образы килеп керә. Ул Мотаһарның әле күнеленә бөтенләй үк әшәкелек оялап өлгермәгән оныгы Вадимга да унай йогынты ясый башлый. Бу—укучы күнелендә дә урнаша башлаган күнелсезлек, төшенкелек, өметсезлек кебек нәрсәләрне юкка чыгара. Җыеп әйткәндә: Айдар Хәлим үзендәге гаделлекне яклау, милләтпәрвәрлек идеяләрен бу әсәрендә шактый көчле әдәби чаралар ярдәмендә бирә алган.

Гариф Ахунов 1999 елда Тимерхан Борһанов турындагы документаль повестен, ниһаять, тәмамлап, очлап куйды. Әсәрдә гомерен халыкка багышлап, чын кеше булып кала белгән шәхес үзенең тормышчан сыйфатлары аша шактый тулы яктыртылган.

Арча ягының тагын бер талантлы язучысы Радик Фәизов әле күптән түгел генә укучыларны «Ике әни» исемле кызыклы повесте белән куандырган иде. Ә үткән елны бу автор «Тәнре хөкеме» исемле хыялый повестенда безне яна идеаллары, цивилизация иярткән яман чирләр белән бозылмаган күркәм һәм тигез кешелек җәмгыятенең прообразы белән таныштырды. Әдип хыялында гына ясалса да, мондый гадел җәмгыятьне бик тансыклаганбыз ахры: әсәрне укыганда Радик Фәизовның шул кара урманнарында гөмбәләр, поши итләре генә ашап, гадәти киемнәребез урынына өсләребезгә поши тиреләре генә ябынып, телевизорсыз, трамвайсыз көн итәсе килә башлый—гаделлек бәрабәренә барына да түзәр идек!

«Агыйделнең аръягында» исемле публицистик-тарихи романында аның авторы Зәки Зәйнуллинны гадәти роман төзү алымнары—төзек сюжет, уйлап чыгарылган вакыйгалар әзлеклелеге кызыксындырмый—бәлки шуна күрә дер, автор чәчмә әсәрне иҗат итүнең аерым бер төре, яисә мәгълүм ысуллары белән генә чикләнми дә. Әсәрнең

роман-кыйсса дип аталуы да юкка гына түгел. Чыннан да, биредә «кыйсса» сүзенең традицион мәгънәсендәге тормышны инләп алу сәләте, кинлек, эпиклык сизелеп тора.

Әсәрне башлаганда автор үз алдына нинди төп иҗат һәм гражданлык максаты куйганлыгы хакында да ачыктан-ачык әйтә: «...татарның фаҗигале, катлаулы, данлыклы, сатлыклы, белемле, динле, денсез, изелеп онытылган тарихын барлап, сирәк-мирәк кенә сакланып калган энҗе бөртекләре кебек истәлекләрдән күрәшче, игенче, сугышчы, галим, диндар, сәүдәгәр, сәяхәтче, иманлы Казан татарларының данын, горурлыгын торгызып, үзебезне тагын бөек, көчле халыклар сафының иң алдына бастырырга кирәк.»

«Агыйделнең аръягында»—әнә шул олы максатка бару юлында ясалган бер адым. Язу алымнарын да автор алдан ук үзе билгеләп куйган: «...роман-кыйсса документларга нигезләнеп тә, күбрәк булган хәлләргә, риваятьләргә таянып та язылды». Шуның белән бергә, без Зәки Зәйнуллинның гадәти кабинет елъязмачысы түгеллеген дә яхшы беләбез. Кирәк булганда, ул үзендәге хөр һәм кешелекле гражданлык һәм милләтне яклау сыйфатларын, шәхси тормышы тәҗрибәсенең байлыгын, философик һәм художникларча образлы фикерләү сәләтен эшкә җигә—шулар ярдәмендә шактый киң тармаклы, зур әсәрне бер эзгә салып, берләштереп, язып, башкарып чыгуга ирешә. «Агыйделнең аръягында» кыйссасының «Учител тавы» дип аталган беренче өлеше югарыда әйтелгәннәрне раслап, алда булачак матур ачышларга өметләндереп тора. Биредә әдип җанына якын кечкенә ватаны—Башкортстанның көньягында җәйрәп яткан Эстәрле буйлары, аның бай, фаҗигале тарихы, затлы, абруйлы кешеләре—данлыклы Тукаевлар нәселе, Акмулла, Мирсәет Солтангалиев кебек тарихта билгеле шәхесләре белән төрле яклап таныштыра, тасвирлый, аларны укучының күңеленә якынайта. Гомумән, бу авторның әсәрләре информация, мәгълүмат муллыгы, янәча күзәтүләр байлыгы, үзенә бер төрле эчкерсезлек, фикер хөрлеге һәм кыюлыгы, теленең халыкчан гадилеге һәм матурлыгы белән аерылып тора.

Язучы Әхәт Гаффар үз иҗат стихиясенең бер-берсенә үзара ярашып бетмәгән, хәтта капма-каршы куелырлык ике төрле хасияте белән гаҗәпләндерә. Шуларның берсе—әйтергә теләгәннәрне халкыбызның үз телендә, бу телнең, сөйләмнең иң нечкә нюансларын, борылышларын саклап, кадерләп, оста эшләнгән аңлаешлы әдәби образлар ярдәмендә укучыга җиткерү. Ә икенчесе—әйтәсе фикеренең очын, эзләрен буталчыкландырып, күз күрмәгән, колак ишетмәгән яна сурәтләр уйлап чыгарып, яисә шуларның үрнәкләрен дөнья әдәбиятыннан үзләштереп, җыеп, үзгәрткәләп, шуларның бөтенесен болардан бигүк хәбәрдар булмаган укучы алдына кинәт кенә китереп аударып, тегене шаккатырып, зиһенен бер мәлгә томалап, өнсез итү...

Мисалларын бик еракта эзләп йөрисе дә юк. 1999 елны дөнья күргән «Богау» исемле китабына әлеге тезисларыбызның беренчесен раслардай бик матур хикәяләре һәм «Дәрья башы» исемле яхшы повесте белән бергә шул җыентыкка исем биргән яна романы да янәшә урнаштырылган. Минем үземә «Богау» романы хәзерлексезрәк укучыны бик тиз аяктан ега торган, гадәти тормыш күренешләре белән алыш-биреше бик аз булган образлар шыплап тутырылган әсәр кебегрәк булып тоелды. Мәсәлән, чәчү вакытында басуда шайтан өермәсенә элэгеп, кыл урталай (?!) ярылган тракторны һәм чәчкечне күз алдына китереп бастыра алмыйча интектем. Аннан соң әсәргә көтүләре белән шүрәлеләр килеп керәләр. Мина калса, соңгы еллар татар әдәбиятында бу җан ияләренә булган кытлыкны Туфан Миңнуллин, Фәнис Яруллин кебек әдипләребез хәтсез генә киметкәннәр кебек иде инде. Әхәт Гаффар шүрәлеләре дә эпизодик, очраклы затлар гына түгел. Алар бөтен әсәр буенча үтәләр һәм ниндидер конкрет эстетик функцияләр дә башкаралар... Дөресен әйткәндә, әлегә мин аларны аңлап та, кабул итеп җиткерә дә алмадым. Һәм моның өчен авторны гаепләргә ашыгырга кирәктер, дип уйламыйм... Чөнки мин әлеге фикерләремне бераз консервативрак традицияләрдә, реаль, тормышчан әдәбият рухында тәрбияләнгән укучы буларак кына әйтәм.

Чыннан да, гел реалистик позицияләрдән генә торып эш иткәндә модернистик, иррациональ яисә сюрреалистик пландагы әсәрләрне объектив бәяләү—кыенрак эш. Шулай да бер әйберне шәйләдем: Ә. Гаффар бүгенге көн укучысына гына исәп тотып язмый ахрысы—бәлки бу иҗат туып килә торган яңа гасыр әдәбиятчылары тарафыннан дөресрәк бәяләнер. Ә минем үземә бу талантлы әдипнең минем күзләрем житәрдәй

офыклардан читләшеп, китеп югала баруы кызганычрак булып тоела.

Ничектер, әлегә кадәр язучы Камил Кәримовның сүзләренә, җөмләләренә нәкъ тиешле мәгънәне салып, матур әдәби сурәтләр тудыра белүче, шактый ук тәҗрибәле әдип икәнлеген белмичәрәк йөргәнбез икән. Ул бит моннан элегрәк тә әйбәт кенә повестьлар иҗат иткән. Күрмәгәнбез. Күренер өчен «Ком сәгате» романы кирәк булган икән. Әсәрдә һәр абзац саен диярлек кечкенә-кечкенә, өр-яңа, таушалмаган, кабатланмаган миниатюр образ-сурәтләргә юлыгасың. Теле ифрат та бай бу әдипнең! Әсәрнең аерым өлешләренә тукталып, кат-кат укып утырып була. Илья Ильф, Евгений Петров, Андрей Платонов, Ярослав Гашек әсәрләренең аерым урыннары ничә тапкыр укысаң да туйдырмый ич! Шундыйрак урыннар, бәхеткә каршы, Камил Кәримов әсәрендә дә байтак очрый. Бу язучының тел күренешләренә үтә сизгерлеге яңына фикерләү сәләтенең дә үзенә бер төрлерәк, үзенчәлеклерәк икәнлеген күшарга була.

Материалы-темасы да—әлегә беркем тарафыннан да яктыртылмаган өлкә—артезиан коелары бораулап, халыкны су белән тәэмин итеп йөрүчеләрнең тормышлары. Шундыйларның берсен—50 яшьлек Фазылны, үзе бик китәсе килмәсә дә, пенсиягә озаталар—кулына ине ике, буе өч метрлы келәм тоттыралар. Кешегә бушлай мондый келәм бирү экренләп пенсиягә җибәрү символына әверелә. Мондый мәгънәле һәм кинаяле детальләр әсәр дәвамында күп очрый. Шулай да, Камил Кәримовның иң зур табышы дип Су образын санар идем. Суга мәдхия, аны олылау, аңа соклану, эчәргә су табып бирүчеләрне хөрмәтләү... Мәгълүм ки, бер генә җан иясе дә, шул исәптән кеше дә, ризыксыз да, сусыз да тора, яши алмый. Беренчесен, ягъни ризык мәсьәләсен, татар әдипләренең ничәмә-ничә тапкыр күтәргәннәре бар. Мәҗит Гафуриның, Галимҗан Ибраһимовның ачлык дәһшәтен тасвирлаган яисә башка әдипләребезнең Ватан сугышы елларында ипигә-бәрәңгегә зар-интизар булып яшәгән заманнар хакында язылган әсәрләрне генә искә төшерик... Тик адәм баласына һәрдаим суы да кирәк бит. Ниһаять, монысын да искә алдылар. Кешеләрне суга туендырып торучылар турында зур әсәр—роман иҗат ителде. Камил Кәримов шушы изге юлга гомерләрен багышлаган кешеләрнең тормышларын, эш-хәрәкәтләрен, эчке халәтләрен, үзләренең дә кешечә яшәргә тырышу-омтылышларын шактый тулы итеп сурәтләп бирә алган.

Ахырда, олы, игелекле эшләр башкарып, пенсиягә киткән Фазыл су күплектән, юешлектән җәфа күреп интегә башлый—Яңа Савиндагы фатирының идән асларына су керә, ә идәндә бакалар сикерешә... Менә нинди була ул тормышның контрастлы сәер яклары... Ә боларны укыганда миңа Камил Кәримов бик олы, бик талантлы, Мөхәммәт Мәһдиев дәрәҗәсендәге шәхес, сүз остасы кебек булып күренә башлады.

Соңгы еллар татар прозасындагы сизелерлек зур үзгәрешләр «зыялы проза» дип исемләнердәй әдәби тармакта эшләүче әдипләребезнең иҗади активлыклары белән бик тыгыз бәйләнгән. Марсель Галиев, Фәнис Яруллин, Зөлфәт Хәким әдәби хәзинәләрен җыеп, туплап, өчәр-дүртәр томлы сайланма әсәрләр җыелмасы рәвешендә укучыга тәкъдим итә алдылар. Айдар Хәлим, Миргазиян Юныс, Әхсән Баянов, Альберт Хәсәнов, Тәүфикъ Әйди, Тәлгат Галиуллин, Вакыйф Нуруллин кебек прозаикларыбыз да гасыр ахырында иҗатларының үзәкләре булырдай күләмле, тирән мәгънәле әсәрләр иҗат иттеләр. «Соңгы сулыш», «Гөнаһ», «Тәүбә», «Әлмәк», «Догалы еллар», «Урланган ай» ...—мондый үзенчәлекле, хәтта уникаль дип аталырлык романнар, эсселарны инде тиешенчә тикшерелеп, өйрәнелеп, лаеклы бәяләрен алдылар, дип кем әйтә алыр? Рәфкать Кәраминең «Очар кошлар белән янәшә», Азат Вергазовның «Йөрәк җыр сорый» кебек яңа буыннарны тәрбияләү мәсьәләләрен кыю рәвештә күтәргән китаплары да җентекләбрәк өйрәнүне һәм бәяләүне сорый.

Мәсьәлә анда гына да түгел. Шушындый катлаулы шартларда да кирәкле элемтәләрне урнаштырып, спонсорларын табып, акчаларын юнәтеп, сыйфатлы китаплар, әсәрләр бастырып чыгара алган мондый булдыклы, уңган ир-атларыбызга мактау һәм рәхмәт сүзләре әйтергә генә кала.

Олы әдипләребездән Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла үзләре сайлаган өлкәдә—халкыбызның чын тарихын яктырту юнәлешендә күп еллар дәвамында гаять нәтиҗәле эшләп киләләр. Аларның һәр кайсының тарихны яктыртуда үз юллары, үз алымнары, мәсьәләгә сәнгатьчә якын килүнең үз таләпләре, үз принциплары бар. Кайберәүләргә алар бәхәслерәк булып та күренә торгандыр. Әмма, ничек кенә булмасын, мондый активлыкны хупларга кирәк. Әлегә җитди, тәфтишлерәк

анализ күбрәк Нурихан Фәттах әсәрләренә карата гына булды. Анысы да бәлки җитәрлек түгелдер. Ә инде Мөсагыйт Хәбибуллин, Рабит Батулла әсәрләренә тәнкыйть һаман да битараф кала бирә. 1999 елда дөнья күргән «Атилла» исемле зур роман да тиз арада әдәбиятчылар һәм тарихчылар тарафыннан бәяләнер дип өметләнәбез.

Иҗат мөмкинлекләре чикләнмәгән, зур потенциаль мөмкинлекләре булган тагын бер язучының исемен атап үтәсем килә—ул Тәүфикъ Әйди. Кызганычка каршы, аның иҗаты әлегә бөтенләй өйрәнелмәгән килеш кала бирә. Узган елгы әдәбиятка ул «Иблискә ришвәт» исемле романы белән катнашты. Менә-менә дөньяга чыгам, дип торучы, инде күптәннән язылып беткән байтак башка әсәрләре булуы да безгә мәгълүм. Гаять югары хәзерлекле, эрудицияле бу каләм остасының иҗади ачышлары бик тиз арада киң танылыр, дип күрәзәчелек итәм. Болай әйтергә ныклы нигезем дә бар, чөнки бу иҗат инде ярлары тулып, ташырга торган елганы хәтерләтә—менә кояш тагын яктырак карар... һәм бу дәрьядай иҗат ташкыны үзенең бөтен тулылыгында укучыларга барып ирешер. Моның өчен хәзер мөмкинлекләр туып килә.

Мәгълүм ки, укучыларның берничә буынын совет әдәбияты, бигрәк тә социалистик реализм әдәбияты, фәкать унай, үрнәк геройлар мисалларында гына тәрбияләргә тырышты. Бу начар түгел иде сыман. Әмма әдәбият-сәнгать тормышны берьяклап кына чагылдыра алмый. Әгәр гел шулай гына булса, аның мөмкинлекләре бик тар булыр иде. Киресенчә, ул безне тормыш-яшәешнең бөтен яклары турында уйландырып, төрле тормыш сабаклары, гыйбрәтләре мисалларында да тәрбияли яисә күңелләребезгә төрлечә тәэсир итә ала. Мона охшашлырак уйлар миндә язучы Әнәс Галиевнең «Чигенгәндә» («Казан утлары», 12 сан) повесте белән танышканда туды. Бу авторның үзенең дә, әлеге әсәренең дә язмышлары җиңелләрдән булмаган. Повесть 1980 елда ук язылып, тагын 20 ел үткәч кенә укучысына барып җитә алган. Ә мона әлләни гаҗәпләнәсе дә юк. Хикмәт нәрсәдә соң? Моның сәбәпләре авторның катлауланыбрак киткән биографиясендә икән. Дәһшәтле сугышларда катнашып йөргәндә Әнәс Галиев фашистларга әсирлеккә эләгә. Сугышлар бетеп, исән-сау әйләнеп кайткач та, калган гомерен яраткан эшенә—әдәбиятка гына багышлый алмый. Иҗат мөмкинлекләре анарга сонрак, үзе олыгаеп килгән елларда гына ачыла башлый. Махсус профессиональ әзерлекнең җитеп үк бетмәве дә үзен сиздерә... Шуна күрә аның әдәби тәҗрибәләре ул исән чагында да кайберәүләрдә каршылыклы фикерләр уяткалый иде. Ә бу юлы без бәхетле очрак турында сөйлибез—күренекле әдип Аяз Гыйләҗев кульязманы күреп алып, төзәткәләп, редакцияләп, матбугатка тәкъдим иткән, һәм шулай итеп «Чигенгәндә» исемле повесть укучыга барып җитә алган.

Әлбәттә, мондый әсәр моннан 20 еллар элек тә дөнья күрә алмаган булыр иде. Ә менә бүгенге көннең рухына, ихтыяҗларына ул бик хуш килеп тора.

Повестьта 1941-42 елларда фашистлар белән сугышканда Кызыл Армиянең чигенүе сурәтләнә. Автор Көньяк фронтта хезмәт иткән, сугышкан солдат буларак, үзе дә җиңелү ачысын татый. Мемуарлар, баштан кичкәннәр рәвешендә язылган әсәрдә ышандырырлык урыннар бик күп. Аларны Әнәс Галиев биографиясенең бер өлеше дип тә кабул итәсең. Бередә батырлык, фидакарьлек күренешләре дә бирелгән. Ә инде җиңелү, чигенү фаҗигаләренең төп сәбәпләрен ачарга ул дәгъва итми, ул аларны хәтердә калырлык күренешләр, детальләр белән тулыландыра гына... һәм... шул фаҗигалар турында тирәннәнрәк уйланырга мәҗбүр итә. Әнәс Галиевнең бу повесте тоташтан булганнарны югалту халәте, шуна бәйле рухи фаҗига белән сугарылган. Әгәр дә гасыр ахырында илебезнең элеккеге биеклекләреннән төшүен, позицияләреннән чигенүен, күп нәрсәләрне, кыйммәтләрне югалтуын искә алсак, романдагы чигенүләр логикасының бүгенге тарихи вакыйгаларга да авазлаш һәм актуаль икәнлеген сиземләргә була торгандыр.

1999 ел прозасының барыбызны да шатландырган бер ягына тукталмакчы булам: әдипләребез халкыбызны, үткәнебезне, тарихыбызны, телебезне кадерләү, милләтпәрвәрлек юнәлешендәге бай традицияләр барлыгын онытмадылар, үзләренең яңа әсәрләре аша әлеге бәрәкәтле җирлеккә киләсе буыннар күңелләренә үтәрлек итеп милли горурлык орлыклары салдылар. Бу урында Зәки Зәйнуллин, Айдар Халим әсәрләре янына Нурулла Гарифның «Мәмеш Бирде», Вахит Имамовның «Утлы дала», Рафаэль Сибатның «Атлар рәнҗеше» әсәрләрен дә өстәргә мөмкин булыр иде.

Узган елны ни сәбәптәндер хикәя жанрында аеруча җанлану, активлашу күзәтелде. Бу эшкә исемнәре күпләргә мәгълүм язучылар да, яшьрәкләр дә тартылды:

Фаяз Дунай, Кыям Миңлебаев, Рәфыйк Шәрәфиев, Ринат Мөхәммәдиев, Әхмәт Гадел, Заһид Фәйзи, Фоат Садриев, Рашат Низами, Нәсим Акмал, Солтан Шәмси, Шәрәф Әхмәдулла, Фәрит Шәфигуллин, Илдус Хуҗин, Зиннур Хөснияр, Рафис Гыйззәтуллин, Марат Закир, Рафаил Газизов, Рифә Рахман, Роза Мулланурова, Бикә Рәхимова, Филисә Хәкимова һәм тагын бик күп башка исемнәр... Кызганычка каршы, бу урында хикәя проблемалары турында этрафлы итеп, җентекләп сөйләшеп утыру мөмкинлегебез юк. Бераз соңрак махсус сөйләшү оештырсак, байтак кына сораулар да туар иде сыман: без кечкенә күләмле чәчмә язмаларыбызны иҗат иткәндә һәр очракта да бу жанрның шактый ук катгый таләпләрен искә алып бетерәбезме? Бу өлкәдә дөнья һәм татар әдәбияты классиклары туплаган гаять зур иҗат тәҗрибәсе һәм традицияләрен искә алып, алардан да өйрәнәбезме? Әллә «үземчә генә булсын», дип аларны читләтеп йөрибезме? Бу жанрның чын осталары—заманыбыз классиклары да янәбызда гына бит: Фәнис Яруллин, Барлас Камалов, Мәгъсум Хуҗин кебек хикәя кою мастерлары—ник алардан да өйрәнмәскә! Мәсәлән, шул ук Мәгъсум Хуҗинның «Кангый иленда» дигән хикәясе—энәсеннән-җебенә кадәр сүтеп-тикшерелеп өйрәнелерлек әсәр—бу жанрны иҗади үзләштерергә яисә хикәя-новелла язып карарга теләүчеләр өчен менә дигән кулланма. Гомумән, бу әдипнең хикәяләр өлкәсендә 40-50 еллык иҗат дәверендә ирешкәннәре чын әдәби мәктәп булып хезмәт итә ала.

Әлбәттә, тәнкыйтьнең ярдәме дә бик кирәк. Мәкаләмне тәнкыйтьчеләргә карата бераз үпкә сүзләре белән башлаган булсам да, тәнкыйтебез җанланып китәр, алдагы көннәрдә әдәбиятның, прозаның һәм, җөмләдән, хикәяләрнең дә сыйфатларын яхшыртырга үз өлешен кертер, дигән өметтә калам. Язучылар берлегендә яна җитәкчелекнең әдәби процесста тәнкыйтьнең функцияләрен, ролен дөрес аңлавы, шул Берлек структурасында яңадан оештырылган тәнкыйть остаханәсенең (җитәкчесе Мансур Вәли) беренче эшлекле адымнары, «Казан утлары» журналы битләрендә проза һәм тәнкыйтьнең торышы хакында алып барылган дәвамлы сөйләшүләр дә эзсез калмаслар, дип фараз итик. Мәхмүт Әхмәтҗанов, Фәрит Хатипов, Галимҗан Гыйльманов, Хәнәфи Бәдигый, Рафаэль Сибат, Рәфыйк Шәрәфиев кебек махсус хәзерлекле әдәбиятчыларыбызның яна хезмәтләре инде бу фаразларны раслый да башлады.

Әдәби тәнкыйтьнең башлыча эстетик кыйммәтләр байлыгын ишәйтүгә ярдәм итәрдәй тармак булырга тиешлеген таныган хәлдә, мин шулай ук аны тема-проблема, жанр-стиль һәм пропаганда бурычлары яктылыгында да активлаштырырга кирәк дип саныйм. Мәсәлән, мажаралы-детектив жанр чаралары белән җәмгыятьтәге криминаллашуны күрсәтү, фаш итүгә багышланган тармакны ни өчен махсус күзәтмәскә?! Сүз уңаенда гына әйткәндә, бу өлкәдә каләм осталарыбызның пары бераз гына сүрелә төште кебек. Әмма Зөлфәт Хәким, Тәлгат Галиуллин, Нияз Акмаллардай шул шомлы дөнья ишекләрен ачып керергә җөрьәт иткән авторларыбызның эшләп торуларын искә алсак, артык хәвефләнергә җирлек юк та сыман.

Яисә юмор-сатира дип йөртелүче тармакка күз салыйк. Юморның җанлануы—ул бик яхшы фал. Димәк, азмы-күпме сүз иркенлеге бар, тормышлар да күңелләнеп, рәтләнеп, яхшырыбрак китмәсме дигән өмет чаткыларының чагылышы ич бу! Шулай да алдагысын бигүк белеп бетереп тә булмый. Бәлки юмор чаралары гына алга таба җитеп тә бетмәс—ныклап сатирасына тотынырга туры килмәгәе?! Әмма, ничек кенә булмасын, бездә бу һәр ике тармакны тартып алып барырлык кадрлар бар. Шуларның берничәсенең генә исемнәрен атап үтәм: Туфан Миңнуллин, Фәнзаман Баттал, Рабит Батулла, Камил Кәримов, Хәлим Җәләлов, Равил Сабыр, Әхәт Сафиуллин, Шамил Маннапов, Тәлгат Нәҗмиев...

Бер еллык татар прозасын күздән кичергәндә байтак уйлар күзгалды. Әлбәттә, әдипләребезгә карап, «гражданлык кыюлыгыгыз җитенкерәми, тормышның аерым якларын читләтеп үтәргә яратасыз, әдәби осталыгыгызны чарлыйсыгыз бар, дөнья әдәбияты биеклекләренә күтәрелеп, танылсы да бар» дип озак сукранып утырып булыр иде. Тик моның кирәге бар микән? Язучыларыбызның болай да җин сызганып, эшләп торган көннәре бит. Алар хәзер теге яисә бу фиркага, төркемгә, акча өләшүчеләргә ярыйм яисә ярамыйм дип түгел, ә иманнары, йөрәкләре кушканча, зур эшләр майтарырлык көчкә ия икәнлекләренә инанып иҗат итәләр. Үткән елгы татар прозасы әнә шундый нәтиҗә ясарга да мөмкинлек бирә.

*Рецензияләр конкурсына*

# «БЕЗНЕ КЕМНӘР АҢЛАР?»

Шәп шигырь сине сискәндереп җибәрә дә, күңеленә тирән кереп кала. Кереп кала да, аннан мәңге аерылмый, җаның борчып, бимазалап тора, аны гомерлек гамьнәргә сала. Ул инде шагыйрь сүзләре генә түгел,ул—синеке, гүя синә берегеп туган, синең гамь белән бер мизгелдә уянган һәм синең белән бергә генә сүнәчәк.

Нилектән шулай бу? Бәлки син укыган шигырь, күк капусы ачылган чактагыдай, күңелнең догага, изгелеккә яисә шигъри сүзгә сусаган мәленә туры килгәнлектән генәдер? Әллә шагыйрь иҗатының сихри көче нәкъ шушында—шигырь белән күңелләрне айкап ташлый алуда, әлегә кадәр ярлагы хәлендә яткан, әмма әйтерлек сүзләр табылмаган борчулы фикереңне, сагышлы хисеңне, моң сарган җаныңны бер-ике сүз белән ачып, сурәтләп бирүдәме?!

> Танырсыңмы, юкмы, мин булырмын
> Кош тавышы белән кычкырган.

Туңып күшеккән җанны җылытып тергезергә, гамьсезлектән аерып, сагышлы-моңлы итәргә теләгәндәй, әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта шул юллар: «Танырсыңмы... Танырсыңмы...» Алар инде «Гашыйклар тавы» драмасыннан Сәет җыры гына түгел, минеке, синеке, бүтәннәрнеке дә. Котың очып уйланасың: нинди дер халәтебездә, кайсыдыр дөньядан торып кош тавышы белән кычкырсак, шулай кычкыра алсак, танучы булырмы безне? Әгәр танырга тиешле якыннарыбыз, яшьлек язында, бу караңгы чынбарлыкның якты ягында бүленеп калган гөнаһсыз беренче мәхәббәтләребез яисә газиз дәвамчыларыбыз моң тоймый, кошлар тавышына колак та салмый торган туң йөрәклегә, саңгырау җанлыга яки... исереккә үк әверелгән булсалар? Арабызда азмы шундыйлар? Үзебез дә кош тавышларында һәм авылдан бер гаепсез сөрелгәннәрнең йорт урыннарындагы карт тупылларның ыңгырашуында, зират каеннарының серле өнсезлегендә якыннарыбызны таныйбызмы? Хәтеребез саумы? Моның өчен, ким дигәндә, кошлар тавышын, урманнар шавын тыңлый белү, үзенне дә моңлы-хәсрәтле табигать баласы итеп тою кирәктер бит. Шул ук шагыйрь язганча:

> Башларыннан сыйпыйм, хәлен аңлап,
> Таш өстендә үскән юкәнең.
>
> .................................................................
>
> Авыр кагылмагыз... Кызганмагыз!
> Таш өстендә үскән юкәмен,—

дип уйлый алган җаннар гына табигатьнең һәр авазыннан мәгънә табалардыр. Ә без инде язын исәнләшеп кайткан, көзен хушлашып хәвефле ерак юлга кузгалган торналарны һәм кыр казларын да күрми, төркемнәренең елдан-ел кечерәя, сирәкләнә баруына да игътибар итми башладык. Әллә кошлар азайды, әллә безнең күңел күзләре сукырайды! Имин туган якты таңга куана белмибез, матурлыкка соклanudан да биздек. Энҗедәй чыклары белән нурланып утырган чәчәкләргә, җәйге җылы яңгырга, бишектәге сабый елмаюына... Болын-кыр чәчәкләренең татарча исемен әллә оныттык, әллә бөтенләй өйрәнмәгән килеш зая гомер үткәрдек. Инде «такыя» сүзен ничек дөрес язарга дип матбугат битләрендә бәхәсләшәбез, күп балалар аның ни аңлатканын да белмиләр. Без, мөгаен, беркайчан кош тавышлары белән кычкыра да алмабыз, чөнки ул тавышларны отып калмадык. Шөбһәле каркылдасак кына инде... «Җыр югалткан гавәм баш калкыта»—дип кисәтә безне шагыйрь. Бүтән шагыйрь-

Зөлфәт тә—«шигырь укып кинәнәсе малай кастет иги»—дип борчуыбызны арттырган иде. «Җыр югалткан гавәм»не безнең буын тудырып үстерде түгелме? Тырышканбыз, алар әнә күпме! Ничекләр итеп шундый үрнәк күрсәттек, нәрсәдә ялгыштык? Җырлау, сайрау-шагыйрьләр һәм кошлар гамәле генә, дип уйладыкмы?

Әйе, кошлар кайгысы түгел шул бездә. Ишек алдыбызда йомырка салучы тавыклар, аңгыра бройлерлар, итлек каз-үрдәк йөреп торса, шул җиткән. Бездә тамак кайгысы! Газеталар каз сую өмәсен язып мәш килә, шул «канлы сабантуй»ны телевизорлар татарның иң күркәм милли йоласы итеп бар халыкка күрсәтә. Бүтән йоласы булмаган дамы әллә бу халыкның? Шушы авыр күренешләр басымын җиңеп, бер шагыйрьнең кара каенга «каракаем», балакаем» дип җылы туганлык белдерүе гаҗәп тә хәтта. Каеннар кайгысын да, бу җирдә бездән алда яшәп киткәннәрнең кошлар тавышына күчкән моңнарын да шагыйрь генә аңлый, табигать гүзәле-аккошлар—белән дә алар гына сөйләшә ала:

Калдыр, аккош, каурыеңны,
Мин аны изге саныйм,—
Аккоштай саф ак кәгазьгә
Җылы хис булып тамыйм.

Бу—халык шагыйре Илдар Юзеевның «Калдыр, аккош, каурыеңны» исеме белән ак кәгазьгә тамган җылы хисләр җыелмасы. Шагыйрьнең илленче еллардан башлап 1996 елга кадәрге иң әйбәт лирик шигырьләре һәм җырлары тупланган яна җыентыгын «Татар китабы» нәшрияты бастырып чыгарган. Шулай да, көенечлерәк сөенеч бу: китап озаграк туган, аны әзерләгәннән соң үткән өч елдагы никадәр гамьле-уйчан шигырьләре керми калган. Чөнки бу заманда бу илнең Илдар Юзеевтай шагыйрьләр язганны да вакытында китап итеп халыкка тарата барырга акчасы юк. Акчабыз әдәп тәрбиясләргә түгел, үзебез үк төрле юллар белән ишәйткән әдәпсезлеккә каршы көрәшкә кирәгрәк. Моны шагыйрь дә белә:

Җырым да ярдәмгә мохтаҗ
Шушы хәерче илдә,—

ди ул. Ләкин илнең хәерчелеге—шагыйрьләр һәм аларны укучылар өчен генә. Әрсезләнеп талаучы ачкүзләр өчен Рәсәйнең байлыгы һич бетәрлек түгел икән. Шуңа күрә, казнага якынаю максаты белән, депутат мандаты эләктерергә теләүчеләр генә дә сайлаудан-сайлауга күбәя бара. Алар дистә меңнәр түгә-түгә ыргылалар, чөнки «изге мандат» эләксә, уны, йөзе белән кайтачагын яхшы беләләр. Без дә беләбез анысы, тик «уртак көрәш»кә кушылырга кесәбез буш, өстәвенә, әрсезлегебез җитми. Без—бүтәннәр әрсезлеген күреп тә уңайсызланучылар гына.

Мине оятка калдырган
Әрсезләрдән оялдым.
Оят тойгысын белмәгән
Мәнсезләрдән оялдым.

*(«Оялдым»)*

Әмма без бөтен нәрсәдән ояла, «Кеше өчен генә түгел, этләр өчен оялдым»—дип яңа һәм шундыйны җөпләп укый торгач, үзебез мәсхәрәгә калып бармыйбызмы соң? Әнә шагыйрь дә:

Үрнәк түгел, миннән була
Бары гыйбрәт алып,—

ди ич. Дияр дә шул! Менә ул, ягъни шагыйрь—«Казанның билгеле рухи бай хәерчесе»—иленнән куылган мескен таҗик баласына хәер бирергә кесәсеннән акча тапмый, чөнки үз хәле дә мактанырлык түгел.

Кесәләр буш... Күңелем хуш...
Акчасыз-нисез җырлыйм.
Гармун уйнап, бүрек тотып
Урамда гына тормыйм.

Чынбарлыктанмы бу күренеш, әллә булдыксыз бер шагыйрьнең сырхау фантазиясе жимеше генәме? Әгәр ул шигъри җәүһәрләр табып, Халык шагыйре исеме һәм Дәүләт бүләге алса, шуларга ирешерлек таланты булса, гомеренең ничә елы матди яктан тәэмин ителә? Биш? Ун? Ә менә «шушы хәерче иллә» өч ел гына кумәк хуҗалык рәисе булып «уңышлы» эшләгән, «эшчәнлеген» без оялып күзәткән түрәчек үзен һәм бөтен якыннарын гомерлек йорт-җирле һәм автомобильле итеп өлгерә, аның үрнәгендә баш бухгалтеры, агрономы, бригадирлары һәм мөдирләре дә тормышын түгәрәкли... Менә бер рәис колхоздан бушка алып, күп еллар файдаланган йортын шул ук кумәк хуҗалыкка 200 мең сумга сатып киткән. Сатып алучылары өлешсез калгандырмы? Әнә бер урман хуҗалыгы башлыгы, илнең «яшел хәзинә»се исәбенә, балалары өчен дә гади кешенең башы әйләнерлек карьера һәм якты киләчәк кайгыртып куйган... Хакимияттә зуррак урын биләгәннәрне инде әйтәсе дә юк.

Бар да, бар да халык җилкәсендә:
Кемнәр генә анда менмәсен...
Миллион—өзелә-сузыла аркан тарта,
Кәеф-сафа кора мен адәм.

(«*Бурлаклар*»)

Әйе, хәзер Рәсәй халкының нибары ике процентын алып торучы байлар ил байлыгының житмеш процентын үз кулларында тоталар икән. Тик монысы—караңгы прозабыз инде. Шагыйрь кешеләр арасында тигезсезлекнең көчәюен, азгынлыкның гадәтигә әверелеп, инде җәмгыятьтә гөнаһ та саналмавын җаны әрнеп сурәтли, үз хаталарына да борчыла. «Шушы хәлләрдә калуда минем дә катнашым бар»—ди ул бер шигырендә күпләребез исеменнән.

Гөнаһны да, изге гамәлне дә
Фәрештәләр язып баргандыр.
Хаталардан, ялгышлардан ардым,
Ә кемнәрдер азып аргандыр.

(«*Чын йөземне күрәсегез килсә...*»)

Ләкин шагыйрьнең фикер сөреше безне чарасызлык чигенә үк китереп житкерми. Шулай булмаса, үз җаныңнан кан саркытып нигә язып торырга да, аны нигә укырга иде?! Иртәгә дә кеше булып яшисе, яшәрлек рухи көч табасы, бүтәннәргә дә ярдәм итәсе бар бит әле.

Кара чәчләр арасында
Ак кеше булып калдым,
Шәфкатьсезләр дөньясында
Чак... Кеше булып калдым.

Менә ул—шагыйрьләр һәм шигъри җанлылар куанычы. Коры куаныч, дияр кемдер. Дисеннәр. «Азып туйганнар» арасында Кеше булып кала алуның читенлеген һәм... зурлыгын һәркем аңламас аңысы. Шагыйрь мондый ихтималлыкны белеп тора, аңа исе дә китми һәм кыйбласын да үзгәртмәячәк.

Үз намусыма
Тугры җаныма
Нигә килешү, алдау-ялганнар?
Аңламасалар
Аңламасыннар
Аңламас җаннар.

Әмма шагыйрь җаны мәңге-мәңге ачылмыйча да кала алмый, ул хәтта дус булмаганнар алдында да үзенең кемлеген әйтергә тиеш.

Галәт-холкым белән кыр казы мин:
егылып
төшәрмен дә
сызланып,
җан бирермен
соңгы сулышымда
очалмаганнарны кызганып.

Менә ул нинди икән! Чынлап та, нигә әле һаман безгә генә кызганычлар булырга? Гомерне озайта торган рәхәт хәлме әллә ул? Шагыйрь кат-кат әйтә: «Кызганмагыз! Авыр кагылмагыз!» Бүтәннәр, безне мескен итә алулары белән куанып яшәүчеләр дә кызганыч булып карасын бер. Ә без хәзер үткәндәге гамәлләребезне

кабат күздән кичерәбез һәм «без кемнәр?» дип, артык инсафлылыгыбыз, көндәлегебез, беркатлы ышануларыбыз аркасында кая килеп чыктык, дип уйланабыз, шушы хәлгә төшүебез, шуна төшерүләренә юл куюыбыз өчен сызланабыз: «гамьсезлекне биреп, моң алдык».

Бик тирәнгә яшеренгән
Нәфрәт тулы сагышлар...
Кагылмагыз... Безме? Без ул—
Яралы юлбарыслар.

*(«Без»)*

Бер караганда, таш өстендә үскән юкә, икенче караганда, яралы юлбарыс халәте—ике төрле җәмгыять тарафыннан алданган нечкә күңеллеләрнең холкын һәм күпләр аңламый торган холыксызлыгын менә нәрсә билгели! Һәм моны шагыйрьдән башка аңлатып бирүче дә булмас кебек. Тик яралы юлбарыслар бер савыгырлармы, соңгы җегәрләрен җуеп сүнмәсләрме, әрнүләрдән янып бетә язган йөрәкләре чыдармы? Инде болай да:

Һәр хаксызлык өчен яндык-көйдек:
Берәве дә бушка узмыйдыр,
Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп
Йөрәгебез шуңа сызлыйдыр.

*(«Йөрәге сызлаган дустыма»)*

Йөрәксезлек, шәфкатьсезлек, мәнсезлек арта гына барган бу чорда «таш өстендә үскән юкә»ләргә сызланасы да сызланасы икән әле. Ә бит түзәчәкләр—ышаныйк моңа! Хәтерлисезме, корыч тәнле имәннәр дә өшеп корган иң салкын кышны йомшак юкәләр исән-имин кичкән иде. Ничек исән калуларын үзләре генә беләдер. Чөнки беребез дә башларыннан сыйпап хәлләрен сорамадык, шулай сорыйсы дип тә белмәдек... Һәм тагын гап-гади мылтыгы да булмаган хәлдә сугышка куып кертелгән, баштанаяк коралланган дошманга каршы торырга тиеш булган япь-яшь егетләрнең, өч-дүрт ач сабые белән тол калып, тамак ялына да җитмәгән «хезмәт хакы»на дистә еллар ил йөген күтәргән әниләребезнең, гөнаһсыз икәнлекләрен белә торып, бер-берсенең намусына кара ягарга, үзара тапташып, рухи изелеп юкка чыгарга мәҗбүр ителгән зыялыларның, әдип һәм шагыйрьләрнең хәлен кем сорады? Шундый газапларга чыдаган өчен кем аларның кадерен белде? Ниһаять, бүгенге шушы чынбарлык өчен моның кадәр корбаннар кирәк идеме, бөтенесе әрәмгә генә китте түгелме? Шагыйрь яза:

Ник кадерсез соң без, кадерсез?
Була кайчак: югаласы килә
Хәбәр хәтерсез һәм каберсез...

Шагыйренә сабырлык-түземлек бир, Ходаем! Хәер, монда сүз шагыйрь кадере турында гына бармый бит. Бу караклар һәм әхлаксыз түрәләр илендә, гомумән, кешенең кадере чын шагыйрьләрне борчырлык хәлдә. Шулай да югалу—соңгы чик турында өметсез нәтиҗәгә килү өчен генә нечкә җаннарны сыкратып уйланасы да юк. Кадерсезләрнең «хәбәр-хәтерсез һәм каберсез» югала баруы «шәфкатьсезләр дөньясы»нда кемнәр өчендер гомер-гомергә кирәк булган, бу—яңалык түгел. Рәсәй—хәбәрсез һәм каберсез югалучылар иле. Немецлар үзләренең әсир ватандашларынын каберләрен эзләп Идел буйларына кадәр килеп җиттеләр, безнең, җинүче илнең, күп шәһитләре үз җиребездә үк әле дә каберсез ята, һаман да хәбәрсез югалучылар исемлегендә. Бездә югалулар кимесә бер сәбәпсездән сөргеннәр һәм сугышлар уйлап чыгаралар. Җәбернең беренчесен шагыйрь йөрәге кичерә:

Шигъриятнең хәле беркайчан да
Булмаган шул рәхәт, җиңел дә...
Ул һәрвакыт Җәлил жыры сыман
Яшәү белән үлем чигендә,
Туфан сыман сабыр-түзем дә ул,
Такташ жыры кебек тынгысыз...

*(«Шигъриятнең хәле»)*

Ләкин шагыйрьгә үз җанын өлешләп бүлеп иҗат иткән шигъриятнең авыр хәле каршында да оптимист булып каласы бит әле. Чөнки бу дөньяда вазифасы шундый: җир күтәрмәс хәсрәте булса да, укучысын өметсезлеккә түгел, якты уйларга гына чакыра ул. Икенче яктан, шагыйрьгә мондый ышаныч, рухи куәт үз халкыннан, аның шагыйрьне аңлавыннан һәм яклавыннан гына килә ала. Тик дөньяны «аңламас җаннар» гына басып китә күрмәсен!

Беләм, бу уйларым әлегә тик
Дәртле хыял гына...
Тик ышанам: җырның явызлыкка
Бер чик куярына!

*(«Табыйк шундый бер җыр»)*

Монысы—киләчәк эше. Әлегә шагыйрьләрнең исеме һәм даны алар китеп югалгач кына «Без Пушкинлы халык! Без Тукайлы халык!» дип дөнья кинлегендә күкрәк сугучылар өчен кирәгрәк. Берсе дә «Без Пушкиндай, Тукайдай, Такташтай даһиларның гомерен кыскартучылар токымыннан!»—дип тәүбәле сүз әйтмәячәк, аны көтәсе дә юк. Шул кыска гомерле Тукайлар үзләренең мәңгелек иҗатлары аша халыкка озын гомер калдырганнар. Илдар Юзеев хаклы: Алыплардан калган халык гасырларны кичә-кичә вакланса да, Тукай булып, Сәйдәш булып сакланган әле. Безгә аларның моңын танытырлык яна фидакарьләр дә дөньяга килә тора. Бу әхлаксыз заманда аларның безне үз гамьсезлегебез белән бергә-бер калдырмавы да киләчәккә өметне үстерә.

Югалтмагыз, Кояш белән батып,
Кояш белән бергә кайтыр ул.
Такташларның әйтми калган сүзен
Әйтми калмас, барыбер әйтер ул.

*(«Кайтып килә Кояш баешыннан...»)*

Шулай гына була күрсен, дип тели укучы. Югыйсә, аның бушап барган күңеленә тагын кем якты уйлар, игелекле гамьнәр салыр! Бүтәннәр фикерсезлеккә, каты күңеллелеккә, бозык уеннарга гына өнди бит. Талап-урлап җыйган байлыклары ташып торса да, андыйлар безнең салкын дөньяны җылытырлык көчкә ия түгел. Бар ышаныч—нечкә шигъри җаннарда.

Дөнья карый мина үзе өмет белән:
«Суыттыгыз мине, кем җылытыр?» —диеп.

Дөньяны җылыту—менә моны илаһи вазифа дисән дә ярый. Прометей шөгыле! Җылы өләшкәндә «гадәт-холкы белән кыр казы» булганнарның канатлары гына көймәсен.

Илдар Юзеевнын әлеге китабына керергә өлгермәгән соңгы еллар шигырьләре арасыннан «Китәм, диден...» исемлесен һәм «Су анасы монологы»н аерып карыйсы килә. Без күнегеп беткән, шунлыктан игътибар да итми башлаган күренешләрдән илкүләм, милләткүләм нәтиҗәләр ясавы, шул нәтиҗәләрне үзәкләргә үтәрлек итеп нечкә моң аша сурәтләве белән нәкъ Илдарча булган бу шигырьләр «Казан утлары»нын 1999 елгы беренче санында чыкты. «Китәм, диден...» шагыйрьнең мондашы Фасил Әхмәткә багышлана. Әрнүле ике юл:

Фатир алу өчен китәм, диден,
Яшим ич мин ишек төбендә.

Һәм менә бөек мончы, тагын бер «яралы юлбарыс», чынлап ук китеп барды. «Исән чакта үзен аңламаган» халкы өчен шулкадәрне эшләп, китәр алдыннан да күңел түрен шагыйрьгә генә ачкан ул—аны бары шагыйрь генә аңлаган.

Фатир сораганда төштек инде
Түрәләрнен ишек төбенә,—

ди шагыйрь үзенең күп иҗатташлары исеменнән. Әле үзе горур да:

Күпме генә аска тартсалар да
Төшмәдек без иҗат күгеннән.

«Су анасы монологы»—«шәфкатьсезләр дөньясы»ның тагын бер имәндергеч чынбарлыгы хакында. «Дәртле, моңлы, нурлы» Казаннын Тукай мәйданы каршындагы Су анасы сыныннан тарагын каерып алганнар. Шулай итеп, «азып арганнар» әкиятләргә, халыкның күңел төбендәге әдиплеккә һәм шагыйрьлеккә каршы да яуга чыктылар. Димәк, кемнәрдер үз әби-бабаларының рухи ядкәрен танымыйлар хәзер. Шигъри сурәткә, әкиятләргә ышану «эшлексезләр» гамәле генә булып бара, димәк?

Нишләдең? Син мине—әкиятне—
Үзең иҗат иткән халык ич,—

дип сыкрана Су анасы. Тик җавап ишетми, «аңламас җаннар» өнсез. Чөнки фатир сораучы моң ияләре генә түгел, бөек әдәп үзе дә күптән инде «түрәләрнең ишек төбендә». Нәкъ шушы хәл—күп бәлаләрнең сәбәпчесе дә. Мондый шартларда Дәрдмәндтән, Тукайлардан килгән нечкә шигърият тә Сәйдәш моңнары кебек шиксез кысрыкланыр иде дә, әлегә шагыйрьлекне үзенә бертөрле пәйгамбәрлек дәрәҗәсенә күтәрүче Илдар Юзеевларның фидакарьлеге, аларның, үзләренең кадерсезлекләренә дә карамыйча, шигърияткә үҗәтләнеп хезмәт итүе, «үкереп-үксеп» булса да җырлавы моңа ирек бирми. Чөнки «Такташларның әйтми калган сүзен» әйтәселәре, «Туфанның өметен» аклыйсы бар! Авырлыгын аңлап, җаваплылыгын төшенеп тотынганнар алар моңа, «үз юлымнан читкә каерылмам!»—дип, антларын гел янартып торалар. «Калдыр, аккош, каурыеңны» җыентыгы—әйтелгәннәргә тагын бер мисал.

Юк, җинел түгел ул изге зат—
Шагыйрьдән фатиха алулар...
Тагын да авыррак Туфанның
Өметен акларга калулар.

*(«Хәсән Туфан фатихасы»)*

Илдар Юзеев кебек, моңлы шигъриятнең зур талантына «Туфанның өметен акларга калу»ның авырлыгы нәрсәдә икән соң?

Туфан—үзеннән соң җәмгыятьнең тагын бер миһербансыз юлга кереп китәчәген, шигъри сүз кабул итәсе күңелләрнең үз-үзенә бикләнәсен, иҗатташларының яңа рухи сынаулар, яңа алдау-ялганнар, җаннарына яңа сызланулар алдында калачагын ачык белмичә китеп барды. Милләт өстенә империячел котырынуның яңа дулкыны бәрәчәген, зыялыларга ул тарафлардан яңа хәтәрлек көтеп яшәргә туры киләчәген, яңа Ежовларның ышаныч белән дәүләт башына ук үрмәләячәген, «Мин сездән разыймын, егетләр!»—дигәндә, дәвамчыларының тагын бик күп кадерсезлекләр кичерәчәген күз алдына китереп бетермәде. Остаз-шагыйрьнең өметен аклау нечкә җаннарга Туфан үзе уйлаганнан да авыррак бүген. Ихласлыкка, ireккә, кыр казлары очкан биеклеккә омтылган саен катлаулана бара яшәеш. Җаннары бәргәләнү дә шуннандыр.

Йөрәкләрдә—давыл.
«Баламишкин» булып, ярсу белән
Тибә җанда—авыл.
Мин дә сездән аерылып тормыйм,
Сукбай, сәрхүш җаннар...
Кочаклашып, үксеп-үкереп җырлыйм:
Безне кемнәр аңлар?!

*(«Мәҗлестән соң...»)*

Чыннан да, «хыялыннан киткән Җир йөзендә» шагыйрьне аңлаучы бармы бүген?

Барлар һәм булырлар, дип ышаныйк әле. Ышаныйк әле! Бар сагышы-моны, бар гаме—халыкныкы бит аның. Үз-үзебезне, үз ихтыяҗыбызны да аңламаслык хәлгә төшмәгәнбездер ич әле. Шагыйрь үзе ышанганча:

...... янган йөрәкләрне
Аңлаучылар табылыр әле...

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

*Дин һәм тормыш*

Мирза
Мәхмүтов

# КОРЪӘННЕ ТӘРҖЕМӘСЕЗ УКЫП БУЛАМЫ?

## Тагын тәрҗемә турында

«Казан утлары»ның 5—6 саннарында Коръәннең татарчага тәрҗемәсе турында язылган иде. Анда Батулла әфәнденең нөсхәсе яхшырак тәрҗемә ителгән, диелә. Һәм бу—хак. Ләкин һәрбер тәрҗемәдә гадәти хәл булган шикелле, монда да автор, үз сүзе белән әйткәндә, хаталардан хали түгел. Ике телдәге текстны мин үзем дә чагыштыра-чагыштыра арып беттем. Рәхмәт төшкере, Чистай мәчете имамы Нурулла Мөфлюхун Арслани татарча Коръәнне шулай ук гарәпчәсе белән чагыштырып укып чыккан һәм безгә үзе күргән хаталарны күрсәтеп мәктүп (төзәтер өчен, дип аңлыйм) җибәргән.

Ул хат-мәктүптә дөрес күрсәтелгән хаталар да, ялгышып күрсәтелгәннәре дә бар. Хәзрәтнең тәрҗемә мәсьәләсенә үзенең карашлары юк түгел. Тәрҗемә теориясе принцибы—мәгънәви тәрҗемә. Хәзрәт исә сүзгә сүз ысулны яклый. Дөрес күрсәтелгән хаталарыбыздан ваз кичмичә, хатның текстыннан хәзрәт дөрес күрсәтмәгән берничә мисал алып карыйк.

Мәсәлән, ул «Сабийлар» сүзен хата дигән, чөнки Корьәндә «Сабиин» (2 : 62) диелгән, һәм имам «Сабииннар» дип тәрҗемә итәргә тәкъдим иткән. Ләкин «сабиин»—«сабий» сүзенең (Борынгы Саба иле халкы мәгънәсендә) күплек саны гына. «Сабииннар» дип язсак ике мәртәбә күплек сан килеп чыга. Шуңа күрә, «сабиин»ны татарчага «сабийлар» дип тәрҗемә итү дөрес. Гыймран сүрәсендә Батулла, «хактыр ки, Аллаһ бәндәләренең кылмышларын күзәтеп тора», дигән. Арслани, «Аллаһ колларын күрүче», дип тәкъдим итә. Мәгънә ягыннан икесе дә дөрес дисәк була, чөнки татарчага болай тәрҗемә итүдә аерма булуы бер дә зыян китерми.

Гыймран сүрәсендә Батулла, «Мөэминнәр фәкать Аллага гына ышанырга тиешләр», Арслани: «Мөэминнәр Аллаһуга тәвәккәлләсеннәр», дип язган. Монда мин хата күрмим, чөнки мәгънәви ялгышлык юк. Ниса (48): Батулла—«хупламас», Арслани—«ярлыкамас», дип язганнар, әмма бу ике синонимның мәгънә төсмерләре контексттa гына ачыклана. Монда хата юк. Ниса (59) Батулла: «... Вә идарәчеләребезгә буйсыныгыз», Арслани: «Үзегездән булган (Корьән белән эш кылучы) әмер-боерык иясләренә буйсыныгыз», ди. Бу ике җөмләнең мәгънә ягыннан нинди аермасы бар? Мәгънәсе бер, Батулла нөсхәсендә татарча дөрес һәм кыскарак та әйтелгән әле.

Кәһаф (104) Батуллада: «Игелек кылабыз дип, фани дөньяда чабаланганнары бушка киткәннәр». Арсланида: «Аларның дөньяда тырышып булдырган нәрсәләре юкка чыкты. Ә үзләре чыннан да, без яхшы эшләрне эшлибез, дип исәплиләр». Кайсы вариант дөресрәк? Мәгънәви яктан икесе дә дөрес. Кайсы вариант татарча матуррак? Батулланыкы, әлбәттә. Та—һа (73) Батуллада: «Рәхмәте киң булган вә җәзасы да дәвамлы булган бер Аллаһтыр». Арсланида: «Аллаһ—нигъмәт бирүдә хәерле һәм Аның нигъмәте мәңгегә калучырак». Кайсы вариант татарча дөрес һәм матур, кайсысы сүзгә-сүз тәрҗемә икәнлеге күренеп тора.

Әнбия (27) Батуллада: «Алар Алла әмереннән алда сүз сөйләми». Арсланида:

«Сүз белән Аллаһны узмыйлар». Тәүбә (112) Батуллада:*«(Аллаһка)* дан җырлаучылар». Арсланида: «*(Аллаһны)* мактаучылар». «Дан җырлаучы» белән «мактаучы» арасында нинди мәгънәви аерма бар икән? әл-Хаҗҗ (78) Батуллада: «Аллаһка сыеныгыз». Арсланида: «Аллаһка тотыныгыз». Батулла җөмләләрендә бернинди ялгышлык юк, аятьләрнең мәгънәләре төгәл бирелгән, тәрҗемә татарча дөресрәк тә, аһәңлерәк тә, матуррак та яңгырый.

Мөэминнәр (105) Батуллада: «Аятьләребезне укыганда, сез аларны ялганга чыгардыгызмы?» Арсланида: «Әллә безнең аятьләребез сезгә *(дөньяда)* укылмадымы? Ә сез аларны ялганга санадыгыз». Шул ук сүрәнең 116 аятендә Батулла: «Мотлак хаким булган Хак Тәгалә—Бөек. Аннан башка тәңре юк. Ул—бөек Гарешнең хуҗасы». Арсланида: «Аллаһ—чын патша. Ул—Бөек булды. Аннан башка Иляһе юк. Ул—хөрмәтле Гарешнең Раббысы». Гарәпчәсе ничек соң? «Фәтәгалә Аллаһы-л-мәлику-л-хакку лә иләһә иллә һува раббу-л-гарши-л-кәрими». Ничек дөресрәк тәрҗемә итәргә?

Бу аятьтә Аллаһ Бөек һәм хакыйкать иясе, диелгән. Бу яңалык түгел, чөнки алар Аллаһның исемнәре *(туксан тугыз исемнәренең берсе)*, ягъни аятьләрнең күбесендә кабат-кабат әйтелә торган аның эпитетлары. Бу аятьнең төп мәгънәсе шуннан гыйбарәт: сүз тәхет турында бара. Кем аның хуҗасы? Җавап: «Лә иләһу иллә һува» *(аннан башка Иляһе, Тәңре юк)*. Нәрсәнең тәңресе юк? «Гарше курсийныкы»—күктәге тәхетнеке (Җәләләйнең тәфсирендә «Сәриру-л-хөсн»—иң яхшы тәхет, диелә).

Җыеп әйткәндә, югарыда күрсәтелгән тәрҗемә вариантларыннан башка тагын берсе булырга мөмкин. Гарәп дөньясында иң дөрес дип саналган тәфсирләрдән «Җәләләйнең Коръән тәфсирен» укыгач, мондый вариант килеп чыкты: «Хакыйкать иясе Бөек Аллаһтан башка иң газиз *(затлы)* тәхетнең Иляһесе, Тәңресе юк», яки: «Иң кадерле тәхетнең хакыйкать иясе Бөек Аллаһтан башка Иляһесе юк».

Арслани хәзрәт язмасында чагыштырып күрсәтүләр күп. Аның фикеренчә, Коръәнне сүзгә-сүз тәрҗемә итәргә кирәк. Мәсәлән, ул «сүзгә-сүз туры килмәгән сүзләр күп кабатлана» дигән һәм әл-Хаҗҗ сүрәсеннән түбәндәгеләрне хата итеп күрсәткән (беренче сүз—Батулланыкы, икенчесе—Арсланиныкы): **аңламыйсыз—сизмисез; ант—вәгъдә; гаделсезлек—золым; аңларлар—белерләр; йортыгыздан—җирегездән** һ. б. ш.

Ләкин кыйммәтле, иң дөрес һәм кадерле тәрҗемә сүзгә-сүз түгел, мәгънәви тәрҗемә һәм танылган татар әдибе Рабит Батулла моңа күп тырышлык куйган. Дәлил өчен мондый гына да мисал китерәм. Мәгълүм ки, тәрҗемәләр турында гарәп галимнәре бик күптәннән язып киләләр. Мәсәлән, биш йөз ел элек Җәләледдин әс-Суйути язган китап күптән түгел генә урысча да дөнья күрде (*«Совершенство в коранических науках», М., 2000*). Анда да тәрҗемәнең иң беренче принцибы—мәгънәви тәрҗемә, диелгән. Һәрхәлдә, укучыларыбыз Коръәнне тәрҗемә итү инә белән кое казудан да кыенрак икәнен аңлыйлардыр, дип ышанам. Шуңа күрә берәр җирдә ялгышкан булсак, зинһар, күрсәтә күрегез. Рәхмәт кенә әйтербез.

## Ден-иман һәм белем

Белем белән ден **(инану)** -иманның аермасы нәрсәдә? Белем—фән яки тәҗрибә белән расланган төп фикерләр җыелмасы. Белем—ул хакыйкатьне тану дигән сүз; ул аңлау, төшенүгә нигезләнә. Кеше берәр нәрсәне аңлап белер өчен дәлил көтә, белсә генә аңа ышана. Адәм баласы ничек инануга килә? Җыйган белеменә таянып. Бу очракта нинди белеменә таяна? Фәнни белем бар, тормыш тәҗрибәсе биргәне бар, тирә-юньнән җыелган белем була, дини гыйлем бар, аерым шәхес сеңдереп аңлаткан хорафат, мистика була.

Иман исә—ышану, инану дигән сүз. Урысча—«Вера». «Вера»—дин мәгънәсендә йөри. Ләкин «Иман» төшенчәсе «Вера»дан киңрәк, беренче мәгънәсендә генә «Вера»га тәңгәл. Аның икенче мәгънәсе—әдәп-тәртип, әхлак, мәрхәмәт, шәфкать. Татар телендә «иманлы кеше»—ул дини, тәкъва кеше генә түгел, ул—шәфкатьле, әдәпле, мәрхәмәтле кеше. «Имансыз кеше» дип, күбесенчә, дингә бер дә кагылышлы булмаган, әдәпсез кешегә карата әйтәләр. Димәк, «Иман» төшенчәсе «Вера»дан киңрәк һәм ул мөселманча тәрбия бирү методикасына кирәрлек термин.

Иман белән белем икесе дә кешеләрнең үзара аралашуыннан, әйбер яки сүз

беләп алмашуыннан килеп чыгалар. Фән, гыйлем иләре аралашуның өч төрен күрсәтә: телдән аралашу *(вербальная коммуникация)*; хат, язу белән аралашу *(письменная коммуникация)*; ым белән аралашу *(невербальная коммуникация)*, ягъни ишарә, ым, аваз, музыка, аһәң, хәрәкәт белән аңлату һ. б. ш.

Иман белән фәнни белем арасында нинди аерма бар соң? Белем—уйга, аң, хәтер, фикерләүгә бәйле, ул логика кагыйдәләренә нигезләнә, акыл көче, аң белән кабул ителә. Дин-иман да белемгә, дини гыйлемгә нигезләнә, ләкин ул асылда хис-тойгыларга, хиссияткә, күңел сизенүенә күбрәк таяна. Тәкъва кеше өстенлекне белемгә түгел, тойгысына, интуициясенә бирә, аның күңеле теге яки бу мәгълүматның, хәбәрнең дөрес яки ялган булуын сизеп-белеп тора. Ышану башта анда рухи ихтыяҗ формасында хасил була. Аннары ул белемгә, минем аң-фикергә нигезләнмәгән бер җиренә, инстинкт тирәсенә, «яшерен» аңга *(подсознание)* күчә, диләр психологлар.

Коръән турында сүз булганда, без, асылда, дин-иман турында уйлыйбыз һәм сөйлибез. «Күңел күзе белән күрмәсәң, маңгай күзе ботак тишеге», диләр. Коръәннең эчтәлеген мөселман кешесе күңеле белән күреп кабул итә. Андагы аятьләрнең беришесе укымышлы кешегә дә аңлашылмавы мөмкин. Бу хәлдә нишләргә? Сабыр итеп укый бирергә, тукталмаска. Интуициягә таянып, аятьнең эчтәлеген бик теләп, өстәп күңеленә сеңдерергә. Коръәннең үзендә әйтелгәнчә, Мөхәммәд пәйгамбәргә егерме ел буена аять артыннан аять иңдерелгән. Иңдерелгән берсен Мөхәммәд кешеләргә сөйли торган. Аңлашылмаса, тыңлаучылар аңа сораулар биреп, шул аңлашылмаучылыкны ачыклый торган булганнар. Шуңа күрә дә Коръәндәге текст диалог, әңгәмә формасында төзелгән.

Борын-борын заманнардан ук татарлар Коръән сүзләрен гарәп телендә ишетергә гадәтләнгәннәр, дип әйтеп була. Бала чактан ук алар олылардан «иншә Аллa», «Бисмилләһи рахмәни-р-рахим», «Сөбхан Алла», «Әлхәмдулилләһи» шикелле сүзләр хәтергә кереп калалар. Изге сүз тылсымлы сүз булып кабул ителә, аның ниндидер серле мәгънәсе бар шикелле сизелә. Ник алай икән соң? Чөнки аңлашылмаган чит сүзнең нәрсә икәнлеге мәгълүм булмагач, аның берәр сере булырга тиеш кебек тоела. Шулай итеп, кешеләр илаһи сүзләргә ышанырга, аларга таянырга омтыла; мәгънәләре аңлашылмаса да аларны, аһәңенә, сүзнең яңгыравына сихерләнеп тыңлыйлар һәм күңелләре белән кабул итәләр. Чөнки кешенең табигате шулай.

Ә инде теге яки бу **«тылсымлы»** гыйбарә тәрҗемә ителгәч (татарча булсын, урысча булсын), кеше аптырап та кала—серле дигән сүзебез гап-гади мәгънәле сүз булып чыга. Коръән сүзенең тылсымы югала кебек... Шуңа күрә татарларның, бигрәк тә олырак яшьтәгеләрнең, Коръән сүзләрен гарәп телендә ишетәселәре һәм әйтәселәре дә килә. Бу аңлашыла да, чөнки кешенең күңеле төбендә, аңының тирәнгә күмелгән аскы катламнарында гарәп сүзенең аһәңе, гарәп гыйбарәсенең моңы сакланган. Шуңа күрә дини кешенең Коръәнне гарәп телендә укыйсы килә, ялвару догаларын Аллага гарәп телендә җиткерәсе килә, чөнки гарәп теле—Коръән теле ул. Хәер, моңны, аһәңне ишетү бер нәрсә, әмма кешенең табигатенә тылсым-сихернең, аңлашылып җитмәгән нәрсәнең асылына төшенергә омтылу хаҗәте дә салынган бит әле. Шуннан танылмаган хәрефләрдән Изге Сүзне аңлашылган хәрефләргә күчереп уку теләге туа. Транскрипциянең кирәклеге менә шуннан гыйбарәт.

## Транскрипция турында бер-ике сүз

Транскрипция нәрсә ул? Кыскача әйткәндә, чит телдән кергән сүзләрнең хәрефләре танылмаса, әйтелеше бозылмасын өчен, аларны транскрипция юлы белән, ягъни укучыга таныш хәрефләр белән язу. Гомумән, транскрипция беренчедән, фәнни тикшеренүләр өчен, икенчедән, гадәти тормышта куллану өчен кирәк. Әйтик, Коръәнне укырга һәм аерым сүрә яки аятьләрне ятларга теләүчеләр бар. Шуны истә тотып, без Коръәннең ешрак укыла торган кайбер сүрәләрен транскрипция юлы белә укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык. Чөнки гарәп хәрефләре белән янәшә язылган транскрипция күзгә күренеп тора һәм кешенең хәтерендә, аңында, фикерләү ысулында төрле ассоциацияләр (элек булган, күргән, ишеткәннәрне) тудыра. Бу исә кешенең күңеленә тәэсир итә, кәефен күтәрә, рухын канәгатьләндерә, шатландыра.

Транскрипция ике төрле була—халыкара һәм милли. Халыкара транскрипция латин алфавитына тагын берничә аерым билгеләр, символлар өстәлеп ясала. Милли транскрипция шул милләт язуына якынлаштырып ясала. Урысларныкы—үзенә, татарныкы—үзенә.

Гарәп теленең фонетикасы (сүзләрнең әйтелеше) урысныкыннан да, татарныкыннан да үзенә хас авазлар белән аерылып тора. Ләкин урыс фонетикасында булмаган кайбер гарәп авазлары татар телендә бар. Мәсәлән, **җ, һ, ә, къ. гъ, w, v** авазлары һәм хәрефләре. Ә гарәп фонетикасы кайсы ягы белән татарныкыннан аерылып тора? Гадәттә безнең телебездәге авазларга охшамаган каты әйтелеше **съ** (сад), **дъ** (дад), **зъ** (зат), **тъ** (та) бар! Транскрипциядә без аларның астына нокта куйдык. Теш арасыннан чыккан (башкортча) әйтелешкә охшаган **«с»** һәм **«з»** авазлары астына сызык куеп күрсәтелде! Гадәттәге тирән тамак төбендә хасил була торган өч аваз—йомшак **гайн**, каты **гайн** һәм **һәмзә** («мөэмин» сүзендә ишетелгән шикелле) үзебезнең каты әйтелешле **къ, гъ, в** авазларына тәңгәлләштереп, язуда катылык билгесе белән аерылды.

Каты әйтелешле тартык авазлардан соң каты сузыклар—**а, у, ы** язылa; (**о** авазы юк). Мәсәлән, сыйфат, сабыр, таһир, гайре, рамазан (яки рамадан), залим формасында. Йомшак әйтелешле **т, д, з, к, л, м,** тартыклардан соң, йомшак сузыклар языла: мөмкин, зиннәт, дәлил, тәсбих, кәлимә, һ. б.

Гарәп сүзләренең мәгънәсе озын йәки кыска сузыклы хәреф булу белән дә аерыла. Кыска сузыклар язылмый, алар урынына тартык хәрефләрнең өстенә-астына «хәрәкәләр» генә куела. Бер үк сузык аваз сузыла төшеп әйтелсен өчен, татар транскрипциясендә озын сузыкларны ике янәшә сузык хәреф белән билгеләдек. Мәсәлән:

حاكم хааким—боерык бирүче, شاهد шааһит—шаһит, күргән кеше;

حكيم хәким—акыл иясе; شهيد шәһиит—корбан булган кеше һ. б. ш.

Гарәп исемнәре азагында укыганда әйтелми торган суффикс **«ун»**(«танвин»)һәм аның —**«у»**, —**«и»** хәрефләре языла. Алар җәя эчендә күрсәтелде, мәсәлән, **аллаһу ахад(ун), аллаһу самәде(ун)** яки **йауми-диин(и), мин-әл-җиннәти ва нәәс(и)**. Транскрипция «вакыф» кагыйдәләренә туры китереп язылды.

Урыс хәрефләре белән язганда, аерылып торсын өчен, каты әйтелешле хәрефләрнең астына нокта куелды. Мәсәлән, **таһарәт, сабр, рамадан, залим**; **айн**ны татарча **г** белән бирдек, **гайн**ның астына нокта куелды. Теш арасы **с** һәм **з** авазларын астына сызык куеп аердык. **Һәмзә** дип йөртелгән шартлавык тартыкны э хәрефе белән бирдек. Кириллицадагы **я, ю** хәрефләрен «сүтеп» **йа, йә, йу, йү** итеп язабыз. **W** (ирен-ирен **в** авазы) хәрефе бездә, гадәттә, **вә** яки **ва** итеп языла (гарәпләр үзләре **ва** диләр).

Билгеләлек артикле **«әл»** дип әйтелгән **элиф-ләм** дип атала. Аны төрлечә, төп сүзгә кушып та, аерып та язалар. Мәсәлән, **мәлик йаумиддин** дип тә, **мәлик йаум-ед-дин** дип тә. **Ахраҗәтүлард** түгел, **ахраҗәт-ил-ард** һ. б. Икенчесе фәнни яктан дөрес. «Кояшлы» хәрефләр (**р, т, с, ç, д, д, з, ш, б**) алдында **«л»** йотыла. Мәсәлән, **әл-рахмән** түгел, **әр-рахмән** итеп язылырга тиеш.

Безнеңчә **әлиф-ләм** кагыйдә буларак, аерылып язылса, дөреслеккә туры килә, алай булмаса, төп сүзгә кушылып язылган **әлиф-ләм** сүзенең мәгънәсе бозылу ихтималы бар. Мәсәлән, **рахмәни-р-рәхиим** сүзенә **р** кушып язылган хәлдә, телдә булмаган **рахмәнир** сүзе хасил була:

بسم الله الرحمن الرحيم **бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим;**

مالك يوم الدين **мәәлики йауми-д-диин;**

أخرجت الأرض **ахраҗәти-л-ард;**

**ас-саб-ру-р-рахмән; гыйльму-л-йакыйн; әгүзе-билләһи мин-әш-шайтаани-р-рәҗиим; йәә әйүһа-әл-кәәфируунa; судури-н-нәәс; мин-эль-җиннәти ва-н-нәәс.**

Кайбер гарәптән кергән гыйбәрәләр, еллар үтү белән татарлашып, катып калган сүз тезмәсе булып калдылар. Мәсәлән, **бисмилләһи (би-исм-аллаһи)**; **әстәгъфирулла (истәгъфәр Аллаһы)** һ. б. ш. Инде Коръәннең иң еш укыла торган кайбер сүрәләрен транскрипция юлы белән язып күрсәтик. Гарәп язуында баш хәрефләр, сорау билгеләре булмау сәбәпле, без аларны өстәп, «төзәтеп» тормадык.

سُورَةُ الْفَاتِحَةِ (١)
مَكِّيَّة

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ ﴿١﴾
الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿٢﴾ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
﴿٣﴾ مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ ﴿٤﴾ إِيَّاكَ نَعْبُدُ
وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ ﴿٥﴾ اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ
﴿٦﴾ صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ
الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ ﴿٧﴾

## Әл-фаатиха сүрәсе (1)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*1) Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим 2) Әл-хәмду лилләһи рабби-л-галәмиин. 3) Әр-рахмәәни-р-рахиим. 4) Мәлики йауми-д-диин. 5) Ийәкә нәгбуду вә ийәкә нәстәгыйн. 6) Иһдинәэ ҫ̣ыйраата-л-мөстәк̣ыйм. 7) Ҫ̣ыйраата-әлләзиинә әнгамтә галәйһим г̣айрел мәхд̣ууби галәйһим вэ лә-д̣-д̣аалиин.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

**Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.**
**1) Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән *(башлыйм)*.**
**2-3) Галәмнәрнең хуҗасы мәрхәмәтле вә рәхимле Аллага дан булсын.**
**4) Кыйамәт көненең хуҗасы.**
**5) Бары тик сиңа гына табынабыз һәм синнән генә йәрдәм өмет итәбез.**
**6) Безне туры йулдан алып бар.**
**7) Сине ачуландырмаган һәм хак йулдан адашмаган, нигъмәтенә лаек кешеләр юлына күндер.**

سُورَةُ الزَّلْزَلَةِ مَدَنِيَّة (٩٩)
وَآيَاتُهَا ثَمَانٍ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
إِذَا زُلْزِلَتِ الْأَرْضُ زِلْزَالَهَا ﴿١﴾ وَأَخْرَجَتِ الْأَرْضُ
أَثْقَالَهَا ﴿٢﴾ وَقَالَ الْإِنسَانُ مَا لَهَا ﴿٣﴾ يَوْمَئِذٍ
تُحَدِّثُ أَخْبَارَهَا ﴿٤﴾ بِأَنَّ رَبَّكَ أَوْحَىٰ لَهَا ﴿٥﴾ يَوْمَئِذٍ
يَصْدُرُ النَّاسُ أَشْتَاتًا لِّيُرَوْا أَعْمَالَهُمْ ﴿٦﴾ فَمَن يَعْمَلْ
مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ﴿٧﴾ وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ
شَرًّا يَرَهُ ﴿٨﴾

## Зилзилә сүрәсе (99)


ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Изә зилзиләти-л-ард̣у зилзәәләһә.*
*2) Вә әх̣раҗәти-л-ард̣у әҫкаләһә.*
*3) Вә к̣алә-л-инсәәнү мәә ләһә.*
*4) Йаумаизин тухаддисү әх̣бәрәһә.*
*5) Би әннә раббәкә әууха ләһә.*
*6) Йаумәизин йаҫ̣дуру-н-нәәс(у) әштәәтәл лийүрау әгъмааләһум.*
*7) Фәмән йәгъмәл мисҡ̣аалә зәррәтин хайрән йәрәһү.*
*8) Вә мән йәгъмәл мисҡаалә зәррәтин шәррән йәрәһү.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

**Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.**
**1) Җир көчле тетрәү белән тетри башлаганда. 2) Үз эчендәгеләрне тышка чыгарып ташлаганда. 3) Кешеләр, ни булды бу җиргә дип аптырар. 4) Ул көнне җир өстендә ниләр кылынганнарының барысы турында да җир үзе хәбәр итәр. 5) Аллаһның әмере белән җир барысын да сөйләп бирер. 6) Ул көнне кешеләр, кылган гамәлләренә күрә, төркем-төркем булып, хисап**

бирергә барырлар. Җир өстендә чакта нинди гамәлләр кылганлыкларын күрер өчен. 7) Кем тузан бөртеге кадәрле генә игелек кылган булса, хәтта шул да күренер. 8) Кем тузан бөртеге кадәрле генә начарлык кылган булса, ул да күренер.


سُورَةُ العَادِيَاتِ مَكِّيَّة (١٠٠) وَآيَاتُهَا إِحْدَى عَشْرَة

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

وَٱلْعَٰدِيَٰتِ ضَبْحًا ١ فَٱلْمُورِيَٰتِ قَدْحًا ٢
فَٱلْمُغِيرَٰتِ صُبْحًا ٣ فَأَثَرْنَ بِهِۦ نَقْعًا ٤ فَوَسَطْنَ
بِهِۦ جَمْعًا ٥ إِنَّ ٱلْإِنسَٰنَ لِرَبِّهِۦ لَكَنُودٌ ٦ وَإِنَّهُۥ
عَلَىٰ ذَٰلِكَ لَشَهِيدٌ ٧ وَإِنَّهُۥ لِحُبِّ ٱلْخَيْرِ لَشَدِيدٌ ٨
* أَفَلَا يَعْلَمُ إِذَا بُعْثِرَ مَا فِى ٱلْقُبُورِ ٩ وَحُصِّلَ
مَا فِى ٱلصُّدُورِ ١٠ إِنَّ رَبَّهُم بِهِمْ يَوْمَئِذٍ لَّخَبِيرٌۢ ١١

## Гадийәт сүрәсе (100)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим 1) Ва-л-гадийәти дабха(н). 2) Фал-мурийәти кадха(н). 3) Фал-мугыйрәти субха(н). 4) Фаәсәрнә биһи нәкъгән. 5) Фавасатнә биһи җамга(н). 6) Иннә-л-инсәәнә лираббиһи ләкәнүүд(ун). 7) Фа-иннәһү галә зәәликә ләшәһиид(ун). 8) Ва иннәһү лихуби-л-хайри ләшәдиид(ун). 9) Әфалә йагъләмү изә бугсирә мәә фи-л-кубүүр(и). 10) Вә хуссыйлә мәә фи-с-судуур(и). 11) Иннә раббаһум биһим йаумаизил ләхабиир(ун).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.

1) Йөрәк кагып тупырдап чапкан атларга. 2) Тоякларыннан ут чәчрәп узышучы чаптарларга. 3) Таң атканда яу чапкан аргамакларга. 4) *(Кукне)* тузан белән каплаган җылкыларга. 5) Дошман өеренең уртасына бәреп кергән йургаларга шан-шәрәфләр булсын. 6) Бәндәләр чыннан да шөкерсез Аллага каршы (*көферлектә гамәл кылалар)*. 7) Хактыр ки, ул заман кылмышлары белән алар үз көферлекләренә үзләре шаһит. 8) Хакыйкатән, *(адәм баласы)* байлыкмалга табына *(үзе комсызлык өчендә йәши)*. 9) Каберләреннән кубарылып чыгарылачакны алар аңламыйлар? 10) Күкрәкләрендә, күңелләрендә нинди хөсетлек йәшеренгән булса, барысы да фаш ителер. 11) Хактыр ки, Аллаһның барысы турында да белгәнлеге шул көнне ачыкланыр.


سُورَةُ القَارِعَةِ مَكِّيَّة (١٠١) وَآيَاتُهَا إِحْدَى عَشْرَة

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

ٱلْقَارِعَةُ ١ مَا ٱلْقَارِعَةُ ٢ وَمَآ أَدْرَىٰكَ مَا ٱلْقَارِعَةُ ٣
يَوْمَ يَكُونُ ٱلنَّاسُ كَٱلْفَرَاشِ ٱلْمَبْثُوثِ ٤ وَتَكُونُ
ٱلْجِبَالُ كَٱلْعِهْنِ ٱلْمَنفُوشِ ٥ فَأَمَّا مَن ثَقُلَتْ
مَوَٰزِينُهُۥ ٦ فَهُوَ فِى عِيشَةٍ رَّاضِيَةٍ ٧ وَأَمَّا مَنْ خَفَّتْ
مَوَٰزِينُهُۥ ٨ فَأُمُّهُۥ هَاوِيَةٌ ٩ وَمَآ أَدْرَىٰكَ مَا هِيَهْ ١٠
نَارٌ حَامِيَةٌۢ ١١

## Карига сүрәсе (101)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим 1) Әл-каригат(у) 2) Ма-л-каригат(у). 3) Ва мәә әдрокә ма-л-каригат(у). 4) Йаумә йакүүну-н-нәәсү кәл-фәрәәши-л-мәбсүси. 5) Ва тәкуну-л-җибәәлу кә-л-гыһнил-мәнфүүш(и). 6) Фә әммә мән сәкуләт*

*мәвәәзиинуһү. 7) Фә-һүвә фи гыйшәти(н) радыййат(ин). 8) Вә әммә мән хэффэт мәвәәзиинуһү. 9) Фа уммуһү һавийәт(ун). 10) Ва мәә әдрокә мәәһийәһ. 11) Нәәрун хаамийәт(ун).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Афәт капкасын кем кага. 2) Нәрсә ул афәт капкасын кагучы *(кыйәмәт)*. 3) Афәт капкасының кайчан кагылачагы турында сиңа кем әйтә алыр *(беркем дә)*. 4) Ул көнне кешеләр куып таратылган бичара күбәләкләр кебек булыр. 5) Таулар да ул көнне тетелеп буйалган йон пәрәвезләре кебек булыр. 6) Менә *(үлчәүләргә салынган йаман һәм йахшылыклары)* игелекләр йагы авыр басса. 7) Ул кеше *(җәннәттә)* рәхәтләнеп йәшәйәчәк. 8) Төпсәнең гөнаһлар йагы авыр баскан бәндәләрнең. 9) Һавийә исемле җәһәннәм упкыны булыр. 10) Нәрсә ул Һавийә, син беләсеңме 11) Ул—хәтәр кызган ут.





## Тәкәсир сурәсе (102)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рахиим*
*1) Әлһәкум-ут-тәкәәҫур(у). 2) Хәттә зуртуму-л-макабир(ә). 3) Кәллә сәуфә тәгъләмүүнә. 4) Ҫуммә кәллә сәуфә тәгъләмүүнә. 5) Кәллә ләү тәгъләмүүнә гыйльмә-әл-йакыйн. 6) Ләтәрәүннә-л-җәхиимә. 7) Ҫуммә ләтәрәүннәһәә гайнә-л-йакыйн. 8) Ҫуммә лә тусәәлуннә йаумаиҙин гани-н-нәгыим.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Байлык туплау *(хатын, балаларыгыз белән)* мактанышу һәвәслеге сезне. 2) Гүр ийәсе булганга чаклы ычкындырмады. 3) Бу эштән сакланыгыз, озакламый сез *(моның гөнаһ икәнен)* аңларсыз. 4) Сак булыгыз, озакламый аңларсыз. 5) Сак булыгыз, әгәр сез алда ни булачагын белсә идегез. 6) Һичшиксез сез җәһәннәмне күрерсез. 7) Үз күзегез белән күрерсез. 8) Аннан соң, әлбәттә, байлыгыгыз *(харам кылып йәшәгәнегез турында)* соралачак.




## Ґасри сурәсе (103)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Ва-л-гаҫри 2) Иннә-л-инсәәнә лә фии хуср(ин).*
*3) Илләә әлләзинә әмәну ва гамилү-ус-салихәәти. Ва тәваасав бил-хаккый ва тәваасав би-ҫ-ҫабр(и).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1)Шәфәкъ белән ант итәм! 2)Кеше һәрвакыт зыян күрә. 3)Бары тик

иман китереп, игелек кылганнар гына, бер-берсенә хакыйкатьне исбат иткәннәр, түзеп, сабыр иткәннәр алай булмас.

## Һүмәзә сүрәсе (104)

سُورَةُ الهُمَزَةِ مَكِّيَّة (١٠٤)
وَآيَاتُهَا تِسْعٌ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

وَيْلٌ لِّكُلِّ هُمَزَةٍ لُّمَزَةٍ ﴿١﴾ الَّذِي جَمَعَ مَالًا وَعَدَّدَهُ ﴿٢﴾
يَحْسَبُ أَنَّ مَالَهُ أَخْلَدَهُ ﴿٣﴾ كَلَّا لَيُنبَذَنَّ فِي الْحُطَمَةِ ﴿٤﴾
وَمَا أَدْرَاكَ مَا الْحُطَمَةُ ﴿٥﴾ نَارُ اللَّهِ الْمُوقَدَةُ ﴿٦﴾
الَّتِي تَطَّلِعُ عَلَى الْأَفْئِدَةِ ﴿٧﴾ إِنَّهَا عَلَيْهِم مُّؤْصَدَةٌ ﴿٨﴾
فِي عَمَدٍ مُّمَدَّدَةٍ ﴿٩﴾

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Вайлүл ликүлли һүмәзә(тил) лүмәзә(тин). 2) Әлләзи җәмәга маалән ва гаддәдәһү. 3) Йахсәбү әннә мааләһү ахләдәһү. 4) Кәллә ләйүмбәзәннә фи-л-хутама(ти). 5) Ва мәә әдрәкә ма-л-хутамә(ту). 6) Нәәрү Аллаһи-л муукадәту. 7) Әлләти таттaлигу галә-л-әфэидә(ти). 8) Иннәһә галәйһим муәсадәт(ун). 9) Фии гамәдим мәмәддәдә(ти).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим
1) Әче каһәр төшсен кеше артыннан сүз йөртүчеләргә. 2) Байлык туплап, кан калтырап торган сараннарга. 3) Байлыгым-малым мине мәңге йәшәтер, дип уйлаганга. 4) Хәер, ул кеше хутамәгә атылачак. 5) (Ий, Мөхәммәд) хутәмәнең ни икәнен син беләсеңме. 6) Аллаһ йандырган хәтәр тәмугъ булыр ул хутәмә. 7) Бәгырьләрне йандыручы хәтәр уттыр ул. 8) Ул тәмугъның ишекләре бикләп куелыр. 9) Гөмбәзләре озын утлы терәүләр белән терәтелгән булыр.

## Фиил сүрәсе (105)

سُورَةُ الفِيلِ مَكِّيَّة (١٠٥)
وَآيَاتُهَا خَمْسٌ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

أَلَمْ تَرَ كَيْفَ فَعَلَ رَبُّكَ بِأَصْحَابِ الْفِيلِ ﴿١﴾ أَلَمْ يَجْعَلْ كَيْدَهُمْ
فِي تَضْلِيلٍ ﴿٢﴾ وَأَرْسَلَ عَلَيْهِمْ طَيْرًا أَبَابِيلَ ﴿٣﴾ تَرْمِيهِم
بِحِجَارَةٍ مِّن سِجِّيلٍ ﴿٤﴾ فَجَعَلَهُمْ كَعَصْفٍ مَّأْكُولٍ ﴿٥﴾

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим. 1) Ә ләм тәрә кәйфә фәгалә раббукә би-әсхааби-л-фиил(и). 2) Ә ләм йәҗгаль кәйдаһум фи тадлиил(и). 3) Вә арсәлә галәйһим тайранә(н) әбәәбиилә. 4) Тәрмииһим бихиҗәәрәтим мин сиҗҗиил(ин). 5) Фәҗәгаләһум кәгасфим мәәкүүл(и).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим. 1) Раббыңның фил хуҗаларын нишләткәнен күрмәдеңме. 2) Аллаһ аларның мәкерле теләкләрен йукка чыгармадымыни. 3) Аллаһ аларның өстенә төркем-төркем Әбабил кошларын җибәрде. 4) Алар ут кызган ташлар йаудырдылар. 5) Соңра ул аларны икмәге сугып алынган буш басудагы салам-кибәк кебек итте.

سُورَةُ قُرَيْشٍ مَكِّيَّةٌ (١٠٦)
وَآيَاتُهَا أَرْبَعٌ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

لِإِيلَافِ قُرَيْشٍ (١) إِيلَافِهِمْ رِحْلَةَ الشِّتَاءِ
وَالصَّيْفِ (٢) فَلْيَعْبُدُوا رَبَّ هَٰذَا الْبَيْتِ (٣) الَّذِي
أَطْعَمَهُم مِّن جُوعٍ وَآمَنَهُم مِّنْ خَوْفٍ (٤)

## Корәеш сурәсе (106)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Лә иләәфи курәйш(ин).*
*2) Иләәфиһим рихләтә-ш-шитәә ва-ç-çайф(и). 3) Фалийәгбудүү рабба һәәзә-л-бәйти. 4) Әлләзи әтгамаһум мин җугы(н) ва әмәнәһум мин хауф(и).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Кураеш халкының бердәмлеген. 2) Кышкы һәм җәйге сәфәрләренең уңышлы булуын тәэмин иткән. 3)Шушы Кәгъбатулланың Раббысына гыйбадәт итеп, шөкер итсеннәр. 4) Ул аларны ач үлемнән коткарып тамакларын туйдырып, куркынычтан саклап, аларга иминлек бирде.

سُورَةُ الْمَاعُونِ مَكِّيَّةٌ (١٠٧)
وَآيَاتُهَا سَبْعٌ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

أَرَءَيْتَ الَّذِي يُكَذِّبُ بِالدِّينِ (١) فَذَٰلِكَ الَّذِي يَدُعُّ
الْيَتِيمَ (٢) وَلَا يَحُضُّ عَلَىٰ طَعَامِ الْمِسْكِينِ (٣)
فَوَيْلٌ لِّلْمُصَلِّينَ (٤) الَّذِينَ هُمْ عَن صَلَاتِهِمْ
سَاهُونَ (٥) الَّذِينَ هُمْ يُرَآءُونَ (٦) وَيَمْنَعُونَ
الْمَاعُونَ (٧)

## Мәәгунә сурәсе (107)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Ә рәәйтә әлләзи йукәззибу би-д-дәиинә. 2) Фазәликә әлләзи йадуггу-л-йәтиим 3) Ва ләә йахуддү галя тагами-л-мискиин(и). 4) Фавайлүл ли-л-мөçаллиинә. 5) Әлләзиинә һум ган саләәтиһим сәәһунә. 6) Әлләзинә һум йураәууна 7) Ва йәмнәгунә-л-мәәгунә.*


ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Динне йалганга санаган кешене син күрдеңме. 2) Андый кеше йәтимне йанныннан куар. 3) Ач кешенең тамагын туйдырмас. 4) Андыйларның намаз укуы *(ташка үлчим инде)* гөнаһ җыю гына. 5) Аларның намазы ихлас вә җитди түгел. 6) Алар намазны кеше күрсен өчен генә, рийалык белән укый 7) Алар хәер бирүне тыйа.

## Кәүçәр сурәсе (108)

ТРАНСКРИПЦИЯ


*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Иннә әгтайнәәкә әл-кәүçәр. 2) Фасалли ли-раббикә вә әнһәр. 3) Иннә шәәнизәкә һува-л-абтар.*




ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

**Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.**
**1) Хактыр ки, без сиңа кәүсәрне бирдек. 2) Шулай булгач син Раббың ризалыгына намаз укы, корбан чал. 3) Сиңа хөсетлек тотучының нәселе корыр.**

## Кәфирун сүрәсе (109)





ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Куль йәәйүһа-л-кәәфирүүнә. 2) Лә әгбуду мәә тәгбудүүна. 3) Вә лә әнтом гаабидүүна мәә әгбуду. 4) Вә ләә әнә габид(ум) мәә габәдтум. 5) Ва лә әнтум гаабидүүн(а) мәә әгбуду. 6) Ләкум диинукум вә лийә диин.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

**Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.**
**1) Әйт син, әй, кәферләр,—диген. 2) Мин сез табынганнарга табынмам. 3) Сез дә мин табынганга табынмассыз. 4) Сез элек табынганнарга мин табынучы түгел. 5) Сез дә мин табынганга табынучылар түгел. 6) Сезгә—үз динегез, миңа—үз динем.**

## Наср сүрәсе (110)





ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим*
*1) Изә җәәәә насру Аллаһи вә-л-фәтх(ү). 2) Ва рәәәйтә-н-нәәс(ә) йәдхүлүүнә фии диин Аллаһи әфвааҗа(н). 3) Фасәббих би-хамди раббика ва эстагфирһү иннәһү кәәнә таввабә.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

**Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.**
**1) Алладан йәрдәм килеп, җиңүгә ирешсәгез. 2) Кешеләр төркем-төркем булып, Алланың диненә күчәчәкләр. 3) Бас, Раббыңны мактап, тәсбих әйт, аннан йарлыкау сора, шик йук ки Аллаһ тәүбәләрне күпләп кабул итүче.**


سورة المسد مكية وآياتها خمس

بسم الله الرحمن الرحيم

تبت يدا أبي لهب وتب ١ ما أغنى عنه ماله وما
كسب ٢ سيصلى نارا ذات لهب ٣ وامرأته حمالة
الحطب ٤ في جيدها حبل من مسد ٥


## Мисәд сүрәсе (111)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-рахиим*
*1) Тәббәт йәдәә әбии ләһәб(ин) ва тәббә.*
*2) Мәә әгнәә ганһү мәәлүһү ва мәә кәсәбә.*
*3) Сәйаслəә наарән зәәтә ләһәби(н).*
*4) Ва әмрәәәтүһү хаммәәләтә-л-хатаб(и). 5) Фии җиидиһәә хаблүм мим мәсәд(и).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Әбү Ләхәбнең ике кулы корысын! Үзен ләгънәт орсын. 2) Кәсеп итеп җыйганнары да аңа йәрдәм итмәс. 3) Ул йалкынлы утта йаначак. 4) Хатыны да, утын күтәргән килеш. 5) Хатынының муенында хөрмә мунчаласыннан ишелгән бау булыр.


سورة الإخلاص مكية وآياتها أربع

بسم الله الرحمن الرحيم

قل هو الله أحد ١ الله الصمد ٢ لم يلد ولم
يولد ٣ ولم يكن له كفوا أحد ٤


## Ихлас сүрәсе (112)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.*
*1) Куль һува Аллаһү ахад(ун).*
*2) Аллаһү-ç-çамәд(ү).*
*3) Ләм йәлид ва ләм йүүләд 4) Ва ләм йакул ләһү куфууан ахад(ун).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Әйт син, Аллаһ берәү генә. 2) Аллаһ мәңгелек. 3) Ул тудырылмаган да тудырмаган да. 4) Аллага тиңдәшбулганы да йук.


سورة الفلق مكية وآياتها خمس

بسم الله الرحمن الرحيم

قل أعوذ برب الفلق ١ من شر ما خلق ٢ ومن شر
غاسق إذا وقب ٣ ومن شر النفاثات في العقد ٤
ومن شر حاسد إذا حسد ٥

## Фәләкъ сүрәсе (113)


ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.*
*1) Куль әгүзү бирабби-л-фәләк(ый). 2) Мин шәрри мәә халака. 3) Ва мин шәрри гаасикыйн изә вакаба. 4) Ва мин шәрри-н-нәффәсәти фи-л-гукад(и). 5) Ва мин шәрри хаасиди(н) изәә хасәдә.*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘСЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим.
1) Әйт син аларга, таңның Раббысы Аллага сыенамын, диген. 2) Йарал-тырганнарның мәкереннән. 3) Дөм караңгы

төннәрдәге мәкердән. 4) Ырым төеннәренә өреп-өшкереп төкерүчеләрнең мәкереннән .5) Көнчел вә хөсетле кешенең мәкереннән Аллага сыенамын.



سورة الناس مكية (١١٤) وآياتها ست

بسم الله الرحمن الرحيم

قل أعوذ برب الناس (١) ملك الناس (٢)
إله الناس (٣) من شر الوسواس الخناس (٤)
الذي يوسوس في صدور الناس (٥) من الجنة
والناس (٦)

## Нәәс сүрәсе (114)

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим. 1) Күль әгүзү бирабби-н-нәәс(и). 2) Мәәлики-н-нәәс(и). 3) Иләәһи-н-нәәс. 4) Мин шәрри-л-васвааси-л-ханнас(и). 5) Әлләзинә йувасвису фии-ç-судуури-н-нәәс. 6) Мин-әл-җиннәти ва-н-нәәс(и).*

ТАТАРЧА ТӘРҖЕМӘЧЕ

Бисмилләһи-р-рахмәәни-р-рахиим. 1) Әйт син, кешеләрнең Раббысына сыенамын. 2) Кешеләрнең Алласына. 3) Кешеләрнең Илаһына. 4) Шайтанның мәкерле котыртуыннан. 5) кешеләрнең күңеленә вәсвәсә салучы шайтаннан. 6) *(ул шайтан)* җен токымыннан булса да, кешеләрдән булса да (Аллага сыенамын).

آمين الله اكبر

СҮРӘ ИСЕМНӘРЕНЕҢ ТӘРҖЕМӘСЕ

Әл-фатиха - Коръәнне ачучы
Әз-зилзилә — җир тетрәү
Әл-гадийиәт — чабып баручылар
Әл-карига — афәт, кыямәт
Әт-тәкәсир — ишәйү, күбәйү
Әл-гасри — шәфәкъ
Әл-гүмәзә — гайбәт(че)
Әл-фил — фил
Әл-корәеш — корәеш (кабилә исеме)
Әл-мәгунә — хәер-садака
Әл-кәүсәр — кәүсәр; шул (чишмә исеме)
Әл-кәфирун — кяферләр
Ән-наср — ярдәм; җиңү
Әл-мисәд — хөрмә агачы сүзе
Әл-ихлас — ихлас
Әл-фәләкъ — таң
Ән-нас — кешеләр; халык

*Хәсән Туфанның тууына 100 ел*

Марс Шабаев

# АНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ ИДЕ...

Татар шигърияте өчен 2000 ел—Хәсән Туфан елы. Хәтеребез күгендә аның йолдызы балкый. Мәшһүр шагыйребезнең тууына декабрь аенда 100 ел тула. Вафаты—1981 елның 10 июнендә иде.

Хәсән Туфан турында бик әтрафлы истәлекләр китабы бар. «Ак чәчәк атар иде» дип атала ул *(Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1989)*. Мин ул китапның рецензенты, ягъни ана бәяләмә язучысы идем. Анда үземнең дә истәлегем урнаштырылган. Бүген мин шуны, байтак кына яңа сәхифәләр өстәп, «Казан утлары» журналын укучыларга тәкъдим итмәкчемен. Сәбәбе: беренчедән, Хәсән Туфанның вафатыннан соң да ике дистәгә якын ел узды, шигърият сөюче яңа буын үсеп җитте; икенчедән, массакүләм мәгълүмат чараларына цензура бетерелгәч, кем нәрсә тели—шуны сөйли-яза торган елгыр адәмнәр күбәйде, кызганыч ки, бу шаукымнан кайбер мөхтәрәм әдипләребез дә читтә кала алмады: Такташ, Туфаннарны, хәтта Тукайны да (!) «сүтеп-ботарлап» ташларга теләүчеләр табылды, юк-юк та, бу йөгәнсезлек әле дә булса калкып чыга тора.

Кирәкми, каләмдәшләр... Ярамый алай! Халкыбызның асыл затларын хәкарәт иттермик. Хак хакыйкать сүзен тарих әйтер.

Сибгат Хәкимнең үзәк өзгеч шигъри юллары бар:

Аккош күлендә—сагыш, моң,
Юксынып сорый урман:
Гасырның үзе кебек чал
Кайда, дип, синең Туфан?..

Җавап бер: Туфан—халкыбыз йөрәгендә. Тукай, Такташлар белән бергә. Бөекләр—үлемсез.

* * *

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Эзләрем бик иртә салынган...

Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясе бүлмәсеннән Фәхри Насретдиновның ягымлы теноры ишетелә. Ах, шунда кереп, җырны ахырына кадәр тыңлап торасы иде! Ул бүлмә концерт залы түгел. Анда эш бара. Фәхри Насретдиновның җыры да кинәт кенә, иң югары ноктага менеп җиткәч кенә коелып төшә, җыр өзелә...

Бүлмә ишеге ачыла. Коридорга, шаулашып, бер-бер артлы кемнәрдер чыга башлый. Тәнәфес ясаулары, ахрысы. Әнә Сибгат ага Хәким, Җәүдәт Фәйзи, музыкаль тапшырулар мөхәррире Мәһинур Җиһаншина, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина, Фәхри Насретдинов, аккомпаниатор Екатерина Соколова—болар әле генә яңгыраган җырга катнашы булган кешеләр.

Ә менә Хәсән ага Туфан ни өчен алар арасында икән соң? Әллә аның сүзләренә дә берәр яңа җыр язылганмы? Сибгат ага Хәким ияртеп алып килгәндер аны.

Мин, бу ишле төркем янынннан үтешли, кыяр-кыймас кына исәнләшәм:

—Исәнмесез...

Сибгат ага Хәким мине танып алып, күрешергә кулын суза:

—Исәнме, Марс! Хәсән ага, сез танышмы?

—Таныш шикелле... Шабай бит әле? Әйдә, күрешик булмаса!—Хәсән ага ничектер егетләрчә итеп, жилле генә күрешеп куя.

Аның «таныйм шикелле» дигән сүзләреннән миңа рәхәт булып китә. Югыйсә әле алай үземне танытырлык әллә ни эш кыра алган юк. Узган 1957 елның язында без Хәсән Туфанны «Татарстан яшьләре» газеты каршындагы үзебезнең әдәбият-ижат түгәрәгенә чакырган идек. Беренче мәртәбә бер бүлмәдә утыруыбыз шунда булды, ахрысы. Ул очрашуда Хәсән ага Туфан безгә үзе хакында бик кызыклы биографик фактлар сөйләде. Яңа шигырьләрен укыды. Әмма Себерләрдә-сөргеннәрдә йөргәннәре хакында—ләм-мим... Түгәрәк әгъзаларының да кайберләре үз язганнарын укып күрсәттеләр. Шагыйрь аларга матур-матур киңәшләрен дә әйтте. Мин бернәрсә дә укымадым шикелле. Хәсән ага Туфанның әңгәмәне йомгаклап: «Әдәбият өчен киң кирәкле шартларның берсе—үзара дусларча атмосфера булдыру. Иптәшеңнең уңышы—синең дә уңышың, аның уңышсызлыгы—синең дә уңышсызлыгың»,—дигән сүзләре хәтергә уелып калган. Мин аның нәкъ шул сүзләренә басым ясап, «Татарстан яшьләре»ндә информацион хәбәр кисәге дә бастырган идем. Шуннан хәтерләп калдымы икән әллә ул мине? Ә шулай да Хәсән аганың «таныш шикелле»сен ишетү рәхәт!

Шулай итеп, без Хәсән ага Туфан белән «рәсми» танышабыз. Шул көннән башлап ул мине гел Шабай дип кенә йөриячәк.

1958 елның көзе иде бу. Октябрь ахырлары-ноябрь башлары булса кирәк, радиокомитетта ыгы-зыгы килеп бәйрәм тапшырулары әзерләп йөргән көннәребез. Мин—әле өч-дүрт ай гына эшләүче «яшел» мөхәррир. Әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире. Эшнең рәтен-чиратын да бик белеп бетермим әле. Менә бүген дә мине баш мөхәррир Гали Хөсәенов пыр туздырып ташлады. «Сәяси янгырашлы лирик шигырьләр кирәк!»—диде ул. Каршыда Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан басып торганда, форсатны ычкындырырга ярыймы соң?!



*Бер төркем язучылар. Алгы планда—Х. Туфан һәм С. Хәким.*

Шулай да турыдан-туры Хәсән ага Туфанга мөрәҗәгать итәргә җөрьәт кылмыйм. Хәсән аганың Казанга кайтуына ике еллап вакыт узса да, аның чыгышларына бөтен тулай торак белән кубарылып йөрсәк тә, без әле студентлар гына идек бит. Бүген дә мин—кичәге студент. Дөрес, миндә Хәсән аганың быел яз гына чыккан яшел тышлы шигырьләр китабы да бар. Бар гына түгел, андагы байтак шигырьләрне күңелдән дә беләм. Шулай да... шулай да...

Мин тәвәккәлләп Сибгат агага сүз катам:

—Сибгат абый, бәйрәм көннәрендә тапшырырга бирәр шигырь укып китмисезме соң?

Йә Хода, шулай аяк өсте эшләнә торган эшмени соң бу?! Аны бит Сибгат Хәкимнең үенә шалтыратып *(анда да әле көннең икенче ягында гына, юкса Мәршидә апаның: «Сибгатнең эш вакыты»,—дип, телефон трубкасын кырт элеп куюын көт тә тор!)*, гозерләп сорарга кирәк иде. Инде әллә кайчан... Артыңа су кергәч кенә түгел...

Сибгат ага Хәсән Туфанга ымлый. Мин Хәсән агага ялварып карап торам. Кыяфәтем шундый булгандыр, күрәсең, Хәсән ага йомшак кына елмаеп куйды:

—Шигырьләр, дисеңме?

Минем эчкә жылы керде:

—Әйе шул, Хәсән ага...

—Хәлең аңлашыла, энем! Үзем дә радиода эшләгән кеше бит...

Монысы минем өчен яңалык иде. Хәер, Хәсән Туфанның бөтен тормышы яңалык иде бит әле безгә ул елларда.


Хәсән ага ризалашты бит әй! Башкалар жыр тыңлауны дәвам итәргә кереп киттеләр. Ә Хәсән ага:

—Мин хәзер...—дип, радиокомитетның каршыбызда ук торган китапханә ишегеннән кереп тә югалды. Үз китабын алып торырга керүе булды моның, дип уйлагандырмынмы-юкмы—хәтерләмим. Мин инде башка кайгыда идем: моны хәзер усал Гали Хөсәеновка ничек итеп аңлатырга да, ничек итеп Хәсән аганы тиз генә язып алып калырга? Әле бит ул язу студиясенең буш булмавы да бик мөмкин. Мин Гали Хөсәеновны эзләп йөргән арада, Хәсән ага чыгып китсә?.. Ике ут арасында калдым шул! Карасам, Гали Хөсәенов үзе икенче каттан төшеп килә икән! Мин аның каршысына ташландым:

—Гали абый! Хәсән ага риза!

—Нинди Хәсән? Нәрсәгә риза? Нидән кабындың әле?

Мин эшнең нәрсәдә икәнен аңлатып бирергә ашыктым. Гали Хөсәеновның төксе йөзе яктырып китте.



Х. Туфанның «Тел турында» шигыренең кульязмасы.

Китапханәбездә Хәсән Туфан китабы юк икән, әле алдырып өлгермәгәннәр. Хәсән ага аптырап тормаган, шунда ук бер өстәл читенә утырып, кесәсеннән алган бер кәгазь кисәгенә «Тел турында» дигән шигырен күңеленнән күчереп тә язган булып чыкты. *(Бу шигырь Хәсән Туфанның китапларында «Алмаз» дигән исем белән, башкачарак вариантта бирелеп килә.)* Өчәүләп Гали Хөсәенов бүлмәсенә керәбез. Язучылар берлегенең Әдәби фонды җибәргән рәсми үтенеч-хат артына яшел кара белән язылган иде бу шигырь. Аны башта Гали Хөсәенов укый, аннары мин... Хәсән ага үзе, дәшми генә, башын түбән ия төшебрәк елмаеп көтә. Шигырь бик әйбәт:

Гасырларны кичте, исән калды
Туган телебез булган бу алмаз.
Чабаталы,
Чабаталы чакта югалмады,
Татарстанлы чакта югалмас!
Югалмас!—

дигән бик көчле юллар белән тәмамлана ул.

Әмма... туган телне бозуларга каршы, аны сакларга кирәклеген ачынып язган бу шигырь Октябрь бәйрәме көннәрендә үзе генә мөстәкыйль яңгыраса, сәеррәк булыр шикелле иде. Баш тартырга да ярамый, Хәсән аганы һич үпкәләтәсе килми. Безнең аптырабрак торганны аңлаган шагыйрь үзе ярдәмгә килде:

—Бик ярап бетмәс, дисезме?

—Юк, юк! Ярый...—дидем мин кабаланып.—Шушының янына тагын берәр шигырегез булсын иде, Хәсән ага,—дип, аның берничә шигыреннен исемен әйттем.

Хәсән ага миңа кызыксыныбрак төбәп карап торды. Аның шигырьләрен белүем кәефенә хуш килде булса кирәк, ул беразга гына тынып-уйчанланып калды. Әллә соң күңеленнән берәр шигырен кичердеме икән?

—Ярый алайса, сезнеңчә булсын...—Хәсән ага, утырып, бер кәгазьгә шигырь сырлап калды. Мин беренче шигырьне машинкага илтә киттем. Шунда юл унаенда язу студиясендәге хәлләрне дә белешергә кирәк иде.

Шул рәвешле, без Хәсән ага Туфаннан микрофонга үзеннән сөйләтеп, ике шигырь язып алып калдык. Беләсе иде, исәнме икән аның тавышы язылган ул тасмалар хәзер?

Аерым кәгазьгә яшел кара белән язылган икенче шигырь Хәсән Туфан китапларында йолдызлар белән генә бирелеп, «Тагын бер кат уйладым мин...» дип башлана. Анда шулай ук шагыйрьнең безгә язып калдырган нөсхәсеннән аерымлыклар бар. Шулай булмый хәле дә юк, ул бит күңелдән генә язылган иде. Гомумән, яттан сөйләгәндә чыгышлары вакытында Хәсән ага кайбер шигырьләренә еш кына төрле үзгәрешләр кертеп сөйли иде. Әлеге һәр ике шигырьнең дә автографлары миндә кадерле истәлек булып саклана.

Безнең буын бәхетле булды. Без Такташ—Кутуйларны, Җәлил—Кәримнәрне генә түгел, хәтта Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовларны якыннан белгән Хәсән ага Туфанның күңел җылысын озак тоеп яшәдек. Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким... Алар Остазлар иделәр. Без һәркайсыбыз алар мәктәбе аша үттек. Аларның кайгыртучан һәм таләпчән игътибарын һәрдаим тойган, аларның күңел нуры яктырткан исемнәр безнең шигърияттә дистәләрчә... Гамил Афзал—Сажидә Сөләйманова, Шәүкәт Галиев—Илдар Юзиев, Равил Фәйзуллин—Рәдиф Гатауллин, Ренат Харис—Рәшит Әхмәтҗанов, Гәрәй Рәхим—Рөстәм Мингалим... Зөлфәт—Мөдәррис Әгъләмов...

Тыйнаксызлыкта гаепләмәгез: шушы саналганнар арасында мин үземне дә күрәм...

Без—бу ике Остазның рәхмәтле шәкертләре—аларның һәр икесе хакында да кайта-кайта сөйләрбез әле. Сөйләрбез дә, язарбыз да. Бу—безнең изге бурычыбыз.

Сибгат ага Хәким турында хатирәләребез аерым булыр. Бүген сүз Хәсән ага Туфан хакында. Аның безгә, безнең аңа булган мөнәсәбәтләребез хакында...

Өч дистә еллардан артык күңелне тырнап торган бер әрнүле дә, гыйбрәтле дә тарих сөйлисем килә бүген. Күңелемне бушатасым килә...

«Татарстан яшьләре» газетының 1963 ел, 14 март (№ 32) санында бер мәкаләм басылган иде. «Дистә шигырь—бер гомер» дип атала иде ул. «Совет әдәбияты» *(хәзерге «Казан утлары»)* журналының 1963 елгы беренче санында басылып чыккан Хәсән ага Туфан шигырьләре турында иде. Бүгенге көн югарылыгыннан караганда беркатлырак булып яңгыраса да, бу мәкаләне искә алуым очраклы түгел. Аның шактый гыйбрәтле дәвамы бар.

... Телефон шылтырый. Трубкада—Хәсән ага Туфан тавышы:

—Шабаймы-ы?—дип сорый ул суза төшеп.

—Әйе, Хәсән ага...—тәнем эсселе-суыклы булып китә. «Мәкаләмне укыган... Нәрсә әйтер икән?»—Исәнмесез...

—Сәлам, сәлам! Минем янга килеп чыга алмассынмы икән?..
—Кайчан, Хәсән ага?—мин бу чаклысын көтмәгән идем.
—Бүген нинди көн әле?
—Җомга, Хәсән ага...
—Иртәгә сәгать унберләргә, дисәм... ярыймы?
—Ярый...

Трубкада Хәсән аганың сулыш алуы сизелә. Пауза. Мин трубканы куймый торам. Нәрсәдер көтәм. Хәсән ага шуны сизенгән кебек була:

—Хәкимгә укыган әйберенне алып кил, дисәм...—аның шулай, җөмләне кырт кисмичә, сузыбрак өзеп калдыра торган гадәте бар.

Мин, әлбәттә, бу минутта гына Сибгат ага Хәкимгә ни-нәрсә укыганымны хәтерли алмыйм. Аңа бик күп әйберләремне укып-укытып киләм, өметсезлеккә бирелеп: «Булмый! Язуны ташлыйм...»—дип йөргән көннәремдә Сибгат аганың салмак кына, әкрен генә тавыш белән: «Ташлый алмассың... Ул сине якаңнан алган инде...»—дип әйткән сүзләре дә бар иде. «Кына гөле» дигән поэмамны редакцияләр кире каккан бер вакытта, Сибгат аганың, дилбегә буе озын шул әйберне иренмичә укып чыгып, ахырдан: «Без көтмәгән яктан ачылган бу шагыйрь, кызык шагыйрь, яңа шагыйрь...» дип, өметләндереп язып куюы үзе ни бәя тора иде!

Хәсән ага икеләнеп-аптырабрак калганымны сизенде бугай. Йомшак кына итеп өстәде:

—Теге, апаң турында...

Йөземә кайнарлык йөгерде. Сүз минем әле язылу, эзләнү хәлендә булган поэмам турында бара иде. Әйе шул, мин аның бер кисәген Сибгат ага Хәкимгә укыган идем. Сибгат ага үзе өзеп кенә бер сүз дә әйтмичә: «Туфанга укытып карамыйсыңмы?»—дигән иде бит! Димәк, алар бу хакта сөйләшкәннәр булып чыга... Дөресен әйтергә кирәк, мин Хәсән агадан бераз шүрлим. Ул минем «Яшь ленинчы» тирәсенә (инде мин шул газетада әдәбият-сәнгать бүлегендә эшли башлаган идем) «татар шигырен ватып-сындырып йөрүче» егетләрне—Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллиннарны сыендыруымны да өнәп бетерми шикелле. Аларны «бозуда» гаепли. «Ак шигырь белән иркенле шигырь «үги»ләрме?» дип, матбугатта кайнар бәхәсләр кузгатырга да әле ике елдан артык вакыт бар. Ә Хәсән ага Туфанга бер генә әйберемне дә укытып караганым юк әле. Әй, беткән баш беткән! Үзе дәшеп-чакырып торганда... Тотып ашамас әле...

—Рәхмәт, Хәсән ага...—дип әйтә алдыммы икән—хәтерләмим.

Бу турыда алгарак бер сикереш ясап алуны кирәк саныйм.

«Татар шигырен ватып-сындырып йөрүче егетләр»—Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин *(бүгенге Рәдиф Гаташ)* иҗатларына да Хәсән ана Туфан гел тискәре караштa гына яшәмәде. Бу егетләрнең таланты елдан-ел тирәнрәк ачыла барганын күрде, аларның шигъриятъгә киләчәкләренә ышанды. Бу җәһәттән аның Сибгат ага Хәким белән Аккош күлендә (өлкән әдипләребезнең дачалары шунда иде) еш очрашып, сөбхәтләшеп-фикерләшеп яшәве дә ярдәм иткәндер. Сибгат ага Хәким исә бу яшь шагыйрьләргә һәрвакыт хәерхаһлы булды.

Менә бер дәлил.

1969 елда Равил Фәйзуллинның «Мәрмәр» исемле шигырьләр китабы басылып чыкты. Аны шигърият сөючеләр дә, тәнкыйтьчеләр дә бик җылы кабул иттеләр. Хәтта шигырьдән инде яшьлегендә үк читләшеп, прозага күчкән, саллы-саллы повестьлар, бихисап күп хикәяләр иҗат иткән күренекле әдибебез Фатих ага Хөсни дә «Социалистик Татарстан» газетының бер санында Равил Фәйзуллинның әлеге китабы турында «Мәрмәр ясый безнекеләр» дигән матур тәнкыйть мәкаләсе белән чыккан иде. Ул бит татар теленең иң тирән катламнарына төшеп, телнең бар аһәңен-тәмен белеп яза торган, «теленә шайтан төкергән» әдип! Инде шундый мөхтәрәм, абруйлы Фатих Хөсни дә мактый, шагыйрьнең китабын укучыларга куанып тәкъдим итә икән, икенче бер шагыйрь әйтмешли, «юкка түгелдер, юкка түгелдер»...

Инде көз кергән. Сентябрьнең кояшлы, җылы көннәре тора. Алтын көз! Мин Бауман урамындагы Матбугат йортыннан чыгып, ашыга-ашыга өйгә кайтып барам. Иртәгә таң белән Габделхәй Сабитов, Мирсәет Яруллин һәм мин Мишә буена балыкка китмәкче идек. Шуңа әзерләнәсе, җыенасы бар. Килеп туктаган троллейбуска йөгерәм генә дигән идем:

—Шаба-ай!—дигән тавыш тукталырга мәжбүр итте. Борылып карасам—Хәсән ага Туфан! Ул Матбугат йортының аскы катына урнашкан китап кибетеннән чыгып килә икән. Кулында—китаплар. Берсе—Равил Фәйзуллинның «Мәрмәр»е, икенчесе—»Беренче карлыгачлар». Яшь шагыйрьләрнең күмәк җыентыгы. Аны мин редакцияләп чыгарган идем.

—Исәнмесез, Хәсән ага!—«Чукынды балыкка җыену...»—дип, эчтән генә көрсенеп, аның янына киләм.

—Сәлам, сәлам! Менә, китаплар алдым әле. Монысын син чыгаргансың икән,—дип, Хәсән ага «Беренче карлыгачлар» китабын күрсәтә.—Өметле шагыйрьләр. Әле кибеттә актаргалап тордым да, Мөдәррис шигырьләренә төртелдем. Шәп бит!

—Әллә шагыйрьләр секциясе үткәрәсезме? Исәнме, Марс! Без иртән күрешкән идек инде,—Сибгат ага Хәким икән. Ул Хәсән агага баш кагып кына ала. Ничек сиздермичә генә яныбызга килеп баскан, диген? Әңгәмәбезгә кушыла:—Равилне укырга булдыңмы? Укы-укы! Фатихның мәкаләсеннән соң, бигрәк тә...

Күренеп тора: болар инде Фатих Хөсни мәкаләсе турында фикер алышканнар булса кирәк.

Хәсән ага көлемсери:

—Фатих—Фатихча инде. Күпертебрәк мактарга ярата,—ди.—Әмма Фәйзуллинны ачып бирергә тырышкан. Әйбәт язган...

—Шагыйре әйбәт бит...—Сибгат аганың күзендә хәйләкәр очкыннар кабына.—Көчле яшьләр килә... Шулаймы, Марс?—дип, ул кинәт кенә мине дә сүзгә тарта.

—Шулай, Сибгат ага. Алар без генә түгел инде,—дим мин дә.

Хәсән ага ризалаша:

—Менә, Шабайга да шуны әйтә идем әле. Өметле яшьләр, дим...

Мин янә сүз кыстырам:

—Тырыштык инде. Чүп-чарын кертмәскә тырыштык,—дип, Хәсән ага кулындагы «Беренче карлыгачлар» китабына ымлыйм. Үз эшем турында да җылы сүз ишетүе рәхәт бит!

—Фәйзуллиннар мәйдан тотар, дисеңме, Сибгат?—Хәсән аганың уе башка юнәлештәрәк икән. Сибгат аганың җавабын да көтмичә, үзе үк раслап:—Тотсыннар. Шәүкәт, Илдарлардан кыюрак буын. Әле үсәселәре, житлегәселәре алда...—ди.

—Үсәрләр...—Сибгат ага ышаныч белән өсти:—Киләчәк аларныкы, аларныкы!

—Килешәм!—дип, кулы белән һаваны ярып ала Хәсән ага.—Фәйзуллиннар артыннан Мөдәррисләре дә килә бит, Зөлфәтләре дә... Иш янына куш...

Әлеге очрашу-сөйләшүдән соң, Хәсән ага яшел кара белән өндәү вә сорау билгеләрен куя-куя, Равил Фәйзуллинның «Мәрмәр»ен бик жентекләп укыгандыр, шөт. Моның шулай булуына шигем юк. Чөнки янә бер сөйләшүдә (кайда, кайчан икәне тәгаен генә хәтеремдә калмаган) ул шул ук шагыйрьләр турында: «Болар такмакчы Мәхмүт түгел инде...»—дип әйткән иде. Ә Мәхмүт Хөсәенне ул бөтенләй шагыйрь итеп танымый иде шикелле.

Равил, Ренат, Рәдифләр Остазларның ышанычын тулысынча акладылар. Хәзер алар һәркайсысы—күренекле шагыйрь!

Инде янадан Хәсән ага Туфанга курка-курка гына барган көннәргә әйләнеп кайтыйк.

... Маяковский урамындагы 23 нче йорт. Бу йортта шактый күп һәм шактый күренекле әдипләр тора. Минем монда килгәләгәнем бар иде инде. Ләкин Хәсән ага Туфанга беренче килүем. Өйдә ул ялгызы гына иде. Без аргы бүлмәгә үттек. Һәркайда китаплар, кульязмалар... Бигрәк тә кульязмаларның төрле җирдә тәртипсез таралып ятулары хәтердә калган. Бүлмә уртасында—өстәл. Өстәл өстендә—төймәсенә басса, сигарет яки папирос чыгарып бирә торган бер кызыклы савыт-җайланма. Анда төрле сорт сигаретлар, папирослар тутырылган. Өстәл өсте тулы газет-журналлар, машинкадан чыккан, күбрәге исә яшел кара белән чуарланган кәгазь битләре. Таралып-җәелеп яткан газетларның да күпчелеге шул ук яшел кара белән тамгаланган.

Урамда яз, март уртасы булуга карамастан, бүлмә салкынча. Хәсән ага ак күлмәк өстеннән көлсу төстәге бәйләгән йон свитер кигән. Свитер аның какча, ябык гәүдәсен бераз булса да тулыландырып тора шикелле.

Башта без «Татарстан яшьләре»ндәге әлеге мәкалә хакында бер-ике авыз сүз

алыштык. Мәкалә өстәл өстендә ачып куелган хәлендә ята, яшел кара белән төшерелгән сорау һәм өндәү билгеләре дә байтак күренә. Астына сызып-сызып куелган урыннары да шактый. Мин: «Хәсән ага нәрсә әйтер икән?»—дип, куркыбрак кына утырам. Ә ул ни өчендер бәя бирергә ашыкмый, алай гына да түгел, мәкаләне бөтенләй бер читкә алып куя. Күңелне кыбырсытып тормасын, диюе булды, ахрысы.

—Шабай, син Минзәләдәнме әле?

Кинәт бирелгән сораудан мин сискәнеп китәм.

—Әйе, Хәсән ага...

—Үзен турында сөйләмәссенме?—ул «сөйлә» дип катгый итеп әйтми, минем үз иркемә куя.

Мин төртелә-төртелә сөйли башлыйм. Сизенәм: бу сөйләү тикмәгә түгел. Безнең бик күбебез—мин ул вакыттагы яшьләрне әйтәм—Хәсән ага Туфан өчен, Пушкин әйтмешли, «саумы, яшь һәм таныш түгел буын» бит. Әтиемнең укытучы булганын, сугышта хәбәрсез югалганын әйткәч, Хәсән ага: «Әдәбиятчы идеме?»—дип сорап куя. Физик-математик икәнен белгәч, дәшми, башы белән генә ымлый: «Дәвам ит!»—янәсе. 1941 елның кышында Минзәлә базарында еракган гына Муса Җәлилне «күргәнемне» әйтүгә, ул җанланып китте: «Да-а-а?»—дип, ышанырышанмас кабатлап сорады. Мин, тәфсилләбрәк, базарга апа белән итек сатарга килүебезне, шул вакыт чаңгылы берничә хәрбинең яныбыздан узып китүен, кемнәрнеңдер «Муса Җәлил... Муса Җәлил...» дип пышылдашуларын сөйлим. Муса Җәлилне «күрүемнең» бар булганы шул. Аннары Җәлил политруклар курсында укыган бинада—ул педучилище бинасы иде—сугыштан соңгы елларда үземнең дә укуымны, беренче «тере язучыны»—Гомәр ага Бәшировны шунда күргәнемне сөйлим. Хәсән ага урыны-урыны белән елмаеп, күбрәк уйга калып тыңлый бирә. Сөйләвем озынга китте булса кирәк, Хәсән ага кулын җилкәмә салды: «Апаң—теге апаңмы?» Мин төртелеп туктап калдым. Хәсән ага әнә кай тирәдә йөри икән!

Әйе, апа «теге» апа—«Әби-апа» иде...

Поэмага «Әби-апа» исемен дә Хәсән ага Туфан тәкъдим итте. Анысы соңрак, янына кат-кат барып йөргәннән соң булды. Поэманың әүвәлге исеме «Әрнү аралаш» иде.

—Бу исем белән үткәрмәсләр,—диде тәҗрибәле Хәсән ага.—«Әби-апа» ничегрәк булыр? Уйла әле. Укучыны да ымсындырып тора...

Мин аның белән килештем—димәк, «Әби-апа»!

Мөгаллимә Усман кызы Бикташева—әниемнең бертуган апасы—авылда гражданнар сугышы, сәнәкчеләр күтәрелеше вакытларында кызылларга ярдәмләшеп, аннары колхозлашу елларында башлап йөрүчеләрдән була. Авыл советы рәисе булып эшли. Сталинның шәхес культы елларында репрессияләнә, «троцкийчы, халык дошманы» дигән яла ягылып, Минзәлә төрмәсендә судсыз-нисез ике ел утырып чыга. Энесе Гали абый—шулай ук актив комсомол егет, авыл хәбәрчесе—Сталин исеменә хат яза. Бәхеткә, хатның ярдәме тия—апаны коткаралар. Әмма озак та үтми, аның иренә яла ягыла: ул да «халык дошманы», имеш! Бөек Ватан сугышына үзе теләп китеп, штраф батальоннарда сугышып йөреп, юк гаебен каны белән юа ул. Сугыш елларында мин әнә шул апаларда яшәдем. Ул миңа әнием кебек үк кадерле иде.

Сибгат ага Хәкимгә өзекләрен укыган, тарихын сөйләгән поэманың геройлары әнә шулар булырга тиеш иде. «Әби-апа»ны укучыларның: «Анда бит шәхес культы мәсьәләсе бик аз гына төсмерләнә»,—диярга тулы хаклары бар. Әйе, ни кызганыч, шулай шул...

...Хәсән ага Туфан кулында—тышлыгына Мао Цзедунның барельефы төшерелгән һәм алтын иероглифлар белән ниндидер цитата басылган калын каты тышлы дәфтәр. Бу—минем «Кытай дәфтәре» дип йөртә торган шигырьләр дәфтәрем. Аны миңа институтта укыган елларымда бер кытай кызы бүләк иткән иде. Ул елларда Казанда укучы Кытай студентлары шактый иде. Әле Кытай белән безнең аралар бозылып өлгермәгән чак. Хәсән ага дәфтәр тышындагы барельефка бармагы белән басып-басып алды да: «Вота нинди икән ул Мао!»—диде. Аның өчен Кытайдагы Мао культы, Сталинның шәхес культы кебек үк, йөрәк әрнеткеч хәл иде, әлбәттә.

«Кем көчлерәк—иллә шул яши!»—дип,
Уйгурларны йота Маолар...

Хәсән ага Туфанның бу юллары аның Кытайдагы хәлләргә мөнәсәбәтен ачык күрсәтә булса кирәк. «Әби-апа»ның басылмый калган вариантындагы:

Янцызыдан искән шикле җилләр
Кабат раслый безгә боларны.
Юк, күрәсе килми аждаһаны—
Бездә инде үлгән еланны,—

дигән юллар да турыдан-туры Хәсән аганың киңәшен тотып язылган юллар иде. Маоның барельефына бармагы белән төрткәләп: «Бу хакта да әйтеп үтәсе иде сиңа»,— дигән иде ул.

«Әби-апа»ның язылган кадәресе укылып бетә. Шуннан без кухняга чыгып, тәрәзә форточкасына төтен өрә-өрә, сүзебезне дәвам итәбез. Хәсән ага шәхес культы мәсьәләсен тирәнрәк ачарга, публицистик гомумиләштерүләр ясарга кирәклеген сөйли. Миннән кайта-кайта биографик детальләр сөйләтә дә: «Менә бу турыда яз, яме!»—дип, мине тиешле урынга «борыным белән төртә». Ул «борынымны төртеп» яздырган юллардан бер-ике мисал:

... Утыз жиденче ел. Утырасын
Милиция котеп бүлмәндә.
Синдәйләрне, апа, лагерьлар да,
Тынчу төрмә дә
Күп йотачак әле, ай-һай бик күп...
Бәла килде меннәр-меннәргә...
Төрмәләрдә нахак үткән еллар
Табар әле үзенең исемен.
Саулыгыңны гына түгел, апа,
Иманыңны алды ул синең,
Гаделлеккә булган иманыңны...

Яки:

...Лагерьларда инрәп ятканнарның
Себерләрдә, Камчаткаларда
Әрнүләре, үлем сулышлары
Ишетелмәде кайчакларда да...
Ишетелмәде... Ишеттермәделәр—
Хөкем сөрә иде Бериялар.
Аларның сүз бары бер тирәдә:
«Даһи юлбашчыбыз!»—диялар.

Бу юллар хәтта бераз Туфанчарак та янгырый иде. Әмма, кызганыч... Хәер, анысы турында соңрак әйтелер.

«Әби-апа» шактый озак язылды. Хәсән ага миңа ашыкмаска, һәр шигъри юлны үз кичерешләрем аша үткәрергә киңәш бирде. «Кытай дәфтәре»н күтәреп, дәфтәр эченә язылган вариантларны акка күчереп тә, машинкада бастырып та, Хәсән ага Туфан янына янә берничә кат барырга туры килде әле. Үз кулы белән яки теле белән бер генә юл да кертмәде Хәсән ага поэмага. Без бары озаклап сөйләшеп кенә утырабыз. Әмма бу әңгәмәләрнең миңа нинди рухи азык булганлыгын, ничек илһамландырганын белсәгез икән сез!

1964-1965 елларда «Әби-апа»ны мин газет-журнал редакцияләренә тәкъдим итеп карадым. «Социалистик Татарстан» газетының ул вакыттагы әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Флорид Әгъзамов аны бик яратып алып та калган иде. Бераздан, бер сүз дә әйтмичә, кире кайтарып бирде. Басылмавының сәбәбен сорагач, кулларын як-якка җәеп, башы белән түшәмгә таба ымлады. Флорид Әгъзамов акыллы егет— мин эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлап алдым. Илдә шәхес культын фаш иткәннән соң булган «җепшетү» («оттепель») суынуга йөз тоткан чаклар иде бу... Хакимияткә Брежнев, ата сталинчы «соры кардинал» Суслов кебекләр менеп утырган иде... Житмәсә, Евгений Евтушенконың «Сталин варислары» дигән шигырен тәрҗемә итеп тә «янган» идем...

Шулай итеп, Хәсән ага Туфанның миңа булышулары җилгә очты...

Ә поэманы бастырасы, укучыларга ирештерәсе килә! Мин инде кыскартуларга да каршы түгел. Әсәр бит дүртенче елын дөнья күрә алмый ята...

Ниһаять, «Әби-апа» Бөек Октябрь революциясенең илле еллыгына багышланып, 1967 елда бик нык үзгәртелеп-имгәтелеп, искә төшергәндә мине һаман кызарырга мәҗбүр итәрлек булып басылып чыкты. Мин аны Хәсән ага Туфанга күрсәтергә оялдым. Әмма ул үзе алып укыган булса кирәк. Очрашуларыбызның берсендә: «Харап иткәнсең ләбаса теге апанны!»—дип ярып салды. Шунда гына мин үземнең нинди дәр начар эш кылганымны бөтен тирәнлеге белән аңлап алдым... Моны апа да (ул әле исән иде), Хәсән ага Туфан да гафу итә алмаслык начар, бик начар гамәл иде бу...

Үз иманыңнан, үз принципларыңнан бервакытта да кире чигенмәскә кирәклеген мин, мөгаен, менә шул чакта чын-чынлап төшенгәнмендер. Ачы, әмма бик кадерле сабак иде бу минем өчен.

«Әби-апа»ны үзем теләгән, син күрергә теләгән вариантта барыбер бастырырмын әле мин, Хәсән ага! Анда шундый юллар да булыр:

> Китаплары кайтты, исемнәре...
> Берән-сәрән кайтты исәннәре—
> Мин Шабайлар, Хәсән Туфаннар:
> «Кабул итегез, дип, туганнар...»

Ах, ишетсәң иде син мине, Хәсән ага...

Һәм бу изге теләгем тормышка ашты! Ил башына Михаил Горбачев килеп, «үзгәртеп кору» чоры башлангач мәйданга чыккан хәбәрдарлыкның ярдәме тиде. «Әби-апа» беренче исеме белән—«Әрнү аралаш» булып, Хәсән ага Туфан кулыннан үткән хәлендә, бозылмыйча-имгәтелмичә, минем 1989 елда дөнья күргән «Гомер уты» дигән китабыма кертелде.

Әмма ни аяныч!.. Хәсән ага Туфан да, Сибгат ага Хәким дә юк иде шул инде...

> ...Кайсыгызның кулы җылы?—
> Бәйлисе бар йөрәкне...

Шигырьдә шулай дип күнелен ачып салса да, тормышта Хәсән ага Туфан алай чишелеп китеп, аһ-зарларын чәчәргә яратмый иде. Үзе өчен сорый да, йөри дә белмәде шагыйрь. Ә менә башкалар өчен, бигрәк тә үзенең рухына якын яшь шагыйрьләр өчен аның кулы һәрвакыт җылы булды.

Татарстан китап нәшриятында унөч ел эшләп, мин Хәсән ага Туфанның бер генә мәртәбә дә үз китабын чыгару артыннан йөргәнен хәтерләмим. Аның беренче китабын да бит, шагыйрь үзе Кавказ һәм Урта Азия якларында җәяүләп сәяхәттә йөргәндә, дуслары Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәтиләр җыеп чыгара. Туфан үз китабын бер китапханәгә Назыйм Хикмәт шигырьләрен эзләп кергәч, очраклы рәвештә генә күреп ала. Аның соңгы китапларын да башкалар (аерым алганда, Мәсгут Гайнетдинов, Нил Юзиев) төзеп чыгардылар.

Ә менә «Мөдәррис кульязмасын китердеме?» яки «Зөлфәт китабы ни хәлдә?» кебегрәк сорау-үтенечләре була торган иде Хәсән ага Туфанның. Алар өчен аеруча борчыла иде ул.

Зөлфәт, дигәннән...

1968 ел. Минем «Чаян» редакциясендә эшләп йөргән көннәрем. Бервакыт Хәсән ага Туфан мине коридорда очратып туктата:

—Шабай, син коммунистмы әле?—дип сорый ул, «коммунистмы» сүзенә басым ясап.

Көтелмәгән сорау мине аптырашта калдыра, әлбәттә. Хәсән ага авызыннан моны ишетү ничектер сәеррәк. Мондый катгый сорау Афзал ага Шамов яки Ибраһим Гази авызыннан чыкса, табигыйрәк булыр иде. Чөнки алар, нинди дә булса берәр йомыш кушарга кирәк булганда, шулай «үгезне мөгезеннән эләктереп алырга» ярата иделәр. Ә бирегә Хәсән ага Туфан кистереп сорый. Йөзе дә житди-уйчан күренә.

—Әйе, Хәсән ага...—дим мин, сүзләремне суза төшебрәк. Үзем уйлыйм: «Ни өчен болай сорый икән әле ул?»

*(Ул заманнарда «коммунист» сүзе хәзерге кебек каһәрле сүз түгел иде. Халык та*

*аларга ышана-инана иде. Хәсән ага Туфанның үзенең дә: «Вөҗданым да, намусым да бары Ильич юлында...»—дип язган шигъри юллары бар. Шагыйрьнең ихластан әйтелгән сүзләре иде алар. Нишлисең—без барыбыз да үз чорыбыз балалары...)*

Хәсән ага мине тәрәзә буенарак тарта. Бераз текәлеп карап торганнан соң гына, сүзне дәвам итәргәме-юкмы дигән кебегрәк кенә итеп әйтеп куя:

—Син Зөлфәткә ничек карыйсың?

—Әйбәт карыйм, Хәсән ага!

Зөлфәтне Мөслим районының Урәзмәт урта мәктәбендә укыткан елларында Рәдиф Гатауллин «ачкан» иде. Ул аның беренче шигырьләрен «Яшь ленинчы» газетына, «Казан утлары»на тәкъдим итеп, «бик сәләтле малай» дип хатлар да язган иде. Мәсьәлә ачыклана төште шикелле.

Күптән түгел генә Татарстан язучыларының VII съезды булып узган иде. Съезд Татар дәүләт академия театры бинасында узды. Гадәт буенча, галеркада—студентлар «республикасы». Бервакыт шуннан—югарыдан залга уйнаклап-уйнаклап кәгазьләр ява башламасынмы! Бер төркем студентларның үзләренчә листовкалар ташлавы икән бу. Листовка дигәннәрендә әллә нәрсә юк, әлеге дә баягы, шул яшьләр өчен әдәби журнал чыгару мәсьәләсе... Баш китәрлек нәрсә түгел инде...

Залда, әлбәттә, ыгы-зыгы купты. Әлеге кәгазьләрне җыеп ала башладылар. Президиум өстәле артында утыручы рәсми иптәшләрнең йөзләре хәвефле төстә сузылып калган иде.

Бер дә алай «контр» эшлек нәрсә булмаса да, яшьләрнең бу «юләрлеге» шома гына узып китмәде булса кирәк. Тиешле органнар тарафыннан тиешле «оргнәтиҗәләр» ясалды шикелле.

Хикмәт шунда, бу «бунтовщиклар» арасында Зөлфәт тә бар иде. Әлеге ыгы-зыгы вакытында галеркадагы студентлар төрле якка сибелә башлагач, тәнәфес игълан ителдеме-юкмы—хәтерләмим. Әмма Зөлфәтне мин ничектер залга кертеп утырткан идем бугай.

***(Бу вакыйга хакында тулырак мәгълүматны «Идел» журналының 1994 ел, № 7 саныннан һәм «Казан утлары» журналының 1999 ел, № 7 саныннан Рәфикъ Юнысның «Өзелгән спектакль» исемле мәкаләсен укып белергә мөмкин.)***



*Х. Туфан яшь шагыйрьләр арасында. Уңнан сулга: Р. Вәлиев, Р. Гаташ, Г. Морат һәм Р. Зәйдулла. 1979 ел.*

Кыскасы, Зөлфәт өстендә шулай итеп болытлар куера башлаган чак иде бу. Хәсән ага Туфанның тел төбе кая таба барганы аңлашыла.

—Берәр эш табасы иде шул егеткә...—диде Хәсән ага. Аннары, тәрәзә аша урамга карап, бераз тынып торганнан соң, тавышын түбәнәйтә төшеп өстәде:— Югалтмыйсы иде аны...

Мин Хәсән ага Туфанга өздереп кенә бер сүз дә әйтә алмадым. Чөнки әле үзем дә, ике ел чамасы «эшсез йөреп», янарак кына «Чаян»да эш тапкан идем. Ә Зөлфәтне чыннан да югалтырга ярамый... Хәсән ага кадәр Хәсән ага бу хакта сүз алып бара икән, димәк, эш җитди...

Ул вакытта «Чаян» журналында баш мөхәррир булып Альберт Яхин эшли иде. Журналның абруе зур. Альберт Яхинны КПССның Татарстан өлкә комитетында да бик яраталар. Әлбәттә, Зөлфәткә шунда үзебезнең тирәдәрәк эш юнәткәндә бик әйбәт буласы. Хәсән ага Туфанның гозерен озын-озакка сузу да яхшы түгел. Мин баш мөхәрриргә Зөлфәт турында сүз каттым. Альберт Яхин тимерне кызуында сугарга ярата. Ул бер генә сорау бирде:

—Серкәсе су күтәрми торган малай түгелме?

Ул якларын бик үк белеп бетермәсәм дә:

—Юк, юк!—дидем мин ашыгып.

Альберт Яхинның бер «алтын законы» бар иде: «Чаян»да, көлкеле журнал буларак, иң элек үзеңнән көлгәнгә түзә белергә кирәк.

Икенче көнне үкме, Зөлфәт инде баш мөхәррир каршысында басып тора иде. Альберт Яхин ишек төбендә таптанып торган егеткә күтәрелеп карады да:

—Аягыңны сөртеп кердеңме?—диде. Җавап көтеп, күзлек пыялаларын сөртергә кереште.

Зөлфәт аптырап аякларына карады. Аяк киеме чиста иде аның.

—Юк...

—Самолюбиең булса, аны ишек төбенә җәеп, аягыңны шуңа сөртеп кер, диюем, Зөлфәт. Бездә шунсыз эшләп булмый.

—Ә-ә-ә...—дип көлеп җибәрде Зөлфәт. Аның шушы көлүе мәсьәләне хәл итте дә куйды.

Иртәгесен «бунтарь» Зөлфәт «Чаян» бүлмәләренең берсендә башын иеп, тыйнак кына эшләп утыра иде инде. Бу хәлләрдән соң утыз елдан артык вакыт үтеп китте, Зөлфәт һаман да «Чаян» журналы хезмәткәре. Шунда урнашуында Хәсән ага Туфанның да «җылы кулы»ның йогынтысы барлыгын сизмәгән дә булгандыр әле.

Хәсән ага Туфан игелеген күргән бик күпләр шулайдыр. Ул яхшылыкны сиздерми генә эшләргә ярата иде. Сөйләнеп йөрми генә...

Хәсән ага Туфан калдырган эстафетаны дәвам итүчеләр, бармы сез? Кайсыгызның кулы җылы?..

1968 елның көзендә Горький (хәзер Түбән Новгород) өлкәсенең Сергач якларында татар әдәбияты атналыгы уздырылган иде. Анда катнашучы әдипләр ишле булып, ике төркемгә бүленеп эшләделәр. Безнең төркемнең җитәкчесе—Мирсәй ага Әмир. Арада иң өлкәнебез, иң хөрмәтлебез Хәсән ага Туфан иде, әлбәттә. Кунарга кергәндә Мирсәй ага белән Хәсән ага гел бергә булалар һәм, төрле йомыш-яракка кирәк була-нитә калса диптер инде, мине дә үзләре белән алалар иде. Көндез мәктәпләрдә балалар белән очрашулардан, кич авыл клубларында ярты төнгә кадәр сузылган кичәләрдән соң, аш-мәҗлес кебекләрендә дә бер-ике сәгать утырылган була. Бу аксакаллар арунын инде ар ягына чыкканнардыр дип уйлыйсың. Юк! Хуҗаларның хөрмәтләп җәеп биргән урын-җирләренә менеп яткач та әле берәр сәгать әңгәмә дәвам итә, уен-көлкеле сүзләрдән төнге авыл өе ярылып китәр шикелле тоела. Булса булыр икән шулкадәр энергия, шулкадәр җегәр! Бигрәк тә Хәсән ага Туфан үзенең тормыш сөючән тынгысыз җаны белән хәйран калдыра иде безне.

Кайсыдыр бер авылда без куна кергән йорт клубка якынрак булып чыкты. Без инде кайтып яткан, уен-көлкеләребез дә сүнгән, Мирсәй ага «дизелен дә кабызып җибәргән» (ул йоклаганда гырлый) иде. Менә бервакыт Хәсән ага шыпырт кына урыныннан кузгалды да тәрәзә буена килеп тыңланып тора башлады. Мин дә колакны торгыздым. Клуб ягыннан тонык кына булып җыр тавышы килә: «Менәргә-ә-ә иде-е... Урал тауларына-а-а...» Бу Илһам Шакиров тавышы иде. Хәсән аганың Илһамның җырлаганын бик яратканы мәгълүм әйбер. «Киенеп чыгып китәргә

уйламасын тагын...»—дип, урынымны шыгырдатып торып утырдым. Хәсән ага пышылдап кына: «Ишетәсеңме?»—дип сорады. «Әйе...» «Болай сонлап кайда җырлый ул? Кул чабулары да ишетелә кебек...»—Хәсән ага тәмам әсәренгән иде. Мин эшнең нәрсәдә икәнен аңлатырга ашыктым. Авыл клубы мөдире бер килүендә Илһам Шакировның концертын магнитофонга язып алган икән. Шуны еш кына, халык соравы буенча, кабатлыйлар, халык клуб тулып тыңлый икән. Менә безнең дә әдәби кичәбездән соң, «Илһам Шакиров концерты» дәвам итә... «Татарстаннан читтә шул алар... Сагыналардыр татар моңын...»—диде Хәсән ага, урынына кире менеп яткач. Мин дәшмәдем. Татарстаннан читтә күпме еллар кангырап йөргән шагыйрь Хәсән Туфанны Урал буендагы җәйләүләрдә көтү көтеп, авыз эченнән генә татар җыры көйли итеп күз алдына китердем... Сагынмый буламы соң үз моннарыңны?.. Әле бүген генә Хәсән ага мәктәп балаларына «Юкмыш бабай» әкиятен сөйләгән иде.

... Шулай итеп, торнаның
Аягына тагылып,
Еракларга-а-а киттем мин,
Туган илдән аерылып...

Авылларда атналык тәмамланып, район үзәге Уразайга кайтып төштек. Безнең көндезебез буш. «Ял итегез»,—диделәр. Кич белән район мәдәният йортында йомгаклау кичәсе үткәрергә тиешбез. Аннары Казанга... Барыбыз да шактый йончыган, арыганбыз. Кунакханәдән чыгасыбыз килми. Караватларда сузылышып ятабыз. Ә менә Хәсән ага ни өчендер тынгысызлана. Ул ятмаган, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә, әледән-әле тәрәзәгә килеп, урамга карап тора. Мин аны күзәтәм. Хәсән ага сизенеп, җәлт кенә минем якка борыла:

—Әйдә йөреп керәбез!—ди ул, егетләрчә җиңел итеп.

Без урамга чыгабыз. Урамда пычрак, яңгыр явып үткән. Салкынча. Аяк асларыбызга карый-карый, әкрен генә түбән очка таба төшеп барабыз. Шунда кинәт кенә әллә нәрсә булды, мин аңыша да алмый калдым. Урамның икенче ягыннан өстенә кожанмы-плащмы кигән, аякларында кирза итекле берәү:

—Хәсән абыем... Хәсән абыем... Бу синме?—дип безгә ташланды.

Хәсән ага әлеге сәер кешенең кочагында бөтенләй югалып калды.

—Әллә танымыйсыңмы, Хәсән абый?..—әзмәвердәй ир кешенең күзләрендә яшь иде...

—Ба-а-а! Синме бу, брамат?!

Хәсән ага Туфан нindидер исем әйтте. Алар яңадан бер-берсен кысып кочаклаштылар, җилкәләреннән кагыштылар. Хәсән аганың да күзләре яшьләнгән иде...

Мин аларның икесен генә калдырырга ашыктым. «Шушы көтелмәгән очрашуны алдан сизенеп, күңеле борсаландымы икәнни Хәсән аганың? Әүлиялеге бардыр, билләһи! Кара син, ә!»—әнә шундый уйлар белән кире борылдым.

Кунакханәдә:

—Хәсән аганы кайда калдырдың?—дигән сорауга, сөйлисем килеп, телем бик кычытып торса да, нигәдер:

—Хәзер кайта...—дип кенә җавап бирдем. Теләсә, үзе сөйләр әле.

Хәсән ага шактый озак торып, бик әсәрләнеп кайтып керде. Барыбызга да берьюлы мөрәҗәгать итеп:

—Беләсезме, мин кемне очраттым, егетләр?!—диде.—»Теге» елларда үзем белән бергә булган бик якын кешемне...

Ул кеше хәзер шушы Уразайда баш зоотехникмы, баш ветврачмы булып эшли икән. Сергач мишәре икән. Йомгаклау кичәсеннән соң, ул Хәсән аганы үзләренә алып китте. Хәсән ага кунакханәгә икенче көнне иртән генә, йокысызлыктан күзләре кызарынган хәлдә кайтып керде. Күрәсең, алар төн буена керфек тә какмый сөйләшеп утырганнардыр. Нинди очрашу бит!

Без район ашханәсенә соңгы тапкыр чәйләп алырга керәбез. Урамда безне автобуслар көтеп тора. Вакыт тар, озаклап утырырга чама юк. Алдыбызда кыздырылган карп балыклары тау-тау өелеп ятса да, аяк өстән генә дигәндәй, капкалап торганда, Хәсән аганың әлеге «брамат» безнең өстәлгә бер зур графин китереп куймасынмы!

—Саф спирт, Хәсән абый...—диде ул, ничектер унайсызланыбрак. Хәсән ага да унайсызланып калган иде:

—Да-а-а?.. Кирәкмәс иде...—диде.

Без яшьләр шаулашып, ниндидер уен-көлке сүзләр әйтеп, бу унайсызлыкны бетерергә тырыштык. Өстәл өстендә уймак-уймак кына рюмкалар да бар иде. Газиз Мөхәммәтшин:

—Сыйлаганда су эч, диләрме әле?—дип, бер рюмкага графин авызыннан коя да башлады.

—Тукта әле, Газиз,—диде Хәсән ага.—Бер нәрсә эшләп күрсәтәм, кайсыгыз шуны кабатлый ала—графин шуныкы!

Хәсән ага Газиз Мөхәммәтшин сала башлаган рюмканы кулына алды. Рюмкада спирт күп түгел, бер йотым чамасы гына булгандыр. Менә Хәсән ага шырпы сызып, шуна якын китерде. Рюмкага гөлтләп зәнгәр ялкын капты. Хәсән ага аны тиз генә авызына каплады. Без бу хәлгә исебез китеп карап торган арада, Хәсән ага телгә килде:

—Йә, егетләр, кайсыгыз кыю?

Рюмкага янадан Газиз Мөхәммәтшин тотынды. Хәсән ага эшләгәнне бик тырышып башкарырга теләсә дә, Газиз авызын пешерде, зәнгәр ялкын аның ияге буйлап та агып төшкән иде. Без дәррәү көлеп җибәрдек. «Бәхет сынарга» теләүче башка кеше табылмады. Аннары безне автобусларга утырырга да чакыралар иде инде.

—Шартымны үти алмадыгыз, графин өстәлдә кала, егетләр!—дип хәйләкәр елмайды Хәсән ага. Үзе, күчтәнәч керткән әлеге танышын иңеннән кочып алып, ана нәрсәдер сөйли-сөйли урамга атлады.

Спиртлы графин моңаеп өстәлдә утырып калды... Әгәр дә ул безнең белән Сергачка барып житсә, поездга да кереп утырса, ни хәлләр булып бетәр иде икән—әйтүе кыен. Ярый әле Хәсән ага бик оста гына итеп безне анардан «йолып» алып калды.

Бу вакыйганы сөйләвемнең сәбәбе шунда, кайберәүләр Хәсән ага Туфанның:

> Юк, эчмәдек:
> Бездән читтә иде,
> Ерак иде андый шапшаклык,
> Сөйми иде аны аек башлы,
> Туксан градуслы такташлык!—

дигән юлларын канунлаштырып алалар да, аны эчми-тартмый торган бер аскет итеп



*Х. Туфан балалар арасында.*

күрсәтергә тырышалар. Әйе, Хәсән ага эчүне өнәмәде. Сәрхүшлеккә бирелеп, талантларын яндырган шагыйрьләр өчен, бигрәк тә яшьләр өчен аның жаны әрни иде. Әмма ул жир кешесе иде, табигать баласы иде. Тормышның нәни генә куанычларыннан да ямь вә тәм таба белә иде Хәсән ага. Үзеннән фәрештә ясарга тырышучыларны да өнәми иде ул.

Хәер, мин алгарак йөгердем әле...

Йомгаклау кичәсендә Хәсән аганың «браматы» алгы рәтләрнең берсендә утырды. Аның күзләре гел генә Хәсән ага Туфанда булдылар. Хәсән ага бу юлы бары тик «еракларга-а-а киткән» елларына кагылышлы шигырьләрен генә укыды. Ул «браматына» үзенең язмышын сөйли иде...

Бездә дә таң тугандыр,
Инде ул да торгандыр,
Бергә чаклар исенә төшеп,
Күнелләре тулгандыр...
Бездә дә таң тугандыр...

Шагыйрьнең тавышы өзлегеп китә. Ул янында торган стаканнан су йотып куя. Мин аның «браматына» карыйм. Карамасам, яхшырак буласы икән... Минем дә күзләрем дымлана... Хәсән ага укуын дәвам итә:

Уйлыйдыр ул: «Сау микән?
Эче тулы зар микән?
Хәсрәтләрен таратырга
Тәмәкесе бар микән?
Исән микән, сау микән?»

Шыгрым тулы зал бу шигырьләрдән эреп юкка чыга шикелле. Әйтерсең, залда алар—Хәсән ага белән «браматы» икәүдән-икәү генә калганнар да чөкердәшәләр дә чөкердәшәләр. Ә шигырьләр ага да ага...

Материя мин, жаным,
Аның бары
Сөйли, жырлый, сагына торганы...

Менә Хәсән ага башын чөеп жибәрә. Аның аксыл ябык чыраена якты нур иңгәндәй була. Ул шигырь ритмына уң кулы белән һаваны кыеп-кыеп ала:

Житәр жирләр безнең ерак әле,
Үтәсе бар озын юлларны,
Күрәсе бар тышы гына салкын,
Ә йөрәге жылы дөньяны...

«Браматның» да йөзе яктыра. Ул: «Әйе, әйе, Хәсән абыем!»—дип, аны куәтләгән төсле итеп башын кага. Ә Хәсән аганың тавышы ныгыганнан-ныгый бара:

Роман кебек күнелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым,
Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым!—
Роман кебек күнелле син, юл!

Хәсән ага Туфан өчен вакыт та, дөнья үзе дә юкка чыккандыр төсле. Шагыйрьнең иң татлы, иң бәхетле сәгатьләре иде бу...

Минем аны гел шундый сәгадәтле сәгатьләрендә генә итеп искә аласым килә. Сәгадәтле сәгатьләрендә генә...

*Сәнгать*

# ТАЛАНТ ҺӘМ ТЫЙНАКЛЫК

Рәссам Шакир Мөхәммәтжанов Урта Азиядә Жидесу төбәгендәге Тукмак авылында моннан нәкъ бер гасыр элек—1900 елның 1 гыйнварында дөньяга килә. Приказчик агаӣның гаиләсе хәлле яшәсә, ата кеше үзенең улын 15 яшеннән малайлыкта бил бөгәргә жибе ятка бирмәс иде, бөкренне чыгарырга өлгерерсен әле, дияр иде. Әмма Нигъмәт ага, йөрәге сыкрап булса да, мона ризалашырга мәжбүр була. Шулай итеп, булачак рәссамыбыз, башлангыч белем алу белән, укуын ташлый да баштарак шәхси кәсәбәдә, тора-бара өяз кооперативында кара эшче булып күнегү һәм чыныгу ала. 20 яше тулгач, рәссам булу хыялын тормышка ашыру нияте белән, Ташкентка барып, университет рабфагына укырга керә. 1924 елда рабфакны тәмамлаганнан сон, хыялын тормышка ашыру нияте белән Казанга килә. Әмма рабфак белеме белән генә, махсус әзерлеге булмаган егетебез ул чагында институт (Кахутеин) дип аталган уку йортына кабул ителми. Аптыраганнан гына Казан университетының медицина факультетына барып керә. Анда бер генә ел укыганнан сон теләгенә ирешә: Сәнгать училищесында укый башлый. 1929 елда укуын тәмамлап, рәссам-график буларак, Камил Якуб исемендәге Китап фабрикасына гравер булып эшкә урнаша. Бер-ике елдан Мөхәммәтжановны Китап нәшриятына чакырып алалар. Шунда рәссам 1931 елдан алып, сугышта булуын исәпләмәгәндә, лаеклы ялга киткәнче тугрылыклы хезмәт итә. Биредә ул гравер, рәссам-конструктор булып та, бизәү мөхәррире, графбюро башлыгы, өлкән бизәү мөхәррире буларак та эшли.



*Автопортрет*

30 елдан артык вакыт эчендә басмаханә-типографиянен мөмкинлекләрен әйбәт белгән хәлдә, Шакир абзый үзләрчә китапның—юк, алай гына түгел, меннәрчә китапның,—матур булып чыгуын кайгыртып яши, барча алган белемен милли китапларыбызны бизәү эшенә—изге хезмәткә юнәлдерә. Сәнгать училищесында Бакый ага Урманчедан белем алган булса, нәшриятта 30 ел буена эшләү дәверендә Шакир абзый дистәләрчә яшь рәссамны үзе яраткан һәм тугрылыклы булып калган һөнәренә өйрәтә: гәрчә рәсми рәвештә педагог дип аталмаса да, чынбарлыкта ул күп кенә график-рәссамнарның остазына әверелә.

Һөнәрмән, әлбәттә, башкаларны өйрәтү белән генә чикләнми, үзе дә яшьләргә хас кайнарлык белән китап бизәүнең һәртөрле хикмәтләрен эзли. Г. Тукай, Г. Камалның һәм башка бик күп язучыларның китапларын үз кулы белән сәнгатьчә бизәп чыгарган Шакир абзый, һәр кулъязманы сабыр гына укып чыгып, аны бизәүдә нинди материал, нинди ысул һәм техниканы куллану файдалырак булыр, дип уйлана, шуннан сон гына эшләргә керешә. Әйтик, һәркайсыбыз хөрмәт иткән классикларыбызның китапларына ул

житдилек төсмере бирә: төп-төгәл һәм пөхтә иттереп, килешле хәрефләр белән авторның яки җыентыкның исемен язып куя. Рәсемсез-нисез, шундый җыйнак басманы кулына алу белән, үзен дә ирексездән житдиләнеп китәсен, китапның һәр битен гаять зур кызыксыну һәм саклык белән ачасың. Мөгаен, укучыны әдәпкә-инсафка өйрәтүдә, авторның әсәрендә чагылган хисләре һәм сурәтләү осталыгы белән бергә, кулъязманы китап хәленә китереп житкеручеләрнен дә, иң әүвәл рәссамның да роле әйтеп бетергесездер. Кешенең һәм коллективның хезмәтенә хөрмәт белән карарга әнә шулар өйрәтәдер.

Төрле кулъязма белән танышкан чагында китап итеп төрле кыяфәттә күрә аларны бизәргә алынган рәссам. Әйтик, замандашы Ибраһим Газиның «Бригадир кыз» дип исемләнгән китабының тышлыгына почык борынлы, заманча кыска чәчле, кызыл күлмәкле, ак якалы кызыйның профилен ясап кую белән чикләнә.



*«Текстильче Хуҗи» китабының тышлыгы*

М. Пришвинның татар телендә чыгасы китабына бөтенләй икенче төрле бизәү ысулын сайларга мәжбүр була. Чөнки иң таләпчән укучыларның бала-чага икәнен яхшы белә рәссам, бик әйбәт белә—үзе дә әти кеше ич, үзенең дә өендә нәкъ әнә шундый ук укучылар. Китап булгач—анда, һичшиксез, рәсемнәр дә булсын, ул рәсемнәр китаптагы вакыйгаларны дөп-дөрес чагылдырсын, малай-шалайның сурәте шулай ук язганга туры килсен. Китапның теле ошамаса яки рәссам ясаган сурәтләрне яратмаса-кабул итмәсә—китапның кай тарафка «очасын» абайлый Шакир абзый. Һәрхәлдә, малай-шалайның андый китапны ахырына чаклы укып матташмаячагы ана мәгълүм. Мондый хәлне истән чыгармыйча, Шакир абзый, иң әүвәл, китапның тышлыгын яшел төстә бирергә ниятли. Аннары җыентыктагы 7-8 хикәянең һәркайсын өр-янадан җентекләп укып чыга да шундагы төп вакыйганы сурәтләп күрсәтә. Карт-коры, бала-чага, киек җанварларның һәркайсын үзләренә хас табигый шартларда, анлаешлы һәм ышандырырлык тасвирлап бирүне үз алдына максат итеп куя рәссам. Ашык-пошык, аннан-моннан гына ясап ташламый ул, юк, андый гадәтнең нәрсә икәнен дә белми сабыр холыклы Шакир абзый. Ул киез итек тоткан хәлдә катып калган сакалбайның кыяфәтендә, әйтик, нишләргә белмичә аптырап калу галәмәтен бик оста чагылдыра: кай арада тузып өлгерә әле 10-15 ел гына кигән киез итек? Әмма әле иясе ташлаганнан соң да файдасы тия киез итекнең: кошлар аның йонын йолкып, ояларына ташлыйлар. Һәм канатлы дусларыбызның мәшәкатен күрсәтергә тәҗрибәле рәссам һич иренми: аю-мазарны да, ау этен дә, төрле зурлыктагы кошкортны да сабыйларның күңелләренә хуш килерлек итеп тасвирлый.

Басмаханә серләрен бик шәп үзләштергән Ш. Мөхәммәтҗановның ташбасма ысулы белән башкарган рәсемнәре дә игътибарга лаек. Шуны да әйтергә кирәк, Шакир абзый рәсемне ташка һәйбәтләп төшерү белән чикләнми, басмасын ук үзе башкарып чыга (бу ысул автолитография дип атала).

Сәнгатькәрнең графика жанрына караган күпчелек эшләре әнә шул ысулда, яки тушь һәм карандаш белән ясалган. Шунысы кызык, ул рәсемнәр бәп-бәләкәй, ә үзләре сокланырлык матур. Бу очракта аның автопортретлар сериясе аеруча зур осталык белән эшләнгәнен әйтеп үтәргә кирәк. Үзенең килеш-килбәтен матур итеп күрсәтергә омтылган ник бер эше булсын! Дөрес, кыяфәте һәрчак танылырлык, әмма автор үзенең һәр сурәтенә нинди дә булса мәзәк төсмер бирә:

йә ул үзенен урамнан барган чагын шыксызрак итеп күрсәтә, яисә күзләрен, авызборынын көлкерәк иттереп чыгара...

Хәер, Шакир абзыйның «Чаян» журналына рәсем ясавы да тикмәгә булмагандыр. Анын күп кенә рәсемнәренә көлке-мәзәк чалымнары хас. Әйтик, «Урак өсте» дигән карандаш белән тәмам җиренә җиткереп ясаган рәсемен караганда кемнен генә йөзенә елмаю чыкмас икән. Игътибар үзәгендә бер-берсенә иелеп, ләчтит сатып ятучы ике агай, арткы планда алардан бәләкәйрәк итеп ясалган 3-4 хатын-кыз сурәте—алары анын урак ура...

Кечерәк күләмле андый рәсемнәрне, беренче караганда, автор алай артык газапланмыйча, җинел кулдан гына ясап ташлагандыр, дигән фикер туу ы да ихтимал. Тик инде бу беренче карашка гына шулай тоела. Чөнки сәнгатькәр гаять зур осталык аркылы әнә шундый гадилеккә ирешкән. Рәсемдә һәр детальне күрсәтмәгән хәлдә дә ул төп мотивны тамашачының күз алдына китерерлек итеп тасвирлап бирә, ышандыра. Импрессионистларга хас бу алым иҗат кешесеннән гаять зур осталык һәм тәҗрибә туплаган булуын сорый.

Әйе, Шакир Мөхәммәтҗановның, Урманче шәкерте буларак, импрессионистик рухта гаять күп эшләгәннәре, зур күләмле нәкышь әсәрләре иҗат иткәннәре мәгълүм. Юбилей күргәзмәсендәге картиналарына күз салгач, авторның бу жанрда да юмор белән эш иткәненә һичбер төрле шигебез калмастыр. «Күмәк хуҗалык оешканда» дигән әсәрендә автор 30 елларда барча авыл халкын тетрәткән вакыйганы юмористик планда сурәтләп бирә. Картинанын ин алгы өлешендә, колхозга керергәме, кермәскәме, дип уйга калган, тәмам аптыраган ике—ир-ат; чак кына арырак—сердәшләр, ягъни үзләре ишеткән имеш-мимешне пышылдап кына, бер-беренә сер итеп кенә сөйләп торучы хатыннар; тагын да ерактарак, өйләр янында—кызыл әләмнәр: анда җыен, авыл халкы авыр мәсьәләне хәл итә. Киндерне кыйгачлап узган юл—төссез диярлек. Хәзерге күзлектән чыгып бәяләгәндә, ул юлны төссез итүе белән киләчәкнен билгесез вә өметсез икәнлеген автор шул чагында ук шәйләгән, дип тә әйтергә мөмкин булыр иде, әмма авторның ул замандагы уй-фикерләре нинди булганы беребезгә дә мәгълүм түгел, шуна күрә әсәрдә тасвирланган күренешне бәян итү белән чикләнергә туры килә...




*«Әлифба» китабының тышлыгы*

«Аш пешерүче белән урам себерүче арасындагы мәхәббәт» дигән киндердә исә кызыл күлмәкле кызны мөлаем вә унган итеп гәүдәләндерсә, анын янына гәп корырга дип килгән урам себерүчене гаять мәзәк кыяфәттә сурәтли: җилбәгәй җибәргән зәңгәрсу-кара күлмәк, күлмәк өстеннән ак киндер альяпкыч япкан, бүрекне кырын салган, кулда себерке, авызда—папирос...

Ш. Мөхәммәтҗановның андый иҗат активлыгы сугышка чаклы була.

Әле 1935 елда ук җөмһүриятебездә Рәссамнар берлеге төзү өчен Оештыру комиссиясе (оргбюро) булдыралар. Анда, әлбәттә, Ш. Н. Мөхәммәтҗанов та була, активлык та күрсәтә. Югыйсә 1936 елда Рәссамнар берлегенен 1 нче номерлы билетын аңарга тапшырмаслар һәм үзен идарәгә сайламаслар иде. Әмма 10-15 елдан сон аны... рәссамнар берлегеннән мәрхәмәтсез рәвештә чыгарып ташлыйлар...

Ә бит ул сугышка чаклы китапны ин әйбәт бизәүче буларак 1931 елны Парижлагы халыкара күргәзмәдә, 1933 елны АКШта үткәрелгән күргәзмәдә

катнашкан шәхес. Аның импрессионистик рухта эшләнгән эшләре хәзер дә Парижда музейда саклана...

Ватан сугышыннан эшкә сусап кайткан Шакир абзый, халкына тугрылыклы калып, башы-аягы белән китапларны матурлау-бизәү эшенә чума. Ул елларда да, әлбәттә, рәсем ясаудан туктамый. Тик инде үзенә искиткеч таләпчән сәнгатькәр ни җитте эшләрен һөнәрдәшләренә күрсәтергә ашыкмый. Ә инде иҗатка ныклап торып ябышырга һәм дә камиллеккә ирешергә бөтенләй өлгерми дә кала: 1948 елда аны олаудан чөеп аталар...

Әле ярый Татарстан китап нәшриятында Шакир абзыйның кадерен беләләр—гомерен милли мәдәниятькә багышлаган, үз эшендә һөнәри камиллеккә ирешкән бу талантлы вә тыйнак затка хезмәтен намуслы рәвештә, зур тырышлык күрсәтеп һәм җиренә җиткереп башкарган өчен әледән-әле рәсми рәвештә рәхмәт белдерәләр. Ватан сугышына чаклы графика бюросын җитәкләгән, китапны матур итеп, бизәп чыгару эшен җайга салган, сугыштан соң бизәлеш редакциясендә өлкән мөхәррир булып эшләгән талантлы вә кешелекле хезмәткәрнең абруе зур була.

Әдәпле вә инсафлы сәнгатькәр гаилә тормышында да бәхет кичереп яши. Картлыгын Шакир абзый тыныч кына, бернинди дәгъва кылмыйча гына, ара-тирә бала-чагаларының, таныш-белешләренең сурәтләрен ясап, табигать күренешләрен, чәчәк-мазар язгалап уздыра. Шакир абзый Мөхәммәтҗанов татар халкының сынлы сәнгатендә гаять үзенчәлекле эз калдырып, 1971 елның җәендә дөнья куя...

Кеше үзе китсә дә, аның кылган гамәлләре искә алып сөйләргә, эшләгән эшләре исә яшь буыннарга үрнәк буларак сакларга мирас булып кала. Һәркемгә бирелгән иң дөрес, иң гадел, иң кадерле бәя—кеше үзе үлгәннән соң бирелгән бәя. Талантлы тыйнак шәхеснең исемен иң әүвәл сәнгать фәннәре докторы С. М. Червонная күтәреп чыга. Җөмһүриятнең сынлы сәнгать тарихын архивлардан өйрәнгән чагында ул Ш. Н. Мөхәммәтҗановның иҗатын чагылдырган, бөтендөнья күргәзмәләренә катнашуын искә алган материалларга юлыга. Сәнгатькәрнең иҗади колачын ачыклаганнан соң галимә аның исемен «Художники Советской Татарии» (1975) дигән биографик белешмәләр китабына кертеп җибәрә, янә 9-10 елдан соң әзерләнгән зур китабында да аның исемен читләтеп үтми.

Ә инде рәссамның юбилее алдыннан гына русчасы дөнья күргән, татарчасы да үз вакытында чыгачак «Татар энциклопедик сүзлек» тә дә, бүтән мәшһүр шәхесләр белән бергә, Шакир абзый да үзенең лаеклы урынын ала.

ТРның Сынлы сәнгать музее рәссам Шакир ага Мөхәммәтҗановның 100 еллык юбилее уңае белән, сәнгатькәрнең варислары ярдәмендә, искиткеч һәм кызыклы матур күргәзмә оештырды. Бу эштә Ирина Лобашова һәм музейның бүтән хезмәткәрләре зур тырышлык күрсәттеләр. Дәүләт сынлы сәнгать музееның җитәкчеләренә дә, бөтен коллективына да олуг рәхмәтләр әйтмичә мөмкин түгел.

Арабыздан киткән талантларның истәлеген кайгырту—һәркайсыбызның изге бурычы ул.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

Китап күзәту

# МОҢГА ӘВЕРЕЛГӘН ГОМЕР

Рәшит Ваһапов... Бу исемне әйтүгә үк жанны иркәләп тә, моңландырып-сагышландырып та «Урман» , «Нурия», «Әлфия», «Зәйтүнәкәй», «Таң атканда», «Бибисара» кебек жырлар янгырап киткәндәй була. Әйе, сугыштан соңгы ябай елларда анын жырлары ач-ялангач, тән вә жан яраларыннан кан саркып торган халкыбызнын рухи таянычы булды. Анын жырлавын патефон тәлинкәләреннән, соңрак радио кертелгәч, эфир аша тыңлаган авылдашларымның үзара сөйләшкәннәре хәтердә: «Әй, жырлап та карый соң бу Ваһапов! Бигрәкләр дә моңлы бала икән. Ничекләр генә шундый булган диген...»

Әйе, Рәшит Ваһапов дигән жырчының шөһрәте зур иде, аны олысы-кечесе беләләр иде шикелле. Әмма жырчыны чын-чынлап белү өчен анын жырларын ишетү, хәтта үзен сәхнәдә күрү генә дә аз икән шул әле. Ә бу илаһи тавышлы олуг шәхес турында төрле имеш-мимешләрдән тыш, без берни дә белмәгәнбез икән. Дөресрәге, бик аз белгәнбез.




Ниһаять, сөекле жырчыбызнын вафатына кырык елга якын вакыт узганнан соң, анын тормыш һәм ижат юлын тәфсилле тасвирлаган «Рәшит Ваһапов» дигән китап дөнья күрде. Анын авторы—жырчынын якташы, авылдашы, күренекле журналист Рифат Фәттахов һәм китапны нәшер итүдә матди яктан ярдәм иткән «Татгазинвест» акционерлык жәмгыяте *(генераль директоры—Р. С. Ханбиков)*, Түбән Новгородның «Экойл» финанс-икътисад үзәге *(житәкчесе—К. М. Хафизов)* милләтебез өчен бик изге гамәл кылганнар. Рәхмәт аларга.

Китапны укып чыккач, Рәшит Ваһапов дигән моң чишмәсенен Түбән Новгород өлкәсендәге Кызыл Октябрь районы, Актук дигән авыл кизләүләреннән чыгып, татар халкынын күп гасырлык сәнгате дәрьясына килеп кушылганчы булган ифрат катлаулы юлы күз алдыннан уза. Ирексездән, менә нилектән моңы бик тә тирән булган икән бу жырчыбызнын!..—дип, көрсенеп куясын.

Утыз жиденче елларда башланган репрессияләр шаукымы иң башлап Актук авылынын хөрмәтле кешесе, Рәшитнең әтисе—Ваһаб хәзрәткә килеп бәрелә. Күн киемле, таш йөрәкле янычарлар аны—авыл балаларына белем бирүче, Финляндиядәге туганнарыннан һәм якташларыннан ярдәм алып, яна мәчет төзергә йөргән ил агасын—сөргенгә жибәрәләр. Гаилә өстенә «халык дошманы» дигән яла кара канатын жәя. Анын зәхмәтле күләгәсе әле яңа гына укытучы булып эшли башлаган Рәшитнен язмышына да тап булып төшә. Һәртөрле эзәрлекләүләр, кимсетелүләр, хаксызга рәнжетүләр башлана. Ләкин үзешчән сәнгатьтә актив катнашып, «Галиябану» спектаклендәге Хәлил ролендә өздереп жырлаучы, халык яратып өлгергән бу егетне эшеннән үк куып чыгарырга жөрьәт итмиләр. Аны төрле оешмаларга чакыртып тинтерәтәләр, әтисенә каршы сөйләвен, анардан ваз кичүен таләп итәләр. Әмма балачактан ук иман нуры белән жылытылган, яктыртылган күңел мондый гөнаһлы гамәлне кыла аламы соң?! Юк, ул совет коткысында макталган, үз

атасын Иблискә саткан Павлик Морозовлар бәдбәхетлеген эшли алмый! Аңа өч елдан соң сөргеннән кайткан әтисе белән очрашмаска кушалар. Ата белән улы төнлә, кешеләрдән качып, аулак урыннарда очрашып, бер-берсенә хөрмәт күрсәтә, бер-берсен юатышалар... Күп тә үтми, советка каршы коткы таратуда, Финляндия файдасына шымчылык итүдә гаепләп, Ваһаб абзыйны янадан кулга алалар һәм гөнаһсыз жанын кыялар.

«Болар барысы да егерме яшьлек Рәшитнең бәгърен кисә, жанын телгәли,— дип яза китап авторы.—Рәшит Ваһаповның бөтен гомере гаделсезгә рәнжетелү, фажига-хәсрәт тулы булган икән, моның башлангычы әнә шул елларга барып тоташадыр. Р. Ваһапов жырындагы сагыш-моңда бу елларның да эзе бардыр...»

Әйе, «халык дошманы улы» дигән, жан тынычлыгын ала торган кара күләгә Рәшит Ваһаповны Мәскәүдә, татар опера студиясендә белем алганда да, аны тәмамлаганнан соң, шундагы Татар мәдәнияте йортында актер булып эшләгәндә дә, 1941 елның маеннан Казанга кайтып, Татар дәүләт филармониясе солисты булганнан соң да—гомере буена артыннан калмый. Нечкә күңелле, горур жанлы жырчыга боларны тоеп яшәү жинел булмагандыр, билгеле.

Шулар өстенә, иренең айлар буе гастрольләрдә йөрүеннән разый булмаган Хәлифә ханымның аерылып Мәскәүдә калуы, ятимлеккә тарыган ике бала хәсрәте...

Балалары—йөрәк парәләре өчен никадәр өзгәләнеп яшәгәнлеген китап авторы мондый бер мисалда тасвирлый: 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында Р. Ваһапов зур концерт бирә. Менә ул сәхнәгә чыга. «Әлфия» жырын сузып жибәрә. Шулвакыт аның күзе залның урта рәтләрендә күзләрен мөлдерәтеп үзенә карап утыручы улы Шамил белән кызы Венерага төшә. Аларны күрү ата кешегә шулкадәр көчле тәэсир итә ки, ул дулкынланудан жырын оныта, тавышы өзелә. Ул күз яшьләрен күрсәтмәс өчен сәхнәдән чыгып китәргә мәжбүр була. Аның гаделлекне яклаганда туры сүзле булуын яратмаган филармония житәкчеләре, кара көндәшләре шушы хәлне дә үзләренчә файдаланырга тырышалар, халык өзелеп яраткан жырчыны «непрофессионализмда» гаепләү өчен бер сылтау итәләр.

Ләкин калын жир катламнары аша яктылыкка бәреп чыккан чишмәне үз юлындагы бернинди каршылыклар да тоткарлый алмаганы шикелле, үз алдына олы максат куйган талантны да чабуына ябышып кына туктатып, юкка чыгарып булмый. Рәшит Ваһапов Ходай биргән талантының туган халкына хезмәт итәргә тиешлеген аңлаган хәлдә, шәхси кайгы-хәсрәтләренә йомылмый, төшенкелек упкынына ташланмый. Туган халкының үз жырлавын яратуы, гастрольләр вакытында аны үз улы итеп каршылавы, хәер-дога кылып озатып калуы аңа рухи таяныч була, күңел тынычлыгы иңдерә. Рәшит Ваһапов бригадасында гастрольләрдә йөргән танылган нәфис сүз осталары: Әзәл Яһүдин, Фәйзи Йосыпов, Айрат Арсланов, жырчылар: Жәвәһирә Сәләхова, Динә Сиражетдинова, Зифа Басыйрова, баянчы Гани Вәлиев, хатыны Зәйтүнә ханым Ваһапованың һәм башка сәхнәдәшләренең китапта китерелгән хатирәләре әнә шул турыда сөйли. Ул һәркемгә ачык күңелле, жор сүзле, ярдәмчел, мәрхәмәтле. Гастрольләр вакытындагы гүр газабына тиң юл газаплары да, ягылмаган салкын клубларда чыгыш ясаулар да, айлар буе гаилә жылысы күрми интегүләр дә аның нурлы йөзен күләгәли алмый. Ул кыен вакытларда иптәшләренең хәленә керергә дә, уен-көлкеле жор сүзе белән аларның күңелләрен күтәреп жибәрергә дә үзендә көч таба.

Ваһапов бригадасында конферансье булып шактый еллар бергә гастрольләрдә йөргән Әзәл ага жырчының шаян табигатьле оптимист шәхес булуы турында еш искә ала иде. Ул үзенең кайбер истәлекләрен мәзәкләр шаклендә язып, матбугатта да чыгаргалады. Шулардан кайберләрен китапка кертеп жибәрү жырчы холкын төрле яклап яктыртуга ярдәм итәләр.

Ваһапов сәнгатен үзләренә өлге итеп үскән Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов, Рафаэль Ильясов, Хәйдәр Бигичевларның үз остазларына биргән рәхмәтле бәяләре, күренекле музыка белгечләренең бүгенге жыр сәнгатебез турында фикер йөртүләре, эстрада сәнгатендәге табышлар һәм югалтулар хакында уйланулары китапның кыйммәтен, гади укучы өчен генә түгел, сәнгать әһелләре һәм шул сферада житәкчелек итүчеләр өчен дә бәһасен арттыра. Китапны укып чыккач: «Аһ, нигә-нигә генә бездә халык рухына тереклек суы булып коючы талант чишмәләренең кадере юк икән? Нигә соң без милләтебезнең шундый асыл затлары мәңгелеккә киткәч кенә,

исән вакытларында кадерләрен белмәдек шул, дип үкенергә калабыз икән?»—дип уфтанып куясың. Ләкин бу җәһәттән эчке бер тавыш китап авторы һәм үзем белән дә бәхәскә керергә җөрьәт итә. Әлеге зур талантлар үзләре исән вакытта кадер-хөрмәт күрмәделәр, тиешле бәһаләрен ала алмадылар дигән фикер белән килешәсе килми аның. «Гади халыкның, җыр сөючеләрнең тирән мәхәббәте алар өчен иң зур кадер-хөрмәт, иң зур бәһа түгелмени?!—ди әлеге эчке тавыш.—Атказанган дигән мактаулы исемнәр, берсеннән-берсе мәртәбәлерәк премия лауреатлары дигән атамалар вакытлар җил-янгыры белән юылып бетә, ә халык мәхәббәте, халыкчан сәнгать белән үрелеп, киләчәк буыннарга мирас булып кала...» Рәшит Ваһаповның көндәлекләреннән китерелгән өзекләрдә, якыннарына, үзенең укытучысы—Мәскәү консерваториясе доценты А. М. Железновка, гомер юлдашы Зәйтүнә ханымга язган хатларында даһи җырчының дөнья ваклыкларыннан өстен булган горур җаны канат кагуын күрәбез. Бу җәһәттән аның композитор Салих Сәйдәшев белән рухи якынлыгы, иҗади дуслыклары бүгенге сәнгать әһелләренә үрнәк булырлык. Аларның язмышы безнең көннәрдә Рәшит Ваһаповның якташы, опера җыр сәнгатенең иң биек үрләренә күтәрелгәннән соң, бик яшьли арабыздан китеп барган Хәйдәр Бигичевта кабатланды.

Татар халкы талантларга бервакытта да ярлы булмаган. Һәр заманда җырчылары да, шагыйрьләре дә, композиторлары да... шактый булган аның. Ләкин вакытлар узу белән күбесе халык хәтерендә тоныкланган, онытылган. Агымсуда ком-ташлардан аралaнып, төпкә утырган алтын бөртекләре сыман, талантлыларның талантлылары гына халык хәтерендә сакланып калган. Салих Сәйдәшев, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Габдулла Рәхимкуловлар кебек халык бәгыреннән өзелгәннәре генә... Ләкин халык онытмый дип, әлеге милли хәзинәбезне пропагандаламасак та була икән дигән сүз түгел, әлбәттә. Бу кыйммәтле байлыгыбызны без киләчәк буыннарга да мирас итеп, теркәп калдырырга тиешбез.

Сәнгать әһелләренең кыйммәтле мирасын киләчәк буыннарга тапшыруда радио, телевидение бик игелекле эшләр башкара ала һәм алар моны хәл кадәри эшләп тә киләләр. Заманында Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясен җитәкләгән күренекле музыка белгече Зәйнәп ханым Хәйруллинаның милләтебез намына тырышлыгын бүген без рәхмәт хисләре белән бәялибез. Ул Рәшит Ваһаповка репертуар сайларга да, яңа көйләргә сүзләр табарга да, аның иң уңышлы җырларын магнитофон тасмасына яздырырга да күп ярдәм иткән. Хәер, бер Ваһапов кына да түгел, ул вакыттагы башка талантлы җырчылар вә композиторлар да аның хәерхаһлыгына таянганнар. Шуның нәтиҗәсе буларак, без бүген Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Мәрьям Рахманкулова, Динә Сиражетдинова, Фәхри Насретдинов, Азат Аббасов, Усман Әлмиев, Нияз Даутов, Галия Кайбицкая, Зәйтүнә Әхтәмова, Габдулла Рәхимкулов һәм башка профессиональ җырчыларыбызны тыңлап рухи ләззәт алабыз.

Замана ахырында ни уйласаң, шул алга килер, дигәндәй, әле менә бу мәкаләмне язып утырганда да Татарстан радиосыннан бүгенге яшьләр инде оныта башлаган, ләкин милләтебез рухи хәзинәсенең алтын фондына кереп калган кайбер җырчыларыбызның язмаларыннан концерт бирделәр, рәхмәт яугыры. Арада Рәшит Ваһапов белән Җәваһирә Сәләхова башкара торган атаклы «Галиябану» җыры да бар иде. «Урман», «Гөлҗамал», «Олы юлның тузаны», «Сакмар», «Тәфтиләү», «Салкын чишмә», «Рәйхан», «Рамай» кебек татар халык җырларын, Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, Сара Садыйкова кебек композиторларыбызның татар җанын йөрәгеннән бөтен нечкәлекләре белән тоеп язган җырларын кем генә яратып-ләззәтләнеп тыңламас икән?! Шундый «Сирәк музыкаль язмалар»ны сирәк кенә түгел, ә бәлки ешрак ишетәсе иде.

Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясе мөдире, Рәшит Ваһапов мәктәбе җырчысы Рафаэль Ильясов һәм әлеге редакциянең өлкән редакторы Сиринә Латыйпова тарафыннан оештырыла торган «Музыкаль очрашулар», «Радио фондыннан» һ. б. тапшырулар да милләтебезнең моңлы җырларын бүген яңгырату аркылы киләчәккә тапшыруда үз миссияләрен үтәрләр дип уйлыйм...

Халык бит ул шундый: үз талантларының иҗатын гына түгел, аларның гомер юллары нинди Сират күперләре аша узганлыгын да беләсе килә. Хәбәрдарлык булганда төрле имеш-мимешләргә дә урын калмас иде. Ә талантлы шәхесләрнең язмышлары күп яктан охшаш була, ахрысы. Яшәеш шуны күрсәтә. Әнә бит, Салих

Сәйдәшевны аласыңмы, Рәшит Ваһаповнымы, Хәйдәр Бигичевнымы—гомерләре Монга әверелгән бу өч шәхеснең, кабатланмас, үзенчәлекле бу талантларның язмышлары уртак диярлек: Ходай биргән илаһи талантларын тулысы белән халыкка багышлау юлында очрап торган тормыш каршылыклары, дөньяви ыгы-зыгы белән туктаусыз көрәштә рухи көчләренең заяга түгелүе өчен җан тынычлыгын югалтулар, сәясәтле җәмгыять тарафыннан хаксызга рәнҗетелүләр, шулар өстенә һәм шулардан килеп чыга торган шәхси тормышларындагы җайсызлыклардан алган күңел яралары... Гади җир кешесенә дә бик авырга килә торган мондый тормыш сынаулары нечкә күңелле, гаделсезлекләргә чиксез нәфрәтләнүчән һәм рәнҗүчән, әмма үз-үзләрен яклауда күп очракта гаҗиз вә чарасыз булган сәмави җаннар өчен күп мәртәбә кыенрак лабаса. Нәтиҗәдә, Монга әверелгән гомерләрнең яшьли янып, һәлак булуы... Бу хәлләр безнең күз карашыбыз җиткән Тукайлар заманыннан ук шулай кабатлана килә. Нилектән шулай бу? Әллә инде юкса кайчандыр мөстәкыйль дәүләтчелеген югалткан халыкның үзе тудырган талантларын сакларлык, аларга Ходай биргән илаһи көчләрен тулысынча ачарга, аларны тиешенчә кадерләргә рухи һәм икътисади дәрманы җитмәүдән микән? Юкса, гасырга бер туа торган җыр солтаны Рәшит Ваһапов иҗатының үзе вафат булганнан соң кырык елга якын «онытылыбрак торуын» ничек аңларга соң? Ярый әле җырчының авылдашы аның мирасын барлап, архив тузаннарын актарып, фәнни хезмәткә тиң китап язарга алынган. Шуңа кыюлыгы, көче, сәләте җиткән һәм ул аны намус белән башкарып чыккан. Якташлары әлеге китапны дөньяга чыгаруда матди ярдәм иткәннәр.

Янә шунысын да әйтергә кирәк: Рифат Фәттахов узган ел икенче бер якташы—зур талант иясе, мәшһүр актер-җырчы Хәйдәр Бигичев ядкарена багышланган «Китмә, китмә, Сандугач!» дигән китапны төзеп, редакцияләп *(ике китапның да нәшрият мөхәррире—Флорид Әгъзамов)* «Татарстан» журналы нәшриятында бастырып чыгарган иде. Әле моңа кадәр Равил Фәхретдиновның Илһам Шакиров турында «Җырчы» *(Татарстан китап нәшрияты, 1973)* дигән бәләкәй генә мәҗмугасыннан тыш, күренекле җырчыларыбызның тормыш һәм иҗат юлларын яктырткан китаплар күренгәне юк иде шикелле. Белүемчә, хәзерге вакытта Габдулла Рәхимкулов турында язучы Әхәт Сафиуллин, күренекле нәфис сүз остасы Әзәл Яһүдин турында журналист Рафаэль Сальмушев һәм филармония музее хезмәткәре Алсу Хәлилова махсус китаплар чыгару өчен әзерлек алып баралар. Ул мәҗмугаларны нәшер итү өчен матди яктан булышучылар табылырмы—әлегә әйтүе кыен...

Әлегә исә безнең кулыбызда милләтебезнең талантлы ике улына багышланган, затлы кәгазьдә, фоторәсемнәр белән бизәлгән ике китап бар. Тик менә аларның тиражлары гына азрак, 2—3 мең данә генә. Хәлбуки, ошбу китапларны эзләп алып укыячакларына шигем юк. Чөнки бу хезмәтләр гыйбрәтле язмышлы, халкыбыз өчен газиз булган шәхесләребезнең әлегәчә яхшы мәгълүм булмаган тормыш-гомер юлларын яктырту белән бергә, җыр, аеруча профессиональ җыр сәнгатебезнең узганы, бүгенгесе турында бик күп мәгълүмат та бирәләр, аның киләчәге турында уйлануларга да этәрәләр.

Авторның хаклы фикеренчә, «гарасатлы елларда татар халкын Дин һәм Моң саклап калды...» Мин дә мәкаләмне әлеге фикергә аваздаш бер шигыремнән өзек белән тәмамлыйсым килә:

Ач булса да, җырлый иде халкым,
Җаны өчен кирәк булгандыр.
Вакытлыча, бәлки, җыр-моңнары
Азан моңын алыштыргандыр.

Ай һәм Кояш тотылганда,
Җирдә
Бар тереклек ничек моңланса,
Җаннарны шом басар иде шулай
Азан йә Җыр моңы булмаса.

Ай һәм Кояш нуры—икесе дә
Зарур булган кебек Җир өчен,
Кирәк икән Азан һәм Җыр моңы,
Саклар өчен адәм баласының
«Җан үлемсез!»—дигән Өметен...

**Шамил МАННАПОВ**

*Хәтер*

# ДӘҺШӘТЛЕ КӨННӘРДӘ

1941 елның 21 июне. Шимбә көн. Кичне иптәшләр белән паркта йөреп уздырдык. Бик соң кайттык. Шуңа да бик озак йоклаганбыз...

Иртән бераз йөреп керергә уйлап, Казанның Зур Кызыл урамы буйлап бара идем, каршыга пединститутның өлкән укытучысы (сугыштан соң филология фәннәре докторы, профессор) Латыйф Җәләй очрады. Җәләй ага һәрвакыт көр күңелле, юмор катнаштырып сөйли, башкаларны көлдереп кенә калмый, үзе дә рәхәтләнеп көлә иде. Бүген дә, үзе әйткәнчә, кулында симез портфеле. Аның шаярулы сүз әйтүен көтәм. Җәләй аганың йөзе житди, зәңгәр күзләре уйчан. Ул, иелеп, пышылдап кына:

—Бүген радио тыңладыңмы, Әхтәм?—дип сорады.

Аның борчулы йөзен күрү мине сагайтты:

—Тыңламадым. Әллә берәр яңалык бармы?

—Немец басып кергән. Әйдә институтка киттек. Митинг буласы,—диде. Ул чагында пединститут хәзерге Суворов училищесы бинасында иде.

... Митинг башланды. Трибунада райкомнан килгән оратор:

—Фашистлар Германиясе бүген сәгать дүрттә безнең илебезнең дәүләт чикләрен үтеп керде. Дошман көчле һәм мәкерле, хәйләкәр. Илебез алдында зур куркыныч туды... Без җиңәрбез,—дип сүзен тәмамлады.

Аны башкалар алыштырды. Һәр сөйләүче, кирәксә, хәзер үк фронтка китеп, азаккы тамчы каны беткәнче көрәшәчәген әйтте.

Трибунага комсомол комитеты секретаре күтәрелә, ул үзе теләп фронтка китәргә теләүчеләрнең фамилияләрен укый—аларның саны 120 гә житкән.

Митинг Советлар Союзы гимны—«Интернационал»ны жырлау белән тәмамланды. Мин Җәләй агага карыйм, ул—беренче бөтендөнья сугышында катнашып, салкын окопларда яткан, дары исен татыган кеше,—тыныч, горур басып тора. Нәрсә уйлый икән Латыйф ага? Очучы булырга хыялланучы унынчы сыйныф укучысы—бердәнбер улы Әнвәрне, шаяртып: «Юк белән булышма, ахмак, күк биек ул. Очам дип, меңәрсең дә егылып төшеп, биленне кузгатуың бар»,—дип әйтә иде. Еллар үткәч кенә бу егетнең,—Җәләй аганың бердәнбер улы Әнвәрнең,—күккә менәргә өлгермәгәнлеген, жирдә дошманга каршы аяусыз көрәшеп һәлак булуын белдек.

Бу көннәрдә кешенең иң күп жыелган урыны—хәрби комиссариат бинаalары. Алар камалыш хәлендә, фронтка жибәрүне сорап күпме кеше чиратта тора, әмма бинага керү мөмкин түгел. Урамнан яңа гына армия сафына алынган кешеләр жырлый-жырлый үтәләр. Комиссариат янындагылар алардан көнләшеп калалар. Соңга таба кичекмәстән фронтка жибәрүне таләп итүчеләрне, чакыргач кына килергә кушып, эш урыннарына кайтарып жибәрәләр...

... Сугыш инде бер атна бара. Без Мөхәммәт абый Гайнуллин квартирында яшибез. Тулай торак госпиталь өчен алынгач, үзебезнең укытучыбыз йортында сыену урыны тапкан идек.

Көн кичкә таба авышты. Без балконда утырабыз. Сүзебез фронттагы хәлләр турында. Аны һәрберебез үзенчә аңлатырга тырыша. Безнең гаскәрләребезнең чигенүләре йөрәкне әрнетә. Әхтәм Әминев моны әзерлек юклыктан, көчсезлектән дип аңлатса, Касыйм Вахит: «Юк, вакытлы тактик алым бу!»—ди. Баян Гыйззәт исә икесенең фикере белән дә килешә кебек. Минем күңелемә Толстой бюсты, «Сугыш һәм солых» романы килә: «1812 елда Кутузов Мәскәүне калдыра, әмма сугыш Наполеонның бөек армиясен тар-мар итү белән тәмамлана»,—дим. Баян:

—Әллә син немецка Мәскәүне бирергә жыенасыңмы?

—Үткәндәге тарихны бүгенгегә күчерергә жыенмыйм,—дим.

Без бу турыда шактый сүз алып бардык. Кайвакыт тын гына утырабыз. Иптәшләремә карыйм—алар да уйланалар. Бу хәлгә Касыйм Вахит чик куйды:

—Нигә, дуслар, төшенкелеккә бирелергә?! Без бу изге сугышның катнашучылары булабыз, сугыштан соң героик көрәш эпизодлары чагылдырган шигырь, поэма, хикәя, романнар тудырырбыз. Кем белә? Берлинны алучылар арасында, бәлки, без дә булырбыз. Бу кичәне Берлин ресторанында дәвам итәрбез,—диде.

Әхтәм Әминев балалайка алып уйный башлады. Касыйм Вахит аңа кушылып җырлап җибәрде, Баян Гыйззәт рюмкаларга шәраб салды... Шулай итеп, бу кичәне үткәреп җибәрдек. Бу вакытта мондагы иптәшләрнең кайберләре белән соңгы мәртәбә очрашуыбызны белми идек әле.

Озакламый без дә төрле фронтларда аяусыз көрәшкә ташландык...

Ниһаять, Бөек Җиңү көне килде.

Кече политрук Әхтәм Әминев Калуга өлкәсенең Сухиничи станциясен азат итү өчен барган сугышта авыр яралана һәм 1942 елның 6 маенда үлә. Элемтәче Касыйм Вахитов 1942 елның Смоленск җирләрендә барган каты сугышларда һәлак була. Мин, Мәскәү янындагы сугышларда авыр яраланып, госпитальләрдә дәваланып, 1942 елның февралендә, култык таякларына таянган хәлдә, ерак Себердән туган авылыма кайттым. Баян Гыйззәт (1918-1991) Җиңү көнен Кенингсберг шәһәрендә каршылый. Берлин шәһәрендә була, андагы ресторанда Казандагы соңгы очрашуыбызны искә ала.

1945 елның җәендә «бөек барлау» чорында Вахитов, Әминев һәм Харисовның Ватаныбызга ябырылган ерткыч фашистларга каршы аяусыз көрәштә һәлак булуларын белгән идек. Әмма 24-25 яшьлек егетләребезнең безнең арада юклыгына һич тә ышанасы килми иде. Ул чагында уйламаган хәлләр, могҗизалар булмадымыни?! Мәсәлән, миңа да шундый ук хәлне кичерергә туры килде.

Авыр яраланып, хәрәкәтләнүдән мәхрүм булып кар өстендә ятып калдым. Безнекеләр чигенделәр. Шул чагында мине «һәлак булды» дип туганнарыма хәбәр иткәннәр. Иртән һөҗүм башлангач кына үзебезнекеләргә юлыктым. Шуннан соң, бер госпитальдән икенчесенә күчә-күчә, Горький шәһәренә барып җиттем. Әнә шунда гына хат язарлык хәлгә килдем.

Шулай, минем кебек, үлгән дип исәпләнгәннәр, хәбәрсез югалганнарның кайберләре туган якларга әйләнеп кайтты бит. Безнең иптәшләребезнең дә берәрсе кайтыр кебек тоела иде. Аларның соңгы язмышын белергә теләү күңелне борчый.



*Сулдан уңга: беренче рәттә Касыйм Вахит, аның хатыны Сылу, Әхтәм Әминев. Икенче рәттә: Шамил Әхтәмов, Харисов (Свердловск журналистика институты студенты, практикага килгән иде). Баян Гыйззәт.*

Шул турыда туганнарына мөрәҗәгать итү дә нәтиҗә бирмәде, җибәргән хатлар җавапсыз калдылар.

Ел артыннан еллар үтте. Ниһаять, сугыш тәмамлануга дистә ярым ел үткәч, Самат Шакир төзегән «Алар сафта» дигән җыентык чыкты. Китапка Әхтәм Әминев, Касыйм Вахит турында кыскача биографик белешмә бирелгән һәм аларның берничә шигыре урнаштырылган, әмма кайда җирләнүләре әйтелмәгән.

Халкыбызның «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» кебек тапкыр әйтеме бар. Канга манчылып алсуланган гәүдәләрегезне куенына алган изге туфрак кайда икән, дуслар?! Әнә шуны белү өчен хәрби комиссариатларга мөрәҗәгать итәргә булдым. Шул турыда Татарстанның Сарман, Башкортстанның Миякә район хәрби комиссариатларына хат яздым. Сарманга ике мәртәбә язу да нәтиҗәсез булды. Миякәдән болай хәбәр иттеләр:

«Миякә хәрби комиссариаты архив мәгълүматлары буенча Әминев Бөек Ватан сугышында 27.01.1945 елда һәлак булган һәм Көнчыгыш Пруссиянең Дима районында алпавыт Матрау утарыннан (урысчасы «господского двора Матрау») 200 м көнчыгышта күмелгән, кабер 17".

Гаҗәп! 1942 елда ук үтерелгән дип йөргән Әхтәм дошман өнендә көрәшкән түгелме соң? Җиңү таңы китергән елда сугыш тәмамлануга 3 ай 12 көн калгач һәлак булган. Мөмкинме бу?

Миякәдән килгән кәгазьне янадан карыйм. Искәрмәсе дә бар икән. Әминевнең исеме без сораган Әхтәм түгел—Әлтәф. «Атасының исеме күрсәтелмәгән» диелгән. Исемендә ике хәреф туры килми. Миякә авыл Советына хат язам. Ике ай уза. Җавап бирүче юк. Янадан үтенеч җибәрәм. Ниһаять, Авыл Советы рәисе һәм Әминевнең абыйсы Афзал аганың тормыш иптәше Зәйнәп ханым язган хатлар килде. Конвертны ачып укый башлыйм.

Әкият батырлары кебек биш туган Әминевләр илбасарларга каршы яуга киткәннәр. Шуларның өчесе, арысландай көрәшеп, изге Ватаныбыз өчен гомерләрен биргәннәр, икесе, аяусыз көрәштә утлар-сулар кичеп гарипләнгәч, туган якларына кайтканнар. Сугышта алган авыр яралар озак яшәтмәгән аларны, икесе дә вафат булганнар. Әлек мин хат язган Афзал ага 1974 елда үлгән икән. Конвертта вакытлар үтү белән саргайган кәгазь кисәге дә салганнар. Бу госпитальдән килгән хәбәрнең күчермәсе булып чыкты. Кәгазьдә болай язылган иде:

«Сезнең улыгыз политрук урынбасары Әминев Әхтәм Закадинович социалистик Ватан өчен сугышта, хәрби антына тугры булып, геройлык күрсәтеп яраланды, 1942 елның маенда яраланудан үлде.

Мәскәү өлкәсенең Малоярославец шәһәрендә күмелде».

Хәрби госпиталь начальнигы 2 ранг хәрби врач Беляев һәм хәрби комиссар өлкән политрук кул куйганнар. СССР Оборона халык комиссариатының 2293 санлы госпитале мөһере басылган.

Шулай итеп, яшь шагыйрь, уйланылган, әлегә ак кәгазьгә төшерелмәгән әсәрләрен мәңгегә калдырып, 1942 елның кояшлы маенда, сабан тургайларының кешеләргә шатлык китерә торган моңнары яңгыраган чагында авыр яралар аның гомерен өзгән икән! Кабере данлы Кутузовның җиңелмәс полклары Наполеон яуларына каршы һәлакәткә һөҗүм башлаган шәһәр—Малоярославецта икән.

1972 елның гыйнвар ае иде. «Кызыл таң» газетен (№ 13) карап утырам. Бер фоторәсемгә күзем төште. Таныш кешегә охшаган. Ул Касыйм Вахитның Дәүләкән педагогия техникумында укыганда төшкән рәсеме булып чыкты. Шуннан соң «Яшьнәп үткән яшь гомер» дигән мәкаләне укып чыктым. Касыйм 1942 елның 4 октябрендә Смоленск җирләрен азат итү өчен барган каты сугышларда һәлак була. Шоломки авылы басуында күмелә. Сугыштан соң туганнар каберен район үзәге Карманово поселогына күчерәләр.

Дүртенче курста укыганда Касыйм география факультетында укучы авылдаш кызы Сылуга өйләнгән иде. Без фронтта вакытта Сылу ярдәмендә дусларыбызны табып, хәбәрләшеп тордык. Хәзер Сылу да мәрхүмә инде.

Без дүрт дусның язмышлары әнә шулай тәмамланды. Сугыштан, яраланып булса да, икебез генә—Баян Гыйззәт белән мин генә—исән кайта алдык. Хәзер инде мин бер үзем, япа-ялгыз калдым...

**Шамил ӘХТӘМОВ**

*Фән*

# МОНГОЛ ЯУЛАРЫНА ТАГЫН БЕР КАРАШ

Гасырлар агымында үзенә галимнәр, язучылар игътибарын җәлеп иткән һәм Россия тарихында да мөһим урын алган Алтын Урда тарихы, аның төрле илләргә, халыкларга ясаган йогынтысы һаман да үзенең актуальлеген югалтмый. Шуның өстенә Алтын Урда дөнья культурасындагы бәйләнешкә, үзара үтеп керү процессына зур йогынты ясый.

Бу проблемага Мәскәү тарихи мәктәбенең карашы бер мәгънәдә булуы һәркемгә күптән мәгълүм. Ләкин, күп санлы язма чыганакларга һәм күренекле ориенталистларның фәнни хезмәтләренә таянып (Ф. Радлов, В. Бартольд, И. Бичурин, Болкад, М. Сәфәргалиев, Л. Гумилев h.б.), төрле фәннәр казанышларын кулланып, фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнгәндә башка төрле, әүвәлге тезисларга капма-каршы фикерләр дә барлыкка килә.

Бүгенге көндә халыкара җәмәгать оешмалары, төрле илләр тарихчылары тарафыннан Чыңгыз хан «Дәвер кешесе» дип танылa. Монгол—татар яуларының мораль якларына артык тирән үтеп кермичә, аларның йогынтысы, нәтиҗәләре, масштаблары объектив рәвештә дөньякүләм тарихи характер ала, дибез. Бу язмада сүз Чыңгыз хан империясенең төзелеш феномены турында бара. Монархы безгә билгеле булган бер генә җиһангир (полководец) та шундый озын гомерле, бөек империя төзи алмады, алар тиз таркалдылар (Кытай, Осман, Гитлер, Наполеон, Русия империяләре).

Чыңгыз ханның кыска вакыт эчендә зур хәрби уңышларга ирешүе таң калдыра һәм монголлар корылтайда чираттагы поход максаты итеп күрсәтелгән бер генә ил-шәһәр дә аларның баскынлыгыннан котыла алмый. Нилектән бу? Ни өчен җирле халыклар чагыштырмача озак вакыт тыныч, күндәм булып, буйсынып яшиләр? Шулай ук аларның искиткеч тизлек белән һәм өзлексез рәвештә алга бару походлары гаҗәпләндерә. Әмма, гаскәрләре тар-мар ителүенә карамастан, Көнбатыш Европа дәүләтләре ни өчен монгол яуларыннан азат калалар? Бу язма авторның максаты да шул сорауларга җавап эзләү, фикер йөртү, фараз итүендә.

1. Монгол яу-походларының зур темпларына килгәндә, автор тулысынча мәгълүм булган гомум сәбәпләр белән килешә (талантлы гаскәр башлыклары, югары техник кораллану, сугышчыларның әзерлеге h.б.). Монголларның дошманнары көчле, тәҗрибәле, яхшы коралланган була. Мәсәлән: журчәженьнәр, гарәпләр, иранлылар. Ә гарәпләр нәкъ шушы вакытта «төре йөртүчеләр»не җиңгән була. Монголларга, аларның гаскәрләренә югары тәртип, чыдамлык, максатка омтылыш хас була. Һәрьяктан җентекләп тикшерелгән тагын бер караш бар. Ул да булса, монголларның тирән разведка ясауны тәэмин итүе, шулай ук булачак сугыш хәрәкәтен, һөҗүмне дипломатик яктан гарантияләве. Аларның хәрби операцияләре хирургик төгәллек белән эшләнә. Алар, гадәттә, хәрби һөҗүм алдыннан үзләренә союздаш табалар һәм, киресенчә, дошманнарын дипломатик юл белән союздашларыннан мәхрүм итәләр. Мәсәлән, журчәженьнар империясен кытайлар белән буйсындыралар, татарларны—дала күчмә кабиләләре, ә аланнарны кыпчаклар ярдәме белән җиңәләр.

Моннан тыш, кайбер фактик чыганаклар безгә шундый фаразга мөмкинлек бирә: монголлар һәм католик-христианнар арасында стратегик альянс «Урда—Рим Папасы» булмаганмы? Билгеле булганча, монголларда төрле дин әһелләре хезмәт иткән, гаскәрләрдә христиан кешеләре булган, ләкин дин аркасында әлләни ыгы-зыгы тумаган. Ханнар тирәсендә миссионер католик-монахлар өзлексез үз вазифаларын үтәгәннәр. Әмма алар башка максатлар күздә тотканнардыр: әйтик, күзәтүчелек, арадашчылык итү. Билгеле булганча, Папа вәкилләре, католик һәм монголларның

дошманнары уртак булганда, ханнар белән берлектә хәрәкәт итү турында сөйләшәләр (Рубрук илчелеген алырга була). Бу планда тагын бер сәер факт игътибарны үзенә җәлеп итә. Чыңгызхан һәм чингизидлар чорында хәрби походлар еш кына ислам илләренә ясала. Дөрес, бу илләр дә үз карамагында иң әһәмиятле, зур халыкара кәрван юлы томалар. Һәм асылда юлларына хуҗа булу өчен төрле көчләр көрәшә. Мәсәлән, Европа берләшкән хәрби көчләрнең шушы ук максаттан оештырылган «Тәре походлары» уңышсыз тәмамлана. Монголлар бу очракта ота, ягъни көньяк сәүдә юлы алар контролендә була.

Тагын бер нәрсә әһәмияткә лаектыр. Бу—чингизидларны Аурупа илләренә баскынлык итмәве. Югарыда әйтелгәнчә, берләшкән Аурупа хәрби көчләрен җинсәләр дә, алар бер генә католик диние илгә дә һөҗүм итмиләр. Шулай ук рус кнәзлекләренә дә баштарак тимиләр, киресенчә, рус кнәзләре беренче булып «тынычлык» юллап килгән монгол илчеләрен үтерәләр һәм аларга һөҗүм итәләр. Хәтта «Русь» гаскәрләрен Калка елгасында тар-мар иткәннән соң да (1223), Джебе һәм Субудәй «коралсыз җирләргә» керүдән баш тарталар. Кайбер урыс авторлары «бу сугыштан соң монголлар бик хәлсезләнгән, аларны кайтырга чакыралар» дисәләр дә, монголлар ашыгыч рәвештә Болгарга каршы кампания башлыйлар. Димәк, бу вакытта әле корылтай тарафыннан христиан Русен яулап алу бурычы куелмаган. 1236 елда исә Русьны монголларга буйсындыру (ясак җыю, рус кнәзләренә төрле хокуклар бирү һ.б.) бурычы көн тәртибенә куела. Бу тема тикшерелгән, фәнни нигезләнгән булса да, автор үз уйларын, фаразын тәкъдим итә.

Билгеле булганча, рус кнәзләре күптән инде христиан динен тота, ягъни «православие» христианнары булалар (Греция). Ә католиклар һәм Рим Папасы (Ватикан) православиене христиан дип танымый (хәзерге көндә дә астыртын дошманлык яшәп килә). Һәм Русь өстенә «тәре походы» оештыралар, Константинопольне «алуда» катнашалар. Шунысы да сәер: бер яктан «рыцарь орденнары», Мажарстан (Венгрия) белән Швеция католик корольләре, икенче яктан, монголлар Русь кнәзләренә бер үк вакытта, ягъни синхрон рәвештә һөҗүм итәләр. Бу очраклы хәлме? Монголлар христиан мәмләкәтләренең Папага буйсынмаганнарын гына, ягъни католик булмаганнарын гына үзенә буйсындыралар. Мәсәлән, православие чиркәүле Константинопольне монгол окупациясеннән Бәркәнең үлүе генә коткара. Янә бер вакыйганы искә алыйк. Папа илчесе Юлианның белдермәсе (доносение) нәкъ Батыйханның көнбатыш хәрби сәяхәте алдыннан төзелә, анда «...Русь язмышы монголлар тарафыннан хәл ителгән (яулап алу), ләкин католик диние илләргә яу булмас»,—дип хәбәр ителә. Нәтиҗәдә, монголларның католик дөньясы чигендә туктап калуы очраклы хәл түгел, ә алдан ук планлаштырылган максат, туктау сәбәпләренең берсе диясе килә. Монгол һәм католик христианнары арасындагы хәрәкәтнең координацияләнелүен чингизидларның Лиондагы 14 «Вселенский католический собор»да катнашулары дәлилли һәм аларның көнбатыштагы походлары бетүгә туры килә. Әлеге мисаллар, «Урда—Папа» альянсы яшәп килүен дәлилли дип уйлыйбыз.

Буйсындырылган христиан илләрендә хакимият башлыклары үз урынында кала, династияләр өзелми, киресенчә, ислам җирләрендә монголлар үзләренең туры идарә итүен кертәләр. Ә христиан соборларына җиңеллек биреп, аларга йомшаграк, үз итеп карыйлар. Кайбер тарихчылар әйтүенчә, монгол яулары басыла төшү белән «тәре походлары»да бервакыттарак сүнә башлый.

Монгол яуларының уңышлы булуына йогынты ясаучы тагын бер факторга күз салыйк. Ул да булса: Кытайдан Урта Азия аркылы Европага юнәлгән трансконтиненталь «ефәк юлы» һәм халыкара сәүдә элитасының шушы сәүдә юлының үзләре өчен куркынычсыз, ачык табышлы булуы белән кызыксынуы. Монгол чорына кадәр сәүдәгәрләр, төрле куркынычларга дучар булып, тынычлык-саклык мәсьәләсен дә бернинди гарантиясез, дистәләгән илләр чиген гизеп, шушы «ефәк юлы» маршрутында йөргәннәр. Хәтта юлның хәвефсез дип саналган һәм ислам илләре кул астында булган көньяк маршрутында (бүлегендә) дә талаш-сугышлар булып торган. Уңышсыз барган «тәре походлары» да сәүдә мөнәсәбәтләренә зыян китерә, аны катлауландыра, байтак вакыт Италия сәүдә мөнәсәбәтләренә зыян китерә. Аларны байтак вакыт Италия сәүдә шәһәрләре төрле салымнар белән тәэмин иткән (финанслаган). Шуна күрә дә итальяннар Алтын Урдада—католиклар булдыруда һәм аның яшәп килүендә кызыксынучы субъект булгандыр. Бәлки шунлыктандыр, монголлар Константи-

нопольгә уңышсыз сәяхәт ясаганнан соң, итальяннар озакламый Кара диңгезнең төньяк җирләрен, ягъни сәүдә юлларын тулысынча үз хакимлегенә алалар, ә Алтын Урдага һәртөрле ярдәм итәләр, кискен очракларда хәтта хәрби ярдәм дә күрсәтәләр. Алар монголлар нигез салган шушы сәүдә юлында зур табышларга ирешәләр. Белгечләр күрсәткәнчә, XIII нче гасырда Италиянең төньяк шәһәрләрендә икътисади үсеш, мануфактура җитештерү, капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлау тизләнә. Соңрак, киресенчә, Венеция, Генуя, Флоренция сәүдә шәһәрләренең икътисади-сәяси яктан хәлсезләнүе Урда таркалуы һәм аның йогынтысындагы кәрван юлларының бетүе нәтиҗәсе була.

Урда чорындагы тагын бер сәүдә үзәге үзенә файда табып үсә, күтәрелә, ныгый. Бу «ачык» Бөек Новгород шәһәре. Русь шәһәрләреннән берләнбер булып ул ауропача «Ганза шәһәре» дип атала (Ганзейский город) һәм Бөек кнәздән, аның йогынтысыннан азат була. Суздаль, Киев аркылы үтә торган сәүдә юллары белән бәйләнештә тора. Ул, төньяк-көнбатыш Ауропа «капкасы» буларак, монголларга да юл ача. Монголлар Новгородка һөҗүм итми, киресенчә, аларга «тәре йөртүчеләр» (католиклар) белән булган бәхәсләрен хәл итүдә ярдәм итәләр. Башка кнәзлекләр белән чагыштырганда, Бөек Новгород гөрләп үсә, шәһәрдә муллык, байлык арта, таштан төзелгән биналар, чиркәүләр калкып чыга. Соңыннан, Мәскәү чыңгызидлар йогынтысыннан азат ителгәч, Новгород, киресенчә, үз ролен, куәтен, байлыгын һәм бәйсезлеген югалта.

Бу язма башында куелган сорауларның (тезисларның) чираттагысы—буйсындырылган илләрнең гасырлар буе чагыштырмача күндәм булуы: илбасарларга каршылык күрсәтми яшәве турында иде. Кагыйдә буларак, буйсындырылган халыклар үз җирләрендә кала, читкә сөрелми, дәүләт түрәләре үз урыннарын, династияләрен саклый һәм үз тәңресенә табына. Икътисади яктан да монгол-татарлар кул астында булган иксез-чиксез далалардагы сәүдә юллары һәм транзит сәүдәсе үзе халыкларга, бигрәк тә шунда урнашкан мәмләкәтләргә зур файда, табышлар китерә. Югарыда әйтелгәнчә, монголлар аркасында төрле илләр салымыннан азат ителү һәм хәвефсез сәүдә каналын үз кулында тоту иң беренче сәүдә даирәләренә кирәк була. Бу уңайдан игътибарны тагын бер нәрсәгә юнәлтәсе килә. Империядә чыңгызидларның тәхеткә, хакимияткә табигый хокуклары булганмы? Борын-борыннан нәселдән-нәселгә күчкән хокук? Күренекле юлбашчыларның җинелгән илләрне буйсындырып тотуы озакка бармаган. Бу бәлкем аларның гомумтанылган династиядән, нәселдән чыкмауларыннандыр, дип фикерлибез. Мисалга Урдадагы Ногай һәм Мамайны күрсәтергә була. Шул ук сәбәпле Идегәй белән Тимерлан дә, гәрчә объектив рәвештә бөтен мөмкинлек булса да, Урда тәхетен дәгъвалый алмыйлар. Бу җәһәттән «Җәгъфәр тарихы» күрсәткән вакыйганы алыйк. Анда Бөек хан Болгар тәхетенә дәгъва кылучы белән сөйләшә, һәм шунда икесенең дә чыгышы «Хон» (һуннар) каганнарыннан булуы ачыклана. Әгәр чыңгызидлар «һуннар» нәселеннән булса, электән үк һун каганатына буйсынып килгән җирле халык Чыңгыз хан токымына да буйсынырга тиеш була. Ягъни, чыңгызидларның шушы халыклар белән идарә итүгә нәселдән-нәселгә күчеп килгән табигый хокуклары булган. Шуңа өстәп, «Җәгъфәр тарихы»ндагы хан тамгасын алыйк. Автор андагы ике япле сәнәк сыман («двузубец»), хан тамгасының хазар, болгар чыңгызидлары тамгасына охшаш булуына игътибар итә. Моннан тыш, Тимучинның (Чыңгыз ханның) «аксөякләр» нәселеннән дигән юраманы Рашид-әд-Дин һәм Юань-Чао-Биши раслыйлар. («Сокровенное сказание»). Шунысын да әйтергә кирәк: еш кына тәхеткә хокукы булган варис (чыңгызид) утыра алмаган, чөнки олыларга буйсыну канны өстенлек иткән. Ягъни Киев русен таркатуга урын алган «Лествичная система» Урда тәхете үзгәрешләренә дә йогынты ясый.

Беренче яу походлары дәверендә монголларның бердәмлек, оешканлык сыйфатлары әлеге нәселлек-династия мөнәсәбәтләренә дә бәйле булган. Әмма соңыннан, киресенчә, шушы ук мөнәсәбәтләр Җүчи олысының монгол империясеннән аерылып чыгу сәбәпләренең берсе була һәм, гомумән, монгол империясе таркалу процессын башлап җибәрә.

3. Монголлар һәм «Русь» дигән тема буенча да гомумсаналган аспектларга карата да авторның караш-фикерләре бар. Кайбер тарихчылар «Русьта монгол игосы» темасын ачыклаганда, кайсыдыр вакыйгаларны искә алмыйлар бигрәк тә дәреслекләрдә «300 еллык иго» дәверендә кечкенә фактлар үзенә урын тапмый. Шуларның кайберләрен искә алыйк.

Беренчедән, монголларга каршы хәрби хәрәкәтне беренче булып Русь кнәзләре башлый, алар Руська «тынычлык һәм дуслык» юллап килгән монгол илчеләрен үтереп бетерәләр. Икенчедән, «Рязань шәһәрен вәхшиләрчә юк итү» (Евпатий Коловрат) темасы дәреслекләрдә борынгы «Опогибели» дигән әсәргә таянып язылган. Археологик, тарихи чыганакларда бу факт икърар ителми. Бу элек мордва-эрзя шәһәре булып («Эрзянь») урыс кул астына монголларга хәтле күптән түгел генә күчкән. Агач шәһәр. Стратегик мөһим урында урнашканлыктан, ана төрле вакытта төрле көчләр һөҗүм итеп торган. Мәсәлән, нәкъ монгол явы алдыннан Суздаль кнәзе һөҗүм итеп, рязаньлыларны тар-мар итә, шәһәр халкы талана, үтерелә. Тора-бара авылдагы мордва һәм шәһәрдәге урыс халкы арасында бәлки капма-каршылык барлыкка килгәндер, чөнки шәһәрләрне алганда мордва монголларга булышкан (бәлки көчләү нәтиҗәсендәдер)—хәзерге чыганакларда аларның Батый походларында катнашу факты ачыла. Сонрак мордва халкы беренче мәртәбә чингизидлар вакытында дәүләт булып оеша. Шулай ук Е. Коловрат (урыс батыры) турындагы легенда монголларгача барлыкка килмичә, угро-фин җирле халыкларынын көрәшен чагылдырган бер образ түгелме? Монгол походларын яктырткан әсәрләрдә «беренче урыс партизаны» турында искә алалар. Ул кеше, янәсе, бер-ике ел эчендә Урда тылындагы коммуникацияләргә шактый зур зыян китергән. Ләкин Рашид-ад-Дин урыс кешесен түгел, ә кыпчак принцын—Бачманны күрсәтә: «Бачман бер төркем кыпчак, болгар, аланнар белән байтак вакыт Идел борылмаларында кораллы көрәш алып бара»,—ди ул.

Өченчедән, безгә монгол илбасарлары һәм Русьне таркату, дигән сүзләр дә мәгълүм, күптән таныш. Ләкин булганмы сон әле бердәм, бер мәмләкәткә оешкан «Русь»? Булганмы анын берләшкән хәрби көчләре? Юк шул. Киев Русенын һәм байтак кына кнәзлекләрнен (Владимир, Суздаль, Новгород һ.б. һ.б.) булуын беләбез. Шик юк, дошман яулары барча халыкны һәрвакыт бөлгенлеккә, югалтуларга, урыны белән торгынлыкка дучар иткән. Кайсыдыр илләр, милләтләр юкка чыккан, кырылган, ассимиляцияләнгән. Ә инде көнчыгыш урыс кнәзлекләренә килгәндә, аларнын югалтулары чагыштырмача ким була (болгар, аланнарны ал!). «Урман арты» урыс шәһәрләре («Залесная Русь»), гадәттә, штурмга дучар булмый, кайсылары зур каршылык күрсәтмичә генә бирелә. Монголлар, шәһәрне алганнан сон, оборона үзәге һәм хәрби корылмалар булмаган очракта, чиркәүләргә тимиләр. Хәтта соборларга аерым бер льгота бирелә. Тора-бара урыс кнәзлекләрендә Урда чорында халык саны бернича тапкырга арта. Борынгы «Повести временных лет» әсәрендә ул чордагы урыс кнәзлекләренен бертуктаусыз үзара сугышнын, фетнә, сугыш-үтерешләрне күрәбез. Шушындый мөнәсәбәтләр урыс хөкүмәтен оештыруда, урыс җирләрен бердәм итүгә киртә булып тора. Киресенчә, Алтын Урданын яшәп килүе киләчәктә әлеге аерым кнәзлекләрне берләштерүгә юл ача, этәргеч бирә. Дүртенчедән, «Рус халкы үзенен монголларга каршы көрәше белән Европадан монгол коллыгыннан коткарды!»—дигән тезис безгә гасырлар буе тукылып киленде. Монын белән мин килешә алмыйм. Чөнки гасырларга сузылган «иго» дәверендә фәкать ике-өч зур сугышны хәтерлибез—Калкада һәм Донда. Ә монголлар, югарыда әйтелгәнчә, бик кыска вакыт эчендә руслар биләгән җирләрне пычак белән май кискән кебек кенә үтәләр; чагыштырмача ансат кына Идел-Балтыйк буе җирләрен яулап алалар һәм, күп тә үтми, Ауропанын берләшкән рыцарь гаскәрләрен үз җирләрендә тар-мар итәләр. Ләкин Төньяк-Ауропа илләрен үзләренә буйсындырмыйлар. Нилектән? Бусы инде аерым бер тема. Ә урыс җирләре алар артындагы Аурора илләре белән Урда арасындагы берәр «ничейная зона» яки «буфер зона» ролен уйнагандыр, дигән фикер туа.

Сонгы сүз итеп, Идел буе халыклары язмышына Алтын Урда йогынтысынын бер-ике мизгелен алыйк. Чөнки тикшеренүчеләр боларны да телгә алырга яратмыйлар. Урда чорында Русьнын көньяк-көнчыгышка юнәлтелгән экспансиясе 150 еллапка тоткарлана. Шунын нәтиҗәсе буларак, җирле халыклар урыс асимиляциясеннән котылып, үзләрен милләт буларак саклап калалар. Кайсылары үз җирләрен янадан кайтарып, киләчәктә дәүләт булып оешу өчен тагын да зуррак мөмкинлек, шартлар ала.

**Рөстәм НӘБИЕВ,**
*КДУның тарих факультеты аспиранты*

*Котлыйбыз!*

## Камил Кәримовка 50 яшь



Камил Кәримов исеме соңгы елларның әдәбият сөючеләренә дә, тамаша яратучыларына да яхшы таныш. Аның җиңел юмор, арабызда яшәүче гади кешеләргә ихлас ярату белән сугарылган әсәрләрен бирелеп укыган кебек, концерт залларында, телевизор экраннарында да ул катнашкан тапшыруларны яратып карыйбыз.

Язучының беренче әсәрләре 1975 елдан башлап «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталары һәм «Казан утлары», «Чаян» журналларында, шулай ук яшь язучыларның «Идел» альманахында дөнья күрә. 1981 елда Татарстан китап нәшриятында яшь прозаикның «Ундүрт яшьтә» дигән беренче китабы—хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

Әдәби иҗатка тотынганчы шактый бай тормыш материалы туплап өлгергән язучы үз укучыларының йөрәгенә юлны тиз таба. Аның «Бәхетле кеше» дигән китабы 1984 елда, «Вәгъдә» 1985 елда, «Күләгәдә төлке бар» 1990 елда, «Үзеңне бел» 1997 елда дөнья күрде.

Иҗатының баштагы чорында К. Кәримов нигездә лирик хикәяләр һәм кечкенә повестьлар авторы буларак танылса (1983 елда «Казан утлары» журналы аның «Алдавыч көз» исемле повестен бастырган иде) соңга таба ул юмористик әсәрләр язуда аеруча активлык күрсәтә башлады һәм оста юморист буларак танылды, әсәрләре белән сәхнәдә, телевизор экраннарында уңыш казанды.

Аның үткән ел журналыбызда басылып чыккан «Ком сәгате» исемле беренче романын да әдәби җәмәгатьчелек җылы каршылады. Бу әсәре белән Камил Кәримов тормышны яхшы белүче, кызыклы образлар тудыра алучы үзенчәлекле язучы буларак әдәбияттагы үз урынын тагын да ныгытты, иҗади кыйбласын ачыклады.

*Җор күңелле һәм тынгысыз җанлы язучыны 50 яшьлек юбилее белән кайнар котлыйбыз!*

*Безнең календарь*

## Җәвад Тәрҗемановның тууына 80 ел

Балалар әдәбияты. Вакытлар узу белән дә үзенең төсен, рухи кыйммәтен югалтмаучы бу әкият-шигырьләр кайсыбызга гына якын һәм кадерле түгел икән... Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Дәрҗия Аппакова, Әминә Бикчәнтәева, Җәвад Тәрҗемановның гади, балаларның үзләре кебек үк самими шигырьләрен, әкиятләрен кайсыбыз гына белми икән... Инде ничәмә-ничә буынга хәреф танырга, укый-яза белергә өйрәткән «Әлифба» китабындагы:

Йомшак су, йөгерек су!
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын,
Битләрем аллансын!—

дигән матур шигырьне кайсыбыз гына хәтерләми икән...

... Җәвад Тәрҗеманов әдәбиятка бик иртә, мәктәп яшеннән үк килә. Казан шәһәренең 13 мәктәбендә чын иҗади тормыш белән кайнап, зурларны борчыган мәсьәләләрдән дә читтә калмыйча, очрашуларда чыгышлар ясап, беренче иҗат җимешләрен газеталарда бастырып чын балалар язучысы булып өлгерә.

Җиденче класста укыганда ук:

Без көрәштек, без җинүче булдык
Илне төзүчеләр сафында.
Илдә әле көрәш тукталмаган,
Сонгы җину безне чакыра,—

дигән шигыре аның Галимҗан Мөхәммәтшин фатихасы белән «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга. Унынчы класста укыганда исә (1938 елда) аның «Кызыл галстук» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

«Иҗат мәктәбем», дип аталган истәлегендә ул үзе дә *(Ж. Тәрҗеманов «Очрашулар, очрашулар». Татарстан китап нәшрияты, 1990)* Дәрҗия Аппакова, аны язган шигырьләре аша бәһаләп: «Мин аны өч-дүрт бала атасы дип уйлый идем»,—дигән сүзләрен китереп үтә.

Җәвад Тәрҗеманов әллә нинди катлаулы образлар белән эш итми, шаккатыргыч уйлап чыгарулар белән мавыкмый. Аның сөйләме гади, геройлары яндагы кешеләр, шигырендәге вакыйгалар исә барыбыз белән дә көндәлек тормышта очрый торган хәлләр—шуларны сабыйлар күнеленә үтәрлек итеп йомшак кына, җайлы гына сөйләп чыга.

Җәвад Тәрҗемановның иҗаты турында сүз алып барганда аның бигрәк тә әкият остасы булуын әйтмичә китү мөмкин түгел. Әдипнең «Ябалак һәм тавык» (1940), «Күбәләк—җилбәзәк» (1945), «Шуктуган» (1962), «Шаян һәм Наян» (1965), «Көмешкойрык» (1967) исемле әкиятләре инде менә ничәмә-ничә буын балаларының яраткан әкиятләренә әйләнделәр.

Күренекле балалар язучысы Ләбибә Ихсанова «Зур бакчаның бер гөле» исемле мәкаләсендә *(«Казан утлары», 1980, №6)* бу турыда мондый фикерләр әйтеп үтә:

«Җ. Тәрҗеманов иҗатында үзгә урын тоткан жанр—әкиятләр. Әйтерсен лә, Абдулла Алиш үзе сугышка киткәндә Җәвадка васыять әйтеп калдырган: «Менә сиңа каләмем. Менә сиңа кәгазьләрем. Мин кайта алмасам, үлеп калсам да, әкиятләр үлмәсен. Син аларны күп итеп яз. Минем әкиятләрне укыган кебек үк, аларны да балалар яратып укысыннар».

Җәвад Тәржеманов балалар әдәбиятына тугры калып, алар өчен сәхнә әсәрләре дә иҗат итә.

Тормышта булган хәлләргә, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге мәсьәләләргә кагылышлы очерк-язмалары белән катнашып үзенең уй-фикерләрен белдерә. Аның иҗаты һәм тормышы турында сүз алып барганда Җәвад Тәржемановның зур галим булуы турында да әйтмичә калу мөмкин түгел.

Күп еллар фән өлкәсендә эшләү, зур белем, тәҗрибә, Казан университетының үткәндәге тарихыннан бай фактик материаллар туплау «Лобачевскийның яшьлеге» (1965) исемле документаль роман тууга нигез булып тора. Автор үзенең эзләнүләрен дәвам итеп, аның яшьлек чорына гына тукталып калмыйча, Лобачевскийның катлаулы тормыш юлын бөтен тулылыгы белән өйрәнеп «Көмеш дага» (1971) романын иҗат итә. Роман күп телләрдә—рус, француз, немец телләрендә дөнья күрә.


Үзе исән вакытта әдипнең китаплары күп басылып чыга. Вафатыннан соң бу эш ничегрәк тора соң? Заман технологиясе белән төсле-матур тышлыкта, сабыйларга бәйрәм ясый алырлык китаплары бармы? Гомумән, Ж. Тәржемановның мирасы ни хәлдә? Үземне борчыган бу сорауларга җавапны мин аның улы Камил әфәнде белән булган сөйләшүдә таптым.

Камил әфәнде—«Салават» туристлар агентлыгының генераль директоры. Язучы баласы буларак та, шәһәр баласы буларак та күп илләр күргән кеше. Хәзерге башкара торган хезмәте дә турыдан-туры чит илләр белән бәйләнгән. Дөньялар катлауланып китү сәбәпле язучыларның чит илләргә бик үк чыга алмый башлавы, ә язучы кешегә дөнья күрергә кирәклеге бәхәссез. «Гибралтарга барып гыйбрәт ал!» ди мәгълүм бер шагыйребез. Язучылар берлегеннән тәкъдим ясалса, бергәләшеп бу эштә дә ярдәм итәргә алынырга каршы түгеллеген дә әйтеп китте ул. Шулай ук, киләчәктә Тәржемановлар нәселенең (бәлки, татар зыялыларының дип аталыр) музеен булдыру да күздә тотыла икән. Тәржемановларның нәсел шәҗәрәсе еракларга китеп тоташа. Затлы, зыялы нәсел. Күбесе фән кешеләре. Заманында Бельгиядә, Кытайда илчелектә эшләүчеләр дә булган. Күренекле композитор Алмаз Монасыйпов белән дә якын туганнар.

Камил әфәнде бүгенге көндә Җәвад аганың әкиятләр китабын яңадан бастырып, сабыйларга бүләк әзерләү эше белән мәшгуль. Аларны төрек теленда чыгару уе да бар. «Аның иҗатын буыннар хәтерендә саклау—минем бурычым»,— ди ул.

Әйе, язучы үзе үлсә дә, аның иҗаты яшәсен, иҗаты үлмәсен.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**



# КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

**Министрлар Кабинеты 2000 елның 13 мартында «Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгына әзерлек һәм аны үткәрү буенча дәүләт комиссиясе турында» карар кабул иткән иде. Шуңа нигезләнеп Казан шәһәре хакимияте башлыгының да карары дөнья күрде.**

**1000 еллыкка әзерлек буенча дәүләт комиссиясенең составы һәм аның турындагы положение расланды.**

## 1000 еллыкка әзерлек һәм аны үткәрү буенча дәүләт комиссиясе әгъзалары:

**Р. Миннеханов**—Премьер-министр, комиссия рәисе.

**И. Хәйруллин**—Премьер-министр урынбасары, комиссия рәисе урынбасары.

**В. Швецов**—Премьер-министр урынбасары, комиссия рәисе урынбасары.

**С. Когогин**—Премьер-министр урынбасары, икътисад һәм сәнгать министры, комиссия рәисе урынбасары.

**К. Исхаков**—Казан шәһәре хакимияте башлыгы, комиссия рәисе урынбасары.

**Т. Акулов**—Татарстан Президентының халыкара элемтәләр департаменты директоры.

**И. Әминов**—«Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе рәисе.

**Е. Богачев**—Татарстан Милли банкы рәисе.

**З. Вәлиева**—Матбугат эшләре, телерадиотапшырулар һәм массакүләм аралашу чаралары министры.

**В. Васильев**—Татарстан Дәүләт милке белән идарә итү буенча дәүләт комитеты рәисе.

**М. Гаделшин**—Казан шәһәре хакимияте башлыгының беренче урынбасары.

**А. Гусев**—Дәүләт иминлеге комитеты рәисе.

**Р. Госманов**—Казан шәһәре хакимиятенең 1000 еллыкны бәйрәм итүгә әзерлек буенча махсус идарәсе башлыгы, комиссия сәркатибе.

**М. Девятаев**—Казан шәһәренең мактаулы гражданины, Советлар Союзы Герое.

**Р. Закиров**—«Казан» милли мәдәният үзәге директоры.

**Б. Зиннуров**—Президент аппаратының оештыру бүлеге мөдире.

**Н. Коцюбенко**—Татарстан таможня идарәсе башлыгы.

**Р. Миннуллин**—Дәүләт Советы рәисе урынбасары.

**Х. Мортазин**—Физик культура, спорт һәм туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе.

**Р. Мусин**—финанс министры.

**М. Сәлимҗанов**—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры.

**Ә. Сафаров**—эчке эшләр министры.

**И. Тарханов**—мәдәният министры.

**И. Терентьева**—Президент Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире.

**Г. Тулисов**—Министрлар Кабинеты каршындагы транспорт департаменты генераль директоры.

**М. Госманов**—Татарстан Фәннәр академиясе академигы, профессор, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире.

**Ш. Хәиров**—Россия Федерациясе Салымнар һәм җыемнар министрлыгының Татарстан буенча идарә җитәкчесе.

**Н. Хәйруллин**—Казан финанс-икътисад институты ректоры, югары уку йортлары ректорлары советы рәисе.

**Р. Хәкимов**—Татарстан Фәннәр академиясе тарих институты директоры, Президентның сәяси мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе.

**М. Хәсәнов**—Татарстан Фәннәр академиясе президенты.

**И. Шәйдуллин**—төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры.

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ҖИҢҮГӘ БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНА

8 майда Казанда, Татарстан Дәүләт Зур концерт залында республикабыз районнарыннан килгән делегацияләр катнашында Бөек Җиңүнең 55 еллыгына багышланган тантаналы утырыш булды.

Тантаналы утырышны ачып, Казан шәһәр хакимияте башлыгы К. Исхаков Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарын олуг бәйрәм белән кайнар котлады. Аннары тантаналы җыелышта катнашучылар алдында Татарстан Президенты М. Шәймиев чыгыш ясады. Тантаналы утырышта Премьер-министр Р. Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Президент Аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин, республикабыз министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре катнашты.

Соныннан Татарстан сәнгать осталарының зур концерты булды.

## ЗӘҢГӘР ЭКРАНДА—40 ЕЛ

23 майда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Татарстан» телевидениесе үзенең 40 еллык юбилеен билгеләп үтте. Юбиляр коллективны котларга Президент Минтимер Шәймиев, Премьер-министр урынбасары Илгиз Хәйруллин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, күрше республикалар телевидениеләре вәкилләре килгән иде.

Иң беренче котлау сүзе белән Президент М. Шәймиев чыкты. Ул телевидениенең җәмгыятебез тормышындагы әһәмиятен билгеләп үтте һәм күп еллар бу өлкәдә эшләгән хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре бирелү турындагы таныклыклар тапшырды.

## ТӨРКИЯДӘ ЯҢА ЖУРНАЛ ТӘКЪДИР ИТҮ

Төркиянең Истанбул шәһәрендә өряна «Диалог Евроазия» журналын тәкъдир итүгә һәм әлеге басманың киләчәктәге төп юнәлешләрен, кыйбла-мәсләген билгеләүгә багышланган конференция булып узды. Журналның редакция советы әгъзалары итеп безнең республикадан танылган язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре Разил Вәлиев белән Фоат Галимуллин кертелгән иде. Татарстан вәкилләреннән тыш, биредә Албания, Әзербәйҗан, Босния-Герцеговина, Грузия, Кыргызстан, Македония, Молдавия, шулай ук Дагыстан, Башкортстан, Тува, Якутия вәкилләре, Кырымнан килгән язучылар, галимнәр бар иде. Әлеге форум эшендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ҺӘМ КОРЪӘН

Казандагы Татарстан-Америка региональ институтында (ТАРИ) «Мәдәниятара багланышлар: милли педагогика проблемалары һәм әдәби тәрҗемә» дигән халыкара симпозиум булды.

Пленар утырышта ТР мәгариф министры Ф. Харисов, ТАРИ ректоры Д. Шакирова, академик М. Мәхмүтов, ТАРИның инглиз теле укытучысы, америкалы К. Басс, профессор Ү. Әхмәтов, ТАРИның гарәп теле укытучысы, суданлы Әмир Әл-Хаж чыгыш ясады. Киңәшмәдә шулай ук ТР Министрлар Кабинетының фән һәм мәгариф бүлеге башлыгы Р. Вәлиев катнашты.

Пленар утырыштан соң әдәби тәрҗемәнең соңгы казанышларыннан берсе—Рабит Батулла әзерләгән Корьән китабының татарчага тәрҗемәсен тәкъдир итү булды.

* * *

«Татнефть» акционерлык җәмгыяте Татарстан Милли китапханәсенә һәм республикабыз район китапханәләренә яшь буынны милли рухта тәрбияләү өчен зарур булган китаплар тапшырды. Китаплар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхретдин, бертуган Бубилар һәм «Иҗбуби мәдрәсәсе», «Фатих Кәрими» китаплары, Сажидә Сөләйманова, Фәнис Яруллин, Рәшит Әхмәтҗан, Зөлфәт җыентыклары бар.

## МУЗЕЙ ДУСЛАРЫН ҖЫЯ

Быел Татарстан дәүләт музеена 105 ел тулды. Ә «Музейлар көне» безнең республикада 1978 елдан бирле үткәрелеп килеңә. Шул уңайдан Дәүләт Советы депутат-

ларының Разил Вәлиев житәкчелегендәге фән һәм мәдәният буенча комиссиясе музей хезмәткәрләре белән очрашты.

Г. Тукай музеенда 18 майда әлеге көн унаеннан аның беренче директоры Госман Хәбибуллинны искә алдылар. Фондларда саклана торган экспонатлар халыкка күрсәтелде. Фольклор ансамбле, курчак театры артистлары чыгыш ясады.

## ХӘТЕР

* * *

6 май көнне Казаннын Муса Жәлил исемен йөрткән урамында тагын бер истәлек тактасы куелды. Аңа «Бу урамга Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Жәлил исеме бирелгән» дип язылган. Тантананы Казан шәһәре хакимиятенең мәдәният идарәсе башлыгы Р. Төхвәтуллин ачып жибәрде. Аннары Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Миннуллин, Казандагы Яңа Бистә префектурасы башлыгы А. Фәхретдинов, Дәүләт Советының даими комиссия рәисе Р. Вәлиев, Вахитов районы хакимияте башлыгы Р. Борһанов, Татарстан Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый, Татарстанның халык артисты А. Арслан М. Жәлилнең асыл эше, кабатланмас үрнәге турында сүз әйттеләр.

* * *

Мамадыш шәһәре үзәгендә күренекле татар шагыйре Шәйхи Маннур һәйкәле каршысында Ватан сугышында жиңүебезнең 55 ел тулу уңае белән бөек татар композиторы, мәшһүр «Шүрәле» операсын ижат иткән Фәрит Яруллинның бюст һәйкәлен ачу тантанасы уздырылды.

Сынны—Әлфәрит һәм улы Гадел Габдрәшитовлар ижат иткән.

## ЮБИЛЕЙЛАР, КИЧӘЛӘР

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында фронтовик әдипләрдән Мөхәммәт Әблиев (100 ел), Әнәс Галиев (80ел), Әнәс Кари (80ел), Мәжит Рафыйковка (75 ел) багышланган «Хәтер яктысы» кичәсе булды. Шул ук кичәдә язучы-дингезче Локман Бадыйкшановның 80 яшьлек юбилее дә билгеләп үтелде.

* * *

М. Жәлил музеенда каһарман шагыйрьгә һәм аның көрәштәш дусларына—жәлилчеләргә багышланган кичә булды. Анда Татарстан Мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев, Татарстан Республикасының Язучылар берлеге рәисе урынбасары Ш. Мостафин, жәлилчеләрнең туганнары, якыннары чыгыш ясады.

* * *

К. Тинчурин исемендәге театрда шагыйрә Резеда Вәлиеваның «Китмә, Сөю!..» дип исемләнгән ижат кичәсе булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Мәдәният министры урынбасары Л. Имаева, күп кенә әдәбият-сәнгать әһелләре катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

Г. Камал театрында күренекле артист, әкиятче-шагыйрь һәм драматург Хәлим Жәләйнең 60 яшьлек юбилеена багышланган ижат кичәсе булды. Юбилярны Татарстан язучылары исеменнән Ф. Галимуллин котлады.

* * *

Татарстан язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында күренекле әдиптәржемәче Таһир Нурмөхәммәтовның тууына 70 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды. Анда язучылар, Татарстан китап нәшрияты, «Шәһри Казан» газетасы редакциясе хезмәткәрләре, әдипнең якыннары, дуслары катнашты.

## ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗНЕ КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты Указы белән «Казан утлары» журналының бүлек мөдире **Наис Гыйльман улы Гамбәровка** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Мәдәният һәм сәнгатьне үстерүдәге зур уңышлары өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Зур концерт залы директоры, Татарстан язучылар берле әгъзасы **Мансур Әхмәт улы Шиһапов** Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

13 майда күренекле шагыйрь һәм әдәбият галиме **Зәет Мәжит улы Мәжитов** вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Ямьле жәй—фотоэтюд.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Ләбиб Лерон.

# АВЫР ЮГАЛТУ

Татар халкы зур югалту кичерә. 4 июньдә Татарстанның халык язучысы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең бүләк иясе, Татарстан Фәннәр Академиясенең шәрәфле әгъзасы Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов (Гариф Ахунов) кинәт вафат булды.

Гарифҗан Ахунҗан улы 1925 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасының Арча районы Өчиле авылында туа. Алты яшендә әтисез калган Гарифҗанны һәм аның өч туганын әниләре тәрбияли. Сугыш еллары булачак язучының язмышында тирән эз калдыра. 1947 елда егерме ике яшьлек Гарифҗан, Арча педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Яшьтән үк рәсем сәнгатенә гашыйк егет уку елларында иҗатка тагын да ныграк тартыла, матбугатта аның беренче хикәяләре һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләләре басыла. Студент вакытында ук аны «Совет әдәбияты» журналына әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Биредә биш ел эшләү дәверендә ул үзенең әдәби осталыгын үстерә, журналның камиллеген, сәнгатьчә югарылыгын тәэмин итүгә зур өлеш кертә.

1956-1968 елларда яшь язучы Әлмәт якларында яши, тормышны, булачак геройларын өйрәнә. Аның тырышлыгы белән биредәге әдәби берләшмә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә әверелә. Биш ел дәвамында Г. Ахунов ана җитәкчелек итә. Башкалага әйләнеп кайткач, ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире итеп билгеләнә. Аның оештыру таланты аеруча Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә җитәкчелек иткән елларда ачыла. Башта ул җаваплы секретарь, ә 1974-1984 елларда идарә рәисе вазифаларын башкара. Нәкъ шул чорда Татарстан Язучылар оешмасында аеруча эшлекле әдәби мохит булдырылды, китап бастыру эше җанланды, татар китапларын башка телләргә тәрҗемә итү юлга салынды, Чаллы Язучылар берлеге оештырылды, яшь иҗат көчләре белән эшләү активлашты. Г. Ахунов озак еллар СССР һәм Россия Язучылар берлеге идарәләре секретаре булды, 1974-1984 елларда СССР Югары Советы депутаты буларак та үзен ил күләмендә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе итеп танытты.

XX гасыр татар әдәбиятында Гариф Ахуновның зур урыны бар. Әдип хикәя, повесть, роман жанрларын бердәй үз итте, аларның талантлы үрнәкләрен бирде. Аның «Яшьлек яме», «Чикләвек төше» повестьлары, «Хәзинә», «Идел кызы» романнары аеруча киң яңгыраш алды. «Хәзинә» әсәре буенча төшерелгән фильм илебез экраннарына чыкты. Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен ул сәхнә әсәре итеп эшләде, бу спектакль Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының алтын фондына кереп калды. Г. Тукай турындагы күп серияле телевизион фильмны экраннарга чыгаруда да аның өлеше зур булды.

Г. Ахуновның әсәрләре рус, төрек, башкорт, украин, үзбәк, казакъ, кыргыз, белорус, латыш һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителде. Ул үзе дә М. Шолохов, Р. Тагор, Н. Погодин, А. Островский һәм башка күренекле язучыларның һәм драматургларның әсәрләрен татар телендә яңгыратты. Әдип бер үк вакытта кайнар йөрәкле публицист та иде. Аның әдәби тәнкыйтебезгә керткән өлеше үзе бер җитди казаныш.

Г. Ахуновның күпьеллык намуслы хезмәте ил-халык тарафыннан югары бәяләнде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнде. 1973 елда аңа «Хәзинә» романы өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Ул «Татарстанның халык язучысы» дигән шәрәфле исемгә лаек булды.

Без татар әдәбиятының олы бер вәкилен югалттык. Гарифҗан Ахунҗан улы гомеренең соңгы көннәренә кадәр иҗат каләмен ташламады, актык сулышынача әдәбият гаме белән яшәде. Аның язган әсәрләре, таланты, авторның исемен мәңгеләштереп, безнең арабызда кала, алар әле күп буыннарга тормыш дәресләре, әхлак үрнәге һәм ихлас хисләр гәүдәләнеше буларак хезмәт итәр.

Гарифҗан Ахунҗан улы Ахуновның якты истәлеге рәхмәтле татар халкы күңелендә мәңге сакланыр.


**М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миңнеханов, Ф. Х. Мөхәммәтшин, Ә. С. Гобәйдуллин, И. К. Хәйретдин, Р. М. Миңнуллин, И. Г. Тарханов, К. Ш. Исхаков, И. Н. Сабиров, М. Х. Хәсәнов, Р. И. Вәлиев, Ю. Г. Коноплев, Ф. Г. Галимуллин, Т. Г. Миңнуллин, Р. М. Харисов, А. М. Гыйләҗев, Г. Г. Афзалов, Ш. Г. Галиев, Н. С. Фәттахов, И. Г. Юзеев, Р. Г. Фәйзуллин, В. В. Корчагин, Г. А. Паушкин.**



**Гариф Ахунов**

**1925—2000**

Индекс 73210



Лэбиб Лерон

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)